ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

1.2006



*1000нче санны каршылап*

# ҮТКӘН ЕЛЛАР СӘХИФӘСЕ

## “Совет әдәбияты”
## 1933—1965




1933 ел башыннан журнал “Совет әдәбияты” исеме белән чыга башлый. Аның беренче саны (Г. Нигъмәти редакциясендә) “әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы” дип тәкъдим ителә. Икенче саннан журналның җаваплы редакторы—Кави Нәҗми (1933-1934). Шул ук саннан “әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы” дигән билгеләмәгә публицистика дигән сүз дә өстәлә. Илдә “социализм өчен бөек көрәш” дәвам итә. Бу чор авылны социалистик нигездә янабаштан кору—хуҗалыкларны күмәкләштерү темасына язылган очеркларның күп булуы белән аерылып тора.

1937 ел... Ил, халык һәм журнал өчен дә авыр, кара чор: Сталинның шәхес культы тарафыннан халкыбыз зыялыларының юк ителүе, эзәрлекләнүе шартларында редакторлары бик еш алмашынып торса да, журнал яшәвен дәвам итә. Ул елның кайбер саннары, нигездә, тәрҗемә әсәрләрдән тора. Утызынчы еллар ахырына кадәр журналда зур күләмле әсәрләр күп басылмаган. Шул елларда Г. Бәшировның “Сиваш” повесте дөнья күрә.

Бөек Ватан сугышы елларында күп кенә газета-журналлар ябылып бетсә дә, “Совет әдәбияты” чыгудан туктамый. Журнал фронтовик язучылар (М. Җәлил, Ф. Кәрим, Н. Баян, А. Алиш, Г. Кутуй, Х. Мөҗәй, М. Максуд, Г. Насрый, Ш. Мөдәррис, И. Гази Г. Әпсәләмов, Ш. Маннур, А. Шамов, Г. Галиев, Г. Бакиров, Р. Ишморат, Х. Госман, М. Садри, Ә. Маликов, З. Нури һ. б.) белән элемтәдә тора, укучыларын аларның әсәрләре белән таныштырып бара.

Сугыш тәмамлангач, язучылар рухланып яңа әсәрләр иҗат итәләр. Г. Әпсәләмовның “Ак төннәр”е (1947), “Алтын йолдыз”ы (1949), “Газинур”ы (1951), М. Җәлилнең “Моабит дәфтәре” циклына кергән шигырьләре (1953), Н. Дәүлинең “Яшәү белән үлем арасында” повесте (1957), Ш. Маннурның “Муса” романы (1965), С. Хәким, З. Нури һ. б. поэмалары журнал укучыларына җиткерелә.

Журнал сәхифәләрендә илне төзекләндерү чорында татар халкының күркәм мораль сыйфатларын, аның тарихи үткәнен, хезмәт сөючәнлеген чагылдыручы яңа әсәрләр—Г. Бәшировның “Намус” (1948), К. Нәҗминең “Язгы җилләр” (1948) романнары, И. Газиның “Онытылмас еллар”ы (1949), М. Әмирнең “Ялантау кешеләре” (1953), “Саф күңел”е (1959), Г. Әпсәләмовның “Сүнмәс утлар”ы (1959), Ф. Хөснинең “Җәяүле кеше сукмагы” (1961), Г. Гобәйнең “Без үскәндә”се (1963), Ә. Еникинең “Йөрәк сере” (1958), “Рәшә”се (1963), Г. Ахуновның “Хәзинә”се (1962), А. Расихның “Ике буйдак” романы (1964), Х. Вахит пьесалары, Х. Туфан, Н. Арсланов, С. Хәким И. Юзеев, Г. Афзал, Ш. Галиевләрнең поэмалары һәм шигырьләре журнал аша үз укучыларын тапты.

60 нчы еллар башында әдәбиятка килгән яшь шагыйрьләр—Р. Фәйзуллин, Р. Харисов, Р. Гатауллин, Г. Рәхимнәрнең дә беренче әсәрләре “Совет әдәбияты”нда дөнья күрде.

“Совет әдәбияты” 1939 елга кадәр латин шрифтында, аннан соң кириллицада басыла. 1965 елның 6 санынннан бу журнал “Казан утлары” исеме белән чыга башлый.

# Казан утлары
# Qazan utları

*2006*

# 1

**(999)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Әхмәт Рәшит, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(8432) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

Илфак ИБРАҺИМОВ. Олы эшләр елы булыр. 5

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Ренат ХАРИС. Яңа шигырьләр. 8
Марат ӘМИРХАНОВ. И, кылган догам минем... *Повесть.* 15
ЗӨЛФӘТ. Моңнар моңы... *Шигырьләр.* 56
Искәндәр СИРАЖИ. Гыйсметдин тәүбәсе. *Хикәя.* 61

**ИЛДУС ГЫЙЛӘҖЕВКӘ 60 ЯШЬ**

Рәдиф ГАТАШ. Җир китабын кемнәр яза. 70
Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Җир өстендә узган безнең еллар... *Шигырьләр.* 72

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Идрис ТУКТАРОВ. Үлем эшелоны. 77

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Дискуссиянең кайбер нәтиҗәләре. 82

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Нурулла ГАРИФ. Казан—Мәскәү арасы: гасырлар ярасы. 86

**АДЛЕР ТИМЕРГАЛИНГА 75 ЯШЬ**

Равил РАХМАНИ. Фән һәм хыял канатында. 98
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Әлифба, имла, фәнни истилах. 107

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Алсу ШӘМСУТОВА. "Сискәндереп гамьсез көнне..." 115

**ОСТАХАНӘ**

Рашат НИЗАМИ. Каләм алдым кулыма... *Эссе.* 120

**ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ**

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Буыннар хәтере—милләт таянычы. 142
Равил ӘМИРХАН. Яшәеш һәм иҗат колачы. 143

**ФӘН**

"Татар энциклопедиясе" битләреннән. 137
Фәрит ФӘТТАХ. Кемнәр ул скифлар? 153
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. 156

**ХӘТЕР**

Йолдыз ХӘЛИУЛЛИН. Салмак аккан тирән фикерләр иясе. 159
Әмирхан Еники хатлары. 161

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Югалтма, дөнья, шагыйрәңне! 168

**ЮМОР-САТИРА**

Камил КӘРИМОВ. Сансыз фиргавен. *Кыйсса* 171

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 188

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

Вступительная статья председателя Союза писателей Татарстана И. ИБРАГИМОВА.
"Проза и поэзия": повесть М. АМИРХАНОВА "Моя молитва"; рассказ И. СИРАЗИ "Покаяние Гисмутдина"; стихи Р. ХАРИСА, ЗУЛЬФАТА.
"К 60-летию И. Гилязова": стихи И. ГИЛЯЗОВА (с предисловием Р. ГАТАША.)
"Из сокровищницы татарских рассказов": И. ТУКТАРОВ. "Эшелон смерти".
Дискуссия "Герой нашего времени": "Некоторые итоги дискуссии".
"Публицистика": Н. ГАРИФ. "О взаимоотношениях Казани и Москвы".
"К 75-летию А. Тимергалина": Р. РАХМАНИ. "На крыльях науки и фантазии"; А. ТИМЕРГАЛИН. "Алфавит, орфография и терминология".
"Литературная критика": статья А. ШАМСУТОВОЙ о поэзии Харраса Аюпова.
Эссе Р. НИЗАМИ о творческой лаборатории писателей.
"Страницы из татарской энциклопедии".
"К 120-летию Ф. Амирхана": статьи Т. ГАЛИУЛЛИНА и Р. АМИРХАНА.
"Наука": Ф. ФАТТАХ. "Кто они, скифы?"; А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
"Память": статья Й. ХАЛИУЛЛИНА о классике татарской литературы А. ЕНИКИ; письма А. ЕНИКИ.
"Книжное обозрение": Р. ШАРАФИЕВ рецензирует книгу Ф. Джамалетдиновой "Луна с косичками".
"Юмор-сатира": рассказ К. КАРИМОВА "Забытый фараон".
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Зимний пейзаж". Писательница Назифа Каримова.

# IN THIS ISSUE:

Introductory article by chairman of Union of writers of Tatarstan I. IBRAGIMOV
«Prose and poetry»: story by M. AMIRHANOV «My pray»;
story by I. SIRAZI «Gismutdin's Repentance»;
verses by R. HARIS, ZULFAT.
«To 60th anniversary of I. Gilazov»: verses by I. GILAZOV (with foreword by R. GATASH.)
«From treasury of Tatar stories»: I. TUKTAROV. «Echelon of death». Discussion «Hero of our time»: «Some results of discussion».
«Publicism»: N. GARIF. «About mutual relations of Kazan and Moscow».
«To 75th anniversary of A. Timergalin»: R. RAHMANI. «On wings of science and imagination»; A.TIMERGALIN. «Alphabet, spelling and terminology».
«Literary criticism»: article by A. SHAMSUTOVA about Harras Ayupov's poetry.
Essay by R. NIZAMI about creative laboratory of writers.
«Pages from Tatar encyclopedia».
«To 120th anniversary of F. Amirhan»: articles by T. GALIULLINA and R. AMIRHAN.
«Science»: F. FATTAH. «Who are they, Scythians?»; A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation».
«Memory»: article by I. HALIULLIN about classic writer of Tatar literature A. ENIKI; letters of A. ENIKI.
«Book review»: R. SHARAFIEV reviews book by F. JAMALETDINOVA «Moon with plaits of hair».
«Humour-satire»: story by K. KARIMOV «Forgotten Pharaoh».
Dairy of social-cultural life.
On our covers: «Winter scenery».
Writer Nazifa Karimova.

*The magazine edits monthly*

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 26.12.2005 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-993. Тираж 7011.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2005 ел.



**Илфак Ибраһимов**

*Татарстан Язучылар берлеге рәисе*

# ОЛЫ ЭШЛӘР ЕЛЫ БУЛЫР

Казаныбызның 1000 еллыгын түземсезлек белән көтеп алып, аны бар дөньяны таң калдырып бәйрәм иткән 2005 ел да узып китте—тарихка күчте. Чыннан да, бар дөньяны танга калдырдымы бу олуг бәйрәм, әллә безнең үзебезгә генә шулай тоелдымы? Дөньяны таң калдырды дигән җөмләдән, Казанның соңгы дистә ел дәвамында танымаслык булып үзгәрүен, бәйрәм алды көннәрендә төзелеп бетеп сафка баскан дистәләрчә биналар, метро, ипподром, күперләрне генә күздә тотып әйтүебез түгел...

Казаныбызның меңъеллыгын бәйрәм иткән көннәрдә элеккеге СССР дигән олы дәүләттән бүленеп чыккан ил башлыклары һәм Россиянең барлык төбәк җитәкчеләренең Татарстан башкаласына җыелуы, алай гына түгел, хәтта дөньяның дүрт тарафыннан үзләренең тарихи ватанына ашкынып килгән һәм шунда өр-яңадан тормыш корып җибәрү теләген белдергән дистәләрчә, йөзләрчә татар кешесенең Казанга—Татарстанга җыйналуы да таң калдырдымы икән дөньяны?.. Әйе, дөньяны һәм үзебезне таң калдырганы, әлбәттә, югарыда санап үткән вакыйгалар, чараларның булуында—бу, берсүзсез! Әмма дөнья җәмәгатьчелеге игътибарын җәлеп иткәне, Казан шәһәренең Татар дигән бик тә гыйбрәтле язмышлы, дөнья буйлап сибелеп яшәргә дучар булган бер халыкның әлегәчә башкаласы булып торуыдыр...

Хакыйкатьтә татар халкы үз дәүләтчелеген тулысынча җуйган 453 ел вакыт арасы тарих күзлегеннән караганда да аз вакыт түгел... Аның язмышына дучар булган аркадаш милләтләр инде тәмам үз йөзен югалтып барган бер дәвердә, татар халкы, үҗәт тырышлыгын куеп, үз дәүләтчелеген ныгытырга омтылып яши. Бүген халыкның теле, дине, иманы исән! Татарстан дигән Идел-Йорт татар халкы өчен генә түгел, үзе белән аркадаш булган халыкларның Имин йорты булып әверелде... Татарстан халкы таңнан торып эшкә бара. Эшләп тапканы үзе өчен генә түгел, ә дистәләрчә күршеләренең өс-башын бөтен, тамагын тук итәргә җитә... Татарстан дигән Идел-Йорт дөнья күләм алгарышка омтыла һәм шул максатында уңышлы гына нәтиҗәләргә ирешә. Татарстан галимнәренең фәнни ачышлары бөтен дөнья күләмендә көннән-көн ныграк танылу ала. Татарстан дигән Идел-Йортта дистәләрчә халыкларның үзара тату яшәүләре һәм төрле дин тарафдарларының бер-берсенә карата ихтирамлы күршелеге тәгаенләнгән булуы бөтен дөнья җәмәгатьчелеге теленә «Татарстан феномены» дигән атама белән килеп керде. Боларның барысы да Казанның 1000 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә бөтен дөнья җәмәгатьчелегенең игътибар үзәгендә булды...

Бәйрәмнән алган хис-тойгылар рәхәтенә исереп, ихластан куанып әле бик озак яшәргә мөмкин... Әмма Заман аек булуны, үзенә лаек булуны сорый.

Заман һәрвакыттагыча һәм кайчандагыга караганда да кырыс... Заман-Вакыт дигәне һәр кешене, һәр гаиләне, һәр кавемне, һәр халыкны һәр көн саен сыный... Инде аның сынавы ачлык, сугыш, табигый бәла-казалар белән генә түгел, Заман-Вакыт туклык, муллык белән дә сыный. Мең газапларны кичергән адәм балалары уңайлыкларны ничек күтәрер? Шагыйрь әйткәндәй, «кайгыны да җинеп була, бәхеткә түзү кирәк». Сынау—өлгергәнлеккә, әхлак, иман ныклыгына!..

Халык язмышы—иксез-чиксез диңгез, океаннарга чыгарылган бер кораб кебек ул. Олы халыкларга зур кораблар, зур корабка зур җилкәннәр кирәк... Ул җилкәннәрне тотып торучы матчалары да берничә, ә җил уңаена яки каршы юнәлештә тоту өчен билгеләнгән өзелмәс аркан-баулары дистәләр белән исәпләнә... Давыл-гарасатларда ул бау-арканнарны хәрәкәткә китерү өчен тыгыз бәдәнле, елгыр, гайрәтле, көчле ихтыярлы ир-егетләр кирәк. Көч-гайрәт кенә җитми, корабка тәҗрибәле, акыллы капитан да, аек, зиһенле ярдәмчеләре дә кирәк... Иксез-чиксез океанда «һәр ишеткән җан җыларлык» һәм «җаннарны сорап тарткан», глобализация дигән упкын бар... Ул упкынга йотылмас өчен үз кыйбланң, иманың, үз динең, үз мәдәниятең, үз әдәбиятың, сәнгатең кирәк...

Илбашыбыз тарафыннан Тукай елы дип билгеләгән яңа 2006 ел шул кирәкләрне булдыру һәм ныгытуда хәлиткеч ел булсын иде... Тукай елы—димәк, ана телебезгә, татар китабына игътибар һәм ихтирам бермә-бер артачак... Димәк, табыш китерми дигән сылтау белән барлык район-шәһәрләрдә ябылган дәүләт китап кибетләре яңадан ачылачак... Дәүләтебез бүлеп биргән дистәләрчә миллион сумга нәшер ителгән йөзләрчә мең китаплар нәшрият складларыннан кибет киштәләренә, авыл, шәһәр китапханәләренә, мәктәп китапханәләренә күчәчәк, һәм китап укучыга барып җитәчәк. Бу—үз чиратында төнге күңел ачу клубларында, уен автоматлары янында мәгънәсезгә гомер үткәрүче меңнәрчә яшьләребезне затсызлыктан һәм примитивлыктан йолып калачак...

Тукай елы—димәк, йөзьеллыгын билгеләп үтәчәк милли театрларыбызда һәм рус театрында соңгы ике дистә ел дәвамында сәхнәдә бөтенләй булмаган төрледән-төрле һәм шул ук вакытта бердәнбер бөек Тукай образы иҗат ителәчәк. Тукайның бихисап зур иҗат мирасын хәзерге һәм килер буыннарга бөтен тулылыгы белән ачып бирү, фән һәм сәнгать учреждениеләре, оешмалары, барлык уку йортлары, иҗат оешмаларының һөнәри бурычы да. Татарстан Язучылар берлеге, аның Тукай исемендәге клубы, Г.Тукай исемендәге филармония, Г.Тукай исемендәге музей, Республикабызның баш китапханәләре милли иҗатчылар белән эшләүне пропагандалауны Тукайча фидакарьлек белән җәелдерерләр дә...

Халкыбызның каһарман улы шагыйрь Муса Җәлилнең Тукай елында билгеләп үтеләчәк 100 еллыгы тагы да мәртәбәле төс алып, олуг тантанага әверелер. Тукайның яшьтәше һәм фикердәше Фатих Әмирхан, замандашы Гафур Коләхмәтовларны яд итү, Һади Такташ, Мирхәйдәр Фәйзи, Габдрахман Әпсәләмов, Афзал Шамов, Хәйретдин Мөҗәй, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Атилла Расих, Кави Нәҗми, Сажидә Сөләйманова кебек әдипләребезнең һәм бүгенгәчә исән-сау булган дистәләрчә олуг язучыларыбыз, шагыйрьләребезнең юбилейларын үткәрү татар халкының, татар әдәбиятының кешелек һәм заман каршында өлгергәнлегенә имтихан тотуы буларак чагылыш табар.

Тукай елы—өч йөздән артык язучыны берләштергән оешманың бердәмлеген тагын да ныгытыр, һәр язучының иҗат активлыгын, халкыбызны затлы һәм зыязатлы итеп тәрбияләүдә шәхсән җаваплылыгын арттырыр. Халкыбызның ак таплардан арынган үзенең чын тарихын белергә ихтыяҗы зур, чын әдәби иҗатны, әтрафлы сүзне бернинди яңа технология, виртуаль аралашу, хәбәрләшүгә алыштырмаган дистәләрчә мең зыялыларыбыз чын дастаннарга тиң олы эпик әсәрләр, зәвыклы шигырь-поэмалар, җырлар көтә бездән. Тукай

бүләгеп дәгъвалаучы дистәләгән бөекләребез дә, урта, яшь буын язучылар да Тукай елында, ниһаять, үзләренең иң талантлы әсәрләрен иҗат итәрләр.

Тукай елы—Язучылар берлеге идарәсе өчен дә зур сынау елы. Берлек идарәсе язучыларыбызның иҗатын стимуллаштыру һәм социаль көнкүреш мәсьәләләрен хәл итү юлларын эзли.

Илбашыбыз М.Ш.Шәймиевнның язучыларыбызның әсәрләрен рус һәм башка телләргә тәрҗемә итеп нәшер итү тәкъдимен тормышка ашыру өчен идарә каршында тәрҗемә секциясе оештырылды. 2006 елдан башлап «Литературная газета»да «Татарстан әдәбияты» рубрикасын чыгару бу юнәлештә беренче адым булачак. Шулай ук Илбашының хуплавы белән Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый, Һади Такташ, Фатих Хөсни, Җамал Вәлиди, Абдулла Алиш, Гавриил Державин исемендәге премияләрнең матди күләме 10-12 мәртәбәгә күтәрелә. Язучылар берлеге идарәсе һәм «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыятенең килешүе буенча Саҗидә Сөләйманова исемендәге өч премия, өч кызыксындыру премиясе һәм яшь язучылар өчен 10 стипендия булдырылды... Талантлы яшь язучыларны М.Горький исемендәге Әдәбият институтына югары әдәби курсларга укырга җибәрү буенча килешүләр әзерләнә...

Язучылар берлегенең социаль паспорты төзелде һәм шуннан чыгып, республика хөкүмәтенең социаль ипотека программасы буенча язучыларның торак шартларын яхшыртуның хәл итү чаралары күрелә... Бу чаралар язучыларыбыз оешмасының иҗади һәм иҗтимагый-социаль активлыгын үстерүгә дә этәргеч ясар, шөкер.

Тукай елында—милләтебезнең өметле киләчәге булган булдыклы, акыллы җитәкчеләребез һәм эшмәкәрләребезнең милли мәдәниятебез, әдәбиятыбыз һәм сәнгатебезне үстерүгә ярдәмнәре тагы да күбәер. «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте һәм аның «Рухият» фонды, «Татэнерго», «Түбәнкамашин», «Татспиртпром», ТАИФ, «Түбәнкама нефтехим», «Татарстан сөте», «Таттрансгаз» шикелле оешма һәм предприятие җитәкчеләре кебек чын ирегетләр саны ишәер.

Тукай елында—дөнья буйлап сибелгән милләттәшләребез белән элемтәләребез әдәбият һәм сәнгать чаралары аша тагын да колачланачак. Бу изге эшләрдә халкыбызның чын ихтирамын казанган, тагын бер айдан үзенең бер меңенче саны белән дөньяга чыгачак «Казан утлары» журналы да һәрвакыттагыча әйдәп барыр. Язып үткән һәм үтмәгән барлык уй-теләкләр тормышка ашар кебек. Чөнки мәркәзе мең яшьлек Казан булган, мең сынаулар үткән, әмма сынатмаган халкыбыз—булдырабыз, дип яши, һәм булдыра да!



## Ренат Харис

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Чиксезлеккә ышану сонеты

Чиксезлек һәм Хыял гына чиксез.
Хисләр чикле, чикле уйлар да...
Хыял гына, ярый, тышау-биксез,
чиксезлекне аңа буйларга.

Аны олы шартлау итәмен дә,
чиксезлеккә чәчрим, таралам...
Һәм сизәмен: балкып, аң-тәнемдә
Галәм зурлык Ана ярала,

күкрәк бирә, сораганны көтми...
Бу акылдан шашкан, димәгез—
без, шагыйрьләр, шулай, Җирдән китми,
чиксезлекнең сөтен имәбез.

Телебездә кайчак чит сүзлек—
җаныбызда чөнки чиксезлек.

### Хата эзләү сонеты

Кем ясады Җирдә иң зур хатаны?
Кайсы илдә, нинди телдә, гасырда?
Җавап эзләп, әле дә баш ватамын...
Һәм бөекләр күз алдыма бастылар.

---

Ренат ХАРИС (1941) – *Татарстанның халык шагыйре; Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Мөхәммәтме? Иисусмы? Буддамы?
Адәм?.. Ленин?.. Чыңгыз ханмы?... Әле дә
бар кешелек, ниятендә буталып,
бәхетенә юл табалмый һәр илдә!..

Ә кем кылды Җирдә иң зур игелек?
Шул ук затлар искә төшә иң элек,
чөнки алар—планетар аң үзәге!

Бу сорауны күп буыннар кабатлар.
Нигә кирәк сорауларга җаваплар?!.
Әллә дөнья берәр фетнә сизәме?..

## Реформаларга карышу сонеты

Яз түгелдер... Язга әле ерак.
Җылы гына килде кайдандыр...
Могҗизаңны күптән көтеп торам—
Җирне, Аллаһ, тизрәк әйләндер,

ил күкрәгән кояш җылысына
тизрәк ура, озак чыгарма...
Кала яздык утсыз учак сыман,
куәт тә юк артык чыдарга.

Могҗизаңның үзәгенә керт тә,
аччы тыныч күчеш серләрен—
реформалар каның сөртә-сөртә,
ничә буын инде керләнде...

Юа алмый канны ташулар,
су ташулар—бәхет башына!..

## Күләгәне өнәмәү сонеты

Тәңре кырын кичкән болытларның
Җир өстеннән шуган күләгәсен
мин туктатып тормак булып карыйм,
миннән узгач... Көчсез ләкин әфсен...

Күләгәгә баткан урман, дала
кайгы-хәсрәт күмгән күңел төсле.
Шул вакытта җанда сут туктала—
җирдә—чәчәк, тәндә—күңел үсми.

Күләгәдә яшәп караган бар,
йөрәгемдә кояш йөртсәм дә мин!..
Бу шигырь дә шунда яралгандыр...

Ләкин җил бар—мәләк хәрәкәте!
Һәм мин эчәм терек нуры тәмен—
күктән иңгән дога бәрәкәтен...

## Караңгылык сонеты

Яктылыкның үзәгендә кояш тора!
Караңгылык үзәгендә нинди җисем?
Кайчакларда күңелемне шушы сорау,
бик хәвефле хәнҗәр булып, китә кисеп.

Һәм мин эзлим караңгылык чыганагын.
Нигә эзлим? Ниемә ул минем кирәк?
Һәм кайдадыр үзәгемдә чыга янгын,
һәм сулкылдап үрсәләнә башлый йөрәк.

Мин кояшны күк йөзеннән сөртеп алам,
йолдыз, Айны офык артларына салам,
ә яктылык һаман-һаман күзгә керә.

Мин аптыраш чоңгылына тәмам чумам,
каш җыерам, тешем тешлим, күзем йомам
һәм... караңгылык үзәген шунда күрәм...

## Тулган ай сонеты

Ай тулышты төн нурыннан, өрелеп...
Качыштылар вак йолдызлар аңардан...
Ярканатлар канат җәйде иренеп,
һәм киттеләр күктән азык ауларга.

Лунатиклар, буйсынып нур-әмергә,
уяу төшләр дөньясына чыктылар.
Һәм алар да очышларга әзерләр—
фәрештәләр чөнки һаман йоклыйлар...

Үзе шомлы, үзе серле яктылык
гаҗәеп үз һәм коточкыч ят булып,
үле күздәй карап тора күшегеп,

шул яктылык сеңә башлый сүзләргә,
аларның да җылылыгын үзгәртә...
Кеше тизрәк яба йөрәк ишеген...

## Җавап эзләү сонеты

Тән туа да үлә... Ә җан кала...
Ул үлемсез рухтыр, күрәсең.
Димәк җанны нидер тартып ала!
Нәрсә икән? Ничек беләсе?

Чиксез Галәм микән? Йә йолдызмы?
Берәр көмәндәге баламы?
Аллаһ каршында, аһ, әхлак боздым—
сорауларны кире аламын...

Кире алып буламы соң аны?
Сорау бит ул уебызның җаны...
Җавабы юк сорау—үлемсез.

Җан һәм Сорау әллә тиңдәшләрме?
Гареш нигезендәге эшләрне
аңлый калсак, булыр... күңелсез.

## Йөрәк фасылы сонеты

Үзгәрешләр генә, үзгәрешләр
сиздерәләр вакыт агышларын.
Ә кешедә мәңге бетмәс эшләр:
югалтуын барлый, табышларын...

Кышның язга авышканын күрә
бозның елап үлүенә карап.
Җәйләр уза... Сары җилләр өрә,
Җирнең миндә үскән чәчен тарап...

Ә йөрәктә елның фасыллары
юкка чыга, эреп кайнар канда...
Һәм күрәләр шагыйрь асыллары:
сөю дигән фасыл гына анда!

Шул фасылда асыл шагыйрь эри—
үз канында үзе агып йөри...

## Ялгыш тыңлау сонеты

Лалә-гөлгә тиңли сине кемдер...
Лалә-гөлләр көнгә ачыла.
Кояш нурларына, әнә, сеңде
төн серләрен җыйган тамчылар.

Син ачыла торган вакыт—төндер.
Төндә—тышаусызлык тылсымы!
Бәлки, җәннәт назларына тиңдер
шул тылсымга бергә буйсыну?!

Каршымыни мондый тыңлаүгә мин?
Бу тыңлаүдә—минем теләгем:
дәрт ялкыны дигән ут аша

синең көнең минем төнем белән,
минем көнем синең төнең белән,
һич югында, уйда тоташа...

## Файдалы аумакайлык сонеты

Күкрәгән Җир яктыгарак бора...
Таңнан төнгә шәүләм сузам да,
кояш сәгатедәй басып торам
көн белән төн тигез ызанда.

Бүген Җиргә иңде язгы хаклык—
ак нур белән кара балансы!
"Гадел" кояш ләкин көннәр яклы—
куш минутлар көнгә ялгансын!

Ә көз көне көзге хаклык кылә.
Ул чакта да кояш эшне белә—
төн ягына бераз авыша...

Һәм кояшка беркем үпкә тотмый,
оттырмый да чөнки һәм дә отмый...
Аумакайлык кына ябыша...

## Мирсәет Яруллин

Исеңдәдер, дустым Мирсәет Яруллин,
мең дә бергә теш кысып кына ярылмый
йөргән чакта өй-эш-иҗат сукмагында,
очраттың да, барына өстәп, тагын да
бер эш бирдең. Мин килештем һич карусыз—
ул елларда кыюлык булган ярыйсы!..

—Бәлки,—дидең,—шаккатризм дип атарлар,
ну шулай да язып күрсәтик татарга
оратория дигән бер яңа әсәр,
әлегәчә татарда юк андый нәрсә...
Һәм аңлаттың оратория нилекне.
Андый "җырны" һич белми идем элек мин...

Һәм тотындым мин язарга сиңа кирәк
либреттоны... Чынын әйтим—бик тә сирәк
газаплана идем мин шигырь язганда...
Шигырьлек тә, ташка үлчим, бик аз анда...
Язамын да сиңа китәм—син хуплыйсың,
тик сорыйсың сүзләрнең утлы уклысын...

Исеңдәдер, шаккатризм тыңларга дип,
"Актерга" халык җыелды күптин дә күп...
Тыңладылар... һәм китте фикер алышу:
мактадылар берсеннән берсе калышмый
Нәҗип[1] ага, Гомәр[2] ага, Заһид[3] ага,
тагын күпләр, безнең иңнән кага-кага...

Әмирхан ага Еники дә сүз алды:
—Сәйдәш увертюраларыннан кузгалды
безнең музыкабызның бу юнәлеше...
"Кеше"[4] дигән бу әсәрнең дә өлеше
сизелерлек булыр әле киләчәктә—
татар музыкасы бүген шау чәчәктә...

Трибунага менде Мирсәй ага Әмир:
—Музыка да, либретто да—шәп, ләкин бер
нюанс бар... Сез уйлагыз әле шунсын:
"Кешенең иң зур нәрсәсе..." дигәннән соң
сузыла да сүзсез музыкаль пауза,
күз алдыннан шулчак төрле нәрсә уза...

Халык көлде... Мин кызардым. Син юаттың...
Тынычландым һәм башка сүз уйлап таптым,
җырлап карап, либреттога шундук керттек:
"Кешенең иң зур байлыгы...!" дип үзгәрттек.
Һәм бу байлык, Мирсәет дус, исән, яши,
кеше җанын кешелеккә таба дәшеп...

---

[1] Композитор Нәҗип Җиһанов
[2] Язучы Гомәр Бәширов
[3] Композитор Заһид Хәбибуллин
[4] "Кеше" ораториясе. Аны беренче тапкыр Н. Джураева җитәкчелегендәге хор башкарды.

## Шамил Анак

Исеңдәдер, Шамил абый, исеңдәдер:
син ул чакта Анак түгел, ә гади бер
шагыйрь идең Казан өчен. Ә чынында—
Мәскәүендә, Прагада, Истанбулда
исемеңнең матур аты чыккан иде:
"верлибрчы" дигән ярлык йоккан иде.

Без таныштык иске Матбугат йортында
һәм сөйләшеп киттек шундук бер үк тында,
бер үк тонда миңа тансык темаларга,
барып җиттек чиксезлек түкәнгән ярга...
Онытылдык... Кич тә җиткән беленми дә...
Барып кердек Пушкиндагы[1] блинныйга.

Дәвам иттек... Антик чорны айкап йөрдек...
Этрускларга, Бабилунга барып кердек...
Күрдек Җирнеке булмаган, күктән иңгән
цивилизацияләрне... Шуннан сеңгән
дымда үскән халыкларны барладың син—
әкрен генә блинныйны арбадың син:

унлап кеше җыелды безнең өстәлгә.
Кафе бикләп, пешекчеләр дә өстәлде.
Син сөйләдең... Юк, син гиздең гыйлемеңдә—
Күл-Тәгиннәр һәм Чыңгыз ханнар илендә
татар тамыры эзенә аяк бастык.
Һәм алышты тарихларның өсте-асты...

Шигырьләрең—белемеңнең тән-бәдәне—
чигеп барды синең затлы фәлсәфәңне
әңгәмәнең күңелдәй ак тасмасына:
кеше тора космик тылсым басмасында!..
Дәлилләрең—Библиядән һәм Коръәннән
һәм бүгенге иң алдынгы космик фәннән.

Төрле телдән төрле сүзләр чагыштырдың...
Безнең уйны Заман белән чабыштырдың...
Мин ул чакта тик студент кына идем,
йөрәгемә ярыш җене шунда тиде—
әй тырыштым Заманага баш бирмәскә,
гел яңарып тормасам да—искермәскә!..

Аһ, ул көнне, Шамил абый, син гаҗәеп
биек идең... Сәмруг коштай канат җәеп,
ас дөньядан өс дөньяга безне ташып,
син үзең дә, абруй булып, өскә аштың.
Мин әле дә сиңа карыйм ияк чөеп.
китәм шулчак теге асыл көнгә тиеп.

---

[1] Казанда 1961–1962 елларда Пушкин һәм Университет урамнары чатында "Блинная" дигән кафе бар иде. Автор.

## Биш Ренат

Исегездәдер дип уйлыйм, адашларым,
күрсәтергә теләп бездә дә баш барын,
җыелдык та, "коры" шәраб эчә-эчә,
ниятләдек үткәрергә күмәк кичә
Актер Йорты[1] диеп аталган подвалда—
подвал булса да, бик якты иде анда.

Бармакларын Шүрәле кебек селкетеп,
композитор һәм пианист Р. Еники
уйнады Шопен "Ноктюрн"ын, сонатина:
пианино сыкрый, гөрли, көлә, тына
һәм пышылдый көйдән генә хасыйл сүзләр:
затлы музыкага бирел, татар,—үзгәр!..

Чыкты Таҗи. Ул—Геракл, Былтыр, атлет—
һәр адымын король Лирдай горур атлый.
Учы белән, шау китереп, һава телеп,
монологлар сөйләде ул елап, көлеп...
Күңелләргә уелдылар нурлы әзләр:
сәхнә кебек иркенлеккә омтыл—үзгәр!..

Әле бары консерваториядә генә
укыса да, Ибраһимов менә дигән
затлы җырчы булачагын шәп күрсәтте—
арияләр, шлягерлар бүләк итте.
Колаклардан күңелләргә күчте сүзләр:
артта калма җырдан, татар,—үзгәр, үзгәр!..

Ибәтуллин—игезәкләрнең сыңары—
аякларда көй дә, сүз дә, җыр да барын
тар сәхнәдә очып биеп исбат итте...
Һәм миңа да шигырь сөйләр чират җитте.
Бик модада иде шигырь ул елларда—
йөри иде кыю, авангард юлларда.

Ил буйлата искән җылы җилләр дәрте
күңлебезне, күзебезне нык үзгәртте.
Исемебез[2] татарныкы булмаса да,
рухыбызны чын татарча—туры, садә,
горур итеп саклап кала алган килеш,
без өндәдек: татар үзгәрергә тиеш!

Исегездәдер дип уйлыйм, адашларым,
җанны кыйган куркаклыкның бозы-кары
тизрәк эрергә кереште безнең утта—
телгә кайта башладылар тарих йоткан
күп шәхесләр, батырлыклар һәм рух эше...
Бу эштә бар биш Ренатның да өлеше!..

---

[1] Үткән гасырның җитмешенче елларында Актерлар Йорты К. Нәҗми урамында Качалов исемендәге театр гомумторагының цоколь этажында урнашкан иде.

[2] Renatus — латинчадан, яңадан яшәүгә әйләнеп кайтуны аңлата.

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



**Марат Әмирханов**

## И, КЫЛГАН ДОГАМ МИНЕМ...

ПОВЕСТЬ

Көн искәрмәстән генә үзгәрде. Иң элек Бөркет тавы ягыннан җил купты. Бакчадагы барча куаклар аны ябалдашларын аска иеп, шаулаша-шаулаша сәламләделәр. Ә кояш риза түгел иде, ахры, үпкәләгән бала шикелле чыраен сытты. Үз йөзенә пәрдә элүне өнәми шул, гел балкып кына торасы килә, күрәсең. Әле генә чәчәктән-чәчәккә кунып бал җыеп йөргән умарта кортларының да безелдәве ишетелми иде инде. Гарасат исен кай арада сизеп алганнар да, кай арада югалып өлгергәннәр.

Шундук Сөн аръягында дөбер-шатыр күк күкрәде, яшен яшьнәде. Офык буйлап ишелә-ишелә каракучкыл болыт өерләре тәгәрәшә башлады. Бөтерелә-бөтерелә әллә нинди рәвешләргә керәләр: оешалар, ургылалар, чәчеләләр; янә оешалар, янә чәчеләләр...

—Әллааһү ләәәә иләәһә илләә һүү. Әлхәййүль каййүүм. Ләә тәьхузуһүү синәтүү үәләә нәүүм...,—дип дога укырга кереште Хисам.

Бу—Әйәтүл Күрси. Тәүге мәртәбә ул аны, моннан алтмыш ике ел элек, Смоленск юнәлешенең ни өчендер Куянкай исемен йөрткән кечкенә станциясендә хәтеренә төшергән иде. Ул мәхшәр монының ише генә идеме соң, җүләр. Ай-һай...

Бүгенгедәй исендә. Салкын иде. Үктәбер ае димәссең, кырлачтагы шикелле җиргә төшкәнче төкерек туна. Поезд исә, бернәрсәгә карамыйча, фронт кочагына ашыга. Утын пүләнедәй тыгызлап тутырылган бер эшелон солдат.

Мәскәү янында аз-маз тәпәләсәләр дә, немецның егәре барыбер хәттин ашкан. Өстенлек алар ягында. Бигрәк тә самолетлары куркыныч. Карга көтүе кебек һаман баш түбәсендә очалар. Шунда асылынып кына торалар әллә? Хәтта малларга да ау оештыралар. Чашулары җитте кабихләрнең.

Марат ӘМИРХАНОВ (1933) *— прозаик; «Таш һәйкәл», «Сөн моңы», «Тәкъдир» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Безнең командирларның бу югалтуларга, үлем-китемгә әллә ни исе китми иде. Чөнки гамьсезлек Кызыл Армиядә гадәти хәл. Жиңү барысын да гафу итә, имеш. Әлеге эшелон да бернинди иминлек чаралары күрмичә генә, "әйдә, ярар"га чыгарып җибәрелгән иде. Сугышчыларны әнә шул "әйдә, ярар" харап итә дә инде. Күбесе дошман белән йөзгә-йөз бәрелешкәнче үк "батырларча" һәлак була. Батырлык дигәннән, бернинди аек акыл белән акланмаганнары да күп булды ул батырлыкларның. Шуңа күрә бүгенге көнгә кадәр, сугыш бетүгә илле сигез ел тулуга карамастан, аның турында халык чын дөреслекне белми. Хәер, Хисам үзе дә хак дөреслекне әйтер көн килеп җитмәгән дип саный. Ялган анынча, соңгы фронтовик белән генә җиргә күмелергә тиеш.

Немец самолетлары Хисам утырган эшелонны да оятсызларча, ялтырап нур сипкән кояш яктысында, көпә-көндез бомбага тоттылар. Кар, туң балчык кантарлары, кан белән буталып, чуарланып бетте. Кая карама, кычкырыш, ыңгыраш. Бомбалар берөзлексез коела да коела. Башта йөрәк өзгеч тавыш чыгарып сызгыралар, аннан җирне ду китереп шартлыйлар. Җәһәннәмең бер якта торсын.

—Безнекеләр нигә күренми, нигә бәреп төшермиләр бу вәхши карчыгаларны,—дип, өзгәләнде әле битенә сакал-мыек та тишмәгән яшь солдат.

Берсендә бер корал юк, мылтык та бер-ике бөртек озата баручыда гына. Ә самолет карчыга түгел, аны мылтыктан гына атып төшерермен димә. Шушы мәхшәрдә, Хисам, армиягә озатканда әнисе Шәмсебәдәр көчли-көчли кесәсенә салган дога-бөтиен хәтеренә төшерде. Җәһәт кенә кесәсен капшап карады. Урынында икән дип сөенеп куйды. Ул моңа кадәр дин белән мавыкмады, киресенчә, комсомол егет буларак, фаш итүчеләр арасында йөрде. Махсус урта белемле ветеринар егеткә атеистик темага лекцияләр сөйләргә, әңгәмәләр үткәрергә кушалар иде. Бөти-мөтиләр—искелек калдыгы. Әгәр берәр иптәше кесәсендә дога йөрткәнен белеп алса, бот чабып көләр иде. Алай гынамы, мәсхәрәләп комсомолдан кудыртачак әле. Ленин комсомолында дингә ышанучыларга урын юк!

Тик Хисам догадан арынырга ашыкмады. Киемнәр алмашынды, дога да яна киемнәр кесәсендә үз урынын тапты. Әлеге хәлнең сәбәбен аңлатыр дәрәҗәдә дә түгел үзе. Ихтимал, буыннан-буынга ата-бабадан килгән тәкъвалек галәмәтедер? Ихтимал. Әйтәләр бит, иман җанда, тәннең һәр күзәнәгендә, канда, рухта, диләр. Күрәсең, аны күңелдән әмер белән генә кубарып ташлап булмый. Әнә, кеше куркыныч янаганда, фаҗига алдында калганда, Газраил белән күзгә-күз очрашканда ике генә затны ярдәмгә чакыра: аның берсе Аллаһ булса, икенчесе—әни!

Баш калкыткысыз шушы үлем туе вакытында ирексездән Хисамның теленә дога килде: "Әллааһү ләәә, иләәһә илләә һүү..."

Ниһаять, дөнья тынып калды. Ул яшеренгән урыныннан чыгып, як-ягына каранып торды. Бер төзек вагон да калмаган, составны токмач шикелле кискәләп, җир белән тигезләгәннәр. Платформа мәет белән тулы. Теге аксыл йөзле яшь солдат та шулар арасында. Чалкан төшкән. Кемгәдер үпкәләгәндәй иреннәрен бүлтәйтеп ята, бәгырь.

Тулы бер эшелоннан алар тугыз гына кеше исән калган иде. Бу хәлләрдән соң Хисам бөти өчен күн янчык текте, җеп белән муенына асып йөри башлады.

* * *

...Җәйге яңгыр кыргый ат көтүе кебек кешни-кешни ябырылып килсә дә, күбеге озакка бармый. Шундый ук тизлек белән үтеп тә китә. Хәзер дә

шулай булды. Сөннен бу ягында яңгыр коя, аръякта инде кояш елмая иде.

—Хисам Сабир, илһамыгызны алай-болай яңгыр юып алып китмәгәндер бит, пошаманга төшкәндәй күренәсез,—дип чыркылдап көлде оныгы Гүзәлия,—карагыз аны, вакыт кыса. Гонорар ишелеп кесәгә керәм дип торганда гына редакция килешүне өзеп куймагае.

Гүзәлия әле быел гына Казан университетын тәмамлап, авылга эшкә кайтты. Мәктәптә татар теле һәм әдәбиятын укытачак. Шигырьләр дә яза ул. Исеме әледән-әле матбугатта күренгәләп тора. Бабасына бу бик зур горурлык. Шигырь яза белүче кешене фәрештәгә тиңли Хисам. Үзе дә аз-маз каләм тибрәткәли анысы. Район гәжитенең даими авторы санала. Әле менә күптән түгел, син фронтовик кеше дип, башыннан үткәннәрне кәгазьгә төшерергә куштылар.

— Миннән барып чыкмас бу эш, егетләр,—дип аяк терәп каршы килде.

Ник дисәң, мәхбүслектән котылып, Котыптан кайтуга сугышка, фронтка, тоткынлыкка мөнәсәбәтле бөтен хатларын, язу-сызуларын утка яккан иде. Бәладән башаяк. Аннан соң инде күпме вакыт узды. Житди эшләр өчен яше дә шактый. Хәер, сиксән яшькә житсә дә зиһен дигәне әле бәйге тотарлык.

Хисам бу эштән котыла алмады. Әлеге дә баягы, оныгы килеп кысылды. Ул бәйләнә башласа, өзми дә, куймый да, барыбер үзенекен итә.

—Мин сезгә бик жиңел ысул тәкъдим итәм, Хисам Сабир,—диде чигенергә юл калдырмыйча,—кулыгызга каләм дә тотмаячаксыз, микрофонга гына сөйләячәксез. Уегызга ни килсә, шуны такылдый бирегез. Калганы минем өстә. Фэрштейн?

Гүзәлиянең сүзе үтә иде аңа. Әнә бит, үзе чибәр, үзе иркә. Нәкъ бәбәлән йомыркасы. Чынында да, чибәр иде кыз. Күл камышы кебек зифа буй-сын. Аккошныкыдай нәфис ак муен. Озын керфекләр. Йомры аяк. Иңнәренә төшеп торган кылгандай аксыл чәчләре, яшькелт күзе үзенә бик килешле. Алар нәселе белән чибәр. Бабасы ягыннан барысы да озын буйлы, төз гәүдәле, аксыл йөзле. Ерак токымнары беренче дулкын Алабуга керәшеннәренә барып тоташа. Нииндидер сәбәп белән бәгъзеләре янә үз диненә әйләнеп кайткан. Шул нәсел жебе әле булса үзгәрмичә дәвам итә.

Хисам, үзе әйтмешли, хәзер язучылык белән мәшгуль. Хәтирәләрен яңарта. Бакча эченә тактадан бер корылма әтмәләп куйганнар иде. Гүзәлия аны дача дип йөртә. Хисам иртән иртүк әнә шул "дача"га юнәлә, ижат күленә чума.

—Яңгыр суы түгел, язгы ташкыны да безгә тубыктан,—диде Хисам көлемсерәп.

—Нәтиҗәсе бармы соң, нәтиҗәсе?

—Каз урынына карга булмаса, бер кассета әзер, тыңлый аласың. Ул арада мин өйгә кереп чәйләп алырмын. Сөйләве дә жиңел түгел икән, тамак кибә.

Хисам үз юлыннан китте. Гүзәлия кассетаны магнитофонга куйды. Анда бабасының тоныграк йомшак тавышы яңгырады.

БЕРЕНЧЕ ТАСМА

### Сугыш

Сугыш миннән хыянәтче ясады. Юк, юк, мин исемемне дә, ватанымны да, халкымны да сатмадым. Ихлас күңелдән армиягә жиңү теләдем. Кулымнан килгәнчә бу жиңүгә үз өлешемне кертергә теләдем. Куянкай станциясендәге мәхшәрдән соң шуны да колагыма киртләп куйдым, сугышта бернинди файдасыз вә мәгънәсез

югалтулар да чамадан артып китә икән. "Саклының сагы ятыр, саксызның башы ятыр" дигән мәкальнең хаклыгына тәмам ышандым. Монда алдыңны-артыңны карап йөрергә кирәк. Үзең турында фәкать үзең генә кайгырта аласың.

Сугышта шундый хәлләргә тарыйсың, әлеге шартларда инде кыюлык та, тәвәккәллек тә, хәтта куркаклык та роль уйнамый. Хөкемдарың—Галиҗәнап Очраклылык. Муса Җәлилнең ачынып-ачынып "Пистолетым итте хыянәт" дигән сүзләренә мин чын күңелемнән ышанам. Ә менә тагы бер яраткан каһарман фронтовик шагыйрем Фатих Кәрим белән бәхәскә дә керәсе килеп куя. Әйтик, "үзең турында уйлама, илең турында уйла", дип яза ул. Үзе турында уйламаган кеше иле турында да уйлый алмый лабаса. Шөкер, Ходай аны әсирлектән саклаган. Шуңа күрә фикер сөреше бүтәнчәрәк. Үлемнән дә саклаган булса, әдәбиятыбыз отар гына иде, әлбәттә. Нишлисең, монысы безнең кулда түгел шул инде.

Мин дә үз теләгем белән "хыянәтче"ләр сафына басмадым. Хәзер менә шул хакта тәфсилләбрәк сөйләмәкче булам.

Безнең подразделение маршал Тимошенко житәкчелегендәге Көньяк-Көнбатыш фронтына карый иде. Харьков юнәлешендә сугышчан операциядә катнашабыз. Батальон командиры майор Никитин безне, үз кул астындагы барлык офицерларны, блиндажына җыйды. Комбат фронтта беренче көннәрдән үк икән. Утны-суны кичкән. Үзенә нибары егерме ике яшь. Сүзен өзеп, кистереп әйтә. Кыскасы, профессионал, үз шөгыленә фанатикларча бирелгән кадровой офицер. Ә шөгыле—сугыш. Бу, гади генә әйткәндә, кеше үтерү. Аныкы гынамы, һәммәбезнең дә шөгыле ул кеше гомерен өзү. Үзебез дә сизмәстән, Аллаһы Тәгалә вазифасына кул суздык.

—Язгы-җәйге кампаниянең язмышы безнең фронтта хәл ителә, иптәш Сталин куйган гомум бурыч искиткеч мөһим. Ул бурыч Мәскәү янындагы уңышлы операцияне дәвам итеп, 1942 елда илебезне фашистлардан тулысынча чистартудан гыйбарәт. Бу—приказ! Приказны тикшермиләр, приказны үтиләр!

Майор кискен хәрәкәт ясап, кулы белән һаваны ярды, күзләрендә миһербансыз очкыннар кабынды, какча гәүдәсе калтыранып куйды.

—Иң сөймәгәнем куркак бәндәләр,—дип дәвам итте командир,—әгәр үз белдекләре белән чигенүчеләрне күрәм икән, белегез, шул ук минутта, шул ук урында үз кулларым белән дөмектерәчәкмен.

Монын шулай булачагына беребез дә шикләнми.

Никитин ике дә уйлап тормаячак. Ул—суворовчы. Ә Суворов мәктәбеннән чыкканнарның кансыз дигән яман даны таралган.

Минем командирлык тәҗрибәм мондагылар белән чагыштырганда күгәрчен борыны кадәр генә. Петлицамда да нәни генә бер йолдыз. Курслар үтеп, кече лейтенант дәрәҗәсе алуыма нибары ярты ай. Шунлыктан, Никитинның әлеге сүзләрен үз адресыма әйтелгән сүзләр дип кабул иттем. Дөресе дә шулай булып чыкты. Башкаларны чыгарып җибәргәч, комбат мине каршысына утыртты да:

—Сабиров, бу синең беренче чирканчык алуың, взводыңны яхшылап әзерлә, матри, үзең башкаларга үрнәк бул,—диде, күзләрен чекерәйтеп. Әйтерсең лә, җан-фәрманга монын киресен эшләргә җай эзлим. Мин-минлегемә сукты командирның ышанычсыз мөнәсәбәте. Бүген генә йомыркадан тишелеп чыккан чеби түгел лә, тел яшереп тормадым, әйттем.

—Юлда мин күргән мәхшәргә юлыккан булсагыз, болай сөйләшмәс идегез, иптәш майор,—дидем Куянкай станциясендәге хәлләрне күз уңында тотып. Майор бу хакта хәбәрдар иде, чеметеп тә алды.

—Аһ, шулаймыни, туп шартлаттылармыни, куркыттылармыни?..

Анын мыскыллы карашыннан утырган урындыгым белән бергә жиргә сенә яздым.

—Уңышлар телим, иптәш кече лейтенант,—диде Никитин соныннан житди төстә. Бу китәргә мөмкин дигәнне аңлата иде.

Блиндаждан чыккач, бермәл тирә-якны күзәтеп тордым. Язгы матур кич. Тып-тын. Һавада чәчәк исе. Алмагачлар шау чәчәктә. Алда да, артта да, унда да, сулда да. Чөнки батальон жиләк-жимеш совхозы жирендә урнашкан. Солдатлар окопта, техника яшерелгән. Шуңа күрә бер жан иясе дә күзгә чалынмый.

—Иптәш кече лейтенант, траншеяга төшегез, монда басып торырга ярамый,—дип кисәтте часовой. Конспирация. Һөҗүм алдыннан күрелә торган саклык чарасы.

Мин комбат кушуы буенча тагын бер мәртәбә взводның әзерлеген тикшердем, боеприпасларны барладым, кешеләр белән сөйләшеп чыктым. Кәефләре әйбәт күренә. Операциянең уңышлы үтәчәгенә тулы ышаныч бар иде.

12 майда, нәкъ иртәнге сәгать дүрттә, салкынча талгын һаваны ярып, күккә ракета иңде. Бу һөҗүмгә сигнал иде. Шул ук мизгелдә дәррәү килеп йөзләгән-меңләгән гаскәри үләксәгә ябырылган чебен өере шикелле атакага күтәрелде.

—Ура! Ура! Ура!

Мин дә пистолетымны баш очында селки-селки окоптан өскә ыргылдым. Күзгә ак-кара күренми. Немецлар безнең көч алдында каушап-югалып калды, ахры. Шулай булмыйча, күр, нинди зур омтылыш, нинди зур теләк! Бер йодрыкка тупланган бу көч бүген һичшиксез канәчкеч Кабил токымының арт сабагын укытачак.

Шундый патриотик ашкынулы хисләр белән алга элдертәбез. Гүя язгы ташкын. Аны туктату мөмкин түгел. Инде, әнә, немец траншеяларына да ерак калмады: жинүле бер ыргым! Их, мать якасына!

Шулчак, уйламаганда-көтмәгәндә, коеп яуган яңгыр шикелле өстебезгә шыбыр-шыбыр килеп ядрә коела башламасынмы! Ул арада жир астыннан гына күтәрелгәндәй башнясына тәре сурәте төшерелгән тумпак борынлы танклар да калкып чыкты. Күзләр акайды. Әмма кан элеккечә үк кайнар, хисләр элеккечә үк ашкынулы. Алдан жентекләп планлаштырган операциягә болар гына киртә була алмый иде. Командование барысын да уйлаган, әлбәттә. Запас вариантлар да бардыр әле. Кыскасы, жиңү безнең якта булачак! Шушы ышанычлы уйларга куәт өстәгәндәй комбатның әче тавышы яңгырады:

—За Родину! За Сталина!..

Бату явыдай янә тезгеннәрне бушаттык. Нишләп немец мыеклы да, без нишләп кыеклы ди. Мә, мәлгунь, совет кургашыннан авыз ит! Дошманның да бирешергә исәбе юк. Котырына, албасты, тәки жиргә ятарга мәжбүр итте бит. Танкларны мылтыктан атып кына туктатып булмый шул. Әнә, юлларында очраган блиндажларны, окопларны, брустверларны вата-изә мөгезсез сыер шикелле өскә киләләр. Бер мүкләге минем алда да пәйда булды. Ара якынайганнан-якыная бара. Күзәтү ярыгы аша хәтта йөртүченең мыскыллы елмаюы да шәйләнгәндәй тоелды. Янәсе, капкында син, егетем. Үземнең дә котым ботыма төште. Нишләргә? Фашистның угы мина төбәлгән. Уңга каерылсаң да, сулга каерылсаң да, качып котылыр чама юк. Тагын егерме-утыз секунд шулай аң-саң килеп торсаң, изеп китәчәк. Шунда кулым үзеннән-үзе яндыру катнашмасы тутырылган шешәгә үрелде. Шөкер, һәр кешегә берәрне биргәннәр иде. Турысын гына әйткәндә, мин аның барлыгын да исемнән чыгарган идем. Рәхмәт фәрештәмә. Жанымны

учыма йомарладым да, тондырдым шешәне танк тарафына. Тукталып калмасынмы үлем тартмасы! Кайсы жиренә тигәндер, белмим, яна башлады бит бу. Ур-а-а!

—Молодец, Сабиров!..—дип кычкырды рота командиры, күреп торган икән. Туп гөрселдәве астында аның тавышы кинәт өзелеп китте. Мин моңа артык әһәмият бирмәдем, чөнки вәзгыять мизгел эчендә үзгәреп тора, бәлкем, штабтан элемтәгә чыкканнардыр, бәлкем... Хәер, мин уйларлык хәлдә идемме соң? Эчем-тышым шатлык белән тулган иде. Тирә-якта үлем, кан, һавада Газраил пәрдәсе, ә мин тиле кеше сыман шырык-шырык көләм.

Яныма рота командирының адъютанты килеп баскач кына айнып киттем.

—Капитан һәлак булды, устав буенча командование вакытлыча сезгә күчә,—диде ул,—нинди күрсәтмәләрегез бар?

—Комбатка хәлне житкерегез!

Адъютант элемтәчене эзләп китте. Ә мин уйга калдым. Тау кадәр җаваплылык лабаса бу! Шулай да әле генә фашист танкын сафтан чыгару миңа көч һәм ышаныч өстәгән иде. Һичнигә карамый ротаны атакага күтәрергә карар кылдым. Тавышымны комбатныкына охшатыбрак, аның ук сүзләрен кабатладым:

—За Родину! За Сталина! Вперед!

Ул орыш кырын мин ни белән чагыштырырга да белмим. Мөгаен, Коръәндә тасвирланган кыямәт көненә тартымдыр. Алмагачлар кара күмергә калган. Күбесе төбе-тамыры белән куптарылып ташланган. Танклар яна, адым саен мәет. Кайда жир, кайда күк—һич белмәссең. Әйтерсең лә, бергә тоташканнар.

Алдыма-артыма карамый йөгерәм. Искәрмәстән бер гәүдәгә абынып киттем. Карасам, Никитин! Эчем жу итеп китте. Күр, утта янмас, суда батмас кешене дә пуля алган бит. Юка иреннәре кысылган, гүя үч алырга чакыра.

Сөйгән кызың бар идеме, комбат, бу ачы хәбәрне ничекләр кичерер инде...

Ихтимал, әлеге бик тә җаваплы минутларда командир атаканың уңышлы үтүе турында гына уйларга тиештер. Ләкин күңел үзенчә хәл итә шул, башка сугыш белән бәйле булмаган чит уйлар да керә.

—За Родину! За Сталина!..

Әле чабабыз, әле ятабыз, әле мүкәлибез. Бервакыт немец пехотасы белән күзгә-күз калдык. Миңа моңа кадәр дошман белән менә шулай йөзгә-йөз очрашып, йодрык һәм штык сугышларында катнашырга туры килгәне булмады. Әлеге тәмуг аша узган солдатларның сөйләвенә караганда, бу вакытта аң югалып тора, имеш. Үз акылындагы кеше әлеге психологик өермәгә түзә алмый икән. Нәкъ менә шундыйлар яу кырында ятып калалар ди: йә йөрәкләре ярыла, йә каршы якның хәнҗәренә юлыгалар...

Без дә шундый хәлдә идек. Әгәр әс-пес килеп торсаң, үзенә эләгә, син алданрак житешергә тиеш! Шул чакта гына исән калуга исәп тота аласың. Бу уен түгел. Бу—сугыш! Күзләргә кан сауды, үлем, курку дигән төшенчәләр ничектер тоныгаеп калды. Ватасы, жимерәсе, кырасы, үтерәсе килә... Бугазга бугаз киләбез. Кычкырышу, сүгенү, ыңгырашу—барысы бергә кушылды. Без дә орчыктай озынча немец белән тәгәрәшеп киттек. Иптәшләремә ярдәмгә ашыкканда искәрмәстән ыргылды ул өстемә. Кулындагы хәнҗәрен дә абайлап алдым. Исән калам дисәң, ничек тә бу хәнҗәрне тартып алырга, кулыннан сугып төшерергә кирәк. Көчле кабәхәт. Гәүдәмә капланып, бугазыма үрелә. Тәки жаен китереп, егып салды. Мин дә бирешмим. Каян жай килде, бар булган көчемне туплап, үлем ачысы белән туп шикелле читкә тәгәрәдем.

—Әһә, ошамыймы, чучка тәре...

Яшен тизлеге белән немецка очып кундым да зур борынынннан умырып тешләп тә алдым. Бу шулай тиз һәм ансат килеп чыкты, әйтерсен лә, фриц үзе борынын жайлап авызыма тыкты. Ну, акырды да сон, чалган дунгыз тавышлары чыгарды. Шул форсаттан файдаланып, хәнжәрен тартып алдым, ниндидер бер канәгатьләнү белән күкрәгенә батырдым...

Өзелгән борынын сонынннан гына төкереп ташладым. Авыз эчендә йөргән, ләгънәт, кызулык белән сизелмәгән.

—За Родину! За Сталина!..

Бу юлы ян-яктан кырмыскалар шикелле чуп-чуар булып янә танклар килә иде. Шушы кадәр танкны тоткарларлык көч юк иде инде. Хәл мөшкел. Бер тиенсезгә кешеләрнең гомерен өзүдән мәгънә юк. Болай да санаулы гына калдык. Тоттым да шушы ду-галәмәттән, төтен, тузан буранынннан файдаланып, ротаны коры елга аша урман эченә алып кереп киттем. Ә бераздан тирәбездә гөрселдәүләр тынды, без дошман тылында калдык. Хәзер ничек тә үзебезнекеләр ягына чыгу жаен эзләргә кирәк.

Немец, бел, без Никитиннарның үчен кайтарачакбыз әле. Канга—кан, үлемгә—үлем!

Кузгалдык. Курыкканга куш, коерыгы белән биш, ди. Тукайча әйтсәм, "бер шыгырдауны ишетсәм, аузыма жаным килә". Алай да егетләргә белгертмим. Тора-бара жайлаштык тагын. Үзебезгә күрә бер батырлык та майтарып ташладык әле.

Борынга ниндидер таныш ис килеп бәрелде. Якында зур су булырга тиеш дип фаразладым эчемнән генә. Сөн—Агыйдел буенда буй житкергән кеше бит, күнел сизә. Фаразлавым хакка чыкты, чыннан да, алдыбызда елга пәйда булды. Ни күрик, шунда гына немецларның кыр кухнясы. Ике агрегат. Мичләре ягулы. Шикләнмиләр дә, бәдбәхетләр. Кешеләре күренми. Ял итәләрдер, мөгаен. Көн "кызу" булды бит. Фәкать сакчы гына әрле-бирле йөрештерә.

—Әйдәгез, фрицларны кичке ашсыз калдырабыз, тыгынмасыннар әле,—диде отделение командиры Мөнир Исламов. Мөнир Сергач мишәре. Усал, кыю, тәвәккәл егет. Әле дә күзләре ауга чыккан жанварныкы шикелле яна.

—Ничек?—дип сорадым.

—Кухняларын яр астына тәгәрәтәбез.

—Аш өчен баш салыргамы?

—Без сугышчы, командир. Сугышчы сугышырга тиеш.

Нәкъ авырткан жиремә китереп сукты бу. Әллә нишләп киттем. Ник дисән, ротаны үз белдегем белән позициядән чыгардым ич. Әгәр моны комбат күреп торган булса...

—Ярый, тәкъдименне башта анлатып бир,—дидем сер бирми генә,—шуннан сон хәл итәрмен.

—Сергей безнен кошлар авазын чыгарырга бик маһир, урманда үскән малай. Ул сандугач булып сайрап жибәрә. Сакчы мона игътибар итмичә калмый, билгеле. Сугышта сандугач сайрасын әле! Фриц әсәрләнеп жыр тынлаганда мин арт ягыннан чыгып, шарт монын башына! Көферне тәмугка озаткан арада сез кухняларның тәгәрмәч асларына куелган ташларны читкә бәрәсез дә, иплэп кенә, әмма бик жәһәт, аска тәгәрәтеп жибәрәсез. И һәм әллүки.

Ләкин эш Мөнир тәгаенләгәнчә генә бармады. Сакчысы бик куәтле иде, каһәр. Башына бер таш кына житмәде, барыбызга да кул тыгарга туры килде.

Кухнялар паровоз шикелле парларын бөрки-бөрки яр астына тәгәрәде. Без елга буена ашыктык. Бәхетебезгә, монда тынлык иде. Немецлар да, безнекеләр дә күренми. Ара-тирә кайдадыр еракта, адашкан автомат кына

тыкылдап-тыкылдап куя. Чын атышулар таң белән башланачак. Шуңа кадәр елганы кичеп, үзебезнекеләргә кушыласы иде.

Мөнирне разведкага җибәрдем. Тиз урады егет.

—Командир, әлегә барсы да тәртиптә, ашыгырга кирәк!—диде.

—Хәзерләнегез,—дип әмер бирдем. Җәһәт кенә чишенеп, киемнәрне биштәрләргә тутырдык та шыпан-шыпан гына елгага кердек. Бер кулда автомат. Үзең суга чәчәсәң дә, аны сакларга кирәк. Чапайча бер кул белән йөзәбез. Су салкын түгел, әмма агым көчле, бөтереп-бөтереп ала. Бер заман ракеталар җемелдәшә башлады. Безнекеләрме, немецлармы—белерлек түгел. Хәер, безне күрә-нитә калсалар, кем булса да ут ачачак. Төннең күзе юк.

Аллага шөкер, сигнал ракеталары гына иде, күрәсең. Салдан ычкынган башбирмәс бүрәнәләр шикелле елга уртасында чупырдашабыз. Биштәр аска өстери, автомат тоткан кул инде бернәрсә тоймый, агач тукмакка әйләнде. Алай да, карышлап кына булса да, аргы якка барыбер якынлашабыз. Тартыша-тырмаша торгач, ниһаять, аяклар катыга тиде. Хәл калмаган иде. Чыгуга киселгән агачтай комга аудык.

Безне шул халәтебездә кулга алдылар. Типкәли-типкәли торгызып, богау салдылар. Мин мона сөендем генә. Болар үзебезнекеләр иде. Сүгенүләреннән таныдык. Якын булып, рәхәт булып китте. Безне алар, мөгаен, кием алыштырган дошман разведкасы дип кабул иткәннәрдер. Зыян юк, анлашырбыз. Әлегә авыз да ачтырмыйлар, касыкка гына китереп сылыйлар, күздән утлар күренә. Шулай да бер арада! “Без майор Никитин батальонынннан”,—дип сүз кыстыра алдым. Колакларына да элмәделәр. Эткәләү-төрткәләү дәвам итте. Тәннең күгәрмәгән урыны калмагандыр, шәт. Землянкага китереп япкач кына, тын алдык. Монда элек автол, солидол ише машина майлары саклаганнар, ахры. Май исе тамакларны ярып керә.

—Әллә бер-бер хыянәтчеләр кулына килеп эләктек инде,—диде сержант Исламов,—белә торып типкәлиләр бит.

—Үзең әйтмешли, сугыш икәнен онытма,—дип кисәттем аны,—андый гына ялгышлар китә инде ул. Рәхмәт әйт, фашистлар кулына эләкмәдек.

—Нинди аерма, дөмбәсли-дөмбәсли китереп яптылар бит әле менә...

—Сержант Исламов!!!

Шушы дуамал сүзләре өчен Мөнирне тетеп ташлау иде ниятем. Ләкин нәкъ шушы вакытта сакчы ишек уемына эленгән чыптаны ачып:

—Младший лейтенант Сабиров, на выход!—дип сөрән салды. Мин, богауларымны кызлар тәнкәседәй челтер-челтер чылтыратып, урынымнан кузгалдым. Егетләр шым булды. Мөнирнең сүзләре аларны да пошаманга төшергән иде. Кырыс булып күренергә тырышсам да, үземнең дә эчем тулы шом. Бер дә юньлелеккә охшап тормый әле бу. Бер-бер хәвеф булмагае.

—Командир, нык тор, рәнҗетергә ирек куйма,—дип кычкырып калды Мөнир.

Мине тагын землянкага алып керделәр. Тик монысы бөтенләй башка иде. Байлар өе, ак өй. Ишеге тактадан ясалган. Чиста, якты. Хәтта мебеле дә бар: иң түрдә зур өстәл, кырыйда тимер караваt, ян-якта берничә артсыз урындык. Фронт шартларында бу инде люкс.

—Алгарак уз!—дигән тавыш ишетелде. Шунда гына өстәл артында күркә шикелле кукраеп утырган кешене абайлап алдым. Петлицаларына да күз төште—подполковник! Кәпери егеткә ошаган. Чәчләре шома итеп таралган, киемнәре ыспай, якасына тегелгән тукымасына кадәр сөттәй ап-ак.

Подполковник керфекләрен дә какмыйча озак кына миңа күз теге багып торды. Бу җансыз, кырыс карашны күтәрә алмадым, башымны түбән идем.

—Нәрсә, оятына чебен кундымы әллә?—дип, карашын үзгәртмичә генә иреннәрен кыйшайтты Кәпери.

Тузар илнен җәнҗалы бетмәс ди, нәкъ кешеләренә килеп капканбыз. Болар особистлар лабаса! Хәрәкәттәге армиянең артыннан шакшы җыеп йөрүчеләр. Чигенүчеләрне сагалап торып, ут ачучылар. Сталин особистларга шундый хокук бирде.

Хәзер, күрәсең, безгә дә тикшерү үтәргә кирәк иде. Монысына гына түзәрбез, баш исән булсын. Ләкин җебеп төшәргә дә ярамый. Йомшаклыгыңны сизеп алсалар, җилкәнә менеп атланырга да күп сорамаслар. Үзе кебек үк күзләремне батырып:

—Безнең рота хәрәкәттәге армиягә карый, ни өчен кулга алдыгыз, безнең нинди гаебебез бар?—дип тикшерүченең үзеннән сорадым.

Подполковник йомыркадан чыкканчы ук әтәч булган кеше иде, ахры, борыны югары, үзен бик эре тота. Әле дә җавап бирергә ашыкмады. Башта кесәсеннән ялтырап торган портсигарын чыгарды, аны тәм табып озаклап ачты, аннан попиросның авызга каба торган өлешен бармаклары белән изгәли-изгәли гармун күреге рәвешенә кертте дә, юка иреннәре арасына кыстырып куйды. Зажигалкасын чертләтеп яндырды, шактый ара ләззәтләнеп ут ялкынына текәлеп карап торды. Папиросын кабызып, тирән итеп суыргач кына әйтеп куйды:

—Сез хәрәкәттәге армия түгел, сез—дизертирлар!

—Иптәш подполковник...

—Мин сиңа иптәш түгел, синең иптәшең Тамбов бүресе. Аңладыңмы?

Вакыты алдан килешенеп куелган иде, күрәсең, землянкага ике хәрби кеше килеп керде. Икесе дә майор. Берсе кара тут йөзле, чеп-чи шадра, әйтерсең лә, битендә шайтан борчак суккан. Ул подполковникның уң ягына кунаклады. Икенчесе, уклау йоткандай төзгә катканы, сул яктан урын алды.

—Ялгышасыз, иптәш подполковник, без дизертирлар түгел, рота шушы хәлендә дә хәрби бурычын үтәргә әзер,—дип, мин өзелгән сүзне ялгап киттем.

—Ә подразделениегез кайда? Нигә алардан аерылдыгыз?

—Немецлар безне чолганышта калдырып, урап киттеләр... Мин ротаны саклап калдым...

Подполковник төссез соры күзләре белән өттереп алды да: “Сезнең исән калуыгыздан ни файда?”—дип урыныннан торып басты. Аннан соң: “Көньяк-көнбатыш фронтына караган җиденче хәрби-кыр судының утырышын ачык дип белдерәм”,—диде. Өстәлнең бер башына сәркәтип тә килеп кунаклады.

Аһ, менә нәрсә, бу суд икән ич! Трибунал! Башым әйләнеп китте, күз алдымда әллә нинди яшелле-зәңгәрле утлар биешеп алды. Сез дөрес эшләмисез, без Ленин-Сталин эшенә чын күңелдән бирелгән чын патриотлар, дип кычкырасым килде. Ләкин телне кузгатып булмый, гүя таш тагып куйганнар.

Минем эчке халәтемдә, нинди тойгылар эчендә кайнавымда судьяларның гаме юк иде, әлбәттә. Алар ниндидер сораулар бирделәр, дәлилләр китерделәр, кычкырдылар, орыштылар. Берсе дә күңелемә уелып калмады, хәтта ни дип җавап биргәннәремне дә хәтерләмим. Подполковникның хөкем карарын укып чыгып, миңа текәлеп карап торган мизгелдә генә күзләрем ачылып киткәндәй булды.

—Аңладыгызмы?—дип сорады ул. Мин әле һаман тиле кешедәй гамьсез кыяфәттә басып торам.

—Нәрсәне?—дидем, ниһаять, телгә килеп.

Судьялар, җилкәләрен җыерып, бер-берсенә карашып алдылар.

—Ротаны сугышчан позициясен ташлап китәргә мәҗбүр итеп, Ватан мәнфәгатьләренә хыянәт иткән өчен сез атарга хөкем ителәсез, Сабиров. Хөкем кичектергесез рәвештә гамәлгә ашырыла. Карар катгый, дәгъваләр кабул ителми. Карар текстын укып чыгыгыз да кулыгызны куегыз.

Мин тинтәк берни булмагандай имзамны сырладым, алдымда әйтерсең лә акча ведомосте иде.

Хәзер шул вакыйгалар исемә төшеп, җиде төн урталарында дерт итеп уянып китәм, кара тиргә батам. Ә ул чакта ишәк төчкергәндә дөньяга килгән хикмәтсез адәмдәй нишләп ваемсыз булганмындыр, белмим. Уйланам-уйланам да, ахыр чиктә шундый нәтиҗәгә киләм: минем күнел егәрен, кальбемне тулысы белән трибунал үзе йоткан булгандыр, дим. Шул психологик контузиядән айнып җитмәгәнмен, күрәсең, дим. Наркоз кебек тәэсир иткән ул суд. Шулай булмыйча, безнең кызның кияү күргәне бармыни дигәндәй, моңа кадәр гел күз уңында йөргән актив комсомол идем лабаса! Алдынгы укучы, алдынгы белгеч, алдынгы курсант... Һәм көтелмәгәндә—суд! Әле ничек акылымнан язмаганмын. Бу хәлне авылда, техникумда, училищеда ишетсәләр әгәр, баш бетәрлек хәбәр ич. Әткәй-әнкәй, туганнар өчен моннан да зуррак хурлыкның булуы мөмкинме соң? Ә Рабига?

О-о, Рабига! Рабигага җиткән кыз бөтен Актаныш районында, Актанышта гынамы, Минзәләсендә юктыр әле. Сурәтен исле май шешәсе тышына төшер дә куй. Чибәрнең чибәре. Алма битле кара каш. Матурлык өләшкәндә Ходай каршына иң беренче булып барып баскан зат. Баскандыр да. Аяк балтырлары, әнә, нинди нык, нинди таза. Юантыграк буй-сыны да күнелне җәлеп итеп тора. Куллары кайнар, йомшак...

Мин бу гүзәл кызның шушы исерткеч кулларын тоткач, исем китеп артыма ава яздым. Билләһи. Фронтка киткәндә озатучылар арасында ул да бар иде. Хәлбуки, безнең авылга килгәненә бер генә атна иде әле. Актаныш урта мәктәбенең тугызынчы сыйныфын гына бетергән әлеге яшь кызны махсус педагогик курсларда укытып, авылыбыз мәктәбенә мөгаллимә итеп җибәргәннәр. Моны тәфсилләп белүемнең сәбәбе шул, Рабиганы күршебез Мөхсинә әбигә фатирга керттеләр. Мин Актаныштан көн дә кайтып йөрим. Ә әнкәй күрше карчык сөйләгәннәрнең барысын да житкереп тора. Әнкәйгә дә бик ошый иде булса кирәк Рабига. "Синең урыныңда булсам, җибәп йөрмәс идем, шул кызның колагын булса да тешләп китәр идем, сугышы да гомер буена бармас, бер бетәр әле",—дип и угаланды әнкәй бәгърем.

—Җыен хорафат синдә инде, әнкәй, нинди колак тешләү ди ул совет заманында,—дип көлгән булдым. Ә бу сүзләр үземнең йөрәгемә сары май булып ятты.

Бер күрүдә үз иттем мин Рабиганы. Тик туры гына китерә алмыйм. Чөнки кич чыкмый, яшьләр белән аралашмый. Ияләшеп җитә алмый, ахры. Хәер, атна эчендә нинди ияләшү ди әле, мәктәбендә дә эше муеннандыр.

Шулай да җае чыкты бит. Укытучыларга район кушуы буенча бер пот бодай оны биргәннәр икән. Баш табиб Кубаров абыйның йомышы белән районнан кайтышлый амбарга сугылган идем. Рабиганың он үлчәткән чагына туры килдем. Егет кеше шушындый форсатны кулыннан ычкындырамы соң?

—Күрше хакы—Алла хакы,—дип, тоттым да капчыкны иңемә салдым.

Кыз нур тулы мөлдерәмә күзләрен күтәреп, шулай якын итеп карады, хәтта колак төбемдә: "Син миңа бик ошыйсың",—дигән сүзләре дә яңгырап киткәндәй булды. Монысы инде, билгеле, хыял җимеше генә иде.

—Рәхмәт, кирәкми, мин үзем...

—Укытучы башыгыз белән капчык күтәреп йөрмәссез бит инде...

Мин алдан барам, ул артымнан теркелди. Минем өчен ин кулай вакыт югыйсә. Бүтән мөмкинлек булмаячак. Чөнки иртәгә чыгып китәсе. Юллама—кесәдә. Тәки рәтле-башлы әңгәмә кора алмадым. Насыйплары үсә торсын әле, дип үз-үземне юаткандай иттем. Әнкәй дөрес әйтә, мин сугыштан урап кайтканчы аны тотмаячаклар. Әле хәзер үк күз атып йөрүчеләре бардыр. Шуна күрә озатучылар арасында Рабиганы күргәч, аптырап киттем. Мина ул юашрак төсле күренгән иде. Ай-һай, бала-чага башыннан йөрмәгәе дип уйлап та куйган идем. Юк, төшеп калганнардан түгел икән, чая кыз икән. Лүрт-лүрт басып каршыма килеп басты да:

—Хисам иптәш, чын күнелдән сезнен батыр комсомол булуыгызны телим. Фашистларны тизрәк тар-мар итеп, исән-сау әйләнеп кайтыгыз,— дип кулын сузды. Дөресен әйтим, ул вакытта әлеге рәсми теләкләрнен мәгънәсенә төшенеп тә житә алмадым. Мине кызнын йомшак, нәфис куллары әсир иткән иде.

Соныннан безне йөриләр дип чыгарганнар.

...Подполковник эшне хәрбиләрчә коры тотты. Алар үз вазифаларын бик яхшы беләләр иде. Барысы да уйланылган, көйләнгән, һәммәсе майланган механизмдай, келт тә итми, үз чиратында башкарыла. Менә кемнәрдән эшкә өйрәнергә кирәк!

Минем кебекләр белән дә еш очрашалар булыр, йөзләрендә бернинди миһербанлылык, хәлгә керү, теләктәшлек чаткылары шәйләнмәде. Конвоирлар төрткәли-төрткәли алып чыгып киткәндә дә көлешә-көлешә сөйләнеп калдылар. Галәти көн, галәти мәл.

Урман илаһи тынлыкта иде. Башымны күтәреп, рәт-рәт тезелешеп киткән зифа буйлы шырпыдай төз чыршыларга карап алдым. Нинди хозурлар, нинди горурлар! Алтынсу-кызгылт кәүсәләренә сөяләсе, сыйпыйсы, иркәлисе килеп китте.

Инде тан ата. Төнге манзара акрынлап төсен алыштыра, биек агач кәүсәләре арасыннан туып килүче көннен тәүге нурлары сәлам бирә. Аяк асты юеш. Чык мул төшкән.

—Як-ягына каранма, атлавынны бел,—дип ашыктырды конвоир.

Берничә минуттан ниндидер ачыклыкка килеп төртелдек. Ярлары карт әбиләрнен тешсез авызы сыман ыржаеп тора. Төбендә хәтта үлән дә үсми икән, зур-зур кәсләр генә аунап ята. Аргы якта яшен яньчеп бетергән ялгыз имән күренә. Шыксыз, күнелсез. Жәһәннәмнен ишек алды инде бу. Ләкин әле һаман үземне читтән күзәтүче кебегрәк хис итәм. Әйтерсен лә, мине түгел, башка берәүне атарга алып баралар иде.

Догамны онытмыйм тагын.

—Үтенечем бар,—дидем конвоирга.

—Нинди үтенеч?—дип каршыма минем яшьләрдәге лейтенант килеп басты. Офицерларга җәза биргән вакытта офицер шаһит булып карап торырга тиеш икән.

—Мин мөселман өммәтеннән, догамны кулыма алырга рөхсәт итегез,— дидеме.

—Кулларын чишегез,—дип әмер бирде лейтенант.

Әниемнен догасын тышлыгыннан алып, эчемнән генә берничә мәртәбә укып чыктым.

—Әллааһү ләәәә иләәһә илләә һүү...

Аннан сон доганы янә муеныма асып куйдым. Лейтенант гажәпләнеп карап торды. Карамагае.

Мине яр кырыена китереп бастырдылар. Чын курку шул вакытта килде. Бу минем якты дөньядагы сонгы сулышларым лабаса! Гаскәр кебек үрә

каткан әлеге чыршы агачларын, үлән яфраклары өстендә зәбәрҗәт ташыдай жемелдәшеп утыручы чык бөртекләрен күзләрем башка бервакытта да күрә алмаячак ич инде. Әнкәем, әткәем, туганнарым, бәхил булыгыз!..

Минем үзем кебек шушындый ачы язмышка дучар ителгәннәрне тасвирлаган күп кенә киноларны караганым булды. Идеология, пропаганда белән сугарылган андый эпизодларда совет кешеләре үлемне горур кыяфәттә, ниндидер тәкәбберлек, масаю белән кабул итәләр. Куркаклар гына сыгылып төшә, имеш. Дөрес түгел! Курку адәми затка фарыз хисләрнең иң көчлесе. Гомерне кием шикелле алыштыра алмыйсың. Ул бер генә тапкыр бирелә. Дөрес, бакыйда да тормыш бар диләр. Ихтимал. Тик аны тәгаен белеп булмый! Чөнки аннан бирегә юл киселгән.

Курку минем дә җаныма гына түгел, бөтен күзәнәкләремә үтеп керде. Мин гәүдәмне тоймый башладым, баш очымда фәкать мәрхәмәтсез һәм чарасыз уй гына бөтерелә: үләм бит, үләм...

Үлем ачысы тәнемә бизгәк булып ябышты. Калтыранам, дерелдим, тешләрем бер-берсенә бәрелеп шык-шык килә: үләм бит, үләм...

Беравык телемә килеп:

—Мин гаепле түгел,—дип кычкырып җибәрдем.

Шул вакыт ниндидер могҗиза белән күз алдымда авылыбыз мәчете пәйда булды. Таныйм да, танымыйм да. Ник дисәң, мин белгәндә ул ташландык хәлдә иде инде. Ишекләре каерылган, тәрәзәләре ватык. Манарасына каргалар, чәүкәләр хуҗа иде. Без, малай-шалай, көннәр буе шул каргаларга рогаткадан атып, эш-мәшә килеп йөри идек.

Мәчет ихатасы сирень агачлары белән камалып алынган иде. Чәчәкләре бөтен тирә-якка хуш ис тарата. Тик коймасы инде черегән, хәрабәнең хәрабәсе. Шуңа күрә әнкәй мәчет ишек алдына кергән кәҗәләрне куарга куша иде. Сүзен тынлаганмындыр, ахры, аркамнан сөя-сөя кесәмә кипкән кабак төше салгалаганы хәтеремдә.

Мин беренче сыйныфка укырга кергәндә мәчетнең манарасын аудардылар, соңыннан бинасын да сүтеп алдылар.

Менә шул мәчет күз алдымда тора бит! Мин белмәгән, күрмәгән өр-яңа чагы: түбәсе калай, манара очында ай балкый. Буяулы койма эчендәге күк күзле купшы сиреньнәр шау чәчәктә утыра. Мөәзин азанга оеган...

—Аллаһу әкбәр...

Карыйм, чәүкә кыяфәтендә ай өстенә мин кунганмын, имеш. Гыйфриттәй бер ямьсез кеше миңа рогаткасын төбәгән...

Шунда кинәт кенә барысы да өзелде. Мин ниндидер караңгы упкынга тәгәрәдем. Авырту да сизмәдем, уй уйларга да өлгермәдем. Бары тик колакның чыңлавы гына хәтергә уелып калган.

* * *

Гүзәлия магнитофонны каләмен тоткан килеш тыңлады. Хисам Сабир сөйләгәннәрне кәгазьгә төшерергә иде аның исәбе. Чынлыкта исә бер кәлимә сүз теркәмәде. Бабасының язмышы тетрәндерде аны. Үлемгә хөкем ителүе турында белә иде ул, әлбәттә. Ләкин моңа кадәр бу вакыйганы күңеле аша уздырмаган булган икән. Күр, нинди зур фаҗига кичергән. Кешене атарга хөкем итәләр, күкрәгенә мылтык терилә...

—Җә, ничек, кыз, хикмәт чыгарлыкмы?

Гүзәлия ялт итеп артына борылып карады. Ишек уемында бабасы басып тора иде. Бер-берсенә карашып тордылар.

Хисамның башы әле муенында нык утыра. Дөрес, пеләше шактый киңәйгән, чигә чәчләренә көмеш күптән кунганга охшый. Ләкин озынча

ак мангае тавык йомыркасы шикелле шома, ике каш арасындагы сай буразнаны исәпкә алмаганда, сырлары беленми. Күзләре якты. Аз гына тырпаебрак торган итләч ияге аның зур ихтыяр көченә ия булырына ишарәли. Хисамга һич тә үз яшен биреп булмый әле. Югыйсә, апрельдә генә ду китереп юбилеен уздырдылар.

—Хисам Сабир, ат бәйләрлеген бар әле синең,—диде кыз, бабасыныкы кебек яшькелт күзләрен аннан алмыйча.—Горурланам мин синең белән!

—Ярлылык та яхшы икән, ятып ашар аш булса, дип әйтә торган иде әтекәем. Шуның сыман инде, кызым, хәзергә Аллага шөкер. Алайса кассетада азмы-күпме хикмәт бар дисең инде?

—Шаяртма, Хисам Сабир, хикмәте барын син үзең дә бик һәйбәт беләсең. Каләм дә кертәсе юк, күчерәсе генә.

—Шатландырдың, кызым, рәхмәт, бик рәхмәт.

—Ашыкма, минем әле печтек кенә ачыклыйсы нәрсәләрем бар.

—Ни-нәрсә икән ул, жә, рәхим ит.

Гүзәлия өлгергән чиядәй тулышкан иреннәрен бүлтәйтеп, берара уйланыбрак торды. Аннан соң җилкәсенә төшеп торган саргылт чәчләрен сыйпаштыра-сыйпаштыра соравын юллады.

—Үзеңне немецларга бурычлы дип саныйсыңмы? Сине бит чынлыкта алар коткарган.

Инде Хисамның иреннәре бүлтәеп чыкты.

—Китәле, алай дигән белән дә, син инде бигрәк, кызым...

—Ә нигә, дөрес бит. Особистлар мылтык тәтесенә басып өлгергәнче немецларның снаряды төшеп ярылган ич. Үзең сөйләдең.

—Әйе, 13 майда иртәнге сәгать өчтә немецларның генерал-фельдмаршал Фон Бок командалагындагы "Көньяк" төркеме укышларын ныгыту максатында, бөтен фронт буйлап һөҗүмгә күчә. Мине, чыннан да, шушы һөҗүм коткарды. Ләкин бу сылтау, дөресрәге, алшарт кына. Аның төп сәбәбе, кызым, менә шушы дога—Әйәтүл Күрси.

Хисам күлмәк изүен ачып, күн тышлы догалыгын учына алды.

—Шулай әйтәсеңне белеп торам ич инде, бабакай, юри генә шаяртам. Синең бу хакта сөйләргә әвәслегеңне белгәнгә генә котыртуым.

—Их, бәбәлән йомыркасы. Әйтәм аны, йонсыз мендәргә яткыруы икән әле...

Гүзәлия бабасына каш астыннан гына күз сирпеп алды да, анькына охшатыбрак, һәр сүзенә кул ишарәсе белән мөһер суга-суга салмак кына сөйләп китте: "Харьков орышы командованиенең иң зур хатасы ул. Немецлар тулы бер фронтны камап алып тар-мар иттеләр. Маршал Тимошенконың булдыксызлыгы шунда тулысынча исбатланды. Мин аны алдан ук сизеп-тоеп йөрдем. Сталин эшеннән азат итеп бик дөрес эшләгән..."

—Мин монысын да хәтеренә төшерә алам әле, әфәндем, кәләпүш астын җылытып алган чакларда авызыңда гел шушы сүз ич синең.

—Жә-жә, теленә салынма...

—Яхшы, Хисам Сабир, үзеңне генә калдырам. Илһамың килгән чак, комачауламыйм.

ИКЕНЧЕ ТАСМА

## Әсир

Мин җәмгысе унбер ел әсирлектә булдым. Өч елы—немец ягында, сигез елы—Совет ягында. Дөрес, соңгысы рәсми телдә тоткынлык дип йөртелә. Ләкин әсирлектән аның бер аермасы да юк. Алай гынамы, әсирлекнең үз өстенлекләре бар. Әйтик, әсирнең

хокукы халыкара конвенция нигезендә саклана. Хәтта Гитлер да әсирлек статусын бозарга кыймады. Тик бу статусны ул пленга төшкән бөтен кешеләргә дә бирмәде. Яһүдләр, кызыл комиссарлар, партизаннар Германиянең иң каһәрле дошманнары дип игълан ителде. Хәер, СССРда да әсирләрне төрле категорияләргә бүлгәләгәннәр. Мин яткан лагерьларда күбесенчә йодрык законы хөкем сөрде. Көчленеке тегермән тарта иде.

Болары сүз уңаеннан гына. Бу хакта сүз булыр әле. Ә хәзер мең дә тугыз йөз дә кырык икенче елның унөченче маенда булган вакыйгаларны хәтер иләгеннән уздырыйк.

Мин сулышым кысылудан аңыма килдем. Беренче булып ат картасына ошаган сырлы-сырлы итләч нәрсә күземә ташланды. Бау, вак кына җиз бөжралар... Ботинка табаны ич бу диган уй килеп кадалды башыма. Немецлар әнә шундый калын табанлы, сырлы күк ботинка кияләр иде. Димәк, күкрәгемдә—немец ботинкасы! Ничек? Кайчан? Мине особистлар атканнар иде түгелме соң инде? Һични аңламыйм. Күзләрем югарырак авышты. Анда тишекләре мич авызыдай киерелгән тумпак борын, иске бияләйдәй шәлперәйгән калын иреннәр, җирән чәчле олы баш пәйда булды.

Немец солдаты! Җиңе сызганулы, автоматын маңгаема төбәгән. Әллә бу да атарга җыена инде, үле лабаса мин! Бөтен күзәнәкләремә шушы мәгънәсез уй тула.

—Дөмектер инде, сузма,—дигән тавыш колагымны ярып керде. Сүзләрен сүзгә аңламасам да, мәгънәсе шундый иде.

Аңым тулысы белән кайтты, урынымнан тормакчы булып талпынып алдым.

—Һо-һо, яшисе килә Иванның,—дип көлде җирән чәчнең иптәше.

Немецлар яралыларны, авыру-хәлсезләрне әсир алмыйлар, урында гына эшләрен бетерәләр. Чын-чынлап чират җитүе шушы инде алайса. Мин инде иртә таң белән ни-нәрсә булганын, ни рәвешле исән калганымны төшенеп алган идем. Әнә, янымда гына мине атарга алып килгән особистларның мәетләре аунап ята. Булган монда хәлләр...

Иреннәремә үзеннән-үзе дога кунды: “Әллаһү ләәәә иләәһә һүү...”

—Офицер, офицер...

Җирән чәч автоматын җилкәсенә элде. Күрәсең, немецларга офицер тере килеш кирәк иде.

—Маташма инде шул имгәк белән,—дип үзенекен тукыды тегесе,—нигә башка бәла алырга?

Мин аякларымны, кулларымны селкеткәләп алдым, тәртиптә кебек, кан да күренми. Баш менә үз урынында түгел, әйтерсең лә, алыштырып куйганнар. Аеры да чөере: гөжли, сызлый, әйләнә...

—Шнел, шнел,—дип җирән немец калын табанлы ботинкасы белән типкәләп алды. Аның нигәдер мине исән калдырасы килә иде. Бар көчемне җыеп, аягүрә бастым. Башым чатнап китте, ярыла дип торам. Ләкин ничек тә атлап китәргә кирәк иде. Яшәү-яшәмәвем шуңа бәйләнгән.

—Шнел, шнел!

Алпан-тилпән килеп булса да кузгалдым бит тәки! Егылмадым! Фәрештәләр канатларын куеп, саклап бардылар, күрәсең. И, Ходаем, рәхмәтеңнән ташлама.

—Җәтрәк атла!—дип, чәрелдек тавыш артыма китереп типте. Сынап каравы иде булса кирәк, сөрлегеп китсәм, ике дә уйлап тормыйча арт чүмечемә пуля җибәрә иде. Бу юлы минем бәхетем җинде. Ә бераздан әсирләр төркеменә килеп кушылдым. Безне көнбатышка таба куалап киттеләр. Особистлар сыман кулга богау салмасалар да, як-якта карчыгадай үткен күзле конвоирлар атлый. Келт итәргә дә ярамый, хәзер автоматлары

телгә килә. Бара-бара рәтләр сирәгәйде. Хәзер чират кемгә житәр икән инде, дип куркынышып атлыйбыз. Кичке якта исән калганнарны ниндидер сыер абзарына кертеп тутырдылар. Зур абзар. Колхозы хәлле булганга ошый.

Фильтрация дип аталган сыйрат күперен шушында кичтек. Иң башта яһүдләрне, комиссарларны аерып алдылар, аннан соң командирларны бер почмакка жыйдылар. Петлицаларым кайдадыр умырылып калган икән, шуңа күрә ахры мина игътибар итмәделәр. Үзем, мин командир, дип ыргылып чыкмадым.

Язмышым башкача хәл ителде. Сафта торганда бер төптән юан немец тәгәрәп кенә диярдәй килде дә, моноклен күзенә куеп, мине перчаткалы куллары белән мал базарындагыча капшап-капшап карады.

—Гут, гут, азиат,—дип, янындагы сирәк тешле иптәшенә ым какты.

Югыйсә, мин яшькелт күзле, аксыл чәчле, озын буйлы егет идем, һич тә азиат дип әйтерлек түгел. Әмма бу немец балта мае ялаган кеше иде, ахры, минем мөселман токымыннан икәнемне, ышанычлы һәм карусыз зат булуымны бер карауда сизеп-тоеп алган иде.

Без, азиатлар, шактыйга жыелдык. Төнгә каршы исә поездга төяп алып та киттеләр. Германиягә диделәр. Шулай булып чыкты да.

Безне поездан, ничәдер көн үткәч, таң белән бер урман итәгендә төшерделәр. Төшерә торалар, тезеп урман эченә алып керә торалар. Көн инде туып килә иде. Әнә, агачлар өстеннән алланып кояш күтәрелә, кошлар чыркылдаша. Һава саф. Үлән яфраклары өстендә чык тамчылары жемелдәшә. Югыйсә, без бит хәзер дошман жирендә, фашистлар оясында! Ә табигать, әйтерсең лә, моны белми. Кояш та, кошлар да, чык та, урман да нәкъ бездәгечә. Хәер, шушындый ук илаһи бер иртәдә әле кайчан гына мине үзебезнекеләр кулларымны артка каерып бәйләп, атарга алып барганнар иде. Аңламассың бу дөньяны. Борынгыларның, заманына күрә таяк та еланга әйләнер, дигән гыйбарәләре, гүя бүгенге көнгә атап әйтелгән.

Урман дигәнебез декорация ролен генә үтәгән икән. Эчтә бөтен бер шәһәрчек. Акшарга буялган тәбәнәк бараклар тезелешеп киткән. Араларында төрле-төрле геометрик фигуралар шикелле ком сибелгән юллар, сукмаклар чуалышып ята. Бөтен жир тел белән ялагандай чиста.

Шәһәрчек бернечә кат чәнечкеле тимер чыбыкка уралган. Адым саен диярлек манара. Һәрберсенә агачка утырган карга шикелле сакчы кунаклаган. Беренче карашка, бу корылмалар уенчык шәһәрне хәтерләтә иде. Чөнки тып-тын. Бернинди ыгы-зыгы сизелми. Ә анда, яхшылабрак карап баксаң, меңләгән әсир сыйган икән. Үземнең дә баштан үтте. Немец тәртип ярата да, урнаштыра да белә. Менә без дә бер жепкә теркәлеп акрын гына алга шуышабыз. Авызлар йозакта—ләм-мим. Хәтта як-ягына каранырга да ярамый.

Чираты житкәннәр барак эченә кереп китә дә югала, кереп китә дә югала. Әллә турыдан-туры газ камераларына озаталар инде. Күңелгә шом керә. Күпме хәвефле сүз йөри бу хакта. Әсирләр белән нинди генә тәжрибә үткәрми ди немец галимнәре. Кеше тиресеннән хатын-кызлар өчен төрледән-төрле затлы галантерия әйберләре ясыйлар, имеш. Бик кыйммәт йөри ди андый товар. Ә чимал—без инде, әсирләр.

Ишек уемына якынлашкан саен, йөрәк үрсәләнә бара, нәрсә булыр, алда ни көтә? Кырым чиргүе сыман ишле халык, сүз катар мөмкинлеге генә юк, бәлки, тынычланыбрак та китәр идең.

Ниһаять, эчкә уздым. Анда үзе бер тамаша, барак тулы шәрә халык. Мин дә башкалар шикелле анадан-тума калганчы киемнәремне салып ташладым. Беренче мәртәбә Актаныш хәрби коммисариатында комиссия торулар искә төште. И, шул чактагы оялулар! Оялмыйча ни, егет башың

белән хатын-кыз табиблар каршында шөлдериләреңне асылындырып басып тор әле. Соңыннан ул хәлләрне хәтергә төшереп, малайлар белән ни гомер көлешеп йөргән идек. Сөйләгән саен вакыйгалар өстәлә иде, күперә иде.

Монда гел ир-ат. Аннан соң, гомерең яшәү белән үлем арасында асылынып торганда, оялу-кыенсынулар урап уза икән.

Икенче туктальш чәчтараш янында. Ә дигәнче машина белән башыңны такыр тары кырына әйләндереп куя. Шулай килә-килә табиб биләмәләренә аяк басасың.

—Нинди йогышлы авырулар белән авырганың бар?—дип сорады табиб. Сифлис, корчаңгы, бизгәк хасталары белән кызыксынды. Аеруча тиф өркетә икән мондагыларны. Бәйнә-бәйнә сораштырдылар, тикшерделәр. Дәвалау өчен түгел, әлбәттә. Чиреңне тапсалар, дөмектерәләр генә.

Сез инде, мөгаен, Хисам агай алманчаны су кебек эчә икән дип уйлап куйгансыздыр. Йөри-йөри шомардым анысы. Хак. Әйе, аларның сүзен дә аңлый идем, үземнекен дә аңлата ала идем. Ләкин моңа өч ел вакыт кирәк булды. Әсир төшкән вакытта "һенде һоһ" белән "шнел-шнел"дән ары узмаганмындыр, мөгаен. Ә тәфсилләвемнең сәбәбе бик гади, чөнки чишендерүче дә, чәчтараш та, табиб та рус кешеләре, рус әсирләре иде. Немецлар безгә гомумән җирәнеп карыйлар иде, кая ул чәч алу, тәнгә орыну. Һәммәсе перчаткадан, авыз-борыннары ак марля белән капланган. Ләкин барысы да алар күзәтчелегендә, аларның әмере буенча башкарыла. Бернәрсә дә игътибарсыз калмый.

Табиб озынча какча бармаклары белән каты-каты итеп муеныма баскалап алды.

—Догам, догам,—дип өзгәләнеп пышылдадым.

Кай арада ишетеп алган, "Што он гофорит?!",—дип күзәтүче офицер янибызга килеп тә басты.

—Догасын югалткан,—диде табиб.

—Што, што? Конвой!

Аңышырга да өлгермәдем, алыптай калын гәүдәле, чиертсәң каннары сытылып чыгардай бүртек йөзле ике конвоир мизгел эчендә кулларымны артка каерып, чылбырлап та куйдылар.

—Тентегез!—дигән әмер яңгырады. Ләкин болай да шәрә ич инде мин, барысы да күз алдында. Шуңа күрә конвоирлар да каушабрак калдылар шикелле, берара нишләргә белмичәрәк басып тордылар.

—Киемен тентегез!—дип кычкырды офицер.

Мине җилтерәтеп, ишек катына алып киттеләр.

—Кийемеңне эзләп тап,—диде табиб. Ул тылмач вазифасын да үти иде, ахры, офицерга барысын да җиткереп бара. Югыйсә, тегесе үзе дә русчаны шактый әйбәт сукалый иде.

—Кулларым бәйдә бит,—дидем мин.

—Богауларын алыгыз!—диде офицер!

Бөтенебезнең киемнәр чүмәләдәй өелгән иде. Тотындым актарынырга. Таба гына алмыйм бит, каһәр. Ахыры һәр сәләмәне кулымнан үткәреп, икенче урынга өя башладым. Хәзер язмышымны дога хәл итә. Чөнки табылмаган очракта, немецларның бу хәлне үзләренә каршы юнәлдерелгән бер-бер этлек дип уйлаулары бар. Ул чагында ике сөйләшеп тормаячаклар. Шуңа күрә доганы ничек тә табарга кирәк. Хуҗалар ашыктыра. Каеш камчысы белән конвой бер-икене төшереп тә алды. Аркам икегә ярылды дип торам. Әллә шушы куалауның файдасы тиде, ниһаять, гимнастеркамны танып алдым бит. Аллага шөкер, догам да исән. Офицер аны кулымнан умырып диярдәй тартып алды.

—Прокламация! Партизан!

—Дога булырга тиеш!—диде табиб,—гарәп имлясы белән язылган ич.

—Бу әле бернәрсә турында да сөйләми. Прокламацияне гарәпчә дә язарга була. Экспертизага җибәрегез. Үзен—карцерга!

Шулай итеп, Алман җиренә аяк баскан көнне үк аерым исәпкә алындым. Ә карцер дигәннәре ине-буе бер адым чамасындагы таш капчык икән. Басып кына тормалы. Караңгы. Һавасы авыр, тамакка утыра, ютәлгә тия. Чөнки юеш. Әнә, тып-тып итеп тамчы тама. Түбәсе тишек, ахрысы. Ярар, анысы инде минем кайгы түгел. Ләкин тамчы һич тә үзен онытырырга ирек бирми бит, каһәр. Һаман тама: тып-тып; тып-тып... Гүя тәнне тишкәли.

Колакларымны ике яклап та учларым белән капладым. Аз гына тынычланып торды да, янә тыпылдарга тотынды. Ни генә кыландырып карама, тавыш терекөмеш сыман барыбер ярыгын таба, җаныңа үтеп керә. Инде аңлашылды, бу әсирләрне чыгырыннан чыгару өчен махсус эшләнгән җайланма икән.

Тавыш көчәйгәннән-көчәя бара, әйтерсең лә, баш түбәсенә дөп тә дөп чүкеч белән бәргәлиләр. Бер заман чәчләрне йолкый-йолкый идәнгә ятып ауныйсы килә башлады. Куллар үзеннән-үзе нидер эзли. Әгәр ялгыш кулга бау эләксә, валлаһи, муенга салу җаен эзләр идем.

—Коткарыгыз, үлә-ә-м...

Тавышымны ишеткәннәрме, күзәтеп торганнармы, өстемә бер чиләк салкын су бөркеделәр. Шуннан соң "тамчы"ны да туктаттылар. Дәвам итсә, акылдан шаша идем.

Күпме утырганмындыр, белмим, көннәрдән бер көнне карцерның ишеген ачтылар. Уф, якты дөньяны күрер көннәр дә бар икән! Әсир өчен монысы да зур шатлык.

Мине бинаһая озын баракның уң канатындагы бер бүлмәгә алып керделәр. Анда чабатадай калын кашлы немец офицеры ишекле-түрле йөренә иде. Ишек катында чалмалы башын кырып салып, бер мулла басып тора. Немец йөргән җиреннән тукталып:

—Бу синең догамы?—дип өстәл өстендәге кәгазьгә төртеп күрсәтте.

—Минеке...

Мулла да офицерга башын иде.

—Коммунистик тоталитаризм, тоташ атеизм шартларында динне үз итәргә җөрьәт иткәнең өчен мактыйм,—диде офицер.—Бөек Германия шуның өчен сиңа гомереңне бүләк итә.

Мулла йөгереп килеп аягыма типте, тезләнергә боеруы иде, ахры. Үзе дә сәҗдәгә оеп, дога укырга кереште.

Шаккатмалы хәл, немецлар тәки доганы ачыклаганнар бит. Дин әһеле чакырып китергәннәр.

Мин әлеге мулланы башка күрмәдем, лагерьда мәхәллә юк иде. Әмма аңа бик рәхмәтлемен.

* * *

Сакчы бер кизәнүдә Җамбулны бәреп екты, дык итеп барып капланды мескенем. Югыйсә, һич тә җинел сөяклеләрдән түгел үзе. Казакъларга хас юантыграк гәүдәле, табак битле, казык кебек җиргә береккән егет. Хәер, дым җитенкерәмәсә, имән булып имән дә корый башлый ич. Бу ашау белән әле дә бирешмибез. Пычкы чүбедәй ниндидер катнашма кушылган бер телем ипи белән бер уҗау кәбестә суы җан сакларга, ихтимал, җитәдер дә, эшләтәләр бит. Унике сәгать аяк өстендә.

—Тор!—дип, немец каеш күсәген тагын уйнатып алды. Мондый очракта

тизрәк эшкә тотынырга кирәк, сакчы шунда гына тынычланачак. Кулдашым күрсен дип чыгыр тәгәрмәчен юри дырылдатыбрак әйләндерәм. Күз кырые белән генә күзәтеп-күзәтеп тә алам. Билгеле, моны Жамбул үзе дә белә, тик баш очында яшен яшьнәп торганда онытылып та китәсең бит ул.

Сакчыларның иң сөймәгәне—әсирләрнең бер-берсенә сүз катуы. Сөйләшү эш дәвамында катгый тыела. Сакчыга моның өчен корал куллану хокукы да бирелгән диделәр. Бездә андый очрак булмады-булуын, тик җилем чыбыгын туйганчы ашаттылар, кимен куймадылар.

Жамбулга да, әлеге дә баягы, шул тел өчен эләкте инде. Күршесенә сүз катканын үзем ишетеп тордым. Эш мәнфәгатьләрендә, югыйсә, сүсе чуалган булган.

Жамбулның теле болай да сөяксез. Исеме җисеменә бик туры килә. “Мин мәшһүр акын Жамбул Жабаевның улы”,—дип йөри. Шыттыра, билгеле. “Исемнәрегез нишләп бер үк соң” дигәч, авызын гына ера. Ә үзе әйбәт егет, ярдәмчел.

Ниһаять, Жамбул торып басты. Бик кыенлык белән генә иелеп, кулына бер учма сүс алды. Аны җепсәгә сарый-сарый мина таба ике-өч адым җир атлады. Сакчы канәгать калды, ахры, кусәген бил каешына асты. Барыбыз да җинел сулап куйдык. Күрмәмешкә салынып кылансак та, һәммәбез бу кыйнашны каш астыннан гына күзәтеп торды ич. Теләктәшлек зур, кул гына кыска, берничек тә булыша алмыйсың. Кысылып кына кара, хәзер маңгаеңа тишек тишәчәкләр.

Немецның җәза машинасы да искиткеч төгәл эшли иде. Концлагерьлардагы крематорийларга, мәсәлән, мәхбүсләрне чишендереп, юындырып-коендырып керткәннәр. Янәсе, исле төтен һаваны бозып, тирә-юньдә яшәүчеләргә кыенлык китермәсен. Гитлер үз халкын да алай бик кызганып тормаган. 1944 елның 20 июлендәге һөҗүмнән соң, мәсәлән, Адольф шашар дәрәҗәгә җитә. Путчта катнашучыларга карата нинди генә җәза уйлап тапмыйлар да, ниндиләрен генә кулланмыйлар. Немец төгәл, тәртипле булу өстенә, гаять дәрәҗәдә хиссез, мокыт зат та бит әле ул. Фәндә, хәтерем ялгышмаса, андыйларны саксофок дип йөртәләр. Алманның бу сыйфаты Чыңгыз Айтматов сурәтләгән манкортны хәтерләтә. Әмер генә булсын, теләсә-нинди җәзаны да салкын канлылык белән җиренә җиткереп башкарырга әзер ул. Әлеге очракта да күренә бу. Баштүбән асып кую, стенага кадаклау, кызган тимер белән тәнгә төрле сурәтләр төшерү, чылбырга тарттыру, җенес әгъзаларына кыршау кидерү—болар гестапо тәкъдим иткән җәза төрләренең бик азы гына. Бу гамәлләрнең бер ишесе гаепләнүчеләрнең иң якын кешеләре: әти-әниләре, хәләл җефетләре, балалары, туганнары алдында эшләнеп, кинотасмага төшерелеп барыла. Сонга таба бер оператор (күрәсең, аның тамырларында ари каны акмаган) әлеге хәлләргә түзә алмыйча, акылыннан яза. Сүз дә юк, немец халкын бер үлчәү белән генә үлчәргә ярамый, төрлесе бар. Әмма ничә еллар шул маньякка табынып яшәделәр ич. Бик оста психолог булган ефрейтор Шикльгрубер. Беренче бөтендөнья сугышында немецларның җирләрен тартып алганнар, алар шушы гаделсезлекне генә төзәтәләр, имеш. Хәер, үзебезнең дә этләрне жизни дип зурлавыбызга кайчан гына соң әле? Коммунизм өрәгенә алдандык. Ә ул Каф тау артында булып чыкты. Хәзер, әнә, базарны мактыйбыз. Янә дә алданмаска иде дә, белмим шул. Яхшы ялган бу ялган, филне йотты бу елан гына булмасмы дип шикләнәм.

Чанам салулап китте, ахры, гафу үтенәм. Нишлисең, башымдагы уйлар аерылып чыккан корт күче сыман мыж килә. Шуңа күрә алга таба да мондый салулауларга юлыкмабыз дип ышандыра алмыйм.

...Жамбул сүс сарый-сарый яныма килеп җитте. “Җон, карале, конвой мине күзәтмиме, үтереп эчәсем килә”,—дип пышылдады. Су мичкәсе минем

станок янында тора, берәмтекләп кенә килеп эчәргә рөхсәт бар. Тик конвой бер каныкса каныга бит ул, шуңа шикләнәдер дустым.

Бернәрсә булмагандай калай көрешкәгә салып, тегенә су бирдем. Голт-голт эчеп тә бетерде.

—Аягымда көчкә басып торам, жон,—диде.

—Тартар теленнән табар, ди, бар, эшендә бул,—дип, аңа сүс бәйләме тоттырдым.

Жамбул дөресендә дә тел бистәсе. Жырга да оста. Ихтимал, акын Жамбаевнын берәр чыбык очыдыр. Жаен чыгарып, авыз эченнән һаман нидер көйләп йөри. Берсендә мина атап жыр чыгарган. Татарчага күчергәндә якынча түбәндәгечәрәк янгырый:

> Минем якын дустым, бик затлы, һай,
> Нәселе татар ыруы,
> Алтын Урда атлы бөек дәүләт, һай,
> Аның мактанычы, жыруы.

—Башына тай типкән ахры синең,—дип, ризасызлыгымны белдердем.

Жамбулның кысык күзләре тегәржеп шикелле генә калды.

—Ә нигә сырт жонынны кабартасын, жон?—диде.—Әллә бер-бер хилаф сүз әйттемме?

—Әйттең шул,—дидем үртәлебрәк,—Алтын Урда бөек дәүләт түгел, вәхши монголлар, илбасарлар оясы. Бу—бер. Икенчесе, Идел буе татарларының килмешәк тар-тарларга да, монголларга да катнашы юк. Без болгар нәселеннән.

—Иштең ишәк чумарын,—диде дустым тире бияләй сыман калын иреннәрен кыйшайтып,—"Идегәй" дастаны белән таныш түгелме әллә син?

Без бәхәсебезне очлый алмадык, аралыкта тикшерүчеләр пәйда булды.

—Ахтунг! Ахтунг!

Гадәттәгечә, ике катлы сәке янында үрә каттык. Киртләч борынлы озын немец кулындагы таягы белән эченә салам тутырылган ятакларны, биштәрләрне пыран-заран китереп йөри, актарып кына ташлый. Мондый эзләнүләргә дә күндек инде, алар көн саен кабатланып тора.Профилактика, янәсе. Сырхауларны иртәнге тезүдә ачыклыйлар. Монысы иң харабы. Турыдан-туры лазаретка алып китәләр. Ләкин лазарет дигәннәреннән берәү дә әйләнеп кайтмый. Шуна күрә әсирләр чирләрен белгертмәс өчен жан тырмашалар.

Жамбул моннан соң да Алтын Урда темасына кагылып-кагылып карады. Мин күз дә ачырмадым. Чөнки монгол-татарларны немецлар шикелле үк кан дошманым дип саный идем. Хаталанганмын. Күптән түгел "Мирас" журналында Равил Фәхретдинов дигән галимнең мәкаләсен укып чыктым. Ул Алтын Урданы татар дәүләте дип тәкрарлый. Бик тәфсилле итеп, ышандырырлык итеп язган.

Әсирлеккә төшәрсең дә, немецларга аркан ишәрсең дисәләр, ул кешене тилегә санаган булыр идем. Тәкъдир дәфтәремә шулай язылган булган, күрәсең, әсирлеккә дә эләктем, аркан да ишәм. Станокта аркан ишү мина таныш иде үзе. Без малай вакытта авылга ике оста килгән иде. Амбар читендәге ташландык ихатада машиналарын корып, җәй буе аркан иштеләр. Бөтен авыл кәмиткә жыелган кебек жыела иде. Бала-чага бигрәк тә мөкиббән. Элек колхозның тәгәрмәчле тракторын чебен шикелле уратып ала идек, хәзер менә кызыграк, янарак шөгыль табылды. Житмәсә, өч-дүрт тавык күкәе бирсәң, пароход куласасы сыман олы чыгыр тәгәрмәчен әйләндерергә дә биреп торалар. Мондый вакытта авызлар колакка житә, күрәсезме, машинаны мин эшләтәм, дип, авылны тутырып кычкырудан чак-чак кына тыеласын.

Ул чакта киндер бик уңа иде. Аны өй борынча тараталар. Кул талкышында талкып, сүсне колхозга тапшырасың. Киндер орлыгын куырып та, он итеп тә ашый идек. Баксаң, хәзерге заманның афәте саналган наркотик та икән ич әле ул киндер. Аны-моны белмәгәнбез. Каен тузыннан сагыз кайната идек, кайбер малайлар мүкне, куян тизәген тәмәке итеп суырыштыргалыйлар иде. Ә наркотик дигән сүзне ишеткәнебез дә юк иде.

Колхоз арканнарны хөкүмәткә тапшырдымы, башка хуҗалыкларга сатты микән, анысыннан хәбәрем юк. Ә мондагылары корабльләр өчен әзерләнә диләр. Хәтерем алдамаса, теге рус агайлары өчтән ишәләр иде арканны. Хуҗалык өчен анысы да бик җиткән, әлбәттә. Без Җанбай белән алтылыны ишәбез. Күршедәгеләр сигезлене. Унлыга, уникелегә көйләнгән станоклар да бар, ди. Сүсе бик сыйфатлы. Чәч шикелле шома, чиста. Тарап җибәргәч тагын да ыспайланып китә.

Станокны әйләндерүгә күп көч сарыф ителә. Шуңа күрә алмаш-тилмәш әйләндерәбез. Җеп сузуның да үз кыенлыклары бар. Бармак битләре суерылып, чи иткә әйләнә. Башта бер кием брезент бияләй биргәннәр иде, бик тиз тетелеп бетте. Ямап-ямап та озакка чыдата алмадык. Җәрәхәткә үлән яфрагы булса да ябарга иде дә, лагерь эчендә көндез чыра яндырып эзләсәң дә үлән кисәге табармын димә. Юл-сукмакларга вак таш, башка буш урыннарга ком сибелгән. Һәр нәрсә күз уңында. Син монда үзеңне шәрә килеш сәхнәгә чыккан кешедәй хис итәсең. Бәдрәфләргә хәтта ишек тә куймаганнар.

Лагерьда көннәр игезәкләр шикелле охшаш. Аларны бер-берсеннән аерып булмый. Минуты-секундына кадәр туры килә. Бер үк вакытта торып басабыз, бер үк вакытта ашыйбыз, бер үк вакытта эшлибез. Зимагурлар җырындагыча: “Таң ата да кояш чыга, өстемдә бер күлмәгем”. Немецлар безне инкубатор чебешләренә әйләндермәкче. Фикерсез, дәгъвасез мәхлуклар. Аларга шулай уңай. Ләкин читтән соры кавем булып күренсәк тә, безнең дә азмы-күпме үз дөньябыз бар. Аралашабыз, кем беләндер дуслашабыз, кемнәрнедер өнәп тә бетермибез. Кайвакыт йодрыклар да уйнаштырып ала. Шулай да дус-ишнең ишле булмавы әйбәтрәк. Монда озын колаклар да шактый. Мин, мәсәлән, серемне ике генә кеше белән уртаклаша алам. Берсе Җамбул булса, икенчесе—Серафим.

Серафим белән без якташлар. Ул Башкортстанның Дүртөйле районында туган. Авылларыбыз арасы алтмыш-җитмеш чакрым чамасы гына. Ә Армиягә Энгельс шәһәреннән алынган. Ничек барып чыккан Идел буена, анысы турында мин төпченеп тормадым, үзе сөйләмәде.

Серафим белән бу көнне башка аралашмадык. Еш кына йокы алдыннан эчен бушатып киткәли торган гадәте бар иде. Иделдә балык тотканнарын бик тәфсилләп сөйли иде. Нишләптер бүген киләсе итмәде, үзем янына барырга ирендем. Ә иртән аны аралыкта бауга асылынган килеш тапканнар. Мин үзем күрмәдем, шулай да әлеге блоктагы кешеләрнең әйтүенә караганда, янында “Хыянәтчеләрне шушы язмыш көтә” дип язылган кәгазь кисәге дә табылган, имеш.

Серафимны соныннан лагерьның шымчысы, чыгышы белән немец булган икән дип сөйләделәр. Гөнаһысына керә алмыйм, әмма Башкортстанда немецлар яшәгәнен белә идем. Энгельс шәһәре исә Идел буе немецларының башкаласы иде. Килеш-килбәте дә туры килә иде мәрхүмнең. Аксыл йөзле, саргылт чәчле, төз гәүдәле.

Серафимның шымчы булуына һич тә ышанасы килми. Бик эчкерсез кеше кебек иде. Тик күңелдә шик тә калды. Әйтик, совет әсиренең фаҗигале үлемен ни өчендер немецлар йөрәкләренә бик якын алдылар шикелле тоелды. Югыйсә, мондый үзара дошманлыкны алар, киресенчә, хуплыйлар гына иде. Шул көнне үк лагерьда тоташ тикшерү үткәрделәр, шәхси әйберләрне

жыеп алдылар. Эштән соңгы тентүләр дә катгыйланды. Монысы аңлашыла да. Чөнки Серафимны үзебез ишкән сүс бау белән буганнар иде.

Ә иртән, барыбызның күз алдында, әлеге секциягә беркетелгән бар әсирне дар агачына астылар. Барысы унбер кеше. Мәетләрен өч көн буе алмадылар. Безне эшкә барганда да, кайткан вакытта да, ашханә юлында да шушы унбер дар агачы яныннан йөрттеләр. Йөрәкләр өзелеп төшәр дәрәҗәгә житә иде. Шунда ук учлар йомарлана, күнел ката, бөтен күзәнәкләр үч, нәфрәт хисе белән тула. Бик авыр кичердем бу фажигане. Ник дисәң, мин Серафимны гына югалтмадым, өченче дар агачында якын дустым Жамбулның гәүдәсе дә чайкалып торды. Бәхетсезлегенә, аның урыны да шул секциядә иде. Үзем дә куркып йөрдем. Серафим белән дуслар булуыбыз күпләргә мәгълүм иде ләбаса. Әләкләүләре дә ихтимал идеич. Менә алып китәрләр, менә алып китәрләр дип, атна буе энә өстендә яшәгәндәй яшәдем.

Юраганым юш та була язды. Беркөнне шулай, арып-талып эштән кайткач, ятагымда йокымсырап утыра идем. Төшләнеп тә алдым. Имеш, ниндидер далада адашып йөрим. Коры. Жир яргаланып беткән. Тирә-якта шайтан таякларыннан кала бер үлән әсәре дә юк. Өттереп кояш кыздыра. Шулай кая сугылырга белмичә торганда, кеше дисәң, кеше түгел, жанвар дисәң, жанварга ошамаган бер гыйфрит ырылдап килеп чыкты да, куып та алып китте. Мин чабам, ул куа, мин чабам, ул куа. Колак төбемдә инде кайнар сулышын тоям. Хәлем дә бик чамалы, мыш-мыш киләм.

—Һальт! Һальт!

Бәрәч, немец солдаты лабаса бу! Кинәт кенә күзләрем ачылып китте. Каршымда, дөрестән дә, фриц басып тора иде. Йөзе усал этнеке шикелле, өскә ыргылыр да, ботарлап ташлар сыман. Бу синең Газраилең инде, Хисам, дусларың янына алып китәргә килгән.

Күлмәк аша гына догамны капшап карадым. Күңелем тынычланып киткәндәй булды, йөрәгем дә урынына утырды кебек.

—Әллааһү ләәәә иләәһә һүү...

Мин, буйсынып, урынымнан торып бастым. Бу сакчыга ошады булса кирәк. Зур сирәк тешләре иреннәрен ерып, алга бүртеп чыкты. Тик икенче мизгелдә дубинкасы кулбашыма ятты. Дулкынга эләккәндәй чайкалып киттем, әмма егылмадым, тигезлегемне саклап калдым. Чөнки беләм, сакчылар йомшаклыгыңны сизеп алсалар, отыры котырыналар.

Дөресен генә әйткәндә, бу минутта мин сакчының суккалавына шат кына идем. Алып китәсе булса, әллә кайчан аралыктан өстерәп чыгарыр иде. Димәк, бу әле соңгы кыңгырау түгел. Дөмбәсләвенә генә ничек тә түзәрмен, тире болай да каешка әйләнде инде.

Сакчы күңеле түгәрәкләнгәнче дубинкасын уйнатты-уйнатты да лыч итеп жир идәнгә төкереп, китеп барды. Тик сөенергә өлгерә алмыйча калдым, борылып килде. Бу юлы дубинкасын түгел, казыктай юан бармагын селкеп:

—Спи нэт, русиш свинья!—диде.

Лагерь тормышы элекке эзенә төште. Дар агачларын вакытлыча алып куйдылар. Кайчан кирәкләре чыгар—бу хакта уйламаска тырышабыз. Әлегә тырыша-тырмаша бөек Германиянең хәрби-диңгез флотына аркан-бау житештерәбез. Немецларның фронтта да эшләре уң барганга охшый, багана башларына кадакланып куелган репродукторлардан көне буе марш яңгырый. Аларны дикторларның көр вә тук тавышы алыштыра. Шунда ук бертуктаусыз ниндидер шау-шулы митингларда катнашучыларның "Һайль Һитлер!" дип акырышулары ишетелеп тора.

Мин ялгыз калдым. Эч поша, йөрәк сыкрана. Яна иптәшләр эзлисе килми. Бу әле куркыныч та. Моңа кадәр дә шымчылар күп иде, Серафим һәлакәтеннән соң аларның саны бермә-бер арткандыр дип исәплим. Чөнки

дуслык тәкъдим итүчеләр ишәйде. Бер кешегә дә иярмим, бер кешегә дә кушылмыйм, бер кеше белән аралашмыйм. Арбага таккач, дегет чиләге йөри бит, мин дә нәкъ шуның кебек инде. Ят дисәләр ятам, тор дисәләр торам, бар дисәләр барам, тукта дисәләр туктыйм. Бернәрсәдә гамем юк.

Немецлар үзләрен югары расадагы халык дип саный. Бу мәсьәлә Гитлер хакимияткә килгәч аеруча куерып китә. Безнең матбугат чаралары да аңа битараф калмады, үз фикерләрен белгертеп тордылар, әлеге теорияне фаш итеп, аның ялган теория булуын тәкрарлап яздылар. Хәтеремдә, техникумда тарих укытучысы расизм темасына реферат язарга кушкан иде. Кызыксынып китеп, төпченеп өйрәнгән идем мин бу теманы. Гобино атлы французның җиңел кулыннан китә әлеге тарихның башы. Ул XIX гасырның беренче яртысында ариларны югары раса дип игълан итә. Әлеге чорда ариларга аксыл чәчле индоевропа халыкларын кертәләр. Башлыча индоиран телләрендә сөйләшүчеләргә карый бу төркем. Нацистлар аны тагын да тарайтып, герман халыкларына гына кайтарып калдыралар.

Болар миңа билгеле иде, әлбәттә. Ләкин...

Яраткан Такташым бик оста рәвештә тотып алган "ләкин"нең бу очракта да файдасы тиде бит әле, каһәр.

Бервакыт лагерь янә корт күче шикелле гөжли башлады. Юк, читтән караганда аны күреп булмый. Ул фәкать борчулы күз карашларында, тел очыннан ычкынган өзек-өзек сүзләрдә, йөз мимикасында, аяк атлауларда гына сизелә. Аны тоемлау өчен әсир булырга кирәк. Барлык мәгълүматны бергә туплап нәтиҗә ясаганда, түбәндәге мәгънә килеп чыга иде: кемдер ишеткән, имеш, лагерьда азиатларның яшерен оешмасын тар-мар иткәннәр. Әлеге оешманың әгъзаларын төн эчендә җыеп алып, газ камераларына ташлаганнар.

Моңа, һичшиксез, ышанырга була. Совет солдаты, нинди генә милләттән булса да, тиз генә бирелә торганнардан түгел. Соңгы сулышына кадәр ватан, туган ил, дип тибә аның йөрәге. Тик әлеге хәл чыннан да була-нитә калса, немецлар аны болай гына үткәреп җибәрмәсләр иде. Икеләтә-өчләтә үчен кайтарырлар иде. Серафим фаҗигасеннән соң, әнә, ничек котырындылар. Димәк, нindидер башка максат белән таратыла бу хәбәр.

Күп тә үтми, шикләнүләрем дөрескә чыкты. "Ләкин"нең төбендә бөтенләй икенче мәгълүмат яткан икән ләбаса! Аны лагерь хуҗалары үзләре тиште.

—Арагызда тагын төрекмәннәр калмадымы?—дип сорады дежур офицер иртәнге тезелү вакытында. Димәк, җыю дигәннәре чыннан да дөреслеккә туры килә. Төрекмәннәрне аерып алганнар. Тик нинди максат белән? Монысы менә табышмак. Хәер, ул озак табышмак булып тормады. Баксаң, төрекмәннәр ари токымыннан икән ич, тамырларында немецларныкы шикелле зәңгәрсу төстәге кан ага, имеш. Төрекмәннәрдән махсус легион төзиләр, ди.

Каюм хан житәкчелегендәге "Төркестан легионы" менә шулай барлыкка килә. Төрекмәннәр 1 нче Көнчыгыш мөселман СС полкында да күпчелекне тәшкил итәләр.

Менә монысы ләкин дисәң дә ләкин.

* * *

Бу арада Хисамның кулыннан эше китебрәк тора әле. Майланмаган арба шикелле шыгыр-шыгыр килә башлады. Сәбәбе, тагын шул Гүзәлия инде. Өченче көн аяз көнгә яшен кебек янына бер егет кәмәше килеп төшмәсенме.

Гүзәлия егетне туп-туры Хисам янына алып керде.

—Таныш бул, бабакай, Төркия гражданины Илһан Мәхмүди,—дип, гадәттәгечә, шаяртыбрак таныштырды.

Хисам югалып калды. Онытын нindидер бер чит егет белән житәкләшкән килеш күрү ничектер оят иде.

—Әссәламегаләйкүм, Хисаметдин бәй,—дип, төрек йөзе кебек үк кара чутыр кулларын сузды.

Күр, ничек жиренә житкереп сәламләгән була, хәчтерүш, мәдрәсә шәкерте диярсең, дип борынын жыерды Хисам. Егетнең итагатьлелеге аның ачуын гына кабартты. Чөнки үзенчә инде ул күптәннән оныгының гаилә язмышын хәл итеп куйган иде. Авылның Кәбир исемле егете менә дигән пар лабаса! Югары белемле укытучы. Нәсел-нәсәбенә тел-теш тидерерлек түгел. Бабасы Таһиржан белән Хисам бергә укыды. Әшнәләр иде. Озак еллар колхозны житәкләде. Мәрхүм инде. Менә шулар белән туганлашу иде исәбе. Сөйләшеп тә йөриләр иде ич. Ул инде күнеленнән яучы көтә иде.

Һәм, менә сина мә!

Хисам үзенә сузылган кулларга теләр-теләмәс кенә орынып алды. Бәлки әле борчыласы да юктыр? Ихтимал, бу төрек дигәннәре үтешли генә сугылгандыр? Сабакташлар шулай бит инде алар, аралашалар... Алай дисәң, нигә житәкләшкәннәр?

—Илһан университетны бер ел алдан бетерде,—дип, Гүзәлия таныштыруын дәвам итте, бабасының ут йотуына игътибар да итмәде.— Мине Төркиягә чакыра...

—Әйе, әйе,—дип егет тә сүзгә кушылып китте.—Гүзәлияне әти-әнием, туганнарым белән очраштырырга телим. Күрсен, карасын, ияләшсен...

—Ни калган анда аңа,—дип, Хисам, ниһаять, ризасызлыгын сиздерәсе итте.—Тиздән мәктәптә укулар башлана, ничу тырай тибеп йөрергә...

—Илһан минем кулымны сорарга килгән бит, бабакай,—дип, серне тулысы белән ачты Гүзәлия.

—Монысы әле танышу, үземне күрсәтү генә, Хисаметдин бәй, кыз сорарга әтием белән әнием киләчәк,—дип егет төгәллек кертте.

Кара гарәп булып арага керде бу чутыр. Кәбирең әйтер идем, жибегән. Менә хәзер борынга бөтереп тыгардай кыздан коры калачаксың инде. Ачык авыз. Кеше Төркиядән килгән, ә син... астындагын алты ай эзләгән нәмәстә...

—Илһан милләте белән татар,—диде Гүзәлия мактангандай,—ата-бабалары Саба ягыннан.

Бу минутта Хисамга яравы авыр иде. Һәр сүз аның йөрәгенә ук булып кадала. Йә, хуш, татар булсын, ди, Саба ягыннан булсын, ди. Шуннан? Бик ачуын кабартсагыз, урлатырга да күп сорамас. Кыз урлау бабаларыбыздан килгән гореф-гадәт, бер гаебе дә юк.

Хисам аптырашта иде. Ник дисәң, аның сүзе генә түгел бит әле монда, Гүзәлиянең әти-әнисе ничек хәл итәр?

Әйтәсен әйттеләр дә, язгы чыпчыклар шикелле чырык-чырык көлешеп чыгып та йөгерделәр. Күзләренә ак-кара күренми, чистый шатлык баскан. Күккә сикерерләр иде, шат.

Хисам шактый ара кәгазьләренә текәлеп утырды. Ул көчсез иде. Яшьләр инде барысын да үзләренчә хәл итеп куйган. Аның бердән-бер юанычы башыннан үткәннәрне хәтер жебенә теркәү. Моны ул, шөкер, булдыра әле.

ӨЧЕНЧЕ ТАСМА

### Кол

Бу дөньяда шаккатмалы хәлләр булып кына тора. Мин үзем шәхсән могжизаларның барлыгына тәмам ышандым. Соңгы ярты елда гына да ниләргә генә тарымадым. Ә монысы бөтенләй һуш китмәле. Менә мин, әсир Хисам Сабиров, ямь-яшел ялан уртасында басып торам. Күктә кояш балкый, аның кайнар нурлары битемне, күзләремне,

авыз-борынымны иркәли. Рәхәт. Утырасым килсә, утырам, ятасым килсә, сузылып ятам. Дөрес, монда да мәйдан тимерчыбык белән әйләндереп алынган. Ләкин ул чәнечкеле түгел. Бу—кишәрлек. Терлек кишәрлеге. Немецлар малларны көтүгә кумый. Сугарулы, бөтен унайлыклары булган көтүлекләрдә йөртәләр. Савым сыерларны гомумән абзарда гына тоталар, билгеле бер рацион белән генә ашаталар. Шуңа күрә сөтне дә күп савалар. Бу системаның кайбер элементлары безгә җитмешенче елларда гына килеп житте. Ләкин көтүдән барыбер арына алмадык. Ул һаман табигатькә зур зыян салучы афәт булып кала бирә. Шуның аркасында күпме әрәмәлекләрнең, тугайлыкларның, болыннарның башына җиттек. Күпме чишмәнең күзен томаладык. Пычранган сулыкларның чуты-чамасы юк.

Тукта-тукта, сабыр, ничек соң әле әсир башың белән ошбу хозурлыкка тап булдың, син төш күрергә бик маһир кеше, бәлки, чираттагы төшләнүең генәдер, дип йөз чытулары да бар. Менә, күр, кулларымны, битләремне чеметкәләп карыйм—авырта. Димәк, төшләнмим. Өн бу, өн!

Әйе, мин хәзер мал караучы. Искечә әйтсәк, батрак, кол. Ә ул болайрак килеп чыкты.

Беркөнне төштән соң мине комендатурага алып килделәр. Монда андый хәлләр булгалап тора. Йә нәсел-нәсәбеңне тикшерәләр, йә командирларың белән кызыксыналар. Немецлар мәгълүмат туплауга зур әһәмият бирә. Һәр адымыңны документлаштырып баралар. Бу юлы да шундыерак әңгәмә булыр дип чамалаган идем. Мине исә ниндидер штатски кеше янына керттеләр.

—Танышыйк, мин фермер, исемем Курт,—дип кулын сузды теге. Үзе ашардай булып мине күзәтә. Әйтерсең лә, базарда мал сайлый. Хәтта яныма килеп, җилкәләремне селкеткәләп тә карады. Куллары каты иде фермерның, көчле. Миннән дә риза калды, күрәсең, озынга сузмыйча ниятен дә җиткерде.

—Мин офицер галиҗәнаплары ашханәсен тана ите белән тәэмин итеп торам. Шуңа күрә белемле, таза, яшь караучы кирәк,—диде.—Монда ветеринарлар берничә икән. Синең кандидатураңа тукталдым. Вазифаларыңны җиренә җиткереп башкармасаң, кире китереп тапшырачакмын. Комендатура каршында синең өчен җавап тотам. Шунлыктан, ышанычымны яулаганчы үзеңне овчарка саклаячак. Качарга-нитәргә омтылсаң, ул бугазыңны чәйнәп өзәчәк. Өйрәтелгән.

Дер калтырап киттем. Аh, ул немец этләре! Лагерьның өчтән бере шул аяусыз, котсыз этләрдән тора ич. Тешләренә эләгергә Ходай күрсәтмәсен.

—Мина татар милләтеннән булуың ошады, сине сайлавымның төп сәбәбе шул,—диде фермер,—эшчән һәм тыңлаучан халык ул татар. Бөек фюрерга хезмәт итү безнең барыбыз өчен дә олы дәрәҗә.

Озын торыклы илле яшьләрдәге бу кешенең башы тавык күкәе шикелле тап-такыр. Йөнтәс кашларына, сирәк керфекләренә караганда, чәчләре аксыл төстә булгандыр, мөгаен. Күзләре әле дә зәңгәрлеген җуймаган. Шулай да ул немец затыннан түгел иде. Карауга чамалап алдым. Немецлардан аерып тора торган ниндидер юнылмаган тупас җире бар иде аның. Алан-йолан карана, гәүдәсе дә бил бөгәргә җайлашкан сыман. Ә немецлар төзгә каткан, аларда мин-минлек әллә каян бәреп тора.

—Татарлардан хезмәтчеләрегез бар идеме әллә?—дип сорадым.

Бу сорау яна танышыма ни өчендер ошап җитмәде, иреннәре кысылып, йөзенә җитди төс кунды. Ачуланып нидер әйтергә теләгән иде дә, ләкин бу уеннан кире кайтты, акыл өйрәтүне мәгъкульрәк күрде, ахры.

—Минем шикелле акыллылык күрсәтсәң, үзең дә шундый иркенлекләргә ирешерсең,—диде. Бу сүзләрнең мәгънәсен тора-бара гына аңладым.

Шулай итеп, үз һөнәрем буенча эшли башладым. Урыным мал-туар янында. Келәт өше биек түбәле бер корылмада йоклыйм. Хуҗаның монда бөтен иске-москысы саклана икән. Шулай да, караватн куярга да, өстәл-тумбочкага да урын табылды. Хәтта кием шкафы да бирделәр.

Өстемдә утыз тана. Һәрберсен көнгә бер мәртәбә җылы су белән сабынлап юам, чистартам. Шөкер, суга кытлык юк, торбадан гына килә. Тизәкләрен минутында-секундында махсус савытка җыеп барам. Үлән өстендә тизәк күрсә, хуҗа бүртенеп чыга. Бу шакшы Россия түгел, дип орыша башлый.

Курт үзе дә эштән чирканмый. Иртәдән кичкә чаклы җиңнәре сызганулы. Күлмәкчеләр тота. Асравы да бар. Асрау йорт эшләре белән мәшгуль. Хатыны гына бер шөгыльгә дә кысылмый. Үзе чибәр генә. Тик нигәдер башында һәрвакыт кара яулык.

Якшәмбе көнне Куртлар ял итә. Иртәнге якта парлашып чиркәүгә барып кайталар. Машина белән кемдер алып китә, китереп куя. Бәйрәм табынын пешекче чакыртып хәзерләттерәләр. Табак битле, күмер кабыдай капкорсаклы юан абзый килә. Бишекле мотоциклы көч-хәл белән өстери үзен.

Кичке якта аш-суны асрау террасага чыгара. Хуҗа монда, ни сәбәпледер, бәйрәмне ялгызы гына дәвам итә, озын өстәл башында берүзе генә утыра. Дөрес, ул баштарак: "Маргарита, Маргарита",—дип фрауны чакырып-чакырып карый. Тегесе барыбер башын-күзен күрсәтми. Иренең бу гадәтен өнәп бетермидер, ахры. Ә бераздан Курт яшелле-зәңгәрле тавыш чыгарып, җырлый башлый. Җыр дигәч тә, ашалган патефон тәлинкәсен әйләндергәндәй ул аның тик бер строфасын гына кабатлый:

Иһ, Йомага һогодок...

Ничек рус җырын җырларга җөрьәт итә ул, һич башыма сыймый. Рус милләтеннәнме икән әллә бу, дип тә уйлап куйдым. Ник дисәң, әлегә кадәр мин аны латышка охшатып йөри идем. Акценты нәкъ шуларныкы шикелле иде. "Их, Самара городок" җырын фәкать Балтыйк буенда гына шушы хәлгә төшереп, имгәтеп җырларга мөмкиннәр.

Сер көтмәгәндә ачылды. Чираттагы җомгада хуҗа белән бергәләшеп таналарның сәламәтлеген тикшереп бактык. Тоякларын, тешләрен, борыннарын, җиленнәрен, койрыкларын энә күзеннән үткәргәндәй үткәрдек. Риза калды. Маллар көр, кәефләре шәп иде, уйнаклап кына торалар.

—Туган якта да малчылык белән шөгыльләнергә уйлыйм,—диде ул,—анда җир күп, теләгәнчә җәелергә шарт бар.

—Сезнең туган ягыгыз кайда соң?

—Самарадан...

—Ничек?..

Тотлыгып калдым. Беренчедән, төпченүем хуҗага ошамаска мөмкин. Артык кызыксынуны өнәмиләр монда, үзара да бик сак сөйләшәләр. Икенчедән, кол сорау юлларга тиеш түгел, хокукы юк. Ләкин хуҗаның кәефле чагы иде булса кирәк, чыраен сытмады, тел төбемне кыяфәтемнән аңлап алды.

—1914 елгы сугыш әсире мин,—диде.—Рәхмәт немецларга, какмадылар-сукмадылар, үз гаиләләренә алдылар. Инде менә Көнчыгыш колониядән җир бирергә ниятләп торалар. Чөнки минем улым шул фронтта һәлак булды (менә ни өчен фрау Маргаританың башында кара яулык икән). Алла кушса, быел кышка Рус кампаниясе тәгәлләнер дип өметләнәбез.

Күр, болар инде безнең илне бүлгәләп тә бетергәннәр икән. Шушы

сатлыгына кадәр җир өмет итә ич. И, фашист ләнкәсе! Ачуым кабарды. Тик бу мәгънәсез ачу иде. Аны эченә яшерү хәерлерәк.

—Минем поп кушкан исемем Кирилл,—дип дәвам итте сүзен хуҗа. Кирилл Акимович Смирнов. Хатыным Маргарита чын ари, саф канлы немка.

Шөкер, эчемдә нинди өермә купканын хуҗа сизмәде. Бу һич тә минем файдага түгел иде. Сизүе, дим. Акрынлап мөнәсәбәтләр җайга салынды. Белемемне, тырышлыгымны да күреп-белеп торадыр, әлбәттә. Бу араларда лагерьга кире кайтару хакында да сүз чыгарганы юк. Баштарак адым саен шул янаулары белән җанга тия иде.

Әйе, хуҗа белән ботка пешәргә охшый. Ләкин эте собакының собакысы мәгәр. Ул мине беренче көннән үк дошман күрде. Шуннан соң тамчы да үзгәрмәде гыйфрит. Күзе-башы тонган. Иманым камил, өскә ташланырга сәбәп кенә көтә. Ул моны олы бер канәгатьләнү белән башкарыр иде. Миңа калса, әлегә шул сәбәп юклыкка үзен-үзе ашар чиккә җитеп изалана бу канэчкеч. Әйдә, изалансын, аек баштан андый мөмкинлек бирмәячәкмен.

Әлбәттә, моны әйтүе генә ансат. Ул бит бәйдә түгел, һәрвакыт янымда, бәдрәфкә дә бергә йөрибез. Аяк очында йоклый. Кем өйрәткән аны, ничек өйрәткән—ис китмәле хәл. Хак гамәлне хилаф гамәлдән кешеләр дә аерып бетерә алмый ич. Бу аера, зөбани.

Уйлана торгач, әлеге хәлнең төбенә төшендем тәки. Әлеге дә баягы, ветеринарлыгым булышты. Безгә техникумда кайбер хайваннарны, бигрәк тә этләрне, билгеле бер җирлеккә күнектерү буенча тәҗрибәләр үткәрелү хакында сөйләгәннәр иде. Алар әлеге мәйданга шулай нык ияләшәләр икән ки, аннан хуҗадан башка берәүне дә чыгармыйлар, берәүне дә кертмиләр, ди. Бу нәкъ менә шундый очрак иде. Мин бит качарга җыенмыйм, димәк, Смирновның утары эчендә миңа куркыныч янамый. Шушы ачышымнан соң үземне тынычрак, иркенрәк хис итә башладым. Бүре кадәре бинаһая зур эт тә алай ук куркыныч булып күренми иде инде. Ышанычымны яулаганчы гына дигән иде ич хуҗа да, бәлкем, сакны бөтенләй алыр да әле.

Әнә, маэмай әле дә миннән күзен алмый. Мәрхәмәтсезлектән бигрәк, бу юлы аның карашында сүз белән анлатып булмый торган сагыш чаткылары шәйләнде сыман. Гүя, үз бурычымны башкарырга бер генә мәртәбә булса да җай чыгар инде, егет, дип ялына кебек тоелды. Юк, алабай, нәфесеңне сузма, үпкәләмә дә, минем яшисем килә. Беләсеңме, унтугызым гына тулып килә бит әле. Җанып-көеп кызлар да сөйгәнем юк. Техникумда чагында иң мөһиме уку инде. Рөхсәт тә итмәделәр. Аннан соң сугыш башланды. Укытучы Рабигә бик ошаган иде дә, фронт итәгеннән ычкындырмады. Хәзер аның хакында хыяллану да мәгънәсезлек инде. Сугыш бетеп, исән-сау күрешү насыйп булган очракта да укытучы кыз әсирне түгел, күкрәк тутырып орден-медаль тагып кайткан башка бер лаеклы офицерны сайлаячак. Әгәр сайламаган булса?

* * *

Гүзәлия егетенә Уфаны күрсәтеп кайтты. "Метеор" белән бардылар. Төрек татарына сәфәр бик ошаган. "Агыйдел Мирсәй Әмир сурәтләгәнгә караганда да матуррак икән",—дигән була. Хисам Сабирны да онытмаганнар, бүләк итеп яңа диктофон алганнар. Японда эшләнгән ди. Уч төбенә сыярлык бик унайлы нәмәстә. Искесенең микрофонын кулга тотып сөйләргә кирәк иде. Японныкының ул әйбере эченә беркетелгән, имеш. Бүлмә буенча йөри-йөри дә яздырырга була икән. Теләсәң—яланга

чык, Сөн буена төшеп кит. Кыскасы, йомшартмакчылар. Үзләренә күрә салпы якка салам кыстырулары. "Ялгышасыз, гөмбәчекләрем, сез тимер булсагыз, мин күмер",—дип авыз чите белән генә елмаеп йөри Хисам.

Илһам да Илһан гына түгел, теләгән вакытта гына чакырып китерермен димә. Япон диктофоны да урыныннан кузгата алмас. Гүзәлиянең Төркиягә ашкынуын да исәпкә алмый ул. Мин киткәнче, бетер, имеш. Анысы Алла кулында шул, бәбкәм. Язучылык бик четерекле шөгыль икән. Язучы булып туарга кирәк дип бик дөрес әйтәләр.

Шулай дигәннән, күптән түгел бер журналда укыган вакыйга исенә төште. ВКП(б) Үзәк Комитетының мәдәният бүлеге мөдире: "Язучылар эчәләр, бер-берсе өстеннән шикаятьләр язышалар, тынышмыйлар, әхлаксызлар",—дип Сталинга зарланып утыра, имеш. Иосиф Виссарионович ярдәмчесенең сүзен ярты юлда бүлеп, әйткән мона:

—Минем башка язучыларым юк, иптәш Поликарпов, сезгә булганнары белән эшләргә туры килер,—дигән.

Менә шулай, кызым, мин дә син ашыктыра дип кенә башка кеше була алмыйм инде. Шушылай җай гына барса, бик шәп булыр иде әле.

Аннан китереп, кызым, синен үзеннен дә язмышын хәл ителеп бетмәгән бит әле. Әлегә ул кыл өстендә. Бабаннын урлау ниятеннән кайтканы юк. Төреген буш кул белән үзе генә табанын ялтырайтмагае.

* * *

Көннәрдән бер көнне йокыдан ниндидер сәерсенү хисе белән уяндым. Нәрсәдер булган, нәрсәдер житми кебек. Кулларым, гадәттәгечә, догама үрелде, әллә төшереп калдырдыммы? Йөрәгем тыпырчынып алды. Урынында. Алайса ни-нәрсә житми сон? Эзләнәм, капшанам, борсаланам. Бераздан гына төшендем: эт күренми ләбаса! Сакчымны алганнар икән ич. Әллә ничек кыен булып китте. Чын. Өйрәнелгән иде бит. Маллар янында хужадан да сорасы иттем. Ә анын башы үз чүбеге белән тулган.

—Бүген бер тананы суябыз, илтешергә сине дә алып барам,—диде, минем кызыксынуымны бар дип тә белмәде. Сак шул унайдан вакытлыча гына алынганмы, бөтенләйгәме—анламадым.

Хужа офицерларга дигән малны үзе суя, берәүгә дә ышанып тапшырмый. Ярдәмчеләре бар, билгеле. Алар тотышып, су биреп, пычак кайрап кына торалар. Башта электр тогына тоташтырып, малнын исен алалар, тана ярты үле хәлгә килгәч кенә бугазына пычак салалар. Мин бу эштә берничә мәртәбә катнаштым инде. Күреп торам, Смирнов мал-туар асраунын бөтен нечкәлекләрен үзләштергән чын профессионал. Анын утары һәрвакыт тулы. Бер кишәрлектә бозаулар, икенчесендә—таналар. Сыер асрамый, сөтне сатып ала. Ә бозауларны үзе шикелле фермер китерә. Эше конвейр дәрәҗәсендә жайлашкан.

Кассап күп булса, хайван мордар китәр, ди. Тыгылма дип әйтсә әйтер, мин дә малчы лабаса, кассап.

—Электр тогы зур ит комбинатлары шартларында үзен акласа да, малны берәмтекләп суйганда ата-бабадан килгән, сыналган ысул отышлырак,— дип, үз фикеремне белгерттем.—Ите күпкә тәмлерәк була. Кулга күп нәрсә бәйле. Курыккан малның каны кача.

Смирновнын аксыл кашлары жыерылып мангаена менде. Мина сынабрак, ышанмыйчарак карап торды. Ләкин бу караштa кызыксыну, тәвәккәллек күбрәк иде кебек.

—Жә, алайса, күрсәт осталыгынны,—дип пычагын сузды.

Мин моны көтмәгән идем, каушабрак калдым. Тик әлеге форсатны һич

тә кулдан ычкындырырга ярамый, әшне әйбәт башкарып чыккан очракта, бу абруемны гына күтәрәчәк.

—Астына салырга бераз чиста коры салам кирәк булыр,—дидем.

Тананы тышаулап булышкан арада түшәмлекне алып та килделәр. Элек андый йомышларга мине йөгертәләр иде. Хәзер кулда пычак, статус күтәрелде, әйдә, башкалар теркелдәсен.

Күзләр миндә: бура чаклы бу тананы токсыз ничек егар икән дә, ничек чалыр икән дип гаҗәпсенеп карап торалар. Беләм, аз гына хаталансам да, Смирнов мине читкә тибеп, пычагымны үз кулына алачак. Мин үзем дә мал суеп йөргән кеше түгел. Авылда да андыйлар санаулы гына. Практикам юк чамасы, әйе, аның урынына теориясеннән шактый хәбәрдар. Тананы гына түгел, зур-зур нәсел үгезләрен дә бер селтәнүдә егып була. Көенә китереп аякларын бәйли белергә дә, бауны тарта белергә генә кирәк. Архимед та әйткән ди ич: "Таяну ноктасын гына бирегез, мин Җир шарын да күтәрә алам",—дигән, имеш. Бу да нәкъ шуның кебек.

—Тана егылуга өстенә ятып, мөгезеннән эләктерегез,—дип, янә әмеремне бирдем. Хуҗага әйләндем тәки.

Ни хикмәт, барысы да тәгаенләгәнчә барып чыкты. Эчемнән генә бисмилла укып, пычакны тананың бугазына ышкыдым...

Тунавын хуҗа белән бергә тунадык. Түшкәне ул ваклады. Бу үзе бер һөнәр.

Тагын ярты сәгатьтән без юлда идек инде. Машина тәрәзәсеннән тирә-якны күзәтеп барам. Шар тәгәрәтерлек шома юл. Як-якта җепкә сузылгандай тип-тигез булып яшел куаклар сузыла. Әледән-әле Смирновныкы шикелле хуторлар очрый. Барысы да шундый ук пөхтә, ыспай, мәһабәт. Сугыш немец халкына бернинди зыян салмаган. Гомумән, монда сугыш турында житди уйламыйлар да, ахры. Әнә, Смирнов та кышка кадәр Рус кампаниясе тәгәлләнәчәк дип ышанып тора, чын-чынлап Идел буенда алпавыт утары булдыру хакында хыяллана. Улының үлемен фюрер, Бөек Германия хакына гадел үлем дип саный. Шуның белән горурлана.

Мин дошман тылындагы разведчик сыман юл күрсәткечләрендәге язу-исемнәрне дикъкать белән күзәтеп барам, күңелемә сеңдерергә тырышам. Чөнки шушы вакытка кадәр үземнең кайдалыгымны белмим ич әле. Бәлкем, бу кала нинди дә булса ачыклык кертер?

Алда оеш-оеш биналар калкып чыкты. Күрәсең, тиздән шәһәргә килеп керәчәкбез. Тәрәзәгә тагын да якынрак елыштым. Тәрәзә дигәнем машинаның брезент япмасына уелган уч төбеннән аз гына зуррак ачыклык. Унайсыз. Торак пункт исеме язылган бер мәгълүмат тактасын узып киттек инде, әнә. Сүзе шактый озын иде, укып бетерә алмадым. "Һей" дигәннән соң төртелеп калдым. Алар әле кабатланырга тиеш. Өмет шунда. Дөрестән дә, бераздан тагын зәңгәр тактага юлыктык. Монысында укуны ничек тә "һей"дән соңгы иҗектән башларга кирәк. Чит тел бит, тиз генә төшенә дә алмыйсың. Тәки булдырдым бит: "...н-ха... енха-ген... енхаген. Һейенхаген! Исем дисәң дә исем, ыштыр буе. Тик мондый исемне йөрткән шәһәр Германиянең кайсы төбәгендә урнашкан икән соң? Хәзер шуны ачыклыйсы калды.

Уйламаганда, немец үзе ярдәмгә килде. Шул тәгәллеге инде. Каршыда "Hach Берлин—110 km" дигән язулы зур такта пәйда булды. Монысы мина таныш. Харьков янында "Hach Moskou" дигән юл күрсәткечләрен күргәләгән идем. Димәк, Һейенхаген каласыннан Берлинга нибары йөз ун чакрым. Фашистларның оясына китереп түккәннәр икән. Әллә мине дә Смирнов язмышы көтәме, шайтан алгыры. Мин дә аның кебек "Иһ, Йомага һогодох" дип, террасада сагышланып җырлап утырырмын микән? Хәер, татар җырын сузармындыр, мөгаен: "Һаг угман шаглый..."

Машина йөрешен акрынайтты, аннан соң тормозларын сызгыртып, бөтенләй туктап калды. Полиция посты. Смирновның документларын тикшерделәр, ахры, аның: "Битте, битте", дигән сүзләре ишетелеп торды. Кузовны да ачып карадылар. Мина аны-моны әйтүче булмады, барысы да тәртиптә иде, күрәсең.

Һейенхаген безнең Алабуга кебегрәк шәһәр икән. Ләкин ул Кама буендагы сәүдәгәрләр каласына бөртек тә охшамаган. Корылмаларның һәммәсе таштан. Алар кош оялары шикелле бер төбәккәрәк оешып утыралар. Ук шикелле очлы манаралы биек чиркәү гүя шәһәрне кочагына алган. Ул үзәктә, калган бинаалар шул чиркәүгә сыенган. Чиркәү тәрәзәләренең зурлыгына исең китәрлек. Тоташ витражлар. Челтәрләр... Гөлт иткән. Минем мондый купшы, мондый зиннәтле бинаны күргәнем юк иде әле.

Ыспайлыклары, матурлыклары белән игътибарны җәлеп иткән бинаалар монда күп очрады.

Һейенхагенның борынгылыгы һәрдаим күзгә бәрелеп тора иде. Готика, ренессанс, хәтта роман культураларына караган корылмалар да бар икән. Ул чакта, билгеле, мин готикасын да, романын да, ренессансын да юньлебашлы белми идем. Архитектура минем өчен каты чикләвек иде. Дөрес, хәзер дә мактана алмыйм. Сонрак, инде Совет хакимияте тарафыннан сөргенгә сөрелгәч, күпмедер вакыт Коган атлы бер яһүд профессоры, күренекле архитектор белән урыннарыбыз янәшә туры килгән иде. Аңа белгечлеге буенча журналлар укырга рөхсәт итәләр иде. Бераздан аерым бүлмәгә чыгарып, нинди дер проектлар да эшләттеләр үзеннән. Әлеге журналларны мин дә актарыштыра идем. Азмы-күпме башыма кереп калган.

—Һейенхаген борынгы культуралар очрашкан уникаль кала ул,—дигән иде Коган.

Хәзер шулар хәтеремә төшә дә, үземчә анализ ясыйм. Теге, шәһәрне колачына алып утырган биек чиркәү готика чорында төзелгән икән, дим. XII—XV гасырларда Көнбатыш һәм Үзәк Европада Аллаһ йортларын—культ корылмаларын шулай купшы итеп төзегәннәр. Архитектура фәне нигездә аларга хезмәт иткән.

Шәһәрдә, без барып туктаган җирдә, бакча эченнән обсерваториягә охшаш гөмбәзле бина калкып күренеп тора иде. Гөмбәзе тавык йомыркасыдай, бер җөе юк. Бизәкләре гөмбәз каркасына утыртылган урыннан башлана. Монда барысы да ярымтүгәрәк рәвешендә эшләнгән: тәрәзәләр дә, баскычлар да, бина үзе дә. Ә зиннәтле балкон челтәрле колонналар өстенә кунаклаган. Ихтимал, бу бина ренессанс архитектурасының үрнәге саналган мәшһүр Брамантеның Римдагы Темпьетто кәшәнәсеннән калышадыр да, ләкин аңа карап кына кыйммәте кимеми, дип беләм. Кызганыч, союзниклар Һейенхагенны бик нык бомбага тоттылар, җир белән тигезләделәр. Бер селтәнүдә роман культурасы да, готика һәм ренессанс та юкка чыкты. Ачуым килмәгәе, кешедән дә єрткычрак хайван бармыни соң бу дөньяда?

Гафу, тагын салулап киттем. Без офицерлар ашханәсенә тана түшкәсе илтә идек түгелме?

Машинабызны тоткарламыйча гына тимер капка аша ишек алдына уздырып җибәрделәр. Смирнов монда үз кеше иде. Итне ошаттылар. Аны ошатмаган кеше җүләр булыр иде. Шикәр кебек шыгырдап торган туч ит. Рацион шулай оста төзелгән ки, тана май исәбенә түгел, сум ит исәбенә авырлык җыя. Деликатес. Офицер әфәнделәр тәмле тамакка әйләнеп беткән. Ә монысы башка. Чагыштыргысыз. Ник дисәң, бисмилла әйтеп суелган тана ите. Мөселман кулында тонган. Сизүен сизмәсләр инде, әлбәттә, шулай

да кызык, әйтсәң нишләрләр иде икән? Смирнов маладис, тәвәккәлләде бит тәки. Хәер, татарның мал-туар арасында алыштыргысыз булуын чамалаганга күрә дә мине сайлап алды ич инде. Шуңа күрә пычакны да ышанып тоттырды. Сатучы өчен иң мөһиме—сыйфатлы ит. Шул чакта гына кулланучы канәгать калачак. Офицерлар ашханәсе һәркемгә тәтеми. Ул—ышанычлы һәм дәрәҗәле клиент.

Түшкәне тапшырып, кайтыр юлга чыктык. Смирновның авызы колагында. Сәмәнне мулдан тамыздылар, ахры. Бераз күңел ачып алырга да исәпләде бугай, машинабыз сыраханә янына барып туктады. Һич көтмәгәндә, хуҗа мине дә үзе белән сыраханәгә алып керде. Башкалар шикелле без дә озын аяклы түгәрәк таш өстәл янына килеп бастык. Боларда сыраны китереп бирәләр икән. Ресторандагы шикелле. Көттермичә генә официант ханым килеп җитте.

—О-о, Курт,—дип авызындагы бар тешләрен күрсәтеп елмайды. Смирнов зур учлары белән аның артына үрелгән иде дә, тегесе бик тиз туктатты.

—Ярамый, мин эштә,—диде.

Миндә башка кайгы, тирә-якка күз атам, нинди икән ул кәеф-сафа коручы немецлар? Әнә, аргы башта бер солдат кызын почмакка кыскан, дөньяларын онытып, назланышалар. Өлкәнрәк яшьтәге ике агайның үз хәлләре хәл, болары кызып-кызып ни турындадыр бәхәсләшә. Алларында карта. Димәк, фронт кызыксындыра. Залда тәмәке төтенедәй тоташ гүләү асылынып тора. Совет офицеры, рус әсире шул манзараны тыныч кына күзәтә.

—Битте, битте!..

Официант сыра алып килгән икән. Смирнов янә кул уйнатмак булды, тик апабыз ирек куймады. Эш кагыйдәләре дөрестән дә катгый иде, күрәсең.

Без бер-ике йотым да сыра эчәргә өлгермәдек, репродуктордан марш яңгыры сибелә башлады. Залдагылар, шөгыльләреннән арынып, барысы да үрә катты. Шунда ук "Һайль Һитлер!" дигән өндәмә яңгырады.

—Һайль!!!—дип, зал бер сулышта җавап кайтарды.

Тамаша тынар-тынмаста өстәлебез янына уң аягының чалбар балагын бил каешына кыстырган култык таяклы бер солдат килеп туктады да изүемнән эләктереп алды. Гәүдәсе калтырана, күзләре зәһәрләнеп яна. Юка, усал иреннәре арасыннан елан агуыдай үтергеч сүзләре сыгылып чыкты:

—Әй, син, колга, ни өчен фюрерны сәламләмәдең?

Бу миңа карата чыгарылган хөкем карары иде. Карап торган, паразит. Әгәр ул совет офицеры, әсир икәнемне дә белеп алса, котылу юк. Вәйт каптым. Өстәвенә, тел ягы чамалы. Аңласам да, дулкынланган вакытта кайтарып әйтүләре мең бәла. Язмышым энә очында асылынып калды. Смирнов үзен ут астына куеп, мине якламаячак. Инвалид солдатның ачуы исә мең кешегә җитәрлек. Өметем тәмам киселде. Урам суды ясарлармы, патруль чакыртырлармы? Эчемнән генә догамны кабатлыйм:

—Әллаһү ләәәә иләәһә илләә һүү...

Ярдәм уйламаган яктан килде. Һич көтмәгәндә официант хатын солдатны миннән суырып алды да чәтелдәргә тотынды.

—Аһ, син, әлкәш, көн саен дебош куптарасың, клиентларга бәйләнәсең. Полициягә тотып биргәнне көтәсеңме? Яхшы чакта, ычкын моннан. Мин аның фюрерны сәламләвен үзем күреп тордым. Бөтен кеше күреп торды. Шулаймы, егетләр?

—Әйе, әйе, сәламләде...

Халык официантны хуплады. Солдат хурга калды.

—Әйдә, киттек,—дип пышылдады Смирнов.

—Минем кемлегемне официант ханым белә идеме?—дип сорадым кайткач.

—Юк,—диде Курт,—мин сине аңа әпә дидем. Монда телсез, гарип-горабалар күңлекче булып яллана. Бәхетең, чәчең алманнарныкы шикелле аксыл.

—Мин фрауга бик рәхмәтлемен.

—Чын хәлне белсә, күрсәтер иде ул сиңа рәхмәтне.

—Сезгә инде рәхмәтнең иң зурысы...

Смирновка бу төпченүләрем ошамады, ахры, әйбәт кенә сөйләшеп торганда йөз сиксән градуска борылды да куйды.

—Ни пычагыма миңа синең рәхмәтең, һундук!—дип чекрәйде.—Бел, син хәзер Бөек Германиядә яшисең. Фюрер синең өчен дә фюрер. Аңладыңмы, һундук?

—Аңладым!

Шушы сүзне әйттем дә уйга калдым: мин чыннан да Гитлерны сәламли алыр идемме икән? Мөгаен, юктыр... Ә яшәү белән үлем арасында калганда? Хәер, өздереп кенә әйтүе дә җиңел түгел икән әле.

—Бар, эшеңдә бул,—дип акырды хуҗа. Бу мокыт алдында артыграк чишелеп ташладым, йомшаклык күрсәттем дип уйлады, күрәсең.

Мин эшне бетереп кергәндә караңгы төшкән иде инде. Арылган. Аягөсте генә ашап-эчеп алдым да юрган астына кердем. Саксыз гына йокладым. Этне бөтенләйгә алулары иде булса кирәк.

ДҮРТЕНЧЕ ТАСМА

## Мәгъшука

Көз монда бездәгедән күпкә соңрак килә. Минем исәп буенча хәзер үктәбрнең урталары булырга тиеш, ә кояш һаман җылы нурлары белән җирне иркәли әле. Көннәр матур. Дөрес, урман инде акрынлап саргылт төскә керә башлады. Кырлар да бушап калды. Ара-тирә җылы якларга очып баручы торналар төркеме генә бу бушлыкка җан өрә.

—Торрыйк-торрыйк...

Туган ил, туган яклар искә төшеп, күңелне сагыш баса, йөрәк алгысына. Кайчан да берәр кайтып күрү насыйп булыр микәнямьле Сөн буйларын? Ничек икән анда тормышлар? Минем хакта ни уйлыйлар икән? Хәбәр килмәгәч, кайгыралардыр инде. Әткәй-әнкәй, бик бирешмәгез, улыгыз исән-сау. Ходай кушып, күрешергә генә язсын. Мин дә бик сагындым сезне...

Уйларымны бүлеп, колак төбемдә "Һинде hoh, Сталин капут!"—дигән әче тавыш яңгырады. Шул ук мизгелдә бөтен гәүдәм белән тавыш килгән якка борылдым. Бу хәрби алым, куркыныч янаган якка йөзне куярга училищеда өйрәттеләр. Кулымда мылтыгым гына юк, тәтесенә баскан да булыр идем, шәт.

Ничек борылсам, шул халәттә катып та калдым. Чөнки каршымда уң кулының бармакларын пистолет рәвешенә кертеп тырпайткан бер яшь кыз басып тора иде. Ак маңгаена төшкән бөдрә чәчләре арасыннан кыргый мәченекедәй усал күзләре ялт-йолт килә. Тешләре юка иреннәрен ерып алга чыккан. Нәкъ Ильф белән Петров сурәтләгән Эльза людоедка.

—Һинде hoh,—дип кабатлады кыз.

—Гутен таг,—дип мыгырдандым аптыраганнан.

—Кемгә әйтәләр, кызыл авыз, кулларыңны күтәр!—дип чекерәеп бакты кыз. Күренеп тора, мине кыерсытасы, кимсетәсе килә иде аның. Тик үзе кем соң? Беренче тапкыр күрүем. Нигә дип эш кешесен бимазалап йөри әле ул? Смирновның туганыдыр дисәң, хуҗа мондый башбаштаклыкка юл

куймас иде. Эшне ул дога шикелле изге гамәлгә саный. Әштер-өштер йөргне жене сөйми. Ә бу буялган курчак турыдан-туры эшкә аяк чала. Әнә, коба тана тәбикмәкләрен җиргә койды. Хәзер үк җыеп алмасаң, тояклары белән изә-изә үзе дә пычранып бетәргә мөмкин. Аннан соң күпме мәшәкать. Хуҗаның иң сөймәгәне пычрак мал. Дөресе дә шулай. Таләбе урынлы.

Мин соскыны алып, коба тана ягына атламакчы булган идем, кыз каршыма төште.

—Һинде hoh!

Ачуым чыкты, уен дисәң, уен түгел, чын дисәң, чынга ошамаган. Нишләргә белми торганда, Смирнов пәйда булды.

—Эрна, кызым, ярамый, Эрна,—дип, тегене култыклап алды.

Бу курчак хуҗаның кызы икән ләбаса!

—Кызыл авызыңны бераз гына кытыклап алмакчы идем, әти...

—Мал-туар арасында йөрү сиңа килешми, кызым, беткәнме башка җир, шәһәрдән урап кайтыр идең.

—Аңламыйсың син, әти, безнең Конрадның башына бәлки менә шушы кызыл авыз җиткәндер? Ә ул шыпырт кына йөри бирә. Күралмыйм мин аны. Күралмыйм! Озат лагерына, күземә чалынмасын!

Күр, бу людоедканың исәбе чынлап торып бәйләнү икән ич. Болайга китсә, эшләр хөрти.

—Һундук, эшеңдә бул!—дип кычкырды хуҗа.

Мин тана тизәгенә иелдем, алар гәпләшә-гәпләшә өйгә таба китеп бардылар. Ихтимал, бу минем Смирновларда соңгы көнемдер? Әти кеше, һичшиксез, яраткан кызының таләбен үтәми калмас. Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас, ди.

Бу көнне тимәделәр, өлгермәделәр, ахры. Иртән дә кагылучы булмады. Мин һаман конвой көтәм. Ә хуҗа тыныч кына йөри бирә, әйтерсең лә, берни булмаган. Бераздан, таналарны начар югансың дип әрләп тә ташлады бу. Әһә, мәйтәм, юри бәйләнә, сәбәп эзли.

Ниһаять, кояш баер алдыннан хуҗа чакыртып алды. Сәгатең сукты Хисам ялчы, тиздән чәнечкеле тимер чыбык эченә кертеп ябачаклар, дип уйлап алдым. Әйдә, япсалар тизрәк япсыннар инде, мин күрәсен башкалар күрмәс.

Смирновлар террасада аталы-кызлы чәй эчеп утыралар иде. Мин сәламемне бирдем, хуҗа сүзсез генә башын кагып куйды. Ә кыз томырылып миңа карап тора.

—Син татармыни?—дип сорады ул гаҗәпләнүен яшермичә.—Татарларны мөгезле дип белә идем...

—Татар-монголларның мөгезе төшкәнгә биш былтыр инде,—дип көлде Смирнов.—Рәхмәт Иван Грозныйга, татарны кулга ияләштерде. Әйбәт батрак ул хәзер татар. Кара эшкә коеп куйган. Идел буендагы яңа утарыбызда мин татарларны да ялламакчы булып торам. Күп алар анда...

Смирнов иреннәрен коймак шикелле җәеп, зур канәгатьләнү белән кулларын угалап куйды. Мин исә ачуымнан шартлар дәрәҗәгә җиттем. Күрәләтә мыскыл итә бит, татар мөгезе төшкән кара батрак, имеш. Барыбер моннан куачаклар инде, җавапсыз калдырмыйм әле, белеп торсын дип әйтеп салдым:

—Татар дәүләтле халык, укымышлы халык,—дидем.

—Ә-ә, чабаталы кенәз! Беләм, беләм, а как же.

Смирнов чәен йотып куйды да, үз-үзеннән риза хәлдә, кеткелдәп көлеп алды. Кәефе шәп иде хуҗаның. Эрна исә әле һаман мине күзәтә. Күзе гел минем якта. Уенда ни—аңламассың. Һәрхәлдә, яхшылык түгел инде. Кара син аның утыруларына гына, хан кызы диярсең. Төзгә каткан, башын да бормый, карашларын гына йөртә. Чынаякны да бармак очларына гына

элгән. Кәкитнең кәките, тәкәббер күркә.

Мине кызына тамаша кылмакка гына чакырмагансыңдыр бит инде, дип уйлап та бетермәдем, хуҗа тамагын кырды.

Җә, әйтсән, әйт инде, интектермә, мин дә адәм баласы ла.

—Иртәгә Эрна күршеләребезгә чакырулы,—диде хуҗа үзенә бер җитдилек белән,—ат белән барырга тели, кичтән үк хәзерләнеп куй, син алып барып кайтырсың.

Менә сиңа, кодача, кыстыбый! Мин көткән сүзләр түгел ич бу. Эчемә җан керде. Алып барып кайтам, әлбәттә. Җилдертеп кенә барырбыз, җилдертеп кенә кайтырбыз. Кызының чәч бөртеге дә селкенмәс.

—Хәзер, татар-малай, тузаннарыңны кагып алыйк инде,—дип кыз стенада эленеп торган сирена машинасын алды да, гүләтеп әйләндерергә тотынды.

—У-у-у... У-у-у...

Һава тревогасы дигән сүз бу. Сугыш чорының аерылмас бер билгесе. Немецлар әледән-әле күнегүләр үткәрәләр. Андый машина һәр йортта бар. Сирена тавышы ишетелүгә, хәрби канун көченә керә. Һәр кеше аңа буйсынырга тиеш. Бу хакта Смирнов беренче көнне үк кисәтеп куйган иде. Вазифаларым да тәгаенләнгән. Әле дә итәгемә ут капкандай маллар янына йөгердем. Алар үзләре, гаиләләре, асраулары белән берлектә, бомбоубежищега төшеп киттеләр (монысы да һәр йортта бар).

Таналар ашауларыннан туктаган, колакларын шәмдәй итеп басып торалар. Минем бурыч малларны кишәрлекләр аша якындагы агачлыкка куып кертү. Ул да бүлеп алынган. Агачлык куе, "дошман" очучысы аларны күрмәячәк. Бу инде танакайлар өстенә бомба да төшми дигән сүз. Барысы да уйланылган. Ләкин сугыш логика буенча гына бармый шул, анда әллә нинди көтелмәгән хәлләр дә туып кына тора. Тик барыбер итәк-җинне җыештырып йөрү зыян итми. Аллаһ та сакланганны гына саклармын дигән бит.

Күрсәтелгән вакытта маллар яшерен урында иде инде. Тикшерүче генә булмады. Тиздән һава тревогасы тәгәлләнүне белдереп, янә сирена гүләде.

—У-у-у, у-у-у...

Иркә кыз уйнап туйды, күрәсең.

Эрна фюрер Германиясенең чын патриоты икәнен тагын бер кат дәлилләде. Ул вакытта бөтен алман халкы гашыйк иде Гитлерга. Дөресрәге, гашыйк булып кылангандыр, мөгаен. Безнең кебек инде. Без дә Сталинны алла урынына күрә идек ич. Хәзер, әнә, эте дә, бете дә сугә, типкегә калды. Туй үткәч—дөмбергә. Вакытында дәррәү күтәрелергә кирәк иде аны.

Смирновның кызы кунакка барган утарның хуҗасы барысыннан да уздырган иде булса кирәк. Йортның фасад ягы койма баганаларына Гитлерның гипстан коелган баш сынын кигереп чыккан иде. Украина хаталарындагы читән казыкларына эленгән чүлмәкләр шикелле тезелешеп торалар. Шуларны күргәч, күсәк белән бер-бер артлы челпәрәмә китереп ватып, җиргә коясы килеп китте.

Эрнаны үзе кебек егерме яшьләрдәге фрейлин каршы алды. Ух-ах килеп кочаклаштылар. Алар өйгә кереп киткәч, мин атымны килүче-китүче өчен махсус ясалган мәйданчыкка бордым. Ул туры лапаска охшаш өсте ябулы корылмадан гыйбарәт иде. Ат өчен дә, юлаучылар өчен дә урын бар. Янда гына чыгырлы кое. Үзең эч, атыңны эчер.

Мин дә атны тугарып, солы капчыгын муенына астым (монда солыны улакка салмыйлар, капчыкка салып, атның муенына асалар), коедан су алып эчтем. Суы тешкә тиярлек салкын иде. Инде бераз черем итеп алсаң да зыян итмәс. Ниятем генә барып чыкмады. Юлда урта яшьләрдәге бер

кеше күренде. Авызы лакан чиләге кебек ерык, әйтерсең лә күптәнге танышын очраткан. Минем һич тә немецлар белән аралашасым килеп тормый иде. Шуңа күрә хуҗам Смирнов өйрәткәнчә әпәгә салыштым.

Яна танышым шул елмайган хәлендә җилкәләремнән кага-кага нидер әйтмәкче була. Ләкин сүзләре чыкмый, һаман бер үк авазларны кабатлый: әһ-әһ-әһ... Бәрәч, бу үзе дә әпә икән ләбаса! Әйтәм җирле, авызын җыеп ала алмый. Телсез-чукрак кешеләр шулай була ич, кирәк-кирәкмәгәнгә дә гел елмаеп торалар.

Аңа ияреп, мин дә елмаям, мин дә әһелдим. Аңлыйбыз бер-беребезне. Менә ул фаэтон янына килеп, аның тегермән ташыдай олы тәгәрмәчләренә аяклары белән типкәли-типкәли баш бармагын тырпайтты, шәп, янәсе.

—Әһ, әһ!

Мин хуплавымны белгертеп, башымны каккалыйм.

—Әһ, әһ!

Күзләрен хәйләкәр уйнаткалап, теге йомшак утыргычка ым какты. Бу юлы ике бармагын тырпайтты. Парлап килдегез, дип әйтүе иде, ахры.

—Әһ, әһ!

Аннан соң, чалбар каешына орынып алды.

—Әһ, әһ!

Мин бармак янадым. Аһ, син азгын Мәҗнүн, гадәмеңә хәсәнат!

—Әһ, әһ!

Безнең күңелле әңгәмәбезне асрау хатын бүлде, миңа тәгам чыгарган икән. Әпәне дә үзеннән калдырмады. Аңлавымча, әпә бу йортның ялчысы иде. "Эшең муеннан, ә син ләчтит сатасың, хуҗадан оялыр идең",—дип оршынды асрау.

Хуҗалар юмарт иде, күрәсең. Сыраны да онытмаганнар. Немецлар сыраны күп эчә. Ул аларның милли эчемлеге санала. Смирнов кына өнәп бетерми. Аңа шнапс булсын, катырагы. Хәмергә күнеккән рус геннарыннан жир тишегендә дә котылып булмый икән.

Бер йөнтәс алабайны исәпкә алмаганда, мине башка искә төшерүче күренмәде. Ачыккан, якты чырайдан бигрәк, ризыкларымны ошатты маэмай. Тагын, тагын дип күзгә генә карап тора. Бүлештем инде. Хәзер, Аллага шөкер, тамак кайгысы бетте, хәтта сырасыннан да өлеш чыгаралар бит әнә.

Алабай чираттагы ипи кисәген дә башкалары шикелле җиргә төшермичә авызына эләктерде. Уен шуның белән тәгәлләнде. Чөнки асрау хатын чыгып, атны җигәргә кушты. Эт аны күрүгә, койрыгын чәнчеп, койма буйлап теркелдәде. Асрау йодрыгын төйнәп, нидер кычкырып калды. Һич тә көтелгән кунак түгелсең икән син монда, дип кызганып куйдым маэмайны.

Күп тә үтми, кызлар күренде. Икесендә дә гармун итәкле сөттәй ак күлмәк, башларында кин кырлы шундый ук ак эшләпә, банты гына зәңгәр. Ул билләре, мин сиңа әйтим, кысып тотсаң, бер карыштан артмас, валлаһи. Әкияттәгечә, аккошка әверелеп, канат кагып очып кына китәсе.

Фрейлиннар нәфис вә сыгылмалы сыннарын уйнаткалап, салмак кына атлыйлар, мин атны башыннан житәкләп, бераз ара калдырып, артларыннан барам. Кәефләре күтәренке, күгәрченнәр кебек гөрләшәләр. Чибәрләр, чукынмыш, ирексездән күңел ашкына, гүя ял бакчасына кызлар күзләргә чыккан егетмен.

Ахирәтләр, ниһаять, саубуллаштылар. Эрна фаэтонга менеп кунаклады. Булышыйм дип омтылып караган идем дә, өлгерә алмый калдым. Кыз бик җинел сөякле икән, бер генә ыргылды. Спорт белән дустыр, мөгаен.

Минем урын алда. Кучер өчен зур сандыкка охшаш кузла ясаганнар. Күн белән тышланган. Фаэтон тулаем кыйммәтле күнгә төренгән. Үзе ике

генә тәгәрмәчле, ифрат жинел, ифрат унайлы. Өс япмасы да бар. Затлы әйбер. Атның дирбиясенә чаклы фаэтонга пар итеп сайланган. Смирнов һич тә төшеп калганнардан түгел, зәвыклы агай. Һәр нәрсәнен кадерен белә.

Ат житез, юл такыр. Тәгәрмәчләр жырлап кына бара. Элдертәбез. Хужабикә авыз эченнән ниндидер көй көйли. Әйбәт кунак булганга охшый апабыз. Ә минем үз уйларым. Кызыл Армиянен хәле ничек икән, дим, Герман чигенә килеп житмәделәр микән әле, дим. Кайчан коткарырлар икән әсирлектән, дим. Бернинди мәгълүмат юк. Смирнов, мөгаен, газета алдырадыр инде, тик итәк-жинен жыеп йөри. Радио да анын өендә генә. Жирле халыкның үз-үзен тотышында шулай ук үзгәреш сизелми. Әгәр хәзер, фаразлавымча, чыннан да үктәбер ае икән, димәк, кырык икенче елның ахырына да якынлашабыз...

Уйларыма бирелеп, яңгыр килгәнен дә сизми калганмын. Баксам, урман өстендәге болыт сыекланып ук беткән. Чибәркәйнен дә бернәрсәдә гаме юк, тик жырлавын белә.

—Тпырау!

Кәжә житезлеге белән жиргә сикереп төштем. Шундый ук җәһәтлек белән фаэтонның япмасын күтәреп, жайланмасына беркетеп тә куйдым.

—Әй, пешмәгән, татар-малай, йоклама,—дип, Эрна да үзенен барлыгын белдерде.

Болыт безне барыбер куып житте. Фаэтонның түбәсе ябык булса да, ян-яклары ачык иде. Шуна күрә хужабикәгә дә кырыйдан яңгыр тамчылары бәрә. Ә мин бөтенләй шәрә кузлада утырам.

Ат юлдагы күлләвекләрне чыпыр-чыпыр китереп юырта, күк йөзенең бер ачык жире дә калмады. Бу куна килгән яңгыр иде, ахры, көзге озын колаклы яңгыр.

Күз кырыем белән генә кызыйны күзәтеп алам. Башы жилкәсенә салынып төшкән, күзләре йомык. Йоклап киткән, ахры. Әйдә, йокласын, бәйләнмәсен генә.

Ат йөрешен акрынайта төште. Шул вакыт яңгыр эченнән Эрнаның тавышы ишетелде:

—Әй, татар-малай, мин туңам, яныма утыр!

Тыңламый булмый, Смирновның әмере шундый. Манма булып чыланган япмамны кузла астына төреп тыктым да, хужабикә янына күчеп утырдым. Гәүдәсе өзелгән борчак кузагы шикелле бөрешеп беткән, дер-дер калтырана. Миңа сыенды. Бармак селкетергә дә кыймыйча кыенсынып утырам. Шулай да бер арада оеый башлаган уң кулым искәртмәстән Эрнаның жилкәсенә төшеп кунакламасынмы. Кыз дерт итеп китте.

—Кулыңны ал!—дип кычкырды.

Кулым үзеннән-үзе каядыр очты...

Фаэтон түбәсенә шыбыр-шыбыр иңгән яңгыр көенә жай гына барабыз. Тизрәк кайтып житсәсе иде дә, исән-имин килеш әтисенә тапшырасы иде бу тәкәббер күркәне. Ярый тынды әле. Әнә ничек мулла песие шикелле мыр-мыр килеп, үз-үзенә иркәләнеп кайта. Тик бу минутта кызыйның сыра пары тулган башында әллә нинди йөгәнсез гамәлләр борынлап яткан икән.

—Әй, татар-малай, синең гаремың бар идеме?—дип сорады кыз.

Жилкәләрем жыерылып менде, аптырап калдым.

—???

—Көнчыгышта ир-атлар күпләп-күпләп жарияләр тота ди бит, татарларда да бардыр ич инде андый әхлаксыз кыргый галәт? Сез цивилизацияле халык түгел ич,—дип соравын шәрехләде Эрна.

—Бездә жарияләр жу-у-к, хәләл жефетләр генә бар...

Бөтенләй коелып төштем.

—Синең дә хәләл жефетең бар идеме?

—Жу-у-к...

—Синең соң, татар-малай, хатын-кызлар белән булганың бармы?

Бу әңгәмә мине тәмам мәлжерәтте, дулкынлануымнан очкылык тота башлады. Анысына гына түзәр дә идең әле, чалбар кашагасы бүселеп чыкты монда. Шулай булмыйча, мәмрәп пешкән чия кебек тулышкан кыз сырышып утыра лабаса янымда!

—Хатын-кыз белән булганың бармы?—дип сорыйм мин сиңнән!

Эрна үзсүзле кызларга гына хас түземсезлек белән, күзләрен шакмакландырып, миңа текәлде. Бер генә мизгелгә карашларыбыз очрашты.

Түбән Сөндә, мөгаен, чибәрләр рәтенә кертмәсләр иде Эрнаны. Сары чәчле, сары кашлы кызларны бездә маржа белән тиңлиләр. Маржа маржа инде ул. Көфер зат. Сөн буе чибәрләре кара күзле була. Буй-сыннары мулдан, куллары зур, йөзләре тулган ай шикелле түгәрәк, якты, шома. Ә монын? Йөзе озынча, иреннәре юка, күзләре зәңгәр... Үзе көзге чебеш кебек, учка сыярлык.

Билгеле инде, мин авыл гыйбаты, чибәрлек турында да авыл мөнбәреннән чыгып фикер йөртәм. Миңа да дөнья көтәрдәй нык бәдәнле кызлар ошый. Ләкин Эрна кебекләрне дә читкә типмәс идем. Чөнки мин үзем дә шулар сыңары.

—Жә,—дип ашыктырды хужабикә.

Оялуымнан чөгендер шикелле кызарып чыктым. Алдаша белмим, дөресен әйтсәң, ничектер оят, селәгәй малай гына икән әле син, дип уйлавы бар. Аның минем хакта нәрсә уйлавыннан һични үзгәрми, әлбәттә, кирәкле кишер яфрагы түгелмен. Тик начар фикер дә уятасы килми бит, каһәр. Әсир булсам да, хезмәтче булсам да егет кисәге ич әле. Табигатьнең үз кануннары, сугышың ни дә ана, әсирлегең ни. Милләтеңне дә аермый.

—Син әле һаман гыйффәтле егетмени?

Эрна кысыпмы-кыса. Ул, ниһаять, ни өчен ык-мык килеп торуымны аңлады. Ниндидер дуамал көлү белән буыла-буыла көләргә тотынды. И көлде, и көлде. Мин исә каккан багана шикелле селкенмичә дә утырам, канаты астында чебиләрен йоклаткан тавык кебек хужабикәмне жылытам.

—Һай, татар-малай, татар-малай. Менә сиңа гарем... ха-ха-ха...

Эрна көлеп туйгач, тагын да жайлабрак утырасы итте. Ул мине ир-ат исәбенә дә кертми иде, ахры. Һәрхәлдә, минем яктан ниндидер гыйшык куркынычы янавы турында ике уйлап бер дә кайгырмый иде.

Кызның кыймшануыннан файдаланып, мин дә оеган тәнемә аз гына булса да ял бирмәкче иттем, кулларымны хәрәкәтләндереп алдым. Гөнаһ шомлыгына, кулым кызның күкрәгенә орынып китте. Шул ук секундта—яңагыма чалт берне! Күздән утлар күренде.

—Бар, урыныңа утыр!

Бу минем үземнең дә иң зур теләгем иде. Жинел сулап куйдым. Аллам сакласын, шайтан вәсвәсәсенә бирелүең дә бар.

Шул вакыт колак төбемдә ату тавышы яңгырады, чак кына кузладан мәтәлеп төшмәдем. Баксам, уф, ни күрим! Эрна торып баскан да, пистолеттан шарт та шорт ата. Авызы кәмшәйгән, күзләре кыртәдән чыккан. Үзе еш-еш сулый...

Ләхәүлә! Котырган чистый. Маңгайдан тир бәреп чыкты. Ышан син бу фашистка, атты үтерде. Рус әсирен дөмектерү аңа дан гына алып киләчәк. Тузга язмаган бер-бер искитмәле уйдырма да өстәп жибәрсә? Мактап газеталарга язачаклар.

Бәхетемә, кыз алтатарын минем якка бормады. Патроннары да бетте бугай, тынды. Мине куркыту өчен уйлап чыгарган идеме әлеге исәрлекне, әллә үзен-үзе тынычландыруы идеме? Бәлки, өянәге кузгала торган гадәте бардыр? Ничек кенә булмасын, шөкер, мәхшәр артта калды.

Кыз мина башка сүз кушмады. Кайтып житкәч тә, борылып та карамыйча, йөгерә-йөгерә өйгә кереп китте. Өстемнән таулар төште диярсен, жинеләеп киттем. Садака да бирер идем, шәт, мулласы белән акчасы гына юк. Бик хәтәр сәфәр булды бу.

Шуннан соң атна буе Эрна күзгә-башка чалынмады. Китеп барды, ахры, дип уйладым. Эш-мәшәкать белән тагын берничә көн артта калды. Кыз да томан аръягына, хәтер төпкеленең төбенә төшеп югалды.

Янгырлар туктады. Скандинавия якларыннан искән коры жил бу юлы үзе белән салкынча һава алып килде. Күк гөмбәзе кәләш көткән өй шикелле чистарып калды, кинәйде, яктырды. Гадәттә, кырау алдыннан шушындый аяз көннәр урнаша торган иде. Мөгаен, Көнбатыш Европада да табигать шушы ук кануннар белән яшидер. Тик кыраунын зыяны тияргә ошамый. Малга дигән кукурузны да силослап бетерделәр. Яшелчәләр шулай ук саклауга салынды. Борчылыр нәрсә күренми. Ләкин Смирновны шушы тымызык салкын да хафага салды. Ашыгыч рәвештә малларны тикшереп чыгарга боерды. Таналарны ул аерым игътибарда тота. Чөнки яна елга кадәр аларны сугымга жибәреп бетерергә кирәк. Керем шулардан.

Соныннан гына башыма килде, мондагы мал-туар да европалыларның үзләре кебек үк салкынга чыдамсыз икән ич. Хужа шуңа күрә саклану чараларын күрә. Чыннан да, берничә тананын мөгез төбе йомшарганлыгы беленде. Алдагы тикшерү вакытында барысы да тәртиптә иде, югыйсә. Мөгез селкенүенен болай караганда бернәрсәсе дә юк кебек. Селкенү генә түгел, кортлый да әле ул. Ләкин мал симертү белән шөгыльләнгән чын хужа моңа битараф кала аламы соң? Әгәр дә ул бер-бер инфекциягә бәйле икән, башка малларга йогуы көн кебек ачык. Бәрдерү, сөзешү нәтижәсе генә икән, ул чакта тананы пычак астына жибәрү хәерлерәк. Дәваларга да мөмкин, әлбәттә, тик өстәмә чыгымнар тоту үзен акламаячак. Ябык малнын бәясе дә түбән.

Смирнов эшне коры тотты. Тиз генә ветеринар чакыртты. Тегесе карады, анализлар алды. Кичкә хәбәре дә килеп ирешә: инфекция юк, таналарны суярга рөхсәт. Суйдык. Мәсьәлә тиз һәм вакытында хәл ителде. Ә мин үзебезнең колхозларны искә төшереп, калтыранып куйдым. Күпме өметсез, сырхау малларны асрап иза чигә иделәр. Заготскотка гына озатасы үзләрен. Юк, мал санын киметүгә юл куярга ярамый янәсе. Бу—жинаять! Дөреслектә әлеге сәясәт күпләп-күпләп югалтуларга китерә иде. Мондый шартларда терлекчелек табышлы да була алалмый иде.

* * *

Кыз урлау уе Хисамның башына чын-чынлап кереп утырды. Ачуым килмәгәе, тәки энә белән жеп шикелле бер-берсенә тагылышканнар, аерырга кирәк боларны дигән фикере ныгыганнан-ныгый гына бара. Илһанына да Төректә кыз бетмәгәндер. Кунакка да йөрешмәгәч, нинди кода-кодагыйлар була ди инде? Жырлашып, мактанышып утыру үзе бер гомер лабаса! Үз ишенә, үз татарына житәме сон?

Йә, хуш. Комбат Никитин әйтмешли, ниятнамәнең фәлсәфәсе шик уятмый, көпшәдәге патрон шапыллап нәкъ оясына кереп утыра. Ләкин пуля читкә каерылмасмы, төбәгән урынга тиярме? Монысы инде хәзергә ике билгесезле тигезләмәгә охшабрак тора.

Беренче билгесезлек—шул төмсә чырай Илһан. Аны ничек тә Төркиясенә үзен генә кайтып китәргә мәҗбүр итәргә кирәк. Тик ничек? Бу гамәл теге бәбәлән йомыркасы, ягъни дә оныгы белән бәйле. Дөресрәге, ул әйтсә генә китәчәк төрек. Башкаларның сүзенә колак та салмаячак. Гүзәлия исә, билгеле инде, мәсьәләне хәл итеп куйган. Димәк, бу тигезләмәнен Хисам өчен уңай чишелеше юк. Бөтен авырлык икенче билгесезлек өстенә төшәчәк, Кәбиргә ягъни-мәсәлән. Урларга риза булырмы? Анысы да бит әле аның әсәрле бәгърем, ипи салган көнне ач йөри торганнардан. Их, үзекәем булсаммы, "вә иләйһи торҗагун" дип эләктереп тә алыр идем чибәркәйне, өйгә алып кайтып бикләп тә куяр идем. И вәссәлам! Урланган кыз урланган кыз инде ул. Өйгә кайта алмыйсың, мәсхәрәсе олаудан да артачак.

Хисам берсеннән-берсе хәтәррәк планнар корды. Аларның барысы да Кәбирнең кыюлыгына, тәвәккәллегенә кайтып кала иде. Тик хикмәт шунда, Кәбир үзе бу хакта әлегә бернәрсә дә белми. Тиз арада егетне күреп сөйләшергә, кылын тартып карарга һәм берсүзсез ризалыгын алырга кирәк дип, күңеленә беркетеп куйды.

Хисам кичкырын, бозауларны карап кайтам, дигән сылтау белән түбән очка төшеп китте. Кешеләр белән очрашып, сүз озынайтып торасы килмәгәнгә, ындыр артыннан гына элдертте. Кәбирләрнең йорты Сөнгә аяк терәп утыра. Арт капкаларыннан гына керәсе. Җайлы. Тик, хәерчегә җил каршы дигәндәй, ул килеп җиткәндә генә Кәбир машинасына утырып, каядыр китеп барды. Артыннан зәңгәр төтен алкалары гына сузылып калды.

Их, чукынды, эш пеште дигәндә генә, дип офтанды Хисам комбинатор.

* * *

Смирнов бу араларда үзенә дә, безгә дә тынгы бирмәде. Камчылады гына. Бүген, ниһаять, бу бимазалы көннәргә нокта куйдык. Маллар тикшерелеп бетте: суясы суелды, дәваланасы дәваланды. Ит комбинатына тапшырасылары гына сайланып калды. Без таралышканда кичке эңгер-меңгер төшеп килә иде инде. Арылган. Ятрәк юрган астына! Хезмәтченең иң зур шатлыгы ял бит инде аның. Ул мескенгә күп кирәкми, шул да җитә.

Келәт эче дөм караңгы иде. Тәрәзәләрнең япмаларын күтәргән идем түгелме соң, кемнең кулы кычытты икән? Шымчылар бар димәк. Әйдә, сагаласы килсәләр, сагаласыннар, куркыр нәрсәм юк. Ышанмаулары гына күңелгә тия.

Шул ризасыз уйлар белән утны кабыздым. (Смирнов келәтенә кадәр электр керткән иде.) Бүлмә ялт итеп китте. Ә мин... мин... акылымны җуйдым. Әйе, әйе, акылы зәгыйфьләнмәгән кеше бу тамаша турында хыялланырга да җөрьәт итмәс иде. Җә, хода! Ком чүлендә булсаң, мираж дияр идең, келәт эчендә бит!

—Әй, мәхлук, тиз бул, кире уйлавым бар!

Таныдым, тавышыннан таныдым. Эрна лабаса! Адәм ышанмаслык хәл. Юк, моның төбендә нидер ята. Шаяртуга охшамаган. Провокация! Әлбәттә, провокация. Тик нинди максат белән?

Башым ачылып киткәндәй булды. Бәлки, миңа чыгып кына китәргәдер? Хак. Ин дөресе, бу пәрәвез оясына эләкмәү, аннан ераграк тору.

—Утны сүндер,—диде Эрна ниндидер үзгә, ягымлы самими тавыш белән. Шушы тавыш миңа сихер шикелле тәэсир итте, әллә нишләдем. Бу мизгелдә елан авызына сикерергә әзер торган бака хәлендә идем.

—Яныма кил,—диде кыз.

Мин инде аның карамагында идем. Чыгып китәсе урынга, ятак тарафына

атладым. Юл унаенда утны да сүндердем. Шунда ук муеныма йомшак, назлы куллар уралды. Бу чынында да гүзәл кыз рәвешенә кергән юха елан иде. Ә мин үземчә һаман карышып маташкан булам. Юк, ярамый, һич тә шайтан коткысына бирелергә ярамый, дим. Мөселман кешесенә никахлашканнан соң гына Ходай насыйп иткән хәләле белән зөфаф ятагына яту фарыз, дим. Гыйффәтем булачак кәләшемнең өлеше. Эт кенә ул багана төбе саен пес итеп йөри...

...Эрнаның кочагы шундый кайнар. Әллә нинди исерткеч исләр килә... Үзем каршы, акылым каршы, жаным каршы, ә тән буйсынмый, упкынга тәгәрәвен дәвам итә. Белә торып тәгәри... Шулай да бер мизгелдә бар көчемне җыеп, соңгы сулышын алган сырхаудай кызның гәүдәсен читкә этәрмәкче иттем. Тик ул әлеге ниятемне назлау дип кабул итте, күрәсең, беркеп үк бетте, колак яфракларымны имә, битләремне ялый... Әллә ниләр сөйләнә: “Аh... о-о, майн гот... о-о, дас ист гросс...”

Тәмам эредем. Кулларым кызның өттергеч тәне буйлап түбәнгә шуыша...

...Эрна мина мона кадәр кичереп карамаган мәңге онытылмас ләззәтле дә, татлы да минутлар бүләк итте.

Уянып киткәндә үзем генә идем. Ялгызлыгым шундый әйбәт тәэсир итте ки, хәтта урынымнан сикереп торып биеп тә киттем. Димәк бу төш кенә булган. Димәк, намусым пакь. Ура! Төш дисәң дә төш. Уйлап, хыялланып йөрсәң бер хәл иде. Кем диген әле? Эрна! Һавалы, тәкәббер немка. Кирәге дә юк, поты бер тиен. Аңа үз фашистлары да бетмәгән. Ул соң өйдә дә юк лабаса! Киткәненә атнадан артты түгелме соң инде?

Өстемнән гүя тау төште, үзем биим, үзем такмаклыйм.

Бас кызым Әпипә,
Син басмасаң, мин басам...

Берзаман үземне күреп, артыма утыра яздым: шәрә икәнмен ич! Ләкин бу хәлдән чыгу юлын да тиз таптым, моны да төшемә аудардым. Бик буранлы төш иде бит, чишенеп үк ташланылган икән, каһәр, дип көлгән булдым.

Шулай да көнем шик, икеләнүләр эчендә үтте: булдымы бу хәл, юкмы? Эрна күземә генә күренмәсә ярар иде, дип теләдем Аллалан.

...Ул мине кичен тагын ятагымда каршы алды. Аны күргәч, йөрәгем тибүеннән туктый язды.

—Мачо, чишен, ят,—диде Эрна әмер биргәндәй.

Әле кайчан гына мәхлук идем, инде мачо. Сүзе сүз түгел. Әйе, ул вакытта әлеге сүзнең мәгънәсе миңа билгесез иде. Көнбатышта гайрәтле ир-атларны мачо дип йөрткәннәр икән. Комплимент булган бу. Чыннан да, атна буе без ләззәт дингезендә йөздек. Кыенсынуларым да бетте, намус, пакьлек дигән сүзләр дә онытылды. Хәзер инде очрашу сәгатьләрен үзем зарыгып көтеп ала башладым. Искиткеч кайнар, гаять дәрәҗәдә гыйшыклы кыз иде Эрна. Тәҗрибәсе дә зур иде, күрәсең. Ул мине күп нәрсәгә өйрәтте.

Көннәрдән бер көнне Эрна юкка чыкты. Төн уртасы да житте, таң да беленде, ә мин үз-үземә урын таба алмыйча бүлмә буйлап әрле-бирле йөренәм. Күз алдымда аның камыштай зифа буе, озынча аксыл маңгаена төшкән сары чәчләре... Мин аларны сыйпыйм, иркәлим... Йөрәгем өзгәләнә... Уф...

Ярату идеме бу, анысын белмим, тик шактый вакыт аңыма килә алмыйча эчтән сызып йөрдем. Газапландым. Мона гажәпләнергә дә кирәкми. Чөнки Эрна минем хатыным иде. Үзебезнең мөнәсәбәтләрне мин әнә шулай житди итеп кабул иткән идем. Мин аңа рәсми төстә өйләнергә әзер идем.

Гыйшык сөреме белән хужам Смирновны бөтенләй хәтеремнән чыгарып жибәргәнмен лабаса. Дөрес, без көне буе бергә, элеккечә ул эш куша, ә мин жиренә житкереп үтим. Кызы белән минем арадагы хәлләрне белү-

белмәве әлегә кадәр һич кызыксындырмады. Бервакыт кылт итеп башымны шушы уй чатнатты. Сизендеме икән, юкмы икән? Сизенми калмагандыр дип уйлыйм. Ул чакта, нигә белдерми? Сүз дә юк, әти кеше моны хупламаячак. Әллә кызына катнашырга батырчылык итмиме? Анысы да бик мөмкин. Эрна үзсүзле, тәкәббер һәм тәвәккәл кыз. Барысы да анынча гына булырга тиеш! Бу идеология сугыш чоры немец яшьләренең кыйбласын тәшкил итә иде, ахры. Европаны буйсындыру аларга шундый хокук бирә дип саныйлар иде булса кирәк.

Смирнов, һәрхәлдә, ачуы чыкканда һаман "һундук" дип сүгә. Ярым яралы булса да, Самара төбәгенә бәйләп тотучы яраткан сүзе иде ул аның.

* * *

Хисам Кәбирне икенче көнне мәктәп янында сагалап торды. Күптән түгел аны директор итеп билгеләгәннәр иде. Шуңа күрә каникул, ял вакыты булуга карамастан, мәктәптән башы чыкмый. Чөнки ремонтның иң кызган чагы, кая инде ул җитәкчегә ял? Көне-төне дигәндәй машинасыннан төшми, әле монысы, әле тегесе кирәк. Ә акчаны бик кысып бирәләр, колхозга, эшмәкәрләргә бил бөгеп барырга туры килә. Әле дә районга җыенуы иде. Хисам күзгә чалынуга, кашлары җыерылды. Тагын бер олау сүз төяп килгән икән инде, дип офтанды. Бер гәпкә кереп китсә, туктатырмын димә. Тик авылның гына түгел, бөтен районның абруйлы аксакалына караңгы чырай да күрсәтә алмыйсың. Өстәвенә, бабасы белән бик әшнәләр иде.

—Исәнлек-саулыкмы, Хисаметдин ага, нинди җилләр ташлады бу якларга?—дип, карт белән ике куллап күреште Кәбир. Тегесе үгезне мөгезеннән тотуны мәгъкуль күрде ахры, егет гаманланганча телбистәләнеп тормады.

—Сүз бар, әйдәле, бакчага керик,—диде.

—Мин ашыга идем шул, Хисаметдин ага, районга барышым...

Хисам җөнтәс кашлары астыннан егеткә сынап карап алды да, сүзенең бик тә мөһим икәнлегенә ишарә итеп, колагына пышылдады:

—Тсс, кеше ишетмәсен...

Кәбир картның җәтмәсенә эләккәнен сизми дә калды.

—Нинди сер житкермәкче буласың, Хисаметдин ага,—дип, түземсезлек белән әңгәмәдәшенә бакты.

—Бакчада әйтермен,—диде Хисам, сер пәрдәсен ачмады.

Бакча аллы-гөлле чәчәкләре белән балкып утыра иде. Тирә-якта хуш ис. Бал кортлары безелдәшә, канатларын җилпи-җилпи күбәләкләр оча. Карап туймаслык матур дөнья!

Бу матурлык Кәбирнең дә, Хисамның да күзенә күренмәде. Алар бер-бер эш җимерткәндәй бик житди кыяфәт белән иң эчтәге эскәмиягә килеп кунакладылар.

—Жә, Хисаметдин ага, ни әйтмәкче идең?—диде Кәбир.

—Син безгә кайткан теге төрек кәмәшен күргәнең бармы?—дип сорады Хисам үз чиратында.

—Күргәнем бар. Аның белән әллә берәр нәрсә булганмы?

—Булмаган кая. Син йоклап йөргәч тә теге. Шул кара чуен китегенә Гүзәлияне биреп җибәрәбезмени инде?

Кәбир битараф кына җилкәләрен сикертеп куйды.

—Үзләре килешкәч...

—Килешми торсыннар әле. Белдеңме? Без төреккә кыз үстермәдек. Белдеңме?

—Куй әле, Хисаметдин ага...

—Юк, Кәбир дус, куймыйбыз. Син Гүзәлияне шушы бер-ике көндә урларга тиешсең. Белдеңме?

Кәбирнең күзләре дүрт булды. Дөрес ишетәмме, дигәндәй, әңгәмәдәшенә сәерсенеп карап алды.

—Беләсеңме, Хисаметдин ага, без ничәнче гасырда яшибез?

—Бабаң Таһирҗан кордаш хуплар иде бу гамәлне,—дип үзенекен тукыды Хисам.

Кәбир дәвам итте:

—Гүзәлия миңа бик ошый. Ләкин үзе генә мине тиң итмәде. Аннан соң, мәктәп директоры кыз урлап йөри димени, Хисаметдин ага?

—Мәми авыз икәнсең, энем Кәбир, бигәйбә. Берәүгә фәрештә үбеп үстергән чибәр кыз бирергә торалар, ә ул... тьфү, мин сине егет солтанына санап йөргән булам тагын.

*Дәвамы бар*

---

## *Минем санның бер чаткысы*




2006 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 1000 нче САНЫ ДӨНЬЯ КҮРӘ

**1933 нче ел башыннан “ЯҢАЛИФ” журналы урынына тагын да тулырак программа белән “СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ” исемендә айлык яңа журнал чыгарыла башлый.**

“СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ” журналы Татарстан Совет язучылары Союзының органы булып, бөтен татар совет язучыларының катнашлары белән чыга.

“СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ” журналы—үз алдына түбәндәге бурычларны куя: әдәбият һәм сәнгать өлкәләрендә коммунистлар партиясенең сәясәтен үткәрү өчен көрәш һәм әдәбият-сәнгать проблемаларын марксизм-ленинизмча тикшерү; матур әдәбият һәм сәнгать өлкәләрендә буржуачыл, милли-вак буржуачыл, милли демократчылык һәм башка шундый реакцион тенденцияләргә каршы кискен көрәш алып бару; марксизм тәнкыйте һәм сәнгать методы мәсьәләләрен тикшерү, эшләү.

“СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ” журналы—түбәндәге бүлекләрдән тора: социализм төзелеше, культура революциясе һәм әдәбият-сәнгать өлкәләрендә алда торган мәсьәләләр (мәкаләләр, очерклар h.б.), әдәби әсәрләр (романнар, повестьлар, поэмалар, шигырьләр, очерклар h.б.), әдәбият өйрәнү (методология, әдәбият тарихы, фольклор, телне өйрәнү мәсьәләләре, әдәби мемуарлар, истәлекләр, библиографияләр), сәнгать (театр, кино, музыка, сынлы сәнгать, репертуар, драматургия мәсьәләләре), культура, көнкүреш, библиография, тәнкыйть һәм хроника.

“СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ” журналы—Татарстанның танылган гыйльми һәм әдәби көчләренең якыннан катнашулары белән чыга.

“СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ” журналы бөтен татар язучы һәм шагыйрьләренең иң яхшы романнарын, повестьларын, хикәя, шигырь, поэмаларын бирә. Советлар Союзы халыклары әдәбиятыннан һәм чит ил революцион әдәбиятыннан үрнәкләр бирә.

“СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ” журналы Советлар Союзының, аерым рәвештә милли җөмһүриятләрнең культура үсешләрен чагылдырган материаллар, культурага, әдәбиятка, сәнгатькә карата бай хроника бирә.

“СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ” журналы—социалистик культура активына -алдынгы эшчеләр, колхозчылар, кызылармеецлар, партиялеләр, комсомоллар, вузчылар, әдәбият укытучылар, гыйльми эшчеләр, шәһәр һәм авыллардагы культура эшчеләренә карата чыгарыла.

“СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ” журналына подписка һәрбер почта бүлегендә, китап кибетләрендә кабул ителә.

“СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ” журналына подписка бәясе:

Бер елга—12 сум. 6 айга—6 сум. 3 айга—3 сум. Аерым саны—1 сум.

“СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ” журналы редакциясенең адресы: Казан, почта ящиге № 54.

*(Яңалиф.—1932.—№ 9-10. -Б.2).*



## Зөлфәт

## МОҢНАР МОҢЫ...

* * *

Аңладым бугай былбылның
Сайравы серен—ямен!—
Сайрап бетерми калдыра
Күңленең түрендәген...

Сайрап бетерер-бетермәс
Калганга күрә генә
Моңнар моңы мөлдерәмә
Былбылның йөрәгендә!

Мөлдерәмә моңнар моңы
Бирелер беркөн... әмма
Йөрәге калыр тукталып,
Бөек моң түгелгәнгә!

Бар минем дә
моңнарымның
Тоташтан яндырганы—
Һаман сайрап-сайрап,
Сайрап
Бетерми калдырганы...

Көтәдер былбыл йөрәкнең
Бер ташып түгелгәнен!
...Кабул булыр
яшәештә
Теләгән бар теләгем...—
Бөек моң ташыганлыктан
Туктап калса йөрәгем!..

*ЗӨЛФӘТ (1947) — шагыйрь; "Утлы бозлар", "Адашкан болыт", "Йөрәгемне былбыл чакты" һ. б. китаплар авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Кош оясы—җилле тирәктә!

Язгы тирәк... тибри кош оясы...
Оч ботакта ата саклап тора.
Әнкә кошкай бәбкә чыгармакчы
Кузгалмый ул. Тынган. Гел утыра...

...Көзге тирәк... тибри кош оясы.
Пыскый көзге яңгыр. Кошлар киткән...
Буш ояда җылы эсәре юк.
...Һәммәсе дә вакытлыча икән!

Кышкы җилдә калды кош оясы...
Алда—бушлык, җил, кыш салкынлыгы.
Таныйсыңмы, кеше, язмышыңны?
...Әле генә сайрап торган оя
Буп-буш калды... Сүнде... Тәмам тынды...

## Тезләнү

Бар тезләнү гүзәл зат алдында,
Бар иелү чәчәк сыйпарга,
Сыннарга һәм изге сурәтләргә,
Мәҗүсигә янган утларга.

Бар тезләнү сабый каршысында,
Күзләренә карар өченгә
Бар тезләнү—ярлы—мескенлектән
Каршыңдагы байга, көчлегә...

Болар барысы да аңлашыла—
Яман гамәлме бу, түгелме,
Карамыйсың—җанга рәхәтме бу,
Рәнҗетәме синең күңелне...

Карамыйсың... Әмма акыл кереп,
Дөнья уйландыра башлагач,
Илләр-халыкларның кемлегенә
Колак салгач һәм күз ташлагач,

Тетрәндерде, җирәндерде мине
Тезләндерүе илнең бүтән илне,
Тезләнүе шуңа тегесенең!
Рәнҗетә бу минем күңелне!

Чөнки, ил, дидеңме, халык дисең...
Тарихта юк икән үзгәрү—
Тарихың бит, Кеше, синең, котсыз—
Тезләндерү һәм дә тезләнү!

Нишлим, мин әйтергә тиеш хәзер,
Кирәк икән тагын, тагын да,
Юк, Кешелек, мин тезләнә алмыйм
Үзең кылганнарың алдында!

## Читән

Инде төштә генә калган
Авыл буенча үтәм—
Менә бит ул! Менә бит ул—
Әтәч кычкырган читән!

Кагынып әтәч кычкырды
Чаган җилфердәгәндә,
Әтәч очып төште анда
Никтер әллә кемнәргә!

Мин тәмам бөтен дөньяны
Таныган сыман үтәм—
Әтәч кычкырган читән бу.
Әтәч кычкырган читән!

Узды гомремнең язы да,
Җәе һәм алтын көзе...
Көзге читән чыбыгында
Ул нинди әтәч эзе?

Исән икән бит әле ул.
Исән әле ул читән!
Әтәч эзе генә калган
Читән буеннан үтәм...

* * *

Урман түрендә үк төн кунган җил...
Былбыл канатыммы кагылганга
Назлы сулыш булып уянган ул
Сызылыплар ал таң кабынганда...

Урман түрендә үк төн кунган җил
Кагылды да... чыклар җемелдәште.
Җан уянды... Биек-биекләрдән
Җан уяныр итеп кем ул дәште?

Урман түрендә үк төн кунган җил
Уяна гел былбыл канат каккач...
Шул былбылның назлы канат җиле
Җаның сыйпар—күңел таңың аткач!

Көн килер дә меңгә төрләнер ил—
Гөлләнер ул, хәтта күмерләнер...
Тик барыбер җирнең бер төшендә
Кеше җаны сулкып... шигырьләнер!..

Хәсрәтләрне куып ал таң керсен,
Ояласын, калсын саф күңелдә!
...Керфектәге күз яшьләре кипсен
Урман түрендә төн кунган җилдә...

## Синең күз карашыңа охшаш ул...

Өнсез томанлыктан, болгавырдан
Куркып үрсәләнмә, и күңел!
Бу—таң җиле...
Язмышларны айкап
Өзгәлисе явыз җил түгел!

"Алам!—дисә Тәңре?—Ни калдырыйм?!"
Диярмен: "Ал! Калдыр шушысын—
Аның тик бер ямен—күз карашын—
Таң җиленең тынын-сулышын!"

Таң җиленең тынын һәм сулышын
Кала алсам саклап җанымда,
Димәк, әле булачакмын җирдә,
Таңнар көтәчәкмен тагын да!

Яңа таңның яңа сулышының,
Яңа таңның яңа җиленең
Синең күз карашка охшашлыгын
Беләм... Күптән беләм инде мин!..

## Шумер кызы

Шумерлардан бер кыз каш сикертте!
Чиксез чорлар үткән килеш тә
Синең елмаюның бөек сере
Безгә дә бит бераз тиеш лә!

Иллеме без, чокыр-чакырлымы,
Ком-балчыклы шәрә тугаймы?—
Андамыни хикмәт?!—
Төпкелләрдән
шумер кызы миңа елмайды!

Авазларда, сүздәмени хикмәт?!—
...Ил бик явызланган көннәрдә
Дертләп куям...
Шумер гүзәленең
Күз яшьләре минем мендәрдә...

## Чоңгыл

Ник үлемнән куркасың син, Кеше?
Качып калырмын дип белдеңме?—
Ходай сиңа яшәр гомер биргән
Һәм бирмичә калмас үлемне.

Ә шулай да миңа килгән үлем
Ул чын үлем булмас шикелле...
Бөтерер дә убар бу дөньяның
Бөтерчекле чоңгыл-төпкеле.

Чоңгыл бөтерчеге әзе булып
Вакыт елгасының өстендә
Су алкасы гүя бөтерелер,
Тукгый, тына белмәс һич кенә...

Һәм, ниһаять, ул да тынып калыр.
Вакыт тонар. Дулкын сүрелер...
Вакыт елгасының көзгесендә
Ходай Тәгаләнең мең дәһшәтле,
Мең дәһшәтле килеш шәфәгатьле
Күз карашы гына күренер...

...Яшәр гомер биргән икән Ходай,
Юк, онытмас, бирер үлемне...
Табигатьтән без убылган идек...
Табигатькә кабат убылуны,
Йә, син үлем дияр идеңме?..

## Күпме иярдем йолдыз нурына...

Бүтән ут элеп уйланмам инде—
Минем дә төнге лампалар сүнде,
Сихерләп түгел, шигырьләп хәтта
Аңлый алмадым серен мин төннең...

Йолдызлар һаман калыр җемелдәп
Нидер сөйлисе килгән шикелле...
Йолдызлы күлләр иләсләндерде
Чишмәдәй тонык тымык күңелне!

Гомер буема йолдызы тере,
Җанлыдан җанлы күгемә дәштем,
Тоташ моң тулган йолдыз яктысы
Шигырь язасы кәгазьгә төште...

Күпме иярдем йолдыз нурына,
Кулым иярде, иярде сүзем,
Дертләп күңелем, күк тылсымыннан
Шигырь юлларын тездем дә тездем...

Инде сизенәм, киләчәк бер мәл,
Ул мәл һичкемне читләп үтмәгән.
Ишетелер тавыш: йә, күп уйландың,
Сүндер утыңны, инде кит, адәм!

Төнлә ут эзләп уйланмам бүтән,
Һәм минем төнге лампалар сүнер—
Аңлашылмаган күкләр серенә
Барып кушылыр минем дә гомер...

* * *

Дөньяда бар шәфәгатьле тылсым—
Орлык сыман шытар чуарташ.
Һәм күк белән җир тоташ булыр,
Җир белән күк булыр гел тоташ!

Ирешмәскә ирешүнең хакы
Мәхрүмлектә икән ләбаса.
Әнә, кар бөртеге эреп юкка чыкты—
Илаһиятлы бер тамаша!
Һәм без—шул тамчыдыр...
Һәм ул тамчы
Мәңгелеккә тамып маташа...



## Искәндәр Сиражи

## ГЫЙСМЕТДИН ТӘҮБӘСЕ

ХИКӘЯ

—Я-син, үәлкуръәнил хәким...

Сәлим мулланың калтырап чыккан хәлсез тавышы әле генә мәет озаткан өй эчен гүя тагын да караңгыландырып, тагын да шыксызландырып җибәрде, күнелгә шом өстәлде. Соңгы дүрт ел эчендә бишенче ясинен чыга инде бу йортта хәзрәт. Әмма ул белә—бүгенге мәет озату йоласы заяга—үлмәячәк әле ул, үлмәячәк. Күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый...

Мулланың уйларын ишеткән кебек, авыру ыңгырашып куйды һәм эренләгән керфексез тонык күзләрен ачты.

—Ы-ы-х...

Күптән хәтергә сеңгән Коръән сүрәләрен укып утырса да, үз уйларына чумган мулланы бу ыңгырашу уятып җибәрде. Ул тиз генә укыган сүрәсен очларга ашыкты.

—Сәдакаллһул газим. Әмин. Аллаһу әкбәр. Өйдә кем дә булса бармы? Дамир, улым, атаң аңына килде, су китер!

Дәшүче булмады. Шунда гына Сәлим хәзрәт әле генә гүр иясе булырга җыенып яткан Гыйсметдиннең тонык күзләре үзенә текәлгәнен күрде.

—Кордаш, хәлләрең ничек?

Гыйсметдиннең күзләрендә усал очкыннар уйнап куйды.

—Ы-ы-х...

Әмма ул бары хәлсез итеп ыңгыраша гына алды. Нәрсә сорап торган була инде, белә бит—начар! Инде унбиш ел үлем көтеп ята. Гомер иткән карчыгы Гөлзифаны җирләп кайтты да, егылды. Шул ятудан инде тора алмады, кул-аяктан, телдән язды. Инде менә гел ятудан тәне чери, сөякләре исә тирене тишеп чыга башлады. Тереләй чери Гыйсметдин, тереләй. Ә ул: "хәлең ничек?"—дигән була! Һе, мулла булган, имеш. Күрсәтер иде ул сиңа Алланны-мулланны—теге заман булса... Һай, бар иде көчле чаклар.

---

Искәндәр СИРАЖИ (1972)—*яшь язучы, публицист; хикәяләре, мәкаләләре вакытлы матбугатта даими басыла. Казанда яши.*

Үзен түгел, кара айгырын гына күрсә дә, бөтен авыл халкы өнсез кала иде. Һай, шул чаклар кире кайтса икән!

* * *

1945 елның җәе. Көн кичкә авышып бара. Урман юлыннан авылга җилкәсенә юл капчыгы аскан бер солдат килеп керде дә, туп-туры колхоз идарәсенә юнәлде. Авыл халкы аны танымый калды. Күптән көтте Сәлим бу көнне, исән-имин илгә кайтып шул Чулак Гыйсминең иманын укытсам, үлсәм дә үкенмәс идем, дип нәзер әйтте. Шуңа да, өенә кереп тә тормастан, туп-туры дошманы янына китте.

Колхоз рәисе идарәдә иде әле. Сәлим ишектән керә керешкә бүлмә хуҗасын өстәле артыннан сөйрәп чыгарды да, сугып екты. Гыйсметдин карышып тормады. Ул үзе дә кайчан да булса бу көн киләсен белә иде. Озак типкәләде аны Сәлим. Инде тәмам хәлдән тайгач кына председательнең френч пинҗәген бизәп торучы бердәнбер медален йолкып алып, ачык тәрәзәдән атты.

—Кан коеп алган медаль түгел бу!

Кыйналудан курыкмады Гыйсметдин—төзәлер әле. Ә менә Сәлимнең соңгы сүзләре аны пошаманга салды. Әгәр бу хәбәр райкомга барып җитсә, шунда ук председательлектән алып ташлаячаклар. Әнә, сугыштан ир-атлар да кайта башлады, колхозны җитәкләрлек кешеләр бар. Аннан соң бу сүзләрдә хаклык та юк түгел бит...

Шул ук кичне кара айгырын җигеп район үзәгенә кузгалды ул. Күрәсе кешеләрен күрде, язасы кәгазьләрен язды. Иртәгесен исә Сәлимне алып киттеләр, халык дошманы булган, диделәр. Шул китүеннән ул сигез елдан соң гына авылга әйләнеп кайтты.

Картлар икесе дә бер үк уйны уйлыйлар иде булса кирәк, бик озак берберсенә карашып тын тордылар. Тынлыкны Сәлим хәзрәт бозды.

—Мин сине кичерәм, Гыйсметдин кордаш. Әйе, риза-бәхил.

—Ы-ы-х...—Ынгырашу усал янгырады.—Синнән бәхилләү сораган кеше бармы соң әле монда?! Мин әллә гаепләме? Заманы шундый иде аның, заманы. Кем беренче булып сөйләсә, шул хаклы иде ул чакта.

—Аңлыйм, кордаш, син үзеңне гаепсез саныйсың. Тик шуны бел—тәүбә кылмый торып, гүр сине кабул итмәячәк. Мин сине бәхилләдем, үземнең дә озак яшисем калмагандыр инде. Хуш!

—Ы-ы-х...

Һай, җавап бирә алса икән шушыңа, ишеттерер иде ишетмәгәнен! Ә шулай да Сәлим карт бирешкән, озакка сузмас, ахрысы. Туксанда бит инде ул да.

Гыйсметдин мулланың бөкрәя төшкән гәүдәсенә ишектән чыгып киткәнче карап калды.

—Ы-ы-х!..—Менә тагын үз уйлары белән бергә-бер калды инде. Ичмасам, үлеме дә килми бит аның... Бу юлы хәле начарлангач, әллә әҗәл килде инде, дип куанган иде, тагын юк. Әле кичә генә улы Зөфәрне алып кайтып күмделәр. Төзүче иде, үзе төзегән йорт түбәсеннән егылып төшкән. Соңгы дүрт ел эчендә генә дә дүрт улы вафат булды бит аның, ел саен берәү... Берсе атасының хәлен белергә кайтышлый поезд астына эләкте, берсе машина белән капланып үлде, берсе су коенганда батты...

—Ы-ы-х!..—Берсе генә дә үз үлеме белән үлмәде бит. Авыл халкы, әнә, бу үлемнәрне дә, Гыйсметдиннең авыруын да каргыш дип, хатын-кызларның сугыш елларында түктергән күз яшьләре төште дип сөйләшә.

Каргыш, пычагым, паралич диләр аны! Тәүбәгә кил, имеш. Нинди тәүбәгә, заманы шул иде аның. Әллә бер ул гына халыкны зар елаттымы? Юк, андыйлар меңләгән иде. Әгәр син елатмасаң, сине елатачаклар иде ул чорда. Заман өчен ул гаепле түгел, түгел!

Капка шыгырдаган тавыш картны уйларыннан, акылануларыннан бүлдерде. Тагын кем йөри инде анда сару кайнатып?! Сабира кортка икән.

Авыру янына узуга, карчыкның борынына чергән тән, үлек исе ярып керде. Шулай да борынын капламады, тонган күзләр белән үзенә карап торучы Гыйсметдинне рәнҗетәсе килмәде бугай.

—Нихәл, Гыйсметдин? Ишеттеңме әле, Сәлим мулла вафат. Ходаем, без гөнаһлы бәндәләрне кем ясин укып соңгы юлга озатыр инде. Бигрәк изге җан булган хәзрәтебез. Сездән кайткан да, тәһарәтен алып, намазын укып урын өстенә яуган. Бары үзенә-үзе ясин чыгып кына өлгергән. Йа, раббым, безгә дә шундый җиңел үлемнәр насыйп итсән иде...

—Ы-ы-х!—Сөйләшергә җай чыкканга куанып бетә алмаган кортканы Гыйсметдиннең ачулы ыңгырашуы бүлдерде.—Нәрсә, кортка, күзең чыкканмы әллә! Нинди җиңел үлем турында сөйлисең син, ә?! Унбиш ел көтәм бит инде мин аны. Мин үзем үлем көтәм, череп ятам, ә ул мина килми, тап-таза уларымны алып китә...

Сабира карчык сүзен дәвам итте:

—Менә хәзрәт белән дә бәхилләшә алмый калдым. Синең хәлең дә бик начар дигәч, бәхилләшеп чыгыйм, үкенечкә калмасын дидем. Бәхиллим мин сине, Гыйсметдин, бәхиллим.

—Ы-ы-х!!!

—Бүлдермә, Гыйсметдин, тыңлап бетер! Синең авыл халкы алдында гөнаһларың, ай-һай, зур. Тәүбәгә кил, Ходайдан ярлыкавын сора. Шунсыз гүр иясе була алмассың. Кеше каргышы юкка чыкмый ул. Уларыңның үлеме бер дә юкка түгел...

—Ы-ы-х!!!—Йә, Хода, бусы да шул тәүбә турында сөйли. Әллә бөтен заманы өчен бер Гыйсметдин генә җаваплымы? Инде менә, уларының үлемен дә шул каргыш белән бәйләп маташалар. Юк ул каргыш, юк! Сезнең ишеләрне куркытып тоту өчен мулла-мунтагай уйлап чыгарган аны. Иң авырткан җиргә сугалар бит, балаларны искә алалар. Ә Гыйсметдин яратты уларын. Теге чакта фронтка киткәндә дә Гөлзифасына саубуллашу урынына янап китте бит ул:

—Кара аны, малайларны сакла! Алай-болай булса, кайткач, күрмәгәнеңне күрсәтермен! Мин анда озак маташмам, көт.

Сүзендә торды тагын, ярты ел да узмады, кире әйләнеп тә кайтты.

Гыйсметдинне сугышка кырык икенче елның язында гына алдылар. Безнең гаскәрләр инде чигенүдән туктаган, авырлык белән генә булса да немецны куа башлаган чак. Әле ике ай элек кенә сугышка кергән Гыйсметдин һөҗүм барышында снаряд чокырына тәгәрәп төште. Монда инде үле немец солдаты ята иде. Шунда ук аңлап алды ул—исән калу юлы нәкъ менә шул чокырда икән бит! Тиз генә немецның автоматын алды да, сул кулының терсәк турысына атып та җибәрде—кулсыз калу башсыз калу түгел. Коточкыч авыртудан аңын югалтып егылган Гыйсметдинне санитарлар шунда табып алганнар. Ике ай госпитальдә яткач, кулының сугышка яраксызлыгы мәгълүм булды—терсәк турысында сөякләр чәрдәкләнгән, бөгелми. Шулай итеп фронттан Чулак Гыйсметдин булып, чокыр төбендә ятып калган немец солдаты өчен күкрәгенә "Батырлык өчен" медале тагып кайтып керде ул.

—Тәүбәгә кил, Гыйсметдин, тәүбәгә!

Сабира карчык инде ишек төбенә җиткән иде.

—Ы-ы-х!—Ничек тәүбә итсен ул, ә, ничек?! Гаепле түгел бит ул, түгел! Заманы гаепле! Сабира карчык беткән, комы коелган. Бар иде бит аның да шәп чаклары... Фронттан кайткач, Гыйсметдинне колхозга председатель итеп куйдылар. Яңа председательгә эш күрсәтергә кирәк иде. Шунда ул гаҗәп шәп бер фикергә килде—фронтка райком биргән заданиедән тыш ашлык озатырга! Көз, колхозчылар хезмәт көненә иген алалар. Аз инде дә, язга кадәр җитәр әле, ә яз көне кычыткан чыгар... Әмма бу елны иген кыш чыгарлык тимәде, яртысын Гыйсметдин фронтка озатырга дип тотып калды. Карышып маташучылар да булмады түгел. Әмма аларга сүз бер:

—Син нәрсә, фронтка икмәк җибәрүгә каршымы? Гитлер тегермәненә су коясыңмы? Партия, иптәш Сталин җиңү көнен якынайту өчен көн-төн тырыша, ә син аларга каршымы?

Бу сүзләргә өстәп бер-ике канәгатьсезне төрмәгә дә озаткач, авылдашлары тынычланды. Гыйсметдинне райком җыелышларында башкаларга үрнәк итеп куйдылар, аның турында газеталарга яздылар, радиодан сөйләделәр. Шулай итеп яңа председательнең район җитәкчелеге алдында йөзе ак булды. Әле аңа ничәмә-ничә башка председатель дә иярде. Авыл халкының нәрсә ашап торуы райкомны кызыксындырмады шул. Ә халык ачлыктан шешенә иде. Ул елны язгы кычытканны инде кыш уртасында ук көтә башладылар. Председательгә ашлык сорап килүчеләр ешайды. Тик аның талканы коры булды:

—Бөтен ашлык фронтка!

Көннәрнең берендә Сабира да килде аның янына. Ялварды, елады, биш яшьлек кызым ачлыктан шешенә, диде. Матур иде хатын, әле шул йончыган, ачлыктан сулган килеш тә ирләр күзе төшәрлек иде.

—Ярар, бирермен. Ну бүген ишегеңне бикләмә, керермен.

Кичен килде ул Сабирага. Әле дә хәтерли, бер пот арыш алып килгән иде... Матур иде Сабира, чукынчык... Киткәндә гарьләнеп елап калды. Соныннан авылдашларыннан ишетте, имеш, Сабира, күрше авылга чирмеш карчыгына барып корсак төшертеп кайткан.

Ул елны Гыйсметдиннең кара айгыры кичкырын шактый өйләрнең капка төбендә торды. Бигрәк тә ирләре сугышта үлгән яки хәбәрсез югалган хатыннарга ашлык китергәләп йөрде ул. Әҗере генә гел бер булды. Әйе, яшәп калды Гыйсметдин, дөньясының артына тибеп яшәде! Авылның теләсә кайсы хатыны аныкы иде. Карышып маташучылар да булды. Әнә бит, Сәлимнең Минсылуы ничә керде икмәк сорап, ничә әйтте аңа Гыйсметдин бүген кич ишегеңне бикләмә дип, юк, риза булмады. Дүрт яшьлек баласы шешенеп үлде, икенчесен дә язга чаклы көч-хәл белән алып чыктылар. Ә нәрсә карышып маташырга иде? Шул кирәк!

Ул баланы җирләп кайтканда кара айгыры белән нәкъ каршына килеп чыкты аның Гыйсметдин. Авылдашлар кайсы-кая сибелделәр, тик Минсылу гына юл бирмәде, айгырны йөгәненнән тотып туктатты.

—Син генә гаепле баламның үлемендә. Үзеңнекеләрнең игелеген күрмә, җан биргәндә янында су салырдай кеше булмасын, җеназаңны ятлар озатсын!

Ул чакта Гыйсметдин көлде генә. Әнә бит, аның баһадирдай өч малае бар, хатыны дүртенчесенә көмәнле. Әле тагын булыр, оеткысы Бохарада түгел бит, үзе белән. Оеткысы әйбәт булып чыкты рәиснең. Гөлзифасы әле тагын ике малай алып кайтты, үзе һаман кыз көтте...

—Ы-ы-х!!! Кайда йөри инде бу малай. Арка авыртуга чыдар әмәл юк, әйләндереп салсын иде ичмасам.—Астын алыштырырга да вакыт, ни гомер юештә ята.—Ы-ы-х...

Улы Дамир кайтканын капка келәсе шакылдаудан ук белде. Хәзер ашатыр да, урын-жирен дә алмаштырыр, тәнен дә корытыр.

Дамир өйгә керү белән чишенеп тә тормады, атасы янына узды.

—Куркыттың, әткәй, инде син дә мине ташлап китәсең дип торам. Йә, хәлен ничек?

Гыйсметдин күзен йомып ачты, бу аның—"әйбәт"—дигәне. Дамир сак кына атасының юрганын күтәрде.

—У-у, әткәй, булган икән монда. Тиз генә су жылытырга куеп килим әле.

Менә ничә еллар инде Гыйсметдин улын күзәтә. Яратып тәрбиялиме ул аны, әллә кирәк булганга, кеше сүзеннән куркып кынамы. Бүген ул аерата игътибарлы иде. Ни дисәң дә соңгы улы бит. Әмма Дамирның йөзендә бер генә жирәнү, үзенең вазыйфаларыннан авырсыну галәмәте сизмәде. Ихластан ярата аны улы, ихластан...

—Ы-ы-х...

Атасының ыңгырашуын ишетеп, Дамир йөгереп керде.

—Нәрсә булды, әткәй?

—Ы-ы-х...

—Хәзер, әткәй, юам, урын-жиренне алмаштырам да, ашап алырбыз.

Әйе, әйе, ашап алырга да кирәк бит әле. Ашатканда улы аңа авыл яңалыкларын сөйләр... Бәхете булмады төпчек малайның. Абыйлары мәктәпне тәмамладылар да, авылдан чыгып китә бардылар. Чулак Гыйсми малайлары булып йөриселәре килмәде. Ишләре дә үчекләделәр, араларына кертмәделәр. Авылда аталары күз яше түктермәгән бер генә йорт та юк иде шул. Нишлисең, заманы шундый иде. Хрущев заманында Гыйсметдинне председательлектән алгач, бигрәк тә авыр булды. Әле аннан соң да аның яманатын озак саттылар. Имеш Гыйсми теге дә, Гыйсми бу, ул кансыз булган. Булган, пычагым! Дамир соңрак туды. Ул туганда авыл шактый тынычланган иде инде. Шуңа да атасы турындагы гайбәтләрне ишетмичәрәк үсте, ун классын тәмамлагач, авылда калды. Әй, элегрәк, Гөлзифасы исән чагында күңелле була иде Гыйсметдиннәрдә. Бигрәк тә Сабан туйлары шәп уза иде. Шәһәрдән дүрт килен, дистәгә якын оныклары ияртеп дүрт малай кайтып төшәрләр иде, ул оныклар "бабай" дип килеп кочаклап алырлар иде... Тик, нигәдер, оныклар гел кызлар булды. Нәсел жебен ялгап китәрлек бер малай тумады. Уллары исә, әйткәч, көлә генә иделәр. Их, юк шул инде, узды ул чаклар. Дүрт малай—инде гүр иясе... Оныклар да кайтмый. Хәер, кайтсалар да, бабай, дип муенга асылына алмыйлар. Әбиләре үлгәч кайткалап карадылар алар, "монда воняет" дип китеп бардылар. Воняет инде, бабагыз астына тәрәт итеп яткач...

—Әткәй, әйдә, юып алам.

Янында ләгән белән су тоткан Дамир тора икән.

Юып, чиста урын-жир жәеп куйгач, Дамир атасын ашата башлады.

—Әткәй, иртәгә абыйның өчесен уздырып алабыз инде. Коръән укырга чакырып Сәлим хәзрәткә кергән идем, ул да үлеп киткән икән. Гөлжиһан әбине чакырдым инде...

—Ы-ы-х...

—Нәрсә, әткәй, син каршымы әллә?

Гыйсметдин ике тапкыр күзен ачып-йомды, аның бу "юк" дигәнне аңлата иде. Нәрсә ди, Гөлжине Коръән укырга чакырдым диме? Һе, ул

кайчан абыстай булып өлгергән әле? Ә бит теге чакларда Гыйсметдиннең кара айгыры аның капка төбенә дә тукташтыргалады. Хәзер менә шул абыстай булган. Ярар, булсын әйдә, ул бит Гыйсметдин белән үзе теләп чуалмады, башка чарасы юк иде... Тьфү, тәүбә кылып маташа түгелме соң әле. Юк, юк, үзе теләде ул. Әнә бит, Миңсылу барыбер бирешмәде, жаны теләгән аның, жаны...

Гыйсметдин, ниһаять, арып, авыр, куркыныч төшләр тулы йокыга талды. Төшләре гел бер аның. Әнә ачлыктан шешенеп үлгән баласын аңа сузып Миңсылу килә. Баласының үлем ачысы белән ямьсезләнгән зәп-зәңгәр йөзен Гыйсметдиннең борын төбенә үк суза.

—Син генә үтердең нарасыемны! Нәселең корысын, жан биргәндә бер тамчы су салучың булмасын, женазаңны ятлар озатсын!

Гыйсметдин башын читкә бормакчы, бора алмый, карарга мәжбүр була. Бала шулчак кисәктән күзләрен ачып жибәрә һәм йөзендә усал елмаю пәйда була.

—Әйдә, минем янга. Монда сине көтәләр,—ди ул гүрдән чыккан тавыш белән пышылдап, Гыйсметдин аның жан өшеткеч салкын сулышын да тоя хәтта. Бу төшне күргән саен салкын тиргә батып, астын юешләп уяна ул.

—Ы-ы-х... Тагын йоклап булмады инде. Күзне йому белән төшкә әллә нәрсәләр керә башлый. Йокламаска кирәк, йокламаска...

Әмма никадәр генә тырышмасын, күз кабаклары үзләре йомыла. Тагын шул ук куркыныч төшләр...

Әнә, авыл башыннан чанага жигелгән кара айгыр чабып килә. Чү, Гыйсметдиннең үз айгыры түгелме соң бу?! Алайса, нигә авыз-борыныннан ут-төтен чәчеп нәкъ аның өстенә килә? Гыйсметдин качмакчы була, тик аяклары тыңламыйлар, кургаштан койгандай авырайганнар. Айгыр менә таптыйм дигәндә генә шып тукталып кала, кан баскан күзләре белән Гыйсметдингә карый.

—Әйдә, утыр чанага, мин сине тәмугның иң түренә илтеп куям,—ди дә, ихахайлап көлеп жибәрә.

—Ы-ы-х... Ы-ы-х... Килде, алып китә, әжәл килде! Су, су салыгыз, авызым кипте!

Тик аның бу кычкыруын беркем дә ишетми, бары тик атасының ыңгырашуына Дамир гына йөгереп керә.

—Нәрсә булды, әткәй?

—Ы-ы-х... Нәрсә сорап торган була инде, монысы да... Белә бит инде...

Дамир башта гадәттәге соравын бирде, аннан соң картны юата-юата астын алыштырырга тотынды.

—Әткәй, мунчада су жылынгандыр, мин керләрне генә юып керим әле. Аннан соң тамак ялгап алырбыз,—дип кечкенә бала белән сөйләшкәндәй сөйләнеп чыгып китте.

Кырыктан узган ир бу эшне ияләнгән гадәт буенча тиз-тиз генә башкара иде. Бүген исә, мунчага килеп керү белән атасының йомышын йомышлаган жәймәләре салынган ләгәнне тотып атты да, йөзен каплап сулкылдап елый башлады. Ачык калган ишектән кәкре койрыгын дустанә болгап Сарбай килеп керде һәм аптыраулы караш ташлады. Аның хужасын мондый халәттә күргәне юк иде әле. Куып чыгаручы булмагач, маэмай кыюланып китте, эчкә үк үтеп Дамирның бармак араларыннан саркып чыккан күз яшьләрен яларга тотынды. Эчендәгесен бушатыр кешесе булмаган Дамирга шул житә калды, ул этне кочаклап алып такмаклап ук елый башлады.

—Үлә дә алмады бит ичмасам. Үзен дә, мине дә газаплап ята. Гомер узып

бара. Яшьлегем шунын сасысын җыештырып үтеп китте. Әнә, яшьтәшләрем инде кызларын кияүгә бирә башлады, шапылдатып оныклар сөяләр. Ә мин ни күрәм бу дөньяда? Менә шул ләгән тулы авыру карт чүпрәкләреннән башка мин ни күрәм? Минем бит балаларым да, хатыным да юк. Авыру карт карап ятмыйм дип хатын туйдан соң ике айдан ата-анасына кайтып китте. Инде бу юлы әллә үләме, әллә мин дә кешечә яши башлыйммы дигән идем, юк, тагын элеккечә үк. Әллә исәбе йөз ел яшәргәме инде?!

Озак елады Дамир, бөтен эч серләрен Сарбайга ачты да салды. Ялгыша икән Гыйсметдин карт, ялгыша, авырсына Дамиры, аның үлемен көтеп кенә яши. Элегрәк, абыйлары исән чагында кечкенә генә булса да өмет чаткысы бар иде, әткәйне бик кирәк булса аларга каратып булыр дип уйлый иде. Кичә соңгы өмете өзелде—соңгы абыйсы Зөфәрне җирләделәр, Дамирның сыеныр урыны калмады. Хәзер инде аңа бу йөген ахырынача үзенә генә тартырга туры киләчәк...

Гыйсметдин Гөлҗиһан карчыкның сузып-сузып Коръән укуын тыңлап ята. Кара-кара, фурмысын китерә бит бу Гөлҗи тәре. Әйтерсең гомере буе абыстай булып йөргән...

Коръән уку тәмам булды булса кирәк. Карчыклар гөрләшеп алдылар.

—Иләһи Әмин.

Тагын Гөлҗиһан карчыкның догасы ишетелде.

—Йа, раббым, ошбу укылмыш Каләм Шәрифнең әҗер савапларын Гыйсметдин улы Зөфәрнең рух шәрифләренә багышладым...

—Ы-ы-х... Әйе, Зөфәре вафат бит әле Гыйсметдиннең... Ы-ы-х...

Тик догага кулларын кушырган карчыклар бу ыңгырашуга игътибар итмәделәр. Гүя бу йортта кайчандыр барысын кан калтыратып тоткан Гыйсметдин юк та. Догадан соң чират ашка җитте, өстәлгә бәлеш чыкты булса кирәк, беравык берәү дә сөйләшми торды, авыруга бары тик аратирә кашык шакылдавы гына ишетелеп торды. Тамаклары туйгач, карчыклар авыл хәлләрен сөйләшә башлар. Гыйсметдин мәет ашларының нәкъ менә шул өлешен ярата. Ул бит хәзер дөньяны улы Дамир күзлегеннән генә күрә, ә монда ни дисәң дә, яна караш...

Әмма бүген корткалар нигәдер гайбәт сатмадылар, Дамирны жәлли башладылар.

—Соңгы абыйсы да үлеп китте. Берүзенә авыру атасын карау авыр булыр инде, бичара.

Бусы Сабира кортка тавышы, таныды аны Гыйсметдин.

—Гыйсмигә дә күп калмагандыр инде, иншалла, озак азапламас, үләр. Әле бүген төшемдә салам өйгәннәрен күрдем, мәеткәдер инде.

Монысы—Камәр карчык. Хы, мине тизрәк үтерәселәре килә. Менә, тотыгыз! Үлми әле ул Гыйсметдин, үлми. Ул әле сезнең барыгызның да үлем хәбәрен ишетәчәк!

—Гөнаһлары зур Гыйсметдиннең, гөнаһлары. Шулар тотып тора аны җир йөзендә, шулай газаплый. Тәүбәгә килмәсә, үлә алмас, ятимнәрнең күз яшьләре төшми калмый ул. Әллә сез аның бер-бер артлы дүрт малае үлеп китү тикмәгә генә дип уйлыйсызмы? Юк, каргыш тотты, каргыш. Теге чакта, сугыш вакытында, улын күмеп зираттан кайтканда Миңсылу җан ачысы белән каргады бит аны. Фәрештәнең "Амин" дигән минутына туры килгәндер, әлегәчә барысы да нәкъ аныңча бара.

—Ы-ы-х! Ах, ананны! Кара син бу Гөлҗи тәресен, нәрсә сөйли. Ы-ы-х!

—Әй, Гөлҗиһан ахирәт. Алайса Гыйсметдин Дамиры үлгәннән соң гына үлә булып чыга түгелме соң? Әстәгафирулла, тәүбә диген.

—Шулай, Камәр, шулай. Соңгы улы да үлми торып Гыйсметдин үлә алмас, җәһәннәм аны кабул итмәс. Тәкъдире шул.

Карчыклар сүзләренә бирелеп китеп Дамирнең керүен дә, әңгәмәне тынлап торгач ашыгып өйдән чыгып китүен дә абайламый калдылар.

Әбиләр йортка, аш-суга дога кылдылар да, дәррәү кузгалып кайтыр юлга чыктылар. Йорт хуҗасы Дамирның озата чыкмавына, гомумән, сәдакасен өләшкәннән соң бөтенләй күренмәвенә игътибар булмады—кайгысы зур бит, берәр җирдә моңланып утырадыр. Тик ишек алдына чыккач кына шомлана калдылар. Хуҗаларының эте Сарбай лапас ишегенә карап әллә елап, әллә улап утыра иде.

—Эт улау хәерлегә булмас, мәеткәдер инде, мәеткәдер,—диде туксанын тутырып килсә дә үлемнән үзе бик куркучан Камәр карчык.

—Туктагыз ахирәтләр, кереп карап чыгыйм әле.

Гөлҗиһан абыстай, бозлавыкта таеп егылудан курыккандай, сак кына басып лапаска кереп китте.

—Ләхәүлә үә лә куәтә... Дамир асылынган, керегез тизрәк!

Биш карчык килеп аякларыннан күтәрергә азапланганда ир исән иде әле. Әмма ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән корткаларның кулларында таза ир-атны күтәреп элмәктән салдырырдай егәр калмаган шул, калмаган...

—Әйттем бит, төшемдә салам өйгәннәрен күрдем, дип. Салам өйсәләр, мәеткә инде ул,—дип сөйләнде Камәр корткa кичен бөтен авыл карчыклары янә Гыйсметдиннәр йортына мәет сакларга җыйналгач.

Бу юлы сүз бер генә юнәлештә барды—үлем турында. Дөресрәге, Гыйсметдиннең үлеме хакында. Хәер, Гыйсметдин моңа үзе дә әзер иде инде, аны хәзер бу дөньяда тотып торырлык берни дә калмады—каргыш кабул булды.

Дамирның өчесе дә, җидесе дә Коръәнсез генә узып китте. Гыйсметдин исә көн дә әҗәлен көтте. Тик үлем генә килмәде дә килмәде. Көненә икеөч тапкыр авылның ахирәттә җәннәт өмет итүче корткасы кереп астын алыштырып, тамагына ашатып китә. Безнең якларда кешеләр ярдәмчел бит. Әгәр зур каза килсә, гомер буе бөтен нәсел-нәсәбәтләре кан дошман булып йөрүчеләр дә иске үпкәләрен оныта. Тома ятим калган Чулак Гыйсмине дә ташламадылар, үткәндәге бөтен явызлыгын онытып, өй буенча чиратка салып тәрбиягә алдылар. Әй, гарьләнде моңа Гыйсметдин. Үзенең көчсезлеген, мескенлеген күреп гарьләнде ул. Аның белән хәтта дошманлашмыйлар да бит! Ничек инде ул, заманында бөтен авылны кан калтыратып торткан кеше, шушы көнгә калды...

—Ы-ы-х.. Нәрсә, җәзалыйсыңмы, өстән генә минем сызлануларыма, кимсетелүемә карап кәеф чигәсеңме? Нәрсә көтәсең, инде бит минем сина бирер әйберем калмады, улларымны алып бетердең, сәламәтлегем юк, ник җибәрмисең әҗәлеңне?!

Гомере буе ни Алланы, ни шайтанны танымаган Гыйсметдин шулай итеп көннәрен күкләргә җикеренеп уздыручан булып китте. Сүгенә-сүгенә дә, куркыныч төшләр тулы йокыга тала.

—Чулак Гыйсминең хәле ничек икән?

Авылның ике кешесе очрашса, берсе тарафыннан бирелә торган гадәти сорауга әйләнде бу сүзләр. Ә ул үлмәде дә, үлмәде. Гүя күкләр генә түгел, җәһәннәм дә аннан баш тартты. Әйтерсең, җир-ана бу тереләй чери башлаган, тире белән сөяккә генә калган, үз нәҗесенә батып ятучы языклы адәмне куенына алырга чиркана, җирәнә иде. Инде соңгы улы Дамир гүр иясе булганга да, саташулы төшләр, газап, ләгънәт тулы ярты ел узып китте,

ә ул исән. Бу карар жире дә калмаган тәндә жанның нәрсәгә эләгеп торуы да аңлашылмый.

—Аллаһының кодрәте,—ди вәкарь сакларга тырышып Гөлжиһан абыстай.

Бер көнне исә Гыйсметдиннең төшенә гомер иткән карчыгы, Гөлзифасы керде. Үзе яшь, чибәр икән, биш улы да янында, барысы да аны чакыралар. Менә Дамиры читкәрәк чабып китте дә:

—Әтием, тот мине, тот,—дип уйнарга дәшә.

Әллә кайдан гына Сәлим хәзрәт пәйда булды:

—Тәүбәгә кил, Гыйсметдин! Житәр, күп яттың фани дөньяга ябышып. Тәүбә кыл!

Бу юлы Гыйсметдин йокысыннан жинеләеп, күңеле нечкәреп уянды. Инде ничә ел төшенә кермәгән хатынын, балаларын күрде бит! Бишектән төшкәннән бирле яшь чыкмаган күзләреннән ике тозлы тамчы сытылып чыкты да, жыерчыклы йөз буенча тәгәрәде. Гыйсметдин елый иде. Яшьле күзләрен түшәмгә текәде ул. Юк, юк, түшәмгә түгел, күкләргә бакты һәм Аллаһыга мөрәжәгать итте. Әмма, галәтенчә, жикеренү түгел, тәүбә, ялвару иде бу.

—Ы-ы-х... Раббым, коткар мине бу газаплардан, кичер гөнаһларымны...

Сүзсез дога кабул булды, тәмам йончыган тәнне жан ташлап китте. Соңгы сулышын алганда картның кипшергән, яргаланган иреннәрен бер тамчы су белән чылатыр кеше дә юк иде...

Нәкъ шул көнне авылда тагын бер кеше үлде. Колхозның электригы Буйдак  Рамазанны ток сукты. Икенче көнне ике тома ятим Гыйсметдин белән Рамазанны янәшә жирләделәр. Авыл халкы картның озак үлә алмый ятуын электрикның үлеме белән бәйләде. Имеш, Рамазан атасы Гариф сугыштан кайткач, жиде айдан туган булган, имеш, ул бөтенләй дә Гарифныкы булмыйча, Гыйсми малае икән. Шуна да Гыйсметдин карт ул үлгәч кенә жан тәслим кылган... Ярый, сөйләсеннәр әйдә, тел сөяксез бит. Чынлыкта ничек булганын барыбер белүче юк.

Гыйсметдиннең нигезен кычыткан, алабута басты. Кеше яшәмәгәч, йорт үзе дә әкренләп жимерелә башлады, шомлы төс алды. Мөгаен, шунадыр, хужасыз ятканны бер дә урынында тотарга яратмаган авыл халкы бу йортның бер сайгагын да алып чыкмады. Авыл башка якка үсә башлагач, бу өй басу кырыенда ялгыз гына утырып калды. Гүя ул—имансыз елларның шомлы бер һәйкәле. Балалары тыңламый башласа, ата-аналар аларны шул йортка илтеп кую белән куркыта. Шуңа да бәян иткән вакыйгалардан соң күп сулар акса да, анда катнашучылар күптән гүр иясе булса да, авыл халкы озак еллар үлем көтеп яткан картны онытмый, әле дә искә алып гыйбрәт итеп сөйли.

*Илдус Гыйләҗевкә 60 яшь*

## ҖИР КИТАБЫН КЕМНӘР ЯЗА...

Шагыйрь һәм җир китабы... Сәер янәшәлек түгелме? Һич юк. Илдус Гыйләҗев иҗатын белгән һәркем бу билгеләмә белән килешәчәк. Чөнки ул чын-чыннан туган җир, туфрак, туган төбәге, аның авыллары (Азнакай, Урсай, Балтач, Туйкә... Нинди матур, шагыйранә яңгыраучы исемнәр!) белән мәңгелеккә бәйләнгән шагыйрь. Сибгат Хәким сүзләрен үзгәртеп әйткәндә, "бөтенләе белән җирнеке" ул... Әйе, 1946 елның 15 гыйнварында Урсай авылында туып, мәктәп тәмамлаган егет



Казанда—университетта югары белем алгач та, янә туган якларына кайта: колхоз председателе, партия райкомнарында яхшы ук зур түрә дә була... Орден-медальләр, премияләр иясе, депутат... Үзгәрешләр чоры башлангач, янә күмәк хуҗалыкны җитәкли... Менә шундый хезмәт һәм гомер юлы. Барсы да—туган якта, үз "кече ватаны"нда, Чатыртау, Ык буйларында. Шунда языла аның туган җиренә, якташларына булган мәхәббәтенең инде бөтен илхалкыбыз һәм дөнья язмышы белән бәйләнгән уй-хисләре тулы шигырьләре, китаплары... Әлеге "Җир китабы"... Әйе, "Кул белән чәчәләр, күз белән уралар" дигән табышмак бик урынлы монда: Илдус иҗаты, һичшиксез, тозлы туфрак тәме, тир, күз яше, горурлык, халыкның киң күңеллеге, акыл-фәһеме, тәҗрибәсе белән сугарылган. Ул—чын мәгънәсендә буразнадан баш төртеп калкып чыккан шигъри иген басуы.

Китап исемнәренә генә игътибар итик: "Җилкенү", "Өмет ае" (нигәдер бу атама миңа сабаннан соң җылы яңгырлар көткән июнь ае кебек тоела!), "Серле мәгарә" (бусы да бу төбәк өчен бик табигый табыш: Азнакай якларының Пугач явы эзләрен саклаган урыннары, йә бакыр базлары күзаллана!), "Хак сүз" (бу да остаз шагыйребезнең "Җылы сүз" дигәне кебек, җанга җылы бирүче исем!) һәм "Чатыртау тылсымы" (бусы да әдәбият сөючеләргә бик якын. Марсель Галиевтә дә, Нур Әхмәдиевта да ул тылсымлы тау шигърияте белән аз очрашмадык... Матур исем ул!)... Алар да шагыйрьнең табигатенә ятышып тора кебек: барсы да туган җир сулышы белән өртелгән, туфрак, үлән-чәчкә сутыннан калыккан шигъри авазлар... Табигыйлек, ихласлык, күңел киңлеге, юмартлык, дусларына тугрылык, ир ныклыгы һәм инде олпатлык белән бергә нәкъ Бёрнсча гадилек, садәлек... Шулай: туган ягында яшәп, шигърияткә, иҗатка, фән-белемгә тугры калган талантлар бездә санаулы гына: Фоат Садриев, Дамир Гарифуллин, Гарифҗан Мөхәммәтшин һәм Илдус дустыбыз... Әйе, сука артыннан йөреп язылмыйдыр аларның әсәрләре (Бёрнс чоры түгел!), әмма "сукачыдан һич ким армый шагыйрь акыллы җыр язган чагында" дигән юллар да хәтерләрдә бит. Бигрәк тә бүгенге кебек болгавыр-болганчык заманда!

Мең-мең мәшәкать, хезмәттән бушап торган арада гына язуда түгел монда хикмәт, ә менә бүген, татарны саклап килгән меңьеллык изге Авыл бетеп барганда нишләргә шагыйрьгә? Ничәнче кат инде бу "ватан китә". Ә "изге сөт" калырмы соң?

Авыл белән үзебез дә, димәк, шигърият тә бетәрме? Кая барабыз?

Менә шундый чорда шагыйрь гаять борчулы, әрнүле, хәтта дөнья агышына үпкәле, ачулы, ләкин һаман да дөньяны, тормышны, матурлыкны ир-егетләрчә ярату белән сугарылган булу гаҗәпмени? Шулай гына языла ала аның "игенче догалары", "иң зур куаныч" дип эзләнүләре, йәки "Сусадык, су бирегез" дип рухта кангырганнары... Монда инде шигъри, юмарт, бай җанның кырыс дөнья белән тартышы... Әмма барыннан да бигрәк, ул—халык, милләт гаме белән яшәүче ир-узаман, ил агасы, аксакал булып күз алдына баса. Бүгенге көндә шагыйрь миссиясе—шушы!

Шуна да хәзер сүзне кистереп, катгый рәвештә әйтә, күрсәтә, ышандыра белүче булып күзаллана ул шигырьләрендә:

*Болай гына гади күренәбез,*
*Күзәнәк без—барсын тоючы.*

Хак сүзләр! Инде бу уйлануларда халкыбызның рухи тарихын тирәнтен тоеп аңлауны, ачы язмыш, хәсрәт тулы ил юлын фәлсәфи аңлатуны күрәбез. Ә ул юл—безнең йөрәк аша уза.

*Күпме сандугачлар Себер киткән*
*Җырын белмәгәнгә карганың.*

Узган гасырның фаҗигаләре генәме соң бу? Бу бит тарихи аң, хәтер тавышы, җан авазы... Безгә, ягъни мәркәздә, җылырак урында яшәүчеләргә караганда нығрак, күбрәк өшемиме бу җан? Әнә бит ни ди ул:

*Халык манкортлаша—шуны күреп,*
*Шагыйрь булып яшәп карагыз.*

Яшибез шул әле, яшибез: үз-үзебезне төрле алдаулар, "тәти"ләр, мактаулар белән юатып, тынычландырып (бер Айдар Хәлим генә андый түгел, ахрысы...), чын конформистлар булып беттек. Ә Мәскәүләр һаман якадан җибәрми, өркетә, чигенергә мәҗбүр итә. Күпләрне, зур-зур агайларны...

*Исәнлеген бирсен—илен сатып*
*Көн күрүче әрсез мүкләкләрнең,—*

ди шагыйрь ачы каһкаһә белән. Һәм болай дип тә өсти:

*Чит милләткә хезмәт итүчене*
*Аңлап була... булмый кичереп.*

Мондый юллар элекке абыз-агайларның оран-нидасы кебек яңгырый, безнең карашка. Һәм бу аваз-әрнүләр шагыйрьнең юлдашы да: кайда да аңардан калмый, ул АКШ та йә БМО да Татарстанны, халкын белмәүләренә, танымауларына ачына, ярсып бәхәсләшә. Үзебездә дә адым саен "елый торган ташлар"га юлыга ул, "мәетләрдән өелгән пирамидалар" күрә, нәфрәтләнә, ләгънәтләр яудыра. Сөекле халкының кимчелекләрен әйтүдән дә тайчанмый һәм үз дөньясын—шатлык, кайгысын да яшерми яза. Һәм алар шәхси тойгылар, аһ-зарлар булып түгел, ә ил, халык гаменә тоташ булып хәтердә кала, ихтыярсыз, аңа кушылып янасың, ышанасың. Менә бу, мөгаен, Илдус Гыйләҗев шигырьләренең иң җете ягы: әйе, югалтулар, сагышлар бәрабәренә килгән шигъри табышлар бу. Шагыйрь иҗатының бу хасиятен аның турында әтрафлы мәкаләләр белән чыккан Р. Фәйзуллин, Н. Әхмәдиев, Г. Морат кебек каләмдәшләре дә ассызыклап әйттеләр.

Каләмдәшләре дигәннән, шуны да искә алып үтәсе килә: Илдус дустыбыз университетта (безнең сөекле татар теле һәм әдәбияты бүлегендә!) укыганда, группадашлары арасында соңыннан әдәбиятта ныклы урын алачак, шагыйрь, әдип, журналист булып киң танылачак Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Нур Әхмәдиев, Рафаэль

Сибат, Фәрит Гыйльми, Асия Юнысовалар булды. Илдусны ул чакта без әле белми идек, шигырьләре белән дә күренмәде ул шәкерт чагында. Әйе, Илдус шигырьгә башлап язучы булып түгел, үзе сөйгән туган җиренең хуҗасы, әлеге җир китабы битләрен язган шагыйрь булып килеп керде. Һәр яктан өлгергән ир-егет булып килде. Һәм әлеге шәриктәшләре арасында да сынатмады, соңламады дип уйлыйм.

Быел нәкъ менә М. Әгъләм, М. Галиевлар буыны инде алтмыш яшен тутыра икән ләбаса. Уза гомерләр! Ә Илдус Гыйләҗев атлы (ул ел башында тууы белән дә бәхетле, бәлки?) үзенчәлекле, талантлы шагыйребез—күркәм юбилеен уздыручыларның беренчесе. Котлыйбыз!

**Рәдиф ГАТАШ**

---

# Илдус Гыйләҗев

# ҖИР ӨСТЕНДӘ УЗГАН БЕЗНЕҢ ЕЛЛАР

## Шушы якка карап елмаермын

**Яраттым мин җирне! Үкенгән юк**
**Туган яктан чыгып китмәвемә...**
**Кояш нуры, хәләл көчем сеңгән**
**Амбарларга салган икмәгемә.**
**Сандугачлар җырын ятлап йөрим,**
**Күбәләкләр куна гөлләремә.**
**Татар кызларының күз карашы**
**Нурлар өсти үткән көннәремә.**
**Һәр мизгелен олы бәхет саныйм**
**Җир өстендә узган елларымның.**
**Оҗмах бакчасында йөргәндә дә**
**Туган якка карап елмаермын...**

## Бирешмәс җайдак

**Гомер бит ул, бер карасаң,**
**Ике нокта арасы:**
**"А"дан алып "Б"гә кадәр**
**Җанны саклап барасы.**
**Тормыш-чаптар—җилкәсендә**
**Йөртә сине, җилдереп,**
**Сабантуйга чыккан кебек,**
**Җиңелдереп, җиңдереп.**
**Нокталарны тоташтырган**
**Сызык кына күптөрле:**
**Озыны бар, кыскалары...**
**Азагы һич көттерми.**
**Бәхет шулдыр: өлешеңне**
**Егылмыйча узалсаң;**
**Яшәү көчен, сүрелдерми,**

Күп елларга сузалсаң.
Алтмыш кисәк юл үтсәм дә,
Ялыккан юк, ярышам:
Чаптарымның ялларына
Чытырдатып ябышам...

## Биш тезләнү

Әткәй-әнкәй каберенә
Кайгы тулы башым куеп,
Тезләнгәнем булды минем
Ятимлекнең яшен коеп.
Читтә йөреп, күңелемне
Томаласа дала төсе,
Илгә кайтып тезләндем дә
Иснәдем гөл-үлән исен.
Язмышларны бергә бәйләп,
Бер итәргә гомер юлын,—
Тезем чүктем, сөйгәнемнең
Мәңгелеккә сорап кулын...
Ил алдында бурыч үтәп,
Корал тотып юллар үттем.
Тугрылыкка антлар әчеп,
Тезем чәнчеп байрак үптем.
Намазлыкта дога укыйм,
Уңга-сулга башым борып.
Бер Аллага сәҗдә кылам,
Тезләремә кашым орып...
Сәбәпләр дә җитәрлектер
Ир-егетне сыгар өчен.
Тик барыбер кайгыларның,
Дошманнарның җитмәс көче:
Тезләремне бөгеп тормам,
Тешне кысам, әмма түзәм.
...Килешмәсәң, фани дөнья,
Минем алда үзең тезлән!..

## Кадерең булса гына

Ханнар безгә, элек, китерелгән
Дала якларыннан, Кырымнан...
Чыңгыз оныклары гаярь булган,
Яу чапканнар, татар кырылган.
Соңрак—килгән урыс патшалары,
Алары да кимен куймаган.
Теләгәнчә изгән, чукындырган,
Аскан-кискән, типкән, кыйнаган.
Җирле халык түзгән, тешен кысып,
Туган җирдән мәгәр китмәгән.
Ташбака күк, каты тышчасына—
Үз эченә кереп бикләнгән.
Килмешәкләр чоры үтте инде,
Үз кешебез—әмер бирүче!
...Кабырчыкны салып ташлар өчен,
Кирәк икән—кадерең белүче...

## Монсы кыенрак

Көнчыгышка юл ачылган
Зур ханлык аугач кына:
Мәскәү—МӘСКӘҮгә әйләнгән
Казанны алгач кына.
Заман башка. Киләм дисәң,
Йөрмә син сәнәк белән—
Яулап күрсәт сәнгать белән,
Акыл һәм сәләт белән...

## Бүгенгеләр кайда?

*...Сез кирәк, торыгыз,*
*Торыгыз, Мусалар!*
Сибгат Хәким

Үз халкын яклаган каһарман
Үлемсез икәнен кисәтеп,
Киткәннәр бу якты дөньядан
Татарның кемлеген күрсәтеп.
Көрәшнең туктаган чагы юк,
Без—һаман почмакка кысылган...
"Террорчы", "ваһһабчы", "дошман" дип
Атала хәзер һәр мөселман.
Сез кирәк, батырлар, кайда сез?!
Юл куймыйк әшәке гайбәткә.
Бүгенге Алишлар... Мусалар...—
Торыгыз!
...Булсагыз, әлбәттә...

## Гадел булыйк дисәк

Нинди хәлгә илтеп җиткердек бит,
Уйлый китсәң—хәлләр шаккаткыч:
Шәһидәләр йөри дөнья буйлап,
Билләренә бәйләп шартлаткыч.
Хатын-кызлар чыга үч алырга,
Нәселендә ирләр калмаса.
Гафу итә алмый Кавказ халкы—
Дошманының каны таммаса.
"Террорчы" дип, "кыргый халык", диеп
Гаепләргә, зинһар, ашыкмыйк:
Иң беренче башлап кем суккан соң?
Кертик башта шуңа ачыклык!

## Дәвамлы хыянәт

"Үз иркебез белән кушылдык без,
Яу чапмадык, сезгә карышып",—
Дип "Хуҗага" бирәү гозер көйли,
Билен бөгә-бөгә, тырышып.
Калҗа сорап килгән. Аңа өстәп,
Үз тәхетен кирәк сакларга...

Тарихтан да файда таба белә
Түрә халкы андый чакларда.
"Орышмыйча гына бирелдек",—дип
Оран салу хурлык түгелме?
...Үзең теләп ничек бирмәк кирәк
Туган җирне, халкың, илеңне?!
Безнекеләр, әнә, көрәшкәннәр,
Җиңелгәннәр... әйе, аяныч.
Җиңгән булырлар да иде, бәлки,
Булган булса янда таяныч.
Алар даны, алар батырлыгы
Хәтеремдә көн-төн яктыра.
...Кул күтәреп иркең югалтканчы,
Җиңелүең—мең кат яхшырак...

## Үкенеч ки

*Казандагы дусларга*

Минем бәхет—сездән читтә яшәү,
Кәнәфиләр даулап йөрмимен.
Ничегрәк сезнең "чәйнәшкәнне"
Ишетсәм дә, үзем күрмимен.
Ah!
Бәхетсезлегем дә—читтә яшәү,
Яныгызга бик еш баралмыйм.
..."Татар башын татар ашый" торган
Гамәлләрдән тотып калалмыйм...

## Ерак учак

Галәм учагыннан чәчрәп төшеп,
Утлы күмер җанны пешерә.
Унсигез дә тулмый дөнья куйган
Малаемны искә төшерә.
Төшерә дип әйтү дөрес булмас,
Киткәне дә юк ла хәтердән.
Рухы безнең янда, тел әйләнми
Ташлап китте диеп әйтергә.
"Вакыт узгач, бераз җиңеләер,
Түз, сабыр бул",—диләр туганнар.
Кая җиңеләйсен... өзелмәслек
Чылбыр белән бәйләп куйганнар.
"Кеше китә—җыры кала",—дибез,
Җырлап булмый, күмер пешерә.
Шул учакны барып тапмый торып,
Тынгы килми мәллә кешегә??

## Бүлешер идем дә...

Бер бәхетсез булдың син дөньяда,
Нишләсәң дә, китә кирәгә.
Ярдәм итә алмыйм, теләсәм дә
Бик бәхетле итеп күрергә.

"Күрешик тә, әйдә, киңәшик", дим,
Тәкъдимемне кире кагасың.
Ияләштерүләр күп җиңелдер
Урмандагы бүре баласын.
Нәселеңнең булган гөнаһлары
Сиңа гына әллә төшкәнме?
Котың очар, әгәр сөйли калсам
Синең хакта күргән төшләрне.
Дөрес җирдән аны эзләмисең,
Белмәвеңә калам гаҗәпкә.
...Бәхетне бит була табып кына,
Биреп торып булмый әҗәткә...

## Гомер фәлсәфәсе

Заманында без дә дөнья тоттык,
Чибәр кызлар кочтык, шәраб йоттык.
Матур-матур дәртле җырлар оттык,
Диңгез буйларында җан җылыттык...
Ни теләсәк, кулдан килә иде,
Баш өстендә кояш көлә иде.
Дан-шөһрәткә тормыш күмә иде,
Дошманнар да таный, күрә иде.
Хәзер—әллә шиңдек, көч-дәрт бетте,
Хәтта хәмер үтми, желек кипте.
Кушаяклап еллар мәллә типте?!.—
...Намазлыкка менәр вакыт җитте...

## Ние бар...

Сөйгән ярларны без көттермәдек,
Чыгып чаптык карда, буранда—
Вакытына барып җитә идек,—
Йә, ние бар, дәртең булганда?
Бер эштән дә куркып яшәмәдек,
Каеш янда—билгә буарга.
Тауларны да куйдык күчергәләп,
Ә ние бар, саулык булганда?!
Бу дөньяның бетмәс хәсрәтләре
Әрсезләнеп тынны буганда,
Кайгыларны суга агыздык без...—
Ние бар соң, исән булганда!

*Татар хикәяләре хәзинәсеннән*

## Идрис Туктаров

# ҮЛЕМ ЭШЕЛОНЫ

I

Без, иллеләп тоткын, пычрак, нарсыз вагонга тулып, өчкә-дүрткә бөкләнеп утырдык. Тыгыз. Һәрберсенә ипле урын кирәк: талашалар, кычкырышалар...

Мөхәммәтҗан исемле иптәш:

—Ха! Тыгызмыни? Тыгыз булса, чыгып торыгыз, икенче поездны, курьерскийны көтегез!—дип чәнчеп алгалый.

Мөхәммәтҗан—дәртле, көчле егет. Аның әз генә дә кайгырганын, офтанганын беркайчан күрмәдем. Ул гел җыр белән, көлке ачы сүзләр белән юана, башкаларны да юата белә. Мөхәммәтҗан белән без ике дус: серләребезне уртаклашабыз, киләчәккә планнар корабыз, күргән-белгәннәрне сөйләп, бик күп, бик авыр минутларны да күнелле үткәрәбез. Ул:

—Бу көннәрне сак булып, җилкә тамырларына утырта барырга кирәк. Шулай иткәндә генә айлары, еллары җинел үтәр. Минем, чорт возьми, мондый айларны җинел генә уздырасым килми. Төкерегез барысына да!—ди торган иде.

II

Ишекләрне шартлатып бикләделәр. Тик люкларны гына (конвойлар торган яктан) ачык калдырдылар.

Китәбез дип көтәбез. Әзме-күпме тынычландык. Туп тавышлары һаман дулыйлар. Туп тавышлары якынайган кебек.

—Ну, кызыллар безнең юлны киссәләр!—дип, кайсыберәүләр алдагы көннәрнең нинди хәбәр китерүен дә эзли башладылар.

Сәгать уникене китте. Ашарга, эчәргә биргәннәре юк әле. Эвакуацияне ишетеп, күп иптәшләрнең ата-аналары, ашамлыклар алып, озатырга килгәннәр, ләкин аларны эшелон янына китермиләр, сөйләштермиләр, әйбер-фәлән бирдермиләр. Китергән әйберләре эченнән запискалар эзлиләр. Икмәк эченнән исәнлекне генә белдергән язу кисәге чыкса да, икмәкне кире кайтарып, китергән кешене эт урынына сүгәләр, төрткәләп җибәрәләр. Шулай да бик оста яшерелгән запискалар вагон эченә житкәлиләр. Шундый запискаларның берсендә "Кызыллар ... авылына керделәр. Тоткыннарны коткарырга ашыгалар..."—дигән сүзләр очрады. Хәер, без үзебез дә кызылларның якынлашуларын сизгән идек. Котылырбыз, дип кенә ышанып булмый.

III

—Тукта!.. Ни бар?

Люктан карадык. Еракта яхшы тройка җигелгән экипаж күренде. Тирә-ягыннан кавалеристлар чорнап алган. Килеп житте. Ул юан полковник икән. Эшелон начальнигы булса кирәк. Иптәшләргә дә:

—Начальник появился—бүрекләрегезне киегез!—дигән идем, Мөхәммәтҗан:

—Лыгырдама! Алар алдында бүрекләребезне кайчан салганыбыз бар? Шулай бит, иптәшләр?—диде.

Менә полковник тарантасыннан төште. Эшелонга табан корсагын этеп килә. Житте. Һәрбер вагон янына килеп сораша. Безнең вагоннан да:

—Кто имеет жалобу?—дип сорады.

Мөхәммәтҗан алга чыгып, ирония белән:

—Мы весьма довольны,—диде.

Полковник аңа бик нык текәлеп, байтак кына карап торды да дәшмәде—китте.

Озак вакыт үтмәгәндер, декапот “уу-ух!” дип бер кычкырды да кузгалдык—киттек. Кая киттек, кайсы җирләргә баш олага—белгән юк. Белергә дә теләмибез: бик арылган, уйлар чуалган. Йокы—үтереп килә. Йокларга теләп ятсаң, йоклап булмый.

Әнә бер иптәш чүгәләп утырган да уйга чумган. Әнә берәү йокы аралаш саташа:

—Әни!..

Бүтәннәр анардан көлешеп:

—Әкренрәк, улым, тиздән җитәрбез,—диләр.

Башкорт егете Әхәт көчле, нечкә тавышы белән “Ашказар”ны сузып җибәрде. Шәп җырчы. Ана:

—Ну да җырлыйсың, Әхәт туган!—дисәң, ул:

—Һай, егетләр! Сез минем җырларымны печән чапканда, кырда тыңласагыз икән!.. Монда күкрәк кысыла... Һава кирәк... Ялан кыр кирәк!—ди.

Аңа гел әрнеп карыйсың: көннән-көн беткән төсле ул. Аның белән сөйләшә башласаң да, ул үзенең аерылып калган япь-яшь бикәчкәен генә сөйли. Иптәшләре Әхәт турында әңгәмә ачканнар:

—Җырлый ул. Гел җырлый. Шуңар күрә чыдамас ул, егетләр, бетәр ул!

—Юкка кайгырып беткәнче, җырлап бетүең артыграк түгелмени?

—Син кайгыр да, җырла да, бетмә дә!

—Әхәт андый түгел шул...

## IV

Безне бик ашыктырып алып баралар. Кояш әле югары. Ике-өч станцияне үттек. Ашарга, эчәргә биргәннәре юк. Ашыйсы алай ук килми, әмма эчәргә, эчәргә!.. Бер генә тамчы су эчәргә!..

Кызу. Тиргә коенабыз, утта кайныйбыз. Урыннан торсаң, күзләр томаланып китә дә кире урыныңа егыласың...

Шәп барганлыктан, вагон “авам-авам” дип чайкала. Вагон уртасына утыртылган данлыклы параша да түгелә башлый; тирәдәге иптәшләрнең өсләренә чәчри, идәнне буйый. Һава тагын тончыктыргыч-бөркү хәленә кайта. Параша тулган булса да, аны бер тәүлек үтмәс борын түктермиләр. Ә инде ул түгелгән вакытта—безгә бәйрәм! Чөнки вагон ишеге шул вакытта гына азрак ачык була. Барыбыз да талаша-талаша ишек янына килеп тыгылабыз. Ләкин парашаны бик тиз кире алып кайталар.

Тагын караңгы, тагын бөркү, тагын әрнү... яну... көю... Әле ярый, люкларны япмыйлар.

Байтак көннәр, байтак төннәр, шомлы, йокысыз, тынычсыз төннәр үтәләр...

Әхәт бикәчкәен сөйли дә җырларга тотына, җырлый-җырлый да тагын бикәчкәен сөйләргә башлый... Шәриф күзләрен акайтып:

—Бетте баш, бетте баш!—дию еннән башканы белми. Шәриф—арада иң тупас кеше.

Хәким карт арыш камырыннан катырып ясалган дисбесен тарта-тарта:

Алмачуар тай булмас, дәй,
Егет урламай булмас, дәй,
Урлап-урлап тәүбә кылса, дәй,
Әүлиядан ким булмас, дәй...—

дигән шул ук бер җырны әллә йөз кат җырлый инде шунда...

Җырлап арыгач:

—Вәт заман, безне болай итеп кая алып баралар инде?—дип үз-үзе белән сөйләшә.

Арабызда бер чех офицеры да бар. Ул нигә эләккән? Эләгеп тә нигә погонын салмый? Шуна барыбыз да аптырашта калдык. Кайсылары:

—Ул шпион булырга охшый,—дисәләр дә, ышанып бетермибез.

Мөхәммәтҗан аны, бигрәк тә погонын ташламаган өчен, бертуктаусыз сүгеп килә:

—Господин поручик! Погоныгыз искереп уңа башлаган ич. Нигә әзрәк ялтыратып, яңартып алмыйсыз?

—Ничек соң аны яңартыйм. Хәзергә болай да ярар әле.

—Мин беләм ничек ялтыратырга.

Офицер:

—Ничек?—дип әйтергә дә өлгермәде, Мөхәммәтҗан аның погонын шытырдатып өзеп алды да:

—Менә хәзер алтының очты!—диде.

Тирә-якта көлеш, кычкырыш, сызгырыш китте:

—Пропал совсем господин поручик! Ха-ха-ха!..

## V

Иркутскига җитәрәк эшелондагы иптәшләрдән берничәве акылдан шашты. Аларны аерым бер вагонга бикләделәр. Алар кычкыра башладылар; сөйләшкән җирдән тукталып, ирекле-ирексез тынлый башлыйсың. Шашканнарының берсе өзлексез:

—Я не виноват, я не виноват!—дип кычкыра, арганчы кычкыра да тына.

Соңыннан тагын шул ук сүзне кабатларга тотына. Алар шулай ике тәүлек буена кычкырдылар. Соңыннан кинәт тындылар. Үлек гәүдәләрен юлга ташлап калдырдылар.

Барабыз. Иркутскига җитәбез. Станциягә якынлашыр алдыннан конвоирлар ата башладылар. Эшелон туктады. Конвоирлар сүгенәләр, кычкырышалар. Шпорлар тавышы ишетелде...

Төш. Ахры, бернәрсә дә күренми булырга кирәк: конвоирлар да, офицерлар да нервничать итә башладылар.

—Артларыннан паровозны җибәрергә кирәк!—дигән тавышлар ишетелә.

Шуннан соң гына берничә иптәшнең, люктан сикереп төшеп, качканлыкларын сизәбез. Алар өчен шатланабыз да, көнләшәбез дә: "Ах, без дә кача алсак!"—дип кызыгабыз. Шул ук сәгатьтә:

—Заколотить все люки!—дип, полковникның калын тавышы яңгырый.

Хәлләр тагын авырлаша. Дөм караңгы. Иртәме, кичме—белмибез, аера алмыйбыз. Чын мәгънәсе белән саташа башладык. Төсләребез—үлек төселәр. Хыялларыбыз—балаларныкы кебек. Берәребез тотына берәр вакыйга сөйләргә, аны әкиятләрдәгечә бетерә. Шулай алдаганы өчен бик нык лап озак-озак сүгәбез... Бүтәнебез сөйли башлый. Аны да элек яхшы тыңлыйбыз. Соңыннан ошамаган сүзләре өчен җикеренәбез... шулай...

Тагын байтак төннәр үтә... Маньчжуриягә җитәбез. Владивостокка кадәр алып баралар икән, дигән хәбәр тарала. Бу хәбәргә ышанабыз да, ышанмыйбыз да.

Безгә гел барабыз, гел барабыз кебек тоела. Безгә инде йөрмәгән юл, күрмәгән нужа да юк кебек. Безгә параша да, өсләребездә мыжлап йөргән бетләр дә бернәрсә түгел... Бер генә уй, тик бер генә уй барыбызның да миләрдә кайный:

—Ничек булса да төрмәгә җитәргә, җитәргә... Төрмәгә!

## VI

Эшелон Маньчжурия җирләре буйлап киткәч, Мөхәммәтҗан:

—Давай, туган, вагонның стенасын пәке белән тишәбез дә, карап барабыз,—дип кечкенә генә итеп тишеп тә алды.

Чынлап та, шәп булды бу: бердән карап барасың, икенчедән, җил кереп, вагонның һавасын әз генә булса да яхшырта, җиңеләйтә.

—Егет тә соң син, Мөхәммәтҗан! Кайдан уйлап чыгарасың шундый әкәмәтләрне!

—Мин исән чакта кайгырма! Үлмәсәк, исән булырбыз әле.

Мөхәммәтҗаннан күреп, башкалар да вагон стенасын берничә төштән тиштеләр. Маньчжурия юлы белән барабыз. Көндез кытай авылларын, кытай халкының эшләрен, көнкүрешләрен, аларның кырларын, бакчаларын күргәч, йөрәк бераз тынычланган булды. Төнлә—сопкалар, сопкалар арасыннан төшкән ай шәүләсе

йокларга ирек бирми. Әллә нинди өметләргә, хыялларга чумасын, чумасын да юанасын...

Ниндидер бер станциягә життек. Бу станциядә ике тәүлек газаплы эч пошуы белән үтте. Икмәк өләшкән вакытта бер татар конвоиры:

—Ну, кызыллар, сезнең эш—пиши пропал!—диде.

—Нигә, нигә? Ни булды?

—Атаман Анненковны көтәләр. Шушы ике-өч көн эчендә ул килеп житәргә тиеш. Билгеле, барыбызны да суеп чыгачак.

Без барыбыз да тып-тын булдык.

Тынычланып бетмәгән йөрәкләр тагын шашып тибә башладылар. Чынлап та, кайчан бетәр икән бу газаплар. Күпмегә кадәр чыдарбыз? Ләкин җавап юк. Тик Мөхәмммәтҗан гына элеккечә борчылмаган, бернәрсә дә белмәгән кебек.

Төн. Шпорларын шылтыратып, вагон яныннан сөйләшә-сөйләшә офицерлар үттеләр. Араларыннан берсе:

—Безгә аны көтеп булмас. Тирә-якта партизаннар да очрый башладылар. Кем белә, Анненков килә, дип көтә торгач, партизаннарны каршы алмыйк... Менә шунда булыр бутка...—диде.

Без:

—Аклар шүрли башладылар. Аларның бу куркулары хәерле бит,—дип үз-үзебезне юатырга керештек.

Юануыбыз юкка чыкмады: кузгалдык. Карап барабыз. Юлда (откоста) ватык паровозлар, вагоннар еш-еш очрыйлар. Ул вагоннарны, паровозларны откоска төшерүчеләрнең партизаннар булуын конворирлар сүзеннән генә ишетеп аңладык.

## VII

Владивосток. Иптәшләр: "Инде моннан да ары алып бара алмаслар",—дип сөйлиләр.

Эшелонны порт янына туктатып, люкларны, ишекләрне ачтылар. Безгә хәл керде. Рух күтәрелде. Порт эшчеләре безгә ашамлыклар, тәмәкеләр китергәлиләр. Алардан тирә-якта партизаннарның көннән-көн күбәюләре турында белешкәч, йөрәк шатлык белән тибә башлады.

Портта өч тәүлек яттык. Кайчан төрмәгә озатырлар икән, дип чыдамсызлык белән көтәбез.

Чөнки бер айдан артык юлда киләбез. Өсләребез тузан. Юынырга түгел, эчәргә дә су тансык булып китте. Өс-башта бетләр мыж тулы...

Менә вагоннардан төшеп тезелергә куштылар. Төштек, тезелдек. Барыбызны да санап чыктылар. Тоткыннарның күбесе чирле, вагон идәннәрендә тора алмыйча яталар. Халык җыелып безне карап тора.

Төрмәгә юнәлдек. Як-ягыбызга япон офицерлары ияргән. Әллә кемнәр бер алга, бер артка чыгып, кечкенә генә фотоаппаратлары белән "чик-чик" итеп, уралып йөриләр. Аркаларына баулар аскан кытайлар—носильщиклар кулларын бутап, елмаеп:

—Большевик, большевик,—дип безне каршы алалар.

Шунда Мөхәмммәтҗан фотографка карап:

—Дюжинасына күпме аласың? Тиздән без дә сезне төшерә башларбыз, тик бәясе кыйбатрак булыр,—дигәч, көлке күтәрелгән иде, сакчыларның җикеренүләреннән соң басылды.

Төрмәгә життек. Урынлаштырдылар. Мөхәмммәтҗан белән икебез бер камерага эләктек. Шунын шатлыгыннан, камерага кергәч тә, бер-беребезнең аркаларыбызга берәрне кундырып алдык.

Инде хәзер чыгуны кайгыртырга кирәк. Ничек булса да бер чыксак, сопкаларны бер итеп, Семенов, Каппель, Анненковларның кабыргаларын ишәрбез!

Мөхәмммәтҗан да:

—Наконец-то мы ул моря! Это значит—сиди и жди погоды,—диде.

Барыбыз да шаркылдашып, төрмәне яңгыратып алдык.

*1925*

## Искәрмә

Хикәядән ике җөмләне хәтердә ныгытыйк әле: "Менә полковник тарантасыннан төште. Эшелонга табан корсагын этеп килә". Корсагын этеп килә... Әлеге кыска, әмма аермачык итеп сурәтләүдә, тоткыннарны Ерак Көнчыгыштагы төрмәгә илтүче эшелон начальнигының кемлеге күренүенә өстәп, сөйләүченең-авторның вакыйгага мөнәсәбәтенең тәгаенлеге дә аңлашыла.

Хикәянең вакыйгасы бик тә авыр, тоткыннар ач, эчәргә су да юк, суларга һава җитми хәтта, өстәвенә вак җанварлар тәнне кимерәләр, вагонда тыгыз—бу хәлләрдән котылып булмаслыгы шөбһәсез кебек. Тоткыннар беренче карашка мәгънәсез теләк телиләр хәтта—ничек булса да төрмәгә җитәргә, җитәргә... Төрмәгә! Ә шулай да... Алар арасында гап-гади итеп, тәкерегез барысына да, дип фикерләүче Мөхәммәтҗан һәм җорлыкта аңардан калышмаучы сөйләүче-автор бар бит әле! Шушы ике кеше мәхшәрле сәфәргә баштан ук күпмедер җиңеллек алып киләләр—шаянлыкны эшкә җигәләр. Һәм хикәядә чамасыз газапларны сурәтләү шаяра белүнең дәртле көче белән ахыргача үрелеп бара. Мондый алым исә Идрис абый Туктаровка әсәрен чын осталарча язарга булышкан булыр.

Хикәяне кабат укыган саен, әллә Мөхәммәтҗан һәм автор тормышта бер үк кешеме, дип уйлап куям, чөнки икесенең дә шаяртуларында уртак тасвирлар шактый. Шулай да бер үк кеше түгелдер алар. Чөнки Идрис абыйга әңгәмәсендә төксе бәндә түгел, ә шаян сүзне һәрчак аңлаучы кеше кирәк иде. Бу җәһәттән мин аның Фаил Шәфигуллин белән әңгәмәләрен сокланып тыңлый идем. Алар—остаз белән шәкерт—әдәби иҗат турында сөйләшкәндә, зур җаваплылыкны онытмыйча, күңелне сөендереп шаярта беләләр иде. Кызганыч, яшь аралары кырык елдан артык ике дусның вафатлары арасы унөч көн генә (1982) булды, элгәре яше—Фаил китте...

Идрис абыйның "Үлем эшелоны" хикәясендә үз башыннан үткән хәлләр тасвирлана. Ул, Колчакка каршы өндәүдә гаепләнеп, башта Чиләбе төрмәсенә утыртыла, аннары Владивосток төрмәсенә озатыла...

Идрис Ильяс улы Туктаров 1896 елда хәзерге Башкортстанның Булышлы авылында туган. Ун яшеннән Кучкар алтын приискасында эшли. Шундагы өч класслы рус мәктәбендә, Уфадагы дүрт класслы училищеда укый, кырык яшенә җиткәч кенә Казан педагогия институтын тәмамлый. Ул—журналист, укытучы, клуб мөдире һәм төрле урыннарда озак еллар китапханәче. Соңгысы, шөт, аның иң яраткан һөнәре булгандыр. Патша армиясенә алына, гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша.

Аның хикәяләре шактый ишле, ул "Сиксән беренче штольня" исемле повесть һәм "Ике егет" дигән роман яза, русчадан тәрҗемәләре бар, балалар өчен язган әсәрләре дистәгә якын җыентыкта басыла, гомеренең соңгы елларынача мәкальләргә тиң җор җөмләләр иҗат итә.

Идрис абыйның сыкрануын-зарлануын хәтерләмим мин. Соңгы елларда да үзе озак вакыт яшәгән Яшел Үзән шәһәреннән Казанга килгәндә, инде эре җыерчыклар баскан йөзеннән ипле-тыныч елмаюын җуймас иде ул.

**Мәгъсүм ХУҖИН**

# БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ: ДИСКУССИЯНЕҢ КАЙБЕР НӘТИҖӘЛӘРЕ

“Казан утлары” заман героен эзләп чыккан, дип яздылар бер газетада. Әйе, без чыннан да моннан ике ел элек журналыбыз битләрендә “Безнең заман герое” дигән исем белән бәхәс-дискуссия ачып җибәрдек. Әлбәттә, юктан эш чыгарып, тиктомалдан тотынылмады моңа. Бу сөйләшүне башларга безне бүгенге вәзгыять, тормышыбыз ихтыяҗы мәҗбүр итте.

Хәер, заман каһарманы мәсьәләсе элек-электән актуаль булган. Бөек рус әдибе М. Лермонтов та тикмәгә генә төп әсәрләренең берсен “Безнең заман герое” дип атамагандыр. Ахыр чиктә, хикмәт исемдә түгел, җисемдә. Без чагыштырмача шартлы булган шушы сүзтезмәне өскә, калку итеп куеп, бүгенге әдәбиятыбызда бара торган процессларны, тенденцияләрне мөмкин кадәр анализлап, үзебез өчен мәгънәви максатлар билгеләп (үзәктә, әлбәттә заман герое), сүз сәнгатенең, ягъни язучы хезмәтенең җәмгыятьтәге урынын, кешеләргә тәэсир итү дәрәҗәсен ачыкларга ниятләгән идек.

Куйган төп максатыбызга ирештек дип уйлыйбыз. Бу сөйләшү әдәби җәмәгатьчелегебездә шактый зур резонанс алды. Чыккан мәкаләләр, күтәрелгән мәсьәләләр, аерым теләк-фикерләр кемнәрдәдер хуплау-теләктәшлек тапты, кемнәрдәдер алар канәгатьсезлек, ризасызлык уятты, хәтта кемнәрнедер ярсытты да бугай... Безнеңчә, бу—дөрес күренеш, иҗат эшендә кирәкле шәй. Юкса, соңгы дистә елларда, “бездә тәнкыйть юк, тәнкыйть бетте!..” дигән сүзләр дә еш ишетелә башлаган иде. Утсыз төтен булмый дигәндәй, мондый катгый сүзләргә нигез дә бар. Матбугатта әдәби хәрәкәткә яки аерым бер әсәргә карата чыккан материалларны күздән кичерсәң, шуңа инанасың: аларның күбесе теге яки бу язучының юбилее яки әсәре берәр премиягә тәкъдим ителү уңае белән язылган, китап күзәтү-рецензияләрнең дә күбесе, нигездә комплиментарлыкка, мактауга корылган... Әгәр безнең бу сөйләшү уңае белән чыккан мәкаләләрне укып, җентекле анализ ясасаң, шундый нәтиҗәгә киләсең: юк, “базда дары бетмәгән әле!”, объективлыкка омтылган, дөреслеккә хилафлык кылмаска тырышып, кемнең кем булуына карамастан, йөзенә карап үз фикерен әйтә алучылар бар әле, тәнкыйть исән әле!

Дискуссиянең темасын “Безнең заман герое” дип билгеләгәндә редакция түбәндәгеләрдән чыгып фикер йөртте. Соңгы егерме елда тормышыбызның кискен үзгәрүе аерым кеше, шәхес яшәешендә, аның эш-гамәлләрендә, көнкүрешендә, уйлау-фикерләү рәвешендә, хис-кичерешләрендә ничек, ни рәвешле чагыла? Безнең хәзерге замандашыбыз нинди ул? Ә аның әдәби әсәрендәге чагылышы—без теләгәнчәме, без көткәнчәме?—Менә шуңа охшаш күп кенә сорауларга җавап табарга теләп уйланганда заман герое проблемасы байтак җитди мәсьәләләр бергә килеп кисешкән мөһим үзәк булып тора, анда тормышның һәм әдәбиятның күп яклары чагылыш таба.

Узган сөйләшүнең кайбер нәтиҗәләренә күчкәнче, башта кайбер саннар китереп үтик. Дискуссия материаллары 2004 елның гыйнвар аеннан башлап журналның һәр санында (димәк, барысы 24 санда) басылып килде, өзеклек булмады. Күләм ягыннан алып караганда “Безнең заман герое” дигән темага берничә китап чыгарырга җитәрлек

кызыклы язмалар дөнья күрде. 32 авторның төрле күләмдәге мәкаләләре, фикерләре басылды. Әдәбиятның төрле жанрларында эшләүчеләр бәхәстә түбәндәгечә катнашты: әдәби тәнкыйтьчеләр—13, шагыйрьләр—5, прозаиклар—2, драматурглар—1 кеше. Укучылардан алынган 11 язма урнаштырылды.

Кызганыч ки, сүз нигездә проза әсәрләре, шуларның геройлары турында гына барды. Юкса, фикер яналыгы, тәэсир көче, иҗтимагый янгарыш җәһәтеннән әдәбиятның публицистика, шигърият кебек төрләре соңгы дистә елларда прозага караганда алдарак та торды кебек.

Әчтәлек ягына килгәндә, күпчелек авторлар шуны билгеләп үттеләр: әйе, соңгы унбиш-егерме ел эчендә тормышның үзендә бик күп кызыклы геройлар пәйда булды. Үткән гасырның туксанынчы елларында иң зур күтәренкелеккә ирешкән милли-азатлык хәрәкәте үзе байтак кына көчле шәхесләр, чын мәгънәсендә нык рухлы көрәшчеләр тудырды. Шулай ук халкыбызның хәзерге көндәлек яшәешендә дә батырлык, каһарманлык мисаллары очрап, күренгәләп тора. Бу сөйләшүдә катнашучы авторлар дөрес билгеләп үткәнчә, андый матур күренешләр, үрнәк булырдай шәхесләр кискен үзгәреш кичерүче бүгенге тормышта аеруча зур әһәмият ала. Алар киләчәккә, бигрәк тә яшь буынга, олы юлны, дөрес юлны күрсәтеп торучы рухи ориентирлар кабул ителә.

"Безнең заман герое" дигәндә без, әлбәттә, ин беренче чиратта тормышыбызның әнә шундый якты маякларын күз алдында тотабыз.

Борын-борыннан, кешеләр җәмгыять булып оешып яши башлаганнан бирле, көч яки акыл үсеше ягыннан башкалардан аерылып торган индивидумнар булган, гадәттә алар шул ыруның башлыгы саналган. Аларны, мөгаен, шул заманның беренче каһарманнары дип атап буладыр, һәр чор, һәр халык үзенең көчле шәхесләрен тудырып килгән. Әйтик, колбиләүчелек чоры шәхесе, Рим гладиаторларын көрәшкә күтәргән Спартак шул дәвернең каһарманы түгелмени? Патша колонизациясенә каршы баш күтәргән Батырша? Салават Юлай, Муса Җәлил?.. Болары турыдан-туры көрәштә корбан булып, яшәү финаллары җәзалы үлем белән тәмамланган каһарманнар. Үзләренең фидакарьлекләре белән тыныч тормышта кешелек алгарышына гаять күп файда китергән мәшһүр галимнәр, бик күпләрнең гомерләрен саклап калган табиблар... Яшәешнең төрле сфераларыннан халык күңеленә кереп калган бихисап шәхесләрне искә алырга мөмкин. Алар теге яки бу заманның каһарманнары-геройлары бит.

Каһарман-герой өлгесе беренче нәүбәттә яшьләр өчен, яңа буыннар өчен кирәк (Өлкән яшьтәге кешегә яшәү үрнәге эзләү гадәттә соң була инде). Тәрбия чарасы буларак кирәк. Әдәбият байтак гасырлар буе бу миссияне уңышлы үтәп килде. Китап тотмаган, матур әдәбият укымаган кеше монарчы надан дип саналды, җәмгыятьтә аның урыны түбәндә булды. Талантлы әсәр, андагы персонажлар, автор үзе телиме-юкмы, укучыга тәэсир итми калмый. Димәк, әсәр, аның герое, укучының аның формалаштыруда билгеле бер роль уйный. Ул геройның гамәлләре нинди, максаты нидән гыйбарәт? Ахыр чиктә ул кемнәргә һәм нинди максатка хезмәт итә? Бүтәнчә әйткәндә, нинди идеяне алга сөрә? Төрле заманда, төрле җирлектә, төрле халыкларда кешеләрнең максатлары, тоткан мәсләкләре, идея-иманнары төрле булырга мөмкин. Әмма, кем генә булмасын—аерым бер кешеме, ыруг-җәмгыятьме, милләт-халыкмы, дәүләт-империяме—барыбер аларны бер нәрсә берләштерә: бу Кояш астында үзе теләгәнчә ирекле яшәүгә омтылыш. Бу омтылышның күп формалары, күп исем-билгеләмәләре бар.

Үзебезнең җирлектә соңгы гасырдагы вәзгыятьне, идеологик катаклизмнарны гына искә төшерик. XX йөз башындагы революция-түнтәрелешләр, аны бөтендөньяга җәелдерергә омтылышлар (мировая революция), хосуси милекне бетерү, берничә буынны гариплэндергән сугыш, җирне хуҗасыз калдыру, социалистик җәмгыять төзү, һәм ниһаять, коммунизмга "чыга язу"... Идеологик бу ыргымнарның үзәгендә йөзләрчә миллион кешеләр язмышы... Батырлыклар, фаҗигалар, шатлык һәм кайгы яшьләре һәммәсе бергә үрелгән, буталган... Хакимдарлар үз идеологиясенең җиңүе өчен фәнни һәм иҗади интеллектуаль көчне максимум файдаланырга тырышканнар, билгеле. Халык массаларын тиешле юнәлештә хәрәкәтләндерү өчен үрнәк каһарман-геройлар кирәк булган. Әдәбият төп тәрбия чараларының берсе булган заманда, китап геройларының роле әйтеп бетергесез зур иде. Максатка ярашлы әдәби геройлар тудыру (яки ясау) өчен, иҗат ысулына фәнни төсмер биреп, социалистик реализм методы булдырылды. Шул заманның әдәби геройларын искә төшерик:

Н. Островскийнын Корчагины, М. Шолоховнын Давыдовы... Бездә Г. Бәшировнең Нәфисәсе, М. Әмирнең Минлекамалы, Г. Әпсәләмовнең Газинуры... Бу әдәби геройлар шул елларның сәяси кануннары тәэсирендә беркадәр ясалма булсалар да, аларның берничә буынны патриотик тәрбияләүдәге өлешләрен танырга кирәк. Шул ук вакытта, партия заказы белән язылган меңнәрләгән урта кул әсәрләрдә, төссез, бер-берсенә охшаш, артык "дөрес" бихисап уңай геройлар пәйда булды. Алар яшь укучыларга үрнәк булырлык заман геройлары итеп тәкъдим ителде. XX гасырның икенче яртысында "безнең заманның төп герое"—коммунизм төзүдә актив катнашучы булырга тиеш иде. "Коммунизм төзүче кодекс"н үтәмәгән кешене заман герое итеп күзаллау яки сурәтләү кыен иде...

Әмма... Вакыт дигәннәре һәммә нәрсәгә төзәтмә кертә тора. Ком таулары күчкән кебек, зур дәүләтләр, империяләр таркала, җимерелә тора. Алар белән бергә, табигый, шул империяләрнең җилеме булган идеологияләр дә юкка чыга бара. СССР таркалгач, партиянең унитар системасы җимерелде, какшамас кебек тоелган идеологик маяклар ауды, демократия белән анархия буталып, күпмедер дәрәҗәдә хаос барлыкка килде, рухи кыйммәтләр девальвацияләнде... Төрле сәяси терминнар кибәгеп жилгәреп, төптәнрәк уйласаң, илдә төп үзгәреш шул: илдәге материаль-җисми байлыкның хуҗалары алышынды, илнеке саналган мөлкәт тар бер даирә кулына күчте. Цивилизацияле капиталистик (онытмыйк, нигез сүз—"капитал") мөнәсәбәтләр булмау сәбәпле, "кыргый базар" күпчелек хезмәт иясен хәерчелектә калдырды; аз санлы бер төркем фантастик байлыкларны кулга төшерде, күпләр фәкыйрьлекнең чигенә терәлде.

Менә шул җәмгыятьтә геройлар-каһарманнар эзләп кара инде! Классик мәгънәдә без аңлаган геройлар урынына тормышыбыз мәйданында яңа антигеройлар яки куштырнаклар эчендәге "герой"лар пәйда булды. Аларга мисаллар бихисап. Әйтик, хөкемгә тартылган җинаятьче берничә елдан парламентка депутат булып сайлана, һәм бераздан тагын төрмәгә ябыла... Җәмгыятькә үз хәләл көче белән берни дә бирмәгән яшь-яшь кеше төрле алдау-юлдаулар белән дистә миллиард доллар байлык (тулы бер өлкә-республика бюджеты!) үзләштерә... Яки—ачыктан-ачык фашистик рухлы яшьләр төркемнәре барлыкка килә, кайбер партияләр аларга эчтән теләктәшлек белдерә, рәсми хакимият күрмәмешкә салыша... Олигархмы, скинхедмы, законлы бурмы—алар да бит кемнәрдер өчен авторитет, кумир, темабыз терминологиясе белән әйтсәк, герой, каһарман.

Каһарман-герой өлгесе, иң әүвәл яшь буынга кирәк. Әйе, шулай. Яшь кешенең күңеле буш булалмый: ул барыбер нәрсә беләндер тула һәм рухи корыла. Хикмәт нинди максатка корылуында. Чыннан да, "кеше җаны өчен көрәш бара!" Җепнең очы ахыр чиктә тәрбиягә, яшь буынны тәрбияләү эшенә барып тоташа. Әдәбият, тапталганрак гыйбарә белән әйтсәк, тормыш көзгесе буларак, тәрбияви әһәмиятен югалтмады бит әле! Димәк, әхлакый кануннар шактый ук какшаган бу чорда язучының җаваплылыгы тагын да арта булып чыга. Бу җаваплылык, әлбәттә, авторның персонажларны, әсәрнең умыртка сөяген тәшкил иткән төп геройларны сайлауда һәм аларны образлы сурәтләүдә, дөресрәге, нинди максат куеп, ничек сурәтләүдә чагыла.

Байтак авторлар бик хаклы рәвештә язган ул, соңгы елларда басылган әдәби әсәрләрнең геройлары шактый ук ваклану сизелә—безнең күңелләрне җәлеп итәрдәй зур шәхесләр житми. Дөресрәге, ил һәм халык мәнфәгате белән янып яшәгән якты күңелле олы шәхесләр азрак. Ә бит бу хәлне илнең, җәмгыятнең капиталистик юлга аяк басуы белән генә аклап булмый. Чөнки тулаем кешелек җәмгыятенең, аннары аерым алганда безнең татар милләтенең алдына килеп баскан зур проблемалар азмыни? Ә бүгенге намуслы, кешелекле шәхесләр никадәр борчулы уйлар, кичерешләр эчендә яшиләр? Безнең тирә-ягыбызда әнә шундый зур, якты шәхесләр, әдәби әсәр герое булырдай типлар юкмыни?! Нишләп соң алар безнең әсәрләрдә күренми диярлек?

Бу дискуссиядә әдәби әсәрләрнең тәрбияви ягына хаклы рәвештә шактый гына басым ясап үтелде. Ләкин, шуның белән бергә, без әдәбиятның башка максатлары булуын да истән чыгарырга тиеш түгел. Әдәбият теориясен искә төшерсәк, әдәбият ул, беренчедән, чынбарлыкны, тормышны танып белү чарасы, икенчедән, укучыга эстетик ләззәт бирә һәм, өченчедән, тәрбия коралы.

Соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләр турында уйлаганда без әнә шул өч яссылыкта да уйланырга тиешбез. Аерым алганда, безнең әсәрләребез (бигрәк тә роман һәм

повестьлар) сәнгать ягыннан шактый ук түбәнәйде түгелме? Татар классик әдәбияты безгә мирас итеп калдырган бай образлар галереясы, тел-стиль чаралары соңгы вакытта беркадәр ярлыланды түгелме?

Ә сүзебезнең төп темасы булган заман героена килгәндә, аның рухи дөньясы, уйлары-хисләре безне ни дәрәҗәдә били, мавыктыра ала, баета ала соң?

Әйе, узган дискуссия барышында заман героена карата бик күп таләпләр, үтә дә житди таләпләр куелды. Ләкин, шул ук вакытта без әдәбиятның бронза һәйкәл белән түгел, кимчелекләр хас тере кеше белән эш итүен дә истән чыгармаска тиешбез. Дөнья әдәбиятының классик мисалларын, үлемсез образларын искә төшерсәк тә, аларның иң элек безгә кеше буларак якын һәм кадерле икәнлеген аңларбыз.

Шушы урында тагын бер мөһим якка дикъкать итү сорала. Дискуссиядә катнашучылар билгеләп үткәнчә, соңгы елларда безнең прозада ничектер романтик башлангыч онытыла төште. Аның урынын күбрәк "кара" реализм, вак көнкүреш реализмы биләде. Нәтиҗәдә, әсәрләр җиргә артык якынайды, аларда очыш, күтәренке рух, канатлану калмады, натурализм көчәйде. Ә бит иң якын үткәнебезне—совет чоры әдәбиятын искә алсак та, аның безгә ошаган иң төп геройлары, нигездә романтик шәхесләр иде! Алар үзләренең якты һәм зур эшләре, фидакарьлекләре, иң мөһиме: көчле рухлары, саф хисләре белән безне дә югарырак күтәрә иделәр... Бигрәк тә мәхәббәтне бәян иткән мавыктыргыч әсәрләр җитми бүгенге укучыга.

Дискуссия барышында теге яки бу әдәби әсәр унаеннан язучыларыбызга карата күп төрле таләпләр куелды, кайберәүләр тарафыннан кискен-кискен сүзләр дә әйтелде. Билгеле, бу сөйләшү, дискуссия киң күләмдә фикер алышу, бәхәсләшү максаты белән оештырылды. Һәм анда, чыннан да, карашлар төрлелеге, күплеге ачыкланды. Алар безнең киләчәктәге эшчәнлегебездә, иҗатыбызда ярдәм итәчәк.

Ләкин шул ук вакытта без бер-беребезне тәнкыйтьләү турында сүз алып барганда, тәнкыйтьнең төп максатын күздән ычкындырмасак, шуны онытмасак иде. Тәнкыйтьнең төп максаты—әдәбиятны үстерү, язучыга ярдәм итү. Әнә шул юнәлештә таләпчәнлек һәм кайгыртучанлык күрсәтү. Теге яки бу язучыны түбәнсетүгә, мыскыллауга корылган тәнкыйть исә эшкә ярдәм итә алмый.

Тагын аксиома кебек бер хакыйкать: нинди генә гаярь зат булмасын, үз халкыннан йөз чөергәннәр һич кенә дә заман герое була алмый. Шуңа күрә һәр халыкның үз милли геройлары бар. Йолдыз белән йолдыз сөйләшә дигәндәй, алар еш кына башка халыкларның да уртак геройларына әверелә. Хәзер "милли идея", "милли проект" дигән сүзләр еш ишетелә. Бу юнәлештә Россия күләмендә билгеле бер эзлекле гамәлләр башкарырга уйлыйлар. Уртак Ватан саналса да, күпмилләтле дәүләттә бер генә уртак милли идея була алмый. Һәр морҗаның үз төтене...

Безгә дә ят нәрсә түгел ул милли идея. Әгәр соңгы 10-15 елдагы иҗтимагый тормышыбызга күз салсак, милли күтәрелеш нигезендә монарчы без белмәгән күпме көрәшчеләр, чын мәгънәсендәге каһарманнар пәйда булды? Алар безнең заман геройлары түгелмени? Казанның 1000 еллыгы үткән көннәрдә Президентыбыз М. Шәймиев, халык күзенә карап: "Булдырабыз!" диде. Милли идеянең бер формасы буларак, бу шигарь күп нәрсәне аңлата. Шушы "Булдырабыз" шигарен әйтергә нигез биргән, халкыбыз алгарышына өлеш керткән кешеләр заманыбыз каһарманнары түгелмени?

Әйе, ике ел дәвам иткән дискуссия-сөйләшүгә әлегә нокта куябыз. Әмма йомгак ясамыйбыз. Заман героеның тәгаен моделен билгеләмибез. Теләгәндә дә билгели алмас идек. Заман аңа һәркөн яңа төсмерләр өстәп тора. Шунысына канәгатьбез: журнал битләрендә бүгенге әдәбиятыбыз турында ихлас сөйләшү булды. Кайбер уңышларыбыз белән бергә байтак кимчелекләребез ачылды. Үз-үзебезгә тәнкыйть күзе белән карый алу—рухи сәламәтлегебезнең бер билгесе. Димәк, киләчәккә өмет бар.



**Нурулла
Гариф**

# КАЗАН—МӘСКӘҮ АРАСЫ: ГАСЫРЛАР ЯРАСЫ...

Казан—Мәскәү арасы. Кайсыгызның бу юлларны таптаганы, шул юлларда тапталганы бар? Ни йомышта йөргән иде, юлчы? Юлларың тыныч, төшләрең татлы булдымы? Күңелеңдә нинди хисләр кайнады? Мәскәү шәһәре—"явызлык империясе" буларак билгеле дәүләтнең башкаласы бит ул. Синең белән минем дәүләтне юкка чыгарып, шул җирләрдәге халыкларны талап, канга батырып, башкалар хисабына яшәгән һәм яшәүче башкала. Салкын канлы, хиссез, төссез таш кала, барына да баш кала.

Мәскәү—Казан арасы. Кич утырып бары бер төн генә барасы. Чәйләп аласың да, урламасыннар дип бар булган байлыгыңны баш астына салып, йокларга ятасың. Иртән инде син Мәскәүдә. Монда уйлар, хисләр, дөнья башка...

* * *

Дөньясында тулып яткан юньсезлеккә шаккатып, күңел төшенкелегенә бирелеп йөргән вакыт иде. Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты директоры урынбасары Фәрит абый Солтанов чакырып алып, җылы хәбәр тапшырды. "Мәскәү архивларында эшләргә барырга уйласаң, мөмкинлек табармын. Тик шунысын белеп тор, сиңа, аспирантурада читтән торып укыганлыктан, юл һәм тору урыны өчен акча каралмаган. Ихластан, күңелеңне биреп йөргәң сәбәпле генә ярамыйга карамыйм",—диде. "Институт исеменнән командировкага баруың турында бик шаулап йөрмәссең",—дип тә колакны киртләп куйды. Инде күпмедер вакыт узгач, бу турыда язып, серне ачуым һич тә яхшылыкка яманлык белән түләвем түгел. Киресенчә, язмамда чагылган хисләремә азык биреп, аны дөньяга чыгаруда Фәрит абыйның өлешен искә алуым һәм ярдәме өчен рәхмәтемне белдерүем бу.

Хәер, Мәскәүгә барып архивларда актарынмыйча гына да диссертация язып була икән лә ул. Дөнья булгач, шулай җиңел генә котылучылары да бар икән. Кемнедер гаепләп, кемгәдер төрттерүем түгел үзе. Элек анда барулары авыр иде. Авырлыгы да бүгенге көндәге кебек акча, вакыт юклыктан гына түгел

Нурулла ГАРИФ (1960)—*язучы-публицист; хикәяләре, тарихи темага язылган мәкаләләре вакытлы матбугатта даими басылып килә. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Биектау районында яши.*

иде. Анда бару, архивларга эләгү өчен татарның үзе дә онытып өлгергән җиде бабасын, бар нәсел-ыруын тикшерделәр. Диссертацияләрнең темалары да татар тарихының шанлы һәм данлы чорларына кагылмады. Ул заманнарда партия, комсомол тарихын һәм меңнәрчә милләттәшләребезнең башына җиткән юлбашчыларның тормыш юлын өйрәнү модада иде. Татарны Мәскәүдә килдеңме, дип кул җәеп көтеп торучылар да гомер бакый булмады. Элек түгел, әле бүген дә без алар өчен һаман көпчәк биеклегендә кыркылган "Казан үгиләре"...

Мәскәүгә баруымны белгәч, дус-ишләрем, танышларым Казанда ук борчылды. Алар, уенын-чынын бергә кушып, татарлыгың йөзеңә чыккан, Мәскәү урамнарында тыныч кына йөри алырсыңмы, юкмы инде, дип шаярттылар. Башларыннан кичергән төрле маҗараларны сөйләп куркытырга тырышучылары да табылмый калмады. Әмма мәскәүлеләрнең кайгылары миндә түгел иде. Курыкканнарга гына куш күренгән икән ләбаса! Мәскәү үзе куркытылган ул. Монда дөрестән дә урыс булмаган халыклардан куркалар. Кара тутлы, кысык күзле, алтын тешле кешеләр Мәскәүдә шул чаклы күп ки, барысына кара көйсәң, агуыңнан агуланып үләргә дә күп калмый.

* * *

Казан тимер юл вокзалы. Без бер төркем тарих институты хезмәткәрләренең барыр юлы Мәскәү тарафына юнәлгән. Күңелдә ниндидер авыр, аңлата алмаслык бер тойгы. Юк, туган яктан аерылуга гына бәйле түгел ул, Казан—Мәскәү арасында юл йөрүче татар тарихчылары өчен юл авырлыгының сәбәбе башкада. Поездның йөрәк тибеше ритмында тукылдавы, тәгәрмәчләрнең борылышларда рельсларга ышкылып ыңгырашулары йөрәкләрне озак телгәләячәк әле. Алар безгә Мәскәү тарафына таба куылган богаулы тотыкларның—ерак әби-бабаларыбызның сыктауларын, зар-моңнарын ирештерә. Дәһшәтле елларның сурәтенә атлар кешнәве, чыбыркы шартлавы, ят телдәге сүгенү тавышлары кушыла...

Казан—Мәскәү арасы... Татар күңеленә уелган гасырлар ярасы. Бу яра кайчан да булса бер төзәлерме? Мәскәү тарафыннан гасырлар буена сузылган явызлыкларга нокта куелырмы?

Әле кайчан гына Мәскәүгә күпләр чүпрәк-чапрак, конфет-прәннек яисә иткөлбаса алып кайтыр өчен йөрде. Бу дөньяда мәнсезләргә, үткәннәре белән киләчәген уйламыйча, корсак ягын кайгыртып яшәүчеләргә генә җиңелдер ул... Хәер, бәлки барсы да гади, мин күзаллаганча гына да булмагандыр. Элек туганлык хисләре дә күпкә зуррак иде. Кызыл мәйдандагы Ленин төрбәсе дә күпләр өчен бер рухи кыйбла булды. Олы агайның бар хаҗәтен үтәп йөрүче йомышчы татарларыбыз да аз түгел. Шуңа да карамастан, ул милләттәшләребезне дә бик кимсетәсем килми. Адым саен бөгелә-сыгыла соранулар, кирәге чыккан һәр түрәне җайлау-майлау, теләнүләр аларга да җиңел булмагандыр.

Ярар, үткән эшкә салават. Ә менә бүгенгеләре нәрсә югалткан соң Мәскәүдә? Нәрсә тапкан? Чүпрәк-чапрагы, тәм-томнары бүген Казан кибетләрендә дә тулып ята бит. Үзгәрмәгәне шул: аларны сатып алыр өчен акча кирәк. Ә акча—Мәскәүдә. Күңелдә дүрт ярым гасырга сузылган сорау: бу коллык юлын татарга тагын күпме таптарга туры килер икән?!

* * *

Мәскәү үз кунакларын яратмыйча каршы ала дип әйтмәс идем. Мәскәүгә килүчеләрнең кесәсендә азмы-күпме акча була. Шул сәбәпле алар—көтелгән кунаклар. Акчаны талау поездан төшүгә үк башлана. Монда барсы да сиңа охшарга, ярарга тырыша. Әйтсәң, әйбереңне дә, үзеңне дә кая кирәк шунда илтеп куялар. Барыр җирең, кунар урының булмаса, анысын да табалар. Мәскәү "кәнтәйләрен" дә вокзалның үзендә үк ниндие кирәк шундыен сайлап ала аласың. Бар да товарга әйләнгән, бар да сатыла монда.

Кемнәр ничектер, ә менә без, татар тарихчылары, кемнәр арасында яшәп ятуыбызны да һәм кая килүебезне дә бик яхшы беләбез. Шул сәбәпле, Мәскәүне күреп туйган кешеләрдәй, күзләрне шарландырмыйча гына метрога төшәбез.

Мәскәү метросы Рәсәйнең 90нчы губернасы ул. Аның һәр тарафы караңгылык, шом пәрдәсе белән капланган, борыннарны ярып торф исе килә. Шуңа да карамастан, "метро губернасы"ның үз халкы, идарә системасы, икътисады, хуҗалык эшчәнлеге бар. Мәскәүнең ярты халкы җир астында. Монда берәүләр туа, яши, тамагын туйдыра, икенчеләре мәңгегә күзләрен йома. Метроның без белмәгән башка серләре дә бихисап... Мәскәүнең ошбу губернасы буйлап дистә меңләгән өрәкләр йөри. Алар арасында поезд бәргәннәре дә, йөрәк өянәге тотучылары да, Кавказ тавындагы шартлауларның яңгырашы—террор актларыннан һәлак булучылары да бар. Шул сәбәпле метрода кешенең бер-берсенә күтәрелеп караганын, сүз катканын күрмәссең. Яшьләре бу шомлы уйлардан колакларына радио тыңлагычлары киеп, карашларын кара күзлекләр белән томалап качалар. Бераз укымышлылары күзләрен төрле порнографик, криминаль темаларны яктыртучы газета-журналларга төбәгән. Ай буе яшәп, Достоевский, Пушкин, Лермонтов кебек бөек язучы-шагыйрьләренең әсәрләрен укыган ник бер мәскәүлене очратыйм...

"Фрунзе" тукталышына килеп җитәбез. Җир өстенә чыгуга базар уртасында калабыз. Монда инде башка дөнья. Метрога керү юлы—халыкның иң күп йөргән урыны. Шул сәбәпле, метро тирәсенә базар өстәлләре, төрле киосклар сырышкан. Аларда сатылучы төрле тәм-томнар, күңелне ымсындырган ялтыравыклар яныннан тыныч кына узуы авыр. Тукталып калдың исә, нинди дә булса юк-бар әйбергә йә үзең кызыгасың, йә сатучы нәрсә булса да алырга күндерми калмый. Мәскәүлеләрнең хезмәт хакы өчен ашамлык-эчемлекләрне кыйммәт дип әйтеп булмый. Шул сәбәпле, бәя төшерергә тырышып сатулашучыларны бик күрмәссең.

Көч-хәл белән базарны ерып, Олы Пироговская урамы чатына чыгабыз. Аннан 300 метр тирәсе юл узып, 17 нче бина янына җитәбез. Монда Рәсәй дәүләтенең борынгы актлар архивы (РГАДА) урнашкан. Бу бинада татар тарихының иң караңгы, иң авыр чакларына караган вакыйгаларны сурәтләүче документлар күп саклана. Җиде бабаңны белсәң, тагын җиде буыныңны ачыклап, ханлык чорларына җитәргә дә ерак калмый. Архивның авыр тимер ишекләре сыкранып, теләмичә генә ачыла. Каршыда баштан-аяк коралланган хәрбиләр. Террорчылык шаукымы Рәсәйнең бар җиренә, һәр яшәүчесенең күңеленә үтеп кергән. Тарих институтыннан җыеп килгән дистәгә якын рөхсәт кәгазең булмаса, ярты адым да атлармын димә.

* * *

Архив кунакханәсе тулы. Шул сәбәпле, вакытлы ятаклар тиешле койка-урыннардан күбрәк. Һәр артык урын акча кереме бирә. Шул урынга ия булыр өчен татар болыннарында симергән мал-туарның ит-мае гына түгел, бакчаларда әле яңа өлгергән урыс азыгы—кәбестә-кыяры, помидор-кишере дә капчыклап агыла монда. Безгә дә тәүлегенә "бары 600 сум гына" торган урын тәкъдим итәләр. Татарстанда иң түбән хезмәт хакы аена 700 сум булганда тәүлегенә 600 сум күп тоела. Әмма аларны да гаеплисем килми. Мәскәүлеләр өчен көненә 600 сум керем алу чүп кенә ул. Шуңа да карамастан, без ризалашмыйбыз. Шул ук вакытта акчабыз азлыгын сиздереп мескенләнмибез дә, чәчрәп тә чыкмыйбыз. Елмаеп, безгә поезддан төшүгә ике тапкыр кимрәк түләүле кунакханә, аерым квартирлар тәкъдим итүләрен искәртәбез. Архивка эшкә килеп тә, анда тора алмаганлыгыбыз турында архив җитәкчелегенә хәбәр итәчәгебезне өстәргә дә онытмыйбыз. Чарасызлыкта калдыра белсәң, мәскәүләр чигенә белә ул. Аз гына тын алып уйланучга, без куйган бәя белән ризалашалар. Кара инде, онытып җибәргән генә булганнар, тәүлегенә нәкъ 300 сум торган бүлмә әле иртән генә бушаган икән бит. Кафтау тирәсендәге республикаларның берсеннән килеп эшләгән архив хезмәткәрләре укуларын вакытыннан алда бетереп киткән булганнар. Алдашуларын белсәк тә, әкиятләрен тыңлап бетерәбез. Их! Татар хәйләсен милли сәясәттә дә куллана белсә икән. Кызганыч ки, безнең түрәләр әлегә гел чигенәләр генә...

* * *

Икенче көнне белешмә, рөхсәт кәгазьләре тутыруга бәйле кырык төрле киртәләр узып архив залына аяк басабыз. Фондлар һәм аларның эчтәлеген ачыклаучы тасвирлама кенәгәләренең күплегеннән күзләр камаша. Кайсына тотынырга белмәссең. Әмма без әлеге фондларның эчтәлеге белән Казанда ук танышып килдек. Монда һәр минут кадерле. Казанлылар башкалар арасында үзләренең тырышлыгы белән аерылып тора. Шул сәбәпле, архив хезмәткәрләре, татарларны табигатьләре белән өнәп бетермәсәләр дә, ихтирам итәргә мәҗбүр. Аңлаучылары, аңларга тырышучылары да юк түгел.

Киресен сукалаучылары да җитәрлек...

Заказларымны бирәм дә, калган вакытымны заяга уздырмас өчен борынгы китаплар залына узам. Архив китапханәсе бик бай. Революциягә чаклы басылган тарихи китапларның иң тулы җыелмасы биредә саклана. Керәм дә, анымоны уйлап тормастан, картотеканы өйрәнә башлыйм. Китапханә бер үк архив, бер үк бүлеккә караса да, барлык документларны яңабаштан тутырырга—үзеңнең кем икәнлегеңне, каян килеп нинди тема белән кызыксынуыңны язма рәвештә тагын бер кат аңлатырга кирәк икән. Рәсәйдә бюрократия көчле. Аңгыраеп торсаң, шундук урыныңа утырталар монда. Белешмә кәгазе алып, ярты сәгатьләп шуны тутырам. Картрак чырайлы таза гына сары чәчле апаң, белешмә кәгазенә кырын гына карап: "Сколько же вас там, всем институтом понаехали что ли?",—дип, сукрана-сукрана нидер сызгалый башлый. Башта ук аңлатырга ярамаган тагын—яңа бланк кәгазе биреп кабат белешмә тутырттыра башлый. Үзе мине сөйләндерә. Беренче соравы ук чәнечкеле: "Ну как там, вас режим Шаймиевщины устраивает?". Монысы нәрсә тагы?! Аптыравымнан авып китә язам. Азрак ис-тын җыйгач: "Каян чыгып әйтәсез бу сүзләрне, без үз Президентыбызны бик хөрмәт итәбез. Ә безнең урыслар аны татарлардан да күбрәк ярата",—дим. Сүзем ошамый. Залда утыручы үз хезмәткәрләре ишетерлек итеп: "Менә бит нинди алар, инде без урысларны да "на своих и на чужих разделили",—дип, миңа гаеп ташлый. Авызымны гына ачкан идем, иптәшем арттан касыгыма төртеп, колагыма пышылдый: "Мин беләм аны, провакатор ул, дәшмә, калганын чыккач сөйләрмен",—дип кисәтеп куя. "Әңгәмәдәшем" исә мине яңадан чеметеп ала: "Колшәриф мәчетен дә, үз кешеләрегез төзи алмагач, төрекләргә эшләтәсез икән". Аннан: "Ул мәчетегез безнең дини биналарга охшаган, үз архитектурагыз юкмы әллә?",—дип тә төрттереп куя. Бланк кәгазен тутырганда, уйларым чуалып, кабат ялгышам. Ачуымны басарга тырышам. Шулай да озак дәшмичә тора алмыйм. Тураям да, ханымның күзләренә карап, итагатьле генә җавап кайтарам. "Сез ялгышасыз, киресенчә, сезнең чиркәүләр безнең мәчетләргә охшаган. Киев Русендәге иң беренче таш чиркәүнең безнең бабаларыбыз—болгар осталары тарафыннан салынганлыгын дәлилләүче документлар китапханәгез киштәләрендә саклана. Кирәк тапсагыз, елъязманың томын да, бит санын да әйтеп бирәм. Ышанмасагыз бергә карый алабыз. Колшәриф мәчетен төрекләр төзүгә килгәндә, Россиядә юньле төзү берләшмәләре булмагач ни эшлик соң? Мәскәүдә дә төзүчеләрнең яртысы төрек эшчеләре бит. Алар тиз һәм сыйфатлы итеп төзиләр. Ә төрекләр әле безгә чит-ят та түгел, кардәшләр-диндәшләребез". Аннан болай дип тә өстим: "Нигә аңа аптырыйсыз, Мәскәү Кремлен дә итальян осталары татар кирпеченнән төзегән бит. Нәрсә ояты бар аның, әнә ничек матур,"—дип "салам да кыстырам". Гәптәшем шартлар дәрәҗәдә кызара, әмма дәшми. Китапханәдә эшләүчеләрнең бөтен игътибары бездә хәзер. Барсы да бәхәс ничек очланыр, кем җиңәр икән дип көтә. Вакытлыча туган тынлыктан файдаланып янә бер белешмә кәгазе алдым да чыгып киттем. Кабат кергәндә апаның урыны буш иде... Икенче көнне кичәге "танышым" белешмә кәгазен алып, укып та тормыйча, янә өч-дүрт документка кул куйдырды. Шуннан соң китапханәдән вакытлыча файдалану мөмкинлеге биргән билет тапшырды. Әйтерсең лә, кичә берни булмаган. Ник бер кырын күз карашы ташласын. Артык итагатьлелек тә күрсәтмәдеме икән әле. Аңламассың бу мәскәүлеләрне...

Ул көнне кич буе бүлмәдәшләрем миңа Мәскәүдә үзеңне ничек тотарга ки-

рәклеге турында мораль укыды. Татар баласына кешедән алга чыкмаска, күп сөйләшмәскә, кимсетсәләр дәшмәскә, хаксызлыкка чәчрәп чыкмаска... кирәк икән. Тукта, мин бу сүзләрне кайчандыр ишеткән идем бит инде... Ә, исемә төште. Совет чорында мәктәптә—укытучылар, ә өйдә әни гел шуны тукып тора иде...

Архивта заказлар өч көннән соң килә. Активлык күрсәтсәң, теләгән документларыңны икенче көнне дә алырга мөмкин икән. Исемендә үк серлелек чагылыш тапкан "Тайная канцелярия" фондының (7 нче фонд) документларына күз салам. Документларның күбесе патшага тел-теш тидерүгә бәйле донос буенча тутырылган. Урыслар патшаны исерек баштан сүксә, татарлар мондый сүзләрне аек акылдан ычкындырган.

Менә 1740 елга караган 738 нче эш кенәгәсе (күләме 10 бит). Татар кешесе Мөслим Тимуковның үз халкын яклап, императорга каршы сөйләгән кыю сүзләрен фаш итү турындагы документлар җыелмасы. Кол хәләтенә төшерелгән милләт вәкиленең саргайган кәгазь битләрендә сакланган үткен, кыю фикерләре таң калдыра. Булган бит заманалар, татар да гел тел яшереп кенә тормаган. Турыдан ярган. Нигә бүгенгеләрдә аз бу кыюлык? Нәрсә булды безгә?! Мөслимнең язмышы—меңнәрчә милләттәшләребез язмышының берсе генә. Дөреслекне генә түгел, каршы дәшкәнне дә кабул итмәгән чор бу. Документ ахырында—Тимуковның бар халык алдында чыбыркы белән суктырылуы һәм соңыннан богаулап Себергә озатылуы турында тантаналы рәвештә игълан ителгән карар.

Менә тагын бер таушалып беткән документ. 1746 елга караган, 1075 нче эш кенәгәсе (күләме 12 бит). Анда Патша боерыгына каршы чыгучы Сәет Саинов (Хөсәенов) язмышы...

Татарларга кагылышлы документлар адым саен очрый башлагач, гаҗәпләнүем кими.

1747 ел, 1119 нчы эш кенәгәсе. Гаепләнүче татар кешесе Аднаш Бикбов. Ул императрица Елизаветаны шайтанга тиңләгән. Аднашның кырык биткә сыйган язмышы...

1751 ел, 1494 нче эш (күләме 32 бит). Солдат Семен Серебриков доносы: "татарларның үзләрен көчләп чукындырулары өчен императрица Елизаветаны үтерергә җыенулары турында...". Милләттәшләребездән сорау алулар, җәзалаулар...

1752 ел, 1567 нче эш (күләме 8 бит). Татар кешесе Арслановның татарларның көрәшкә күтәрелүләре турында хәбәр таратуы... Татар халкының дәүләтен югалтканнан соң нәкъ 200 ел узгач та азатлык өчен барган көрәш сәхифәләре. Бүгенгәчә билгесез кала биргән тарихи вакыйгалар... Кемнәр ачар, кемнәр чыгарыр аларны дөньяга?!

"Җинаяте" 1756 елга караган 1781 нче эш кенәгәсендә (3 кисәктән тора) бәян ителгән билгеле шәхес, мулла Габдулла ("Абдул Нагзяльдин") яисә Батыршаның язмышыннан тарихчыларыбызның хезмәтләре буенча без азмы-күпме хәбәрдар инде.

1799 ел, 3406 нчы эш кенәгәсе (күләме 51 бит). Татар кешесе Даут Равиловны чыбыркы белән кыйнап, ни өчен Себер җибәргәннәрен беләсегез киләме? Аның язмышы—шул чорда яшәгән халкыбыз тарихы. Лашманчылык хезмәтенең авырлыклары, кимсенүләр, кешегә санамаулар, үтергәнче кыйнаулар... Моны сөйләү бик авыр. Шәхсән үземнең күпме укып та моннан да тетрәндергеч язмага тап булганым юк иде әле...

Татар халкы үз язмышын үзе хәл итәргә тиеш дип санаган һәм "мин үз язмышыма үзем хуҗа",—дип патша даирәсенә каршы чыккан татар кешесе Әбдүш Атнагуловны һәм аның аннан соңгы язмышын кайсыгыз белә?.. (Ф. 7, тасв. 2, эш. 2629, 40 бит, 1783 ел).

Тарихи документларда дини җитәкчеләрнең эшчәнлеге дә, язмышы да ачык чагыла. Кулымда Җәгъфәр белән Габдерәхим муллаларның дини фанатлыгы турында язылган "данос" кәгазе (Ф. 7, тасв. 2, эш. 2677, 1785 ел). Аларның балаларны ук атарга өйрәтүләре мөселманнарны урысларга каршы кую дип

бәяләнә... Җәзасы да озак көттерми.

Күрәсезме, "террористлар", "мөселман фанатиклары" һәм "вахабчылар" элек тә булган. Бүгенге көндәге ФСБ ролен элек "Тайная канцелярия" үтәгән... Барын да санап, чагыштырып тормыйм. Фикер йөртерлегә булганнарга аңларлык. Бүгенге җитәкчеләр гыйбрәт алырлык язмышлар күп монда. Меңнәрчә эшләрдә—миллионнар язмышы. Бүгенге көндә өлешчә генә санап узган документларның сакланыш номерларын дөньяга чыгару шул чорның җитәкчеләренә хөкем карары булып яңгырасын!

Элекке чорда дөресен сөйләүчеләрне ачыктан-ачык, тантаналы рәвештә юк иткәннәр. Бүгенге чорда андыйларны җайлап, яшәрлеген калдырмыйча гына юкка чыгаралар. Бүгенгеләренең хакимлеге аркасында юк ителгәннәр, авызлары томаланганнарның документ-эшләре үзләренең серлелек вакыты узуын көтеп күпме вакыт ятар да, дөньяга кайчан чыгар әле. Аннан, барын да күрә, белә торып нигә без дәшми торырга тиеш ди!

Юк, курмәүчеләр, күреп тә бу турыда язарга яисә язганны дөньяга чыгарырга куркучылар хаклы түгел!

Көннәр уза тора. Мәскәүнең үзен чыгып күргән юк әле.

Диссертация темасының эчтәлегенә бәйле борынгы Чаллы төбәге тарихын өйрәнүне дәвам итәм. Элек бу җирләр Лаеш өязенә кергән. Очраклы рәвештә Лаеш өязенә чиктәш җирләрнең тарихына ачыклык кертүче материаллар белән дә танышырга туры килә. Кулымда бер карта. Анда Саескан кичүенең каршы ягында урнашкан элекке Спасск шәһәренең планы күрсәтелгән. Бүген бу урындагы торак йортлар, чиркәүләр һәм аның тирәсендәге зиратлар барсы да су астында калган инде. Хәтергә Казан алынганнан соң булып узган вакыйгалар искә төшә. Зур сулар, елгалар тирәсеннән 20-30 чакрым ераклыкка көчләп куылган татар авылларының мәчет, йорт урыннары, зиратлары күз алдына баса.

Татарлар Идел-Кама ярларыннан куылганнан соң нәкъ дүрт гасыр вакыт узгач, меңләгән урыс авыл-шәһәрләре, зиратлары да шул язмышка тарыган. Юк, көчләп кумаганнар аларны. Бу вакыйга Куйбышев сусаклагычы төзелү белән бәйле. Язмыш дулкыннары халыкларны килә-кайта каккан. Ни сәбәптән шулай бу? Моңа берәр аңлатма табылырмы? Белмим. Әмма ни эшлисең, вакыт агышы бернигә дә буйсынмый, беркемне дә аямый. Аның үз бурычы, үз кануннары...

Менә, ниһаять, борынгы Чаллы төбәгенә караган документларга да тап булам. Әмма аларның күбесе, вакыт узу белән яраксызга чыгып, макулатурага тапшырылган. Безнең өчен әлеге документларның атамалары гына сакланган. Ни эшлисең, без һәрвакыттагыча соңга кала бирдек... Чаллы төбәгенең бер ягында керәшен авыллары урнашкан. Шул сәбәпле, чукындыру эшчәнлегенә караган документларга да игътибар итәм. Чаллы төбәге авыллары һәм аларда яшәүчеләр турында тулы тарихи әһәмияткә ия хәбәр 1678 елга караган чыганакта сакланып калган. Борынгы Чаллы шәһәрлегеннән 7-8 чакрым ераклыкта 21 татар (чукындырылмаган) авылы теркәлгән. Искә алынган авылларның бер өлеше "починок" буларак язылса да, аларның урнашулары күп очракта иске авыл урыны ("пустошь") буларак искә алына (Ф. 350, 1 тасв., 1102 эш, 643-644 бб). Тулаем караганда, җир бүленеше һәм халык санын алуга бәйле XVI—XVII гасырлар һәм XVIII гасыр башына караган чыганакларны өйрәнгәннән соң, Казан ханлыгын яулап алу чорында (1552-57) Чаллы төбәгендәге күп авыллар юкка чыккан, халкы таралган һәм соңрак туган җиренә кабат кайтучылар һәм яңа күченеп килүчеләр тарафыннан яңадан торгызылган дигән фикер туа. 1678 елгы документтан аермалы буларак, 1710 елгысында Чаллы төбәге авылларының бер өлеше инде керәшен авыллары буларак теркәлгән. XVII гасыр ахыры, XVIII гасыр башы Рәсәй тормышының иң авыр чоры—Петр I заманы. Кешеләрнең меңәрләп кырылган чагы. Чукындыру кампаниясенә бәйле "бөек күчеш чоры". Татарларның чукынганнары лашманчылык, рекрутлыктан һәм күп ясак түләүдән котылып, җирен дә саклаган, үзе дә, бала-чагасы да исән-имин калган. Баш бирмәгәне, хатынын, бала-чагасын атына утыртып, кабат билге-

сез тарафка юл тоткан. 1716 елгы документта Чаллы төбәгенең Азик Кадрәков йөзлегендәге 20 авылга барлыгы 33 татар, 12 яңа чукындырылган ("новокрещенные"), 32 урыс, 22 чуаш, 10 мукшы—барлыгы 109 гаилә көчләп килгәнлеге хәбәр ителә (Ф. 350, 1 тасв., 153 эш, 845 б.).

Күчеп килүчеләр, яисә көчләп чукындырылганнар белән мөселман татарларының үзара мөнәсәбәтләре нинди булган соң? Бүгенге көнгәчә бу өлкәгә караган документлар дөньяга бик чыгарылмады. Керәшен мәсьәләсе үзе дә Мәскәү тарафыннан татар халкын таркату омтылышына бәйле рәвештә калкып чыкты. Без дә меңләгән документларның берничәсен генә булса да күздән уздырыйк әле. Менә 407 нче фондтагы 42 нче эш кенәгәсе (күләме 16 бит). Документ 1749 елга караган вакыйгаларны бәян итә. Казан губернасы канцеляриясе попрамариясе керәшен татарларын чукынмаган татарлардан сакларга кирәклеге турында чаң кага. Эш кенәгәсенең исеменнән әллә ниләр уйларсың. Әмма, документ белән таныша башлагач, фикерләр үзгәрә. Чиркәү руханиеның йокысын качырган нәрсә мөселман татарлары белән керәшеннәрнең үзара дус булулары һәм шул сәбәпле соңгыларының кабат үз диннәренә кайта башлаулары икән.

1750 елда язылган донос кәгазе 55 нче эш кенәгәсе белән тамгалаган (күләме 3 бит). Татарлар әле яңа гына чукындырылып киткән татарларның тәреләрен йолкып ташлаганнар... Ике кыз баланы мөселманлыкка кайтырга күндергәннәр ("совратили")...

1751 ел, 72 нче эш кенәгәсе (күләме 233 бит). Урыс динен ташлаучы ("отрекшиеся") татарлар турында...

1753 ел, 102 нче эш кенәгәсе. Татар кызларын көчләп чукындыру турында...

Мөселманлыкка кире кайтучы татарлар һәм аларга каршы кузгатылган суд эшләре турындагы язмалар ешайгач, тасвирлама кенәгәсен ябып куям.

Үткәндәге ялгышлар бүгенге көнгәчә безнең язмышларга үрелә...

Залда кыңгырау шалтырый. Тагын ярты сәгатьтән архив залының ябылачагын искәртә ул. Хәзердән үк баш авыртуына түзеп булмый. Бүген дә халкыбыз башына төшкән сынаулардан туган тынгысыз уйлар өермәсе тынычлап йоклатмас инде...

* * *

Җомга көн архив бер сәгатькә иртәрәк ябыла. Вакыт табып без дә шәһәр карарга чыгабыз. Торган урыныбыздан ике йөз метрлап ераклыкта гына Мәскәү елгасы ага. Каршы якта бар дөньясын куркытып торган Мәскәүнең үзәге—Кремль диварлары урнашкан. Өченче Рим төзергә хыялланучылар бу урыннан бар Җир шары идарә ителергә тиеш дип санаган...

Ә бүген Мәскәүдә кем хуҗа соң? Нинди өмет-хыяллар белән яшиләр монда?

Күп төрле алар. Беришләре, армиягә таянганнары, элекке чордагы кебек бүген дә Кремль диварлары артына качып яши. Мәкер-хыялларын, кара эшләрен дә шуның артында планлаштырып, агуларын да Кремль кебек нык сакланган "Останкино" манарасы аша бар дөньяга чәчә. Дөрес, Кремль диварларының тышкы ягына чыгуга ук аларча уйлаучылар сирәгәя...

Икенчеләре Думада пыялалары каралтылган тәрәзәле кабинетларда утыра. Болары да, зур хорның артистлары кебек, Кремль эчендәге зуррак хуҗалары белән бер үк җырны җырлыйлар. Алар шуның белән үзләренең генә түгел, бар туган-тумачалары, җан дуслары һәм бихисап сөяркәләренең тамакларын туйдыра. Кызганыч, мондый депутатлар, төрле дәрәҗәдәге түрәләр арасында безнең милләттәшләребез, диндәшләребез дә юк түгел.

Бүгенге белән яшәлсә дә, хатирәләр ташкыны һаман үткәннәргә сөйрәп кайтара. Карашым—Кремльдә, уем—үткәннәрдә. Дәүләтебезне юк итеп, халкыбызны кол хәленә төшерү планнары шушында корылган. Менә ничә гасыр инде без шуның ачы җимешләрен татыйбыз. Кремль һәм аның тирәсендәге шәһәр биләмәләрендә—миллионнарның түгелгән каны, күз яше, тумаганнар,

туарга тиеш түгелләрнең бәхетсезлеге. Монда ханнарыбызның каннары аккан, таш капчыкларында җаннары чыккан. Ханбикәбез Сөембикәнең күз яшьләре тамган. Үтәмешгәрәен тартып алып чукындыргач, күңелләре телгәләнгән. Яшьли күңеле кыерсытылган бала читләр кулында озак яшәми. Аның җәсәде хәзер дә, безнең каршыбыздагы чиркәү нигезендә, догасыз, кадерсез килеш ята бирә. Монда бүгенгәчә төннәр буе кемнәрнеңдер ыңгырашу, елау тавышлары ишетелә. Күңел күзе булганнарга—күрерлек, җаны иңрәгәннәргә ишетелерлек алар...

Һәр нәрсәнең ахыры була. Ярты дөньясын колачлап, колачлый алмаганын куркытып яшәгән Рәсәй бүген үлем түшәгендә ята. Ул СССР кыяфәтендә инфаркт алып бер хәлсезләнгән иде инде. Тиздән аның икенчесе көтелә. Рәсәйнең гомер буе талап җыйнаган бар байлыгы баш астында. Тирә ягында шул байлыкны кулга төшерергә тырышучылар кайнаша. Әмма алар белән безнең арада бер зур аерма бар. Без татарлар үткәннәргә, горур, иректе, дәүләтле булып яшәгән чорларыбызга карап өметләнәбез. Киләчәктә шул чорлар кабат туар дип хыялланабыз, шуның өчен көрәшәбез, Ә алар үткәннәрдән ояла, бүгенгеләре белән мактансалар да, киләчәкләреннән курка...

Кайту ягына борылабыз. Мәскәүнең мактанырлыгы бар, бөтен җире төзек, урамнары чиста. Соңгы тапкыр Мәскәүдә 1992 елда булган идем. Бу вакытта Союз таркалып, ни булганын аңлап өлгермәгән Рәсәйнең хәле аның башкаласы хәленнән яхшырак иде. Бүгенгедәй хәтерлим: вокзал, базар тирәләрен генә түгел, торак йорт, Кремль яннарын да чүп баскан. Аз гына җил исүгә, үзәк урамнар буенча кәгазь өермәләре куба. Урам, базар-вокзал чатларын бомжлар сарган. Төнлә алар өерләре белән метрога кереп тулалар. Бу чорда Мәскәү Татарстан эшләп тапкан байлыкның әле яртысын гына суыра иде. Шуңа да карамастан, 10 елга барган ярымсуверинетка ия Татарстан авылларга газ кертеп, азмы-күпме авыл юлларына асфальт түшәп калды. Талау нисбәте арткан саен Мәскәү урамнары чистарынып, бомжлар да үзеннән-үзе юкка чыкты. Мәскәү урамнарында селкенеп, эшләмичә эчеп йөрүчеләр бүген дә бар. Әмма аларны бомж дип әйтүе кыен. Бүгенге көндә алар сoранып, урлап, яисә аратирә вокзал тирәсендә йөк ташып та акчаны Мәскәүгә бил бөгүче Рәсәй төбәкләрендә эшләгәннәрдән берничә тапкыр күбрәк таба. Төбәкләрдә яшәүче күпчелек халык исә эшләп тә бомж хәлендә яши хәзер. Мәскәүдә эшләмичә дә яшәргә була. Бүгенге көндә Мәскәү тормышы—бөтен Рәсәйне чагылдыручы көзге түгел инде.

Мәскәүнең тагын бер үзенчәлеге, мактанырлыгы—һәйкәлләр шәһәре булуында. Монда аларны адым саен очратасың. Урыс дәүләтенә хезмәт куйган шәхесләр өчен җизне, бакырны җәлләмәгәннәр. Безнең кебек, һәйкәлләребез тегенди дә мондый дип сатулашып та тормаганнар.

Тагын бер күзгә ташланганы: Мәскәү урамнарында Президент, Дума сайлауларына бәйле ник бер реклама очрасын. Бездә исә 5-6 ел узганнарының да эзе җуелып бетмәгән әле. Аның каравы, Мәскәүдә башка төрле язулар житәрлек. Мин аларның бары күзгә чалынганнарын гына искә алып узам. "Россия все, а остальное ничто", "Смерть врагам", "Россия только для русских"... Бу шигарьләрне укыгач, гади урыс халкы турында да уйланасың. Шул уйлар арасында туган сораулар арасында җавап табалмаслыклары да бар. Мәсәлән, бәхетлеме ул? Бүгенге көндә бездән, үзләре тарафыннан яулап алынган халыклардан яхшырак яшиме? Туар таңы, киләчәге безнекеннән өметлерәкме? Яраталармы, хөрмәт итәләрме аны? Дуслары бармы, күршеләре кемнәр?!..

Архив бинасы янында житәрәк Казакъстаннан килгән кардәшләребезне очратабыз. Мәскәү хәлләре онытылып, сүз Казакъстан тормышына күчә. Казакъ тарихчылары бер елга якын архивта Казакъстан җирләренә караган документларны барлаган икән. Туган җирләрен сагынышканнар, Мәскәүдә соңгы көннәрен эшләүләре турында сөенеп сөйлиләр. Дәүләтле халыкта үткәннәрне бәяләү, халыкка үз тарихын кайтару эше сәясәт югарылыгына күтәрелә шул. Казакъстан дәүләте казакъ халкы тарихына караган барлык төп документларның күчермәләрен үзенә кайтарткан. Хәзер казакъ тарихчыларына

башларын аска иеп Мәскәү тарафына барасы да, кешене кимсеткән төрле кәгазьләр тутырып, озын-озын чиратларда торасы да юк инде.

Дәүләте юк халыкларга ни эшләргә, кемнән теләктәшлек көтәргә? Андый халыклар арасыннан күбрәк үзешчәннәр—һәвәскәр тарихчылар чыга. Аларны дәрәҗә дә, акча да рухландырмый. Милли рух салынган бай күңелле бу шәхесләр башкача яши дә алмый. Тулы канлы дәүләте булмаган без татарларга да хас бу күренеш.

* * *

Рәсәй халкының төп өлеше Мәскәү тормышын телевизор аша гына күреп белә. Мәскәүнең үзендә дә егермедән артык канал эшли. Элекке чорлардан гайре буларак, алар аша яхшы яңалыклар гына күрсәтелә: халыкка пенсия арттыралар, төрле изгеләрен урыннарыннан кучереп җирлиләр. Канал саен концерт, юмор, тамаша... Әйтерсең лә дөньяда да, Рәсәйнең үзендә дә бар да тыныч, бар да имин. Чечен сугышы да, халыкларның үзләренчә яшәешкә омтылышларын бастыручы дәүләт терроризмы да юк. Халыкның тамагы да тук, өсте дә бөтен, күңеле дә тыныч...

Бүген Рәсәйдә халыкларны йоклату бара. Игътибар иткәнегез бармы, телевидение музейларга зур игътибар бирә. Моның сәбәбе билгеле. Рәсәй идарәчеләрен урыс булмаган халыкларның мәдәнияте, теле, гореф-гадәтләре кызыксындырмый. Хәзер күбрәк юкка чыгып баручы халыкларның җырларын, милли киемнәрен, эш коралларының үрнәкләрен җыеп өлгерергә тырышалар. Безне бары музейларда гына күрергә теләүдән туа бу ихтыяҗ. Барлык урыс булмаган халыкларның акыл көче һәм җирләрендәге табигать байлыгы хисабына шундый зур югарылыкка менгәннән соң, үзләренә ничек кылансалар да килешә дип уйлыйлар, күрәсең. Әмма бер күзен ачканнарга төшендә күргәндәй тоелган коточкыч үлем авызы кабат йокыга китергә ирек бирерме?

Мәскәү шәһәренең үз телевидение каналы бар. Анда ара-тирә Кремль кушканча гына сөйләргә тырышмау да чагылып китә. Минә тапшыруны алып баручы безне урам чатларының берсендә Россия Фәннәр академиясенең бер хезмәткәре—Василий Иванович белән таныштыра. Аңарда киноларга төшерерлек, рәссамнарга азык булырлык урыс кыяфәте. Василийның чыгышында ризасызлык билгеләре сизелеп китә. Мәскәү каналында тоткарланып калам. Кызык,... Нәрсә җитми икән бу Мәскәү урысына? Василий үзенең Мәскәү милициясе тарафыннан эзәрлекләнүенә зарлана. Ни дуслары, ни хатыны, балачагалары белән бер иркенләп йөри алмый икән. Адым саен туктатып, кайдан килүем, кем булуым, ни эшләп йөрүем белән кызыксыналар, ди. Сәбәп—көрәк чаклы сакал-мыегы. Теңкәсенә күп тигәннәр, күрәсең, паспортын селки-селки бик дулкынланып сөйли. Еламый гына. "Урыс мин!"—ди ул. "Нәрсә, миңа сакал-мыек йөртергә ярамыйммы инде әллә? Бу бит безнең ата-бабаларыбыздан калган йола",—дип, урыс тарихын сурәтләргә алына. Мисал итеп Явыз Иванны, карагрух Макарийларны искә төшерә... Үз дәүләтендә үзе теләгәнчә яши алмаган урыс кешесен чын күңелемнән җәлләп куйдым. Без кирәк түгел дә түгел инде аларга. Хәтта үзләренең урыс халкын да кайгыртмыйлар, кешечә яшәтмиләр бит алар. Нинди дәүләт соң бу? Кемнәр идарә итә безнең белән? Нигә мин моңа түзеп торырга тиеш ди?!

* * *

Бүген 10 апрель, шимбә, ял итәбез. Архив әле иртәгә дә эшләмәячәк. Вакытны юкка уздырасы килмәгәнлектән, Химкига, фәнни диссертацияләр саклаучы бинага юл алам. Шимбә көн булуга карамастан, диссертация залында халык шыгрым тулы. Күбесе яшьләр. Бу бинада элекке Советлар Союзына кергән барлык төбәкләрдә язылган диссертацияләрнең берәр нөсхәсе тупланган. Дистә еллар буена бар халыкларның акыл көче, хезмәте белән берәмтекләп җыелган тарихы, традицияләре, рухи һәм фәнни байлыгы бирегә агылган. Әлеге хезмәтләр белән танышырга килүчеләр Мәскәү бюджетына көн саен миллионнар калдыра. Мәскәү юктан да акча ясый белә. Бу хезмәтләрдән урыс

булмаган халыкларны ничек тезгенләп тоту, аларның үсеш мөмкинлекләрен тоткарлау турында баш ватучы фәнни оешмалар да файдалана. Шул эшчәнлекнең нәтиҗәсе соңрак Президент, Дума, МВД, ФСБ җитәкчелеге чыгарган карарларда чагылыш таба. Соңрак алар, авыртмаган башка тимер тарак булып, шул халыкларның үзләренә әйләнеп кайта.

Хәер, боларын моңарчы ук белә идем, мине гаҗәпләндергәне башка нәрсә булды: сатира өлкәсенә караган йөзләрчә фәнни хезмәт язылган икән бит. Аларның халыкка, бигрәк тә яшь буынга ничек тәэсир итүе турында да бихисап фәнни хезмәтләр иҗат ителгән. Менә кайдан ала икән ул бетмәс-төкәнмәс юморны Мәскәү артистлары. Дөрес, бу өлкәдә хезмәт куйган татар фамилияләре исемлектә бик очрамый. Безнең халыкка әллә көләргә ярамаган, әллә аның анда кайгысы булмаган. Көлә белү, көлдерә белү дә фән икән ләбаса. Шул сәбәпле, безгә әле татарча көләргә өйрәнәсе дә, көлдерергә өйрәтәсе дә бар.

* * *

Икенче көнне, атна буе күңелдә йөргән хыялыбызны чынга ашырып, Мәскәүдә яшәүче милләттәшләребез белән танышырга чыгабыз. Юл уңаенда үзәк мәчеткә керәбез, намаз укып, хәерләребезне калдырабыз. Ял көне булуга карамастан, мәчеттә кеше күп. Кемнәрне генә очратмыйсың монда. Мәчет 100 ел элек уйсу җирдә төзелгән. Аның янәшәсендәге калкулыкта чиркәү утыра. Бүген урысларның пасха бәйрәме. Әмма безне гаҗәпләндергәне шул: чиркәү тирәсендә бер-ике хәер сорашып, чукынышып утыручыдан гайре ник бер кеше күренсен.

Мәчеттән соң әле яңа гына Татар үзәгенә бирелгән Асадуллаев йортына юл тотабыз. Бу тирәдә урам исемнәре дә татар эзләрен саклый. Олы һәм Кече татар тыкрыкларын узып, Олы татар урамына чыгабыз. Татар үзәгенә кергәч, берара үзебезнең урыс шәһәрендә икәнебезне дә онытабыз... Бина зур. Аның белән танышканда һәркем үзенә кирәген уйлый. Кунакханәгә урнашканда туган кыенлыклар искә төшә. Менә монда бер кунакханә ачып җибәрсәләр икән лә ул! Үзеңчә яшәр, аралашыр өчен көненә мең сумын да җәлләмәс идең. Акчасы барыбер үзеңнекеләргә кала бит. Буш та килмәс идек. Ким дигәндә китаплар булса да тутырып килер идек. Бәлкем, уйларлар әле. Тәүлек саен Казаннан Мәскәү тарафына йөзләрчә фән эшлеклеләре, артистлар, җырчылар һәм башка кунаклар агыла бит. Татар йорты шуның өчен кирәк тә ул...

Мәскәү татарлары үзләрен күп итеп күрсәтергә тырыша. Кем без 800 меңнән, кем миллионнан артык ди. Бу мәсьәләдә безне шаккаттырып булмый. Без тарихчылар һәр мәскәүледә татар каны агуын да беләбез. Әмма, статистика саннарына күз салсаң, татарларның биредә 160 мең тирәсе генә яшәгәнлеге күренә. Әмма анысы да күпертелгән сан түгелме икән әле. Концерт-спектакльләргә, төрле җыелышларга 150ләп кенә кеше килгәч, меңнән бере генә, йөриме икәнни дип уйлап, шикләнеп тә, борчылып та куясың.

Мәскәүдә татарча яшәп була дигән фикергә килдек без. Һәр шимбә, якшәмбе татарлар өчен төрле кичәләр уза. Булсын дип, җиң сызганып эшләүче фидакарьләр аз түгел Мәскәү татарлары арасында. Их, бер иркенләп телевизордан татарча тапшырулар карап, кирәк чакта радиосын да тыңлап булса икән ул!

Ильинка-2. Мәскәү Кремле каршындагы бина. Тыштан ялтыраса да, эчке күренеше ташка үлчим. Бүген монда Мәскәү театрының үзенә күрә бер премьерасы: "Зәңгәр шәл"не күрсәтәләр. Мәскәүлеләргә ярдәмгә, "Хаҗи әфәндenең бер хатыны" буларак, үзебезнең Дания апа Нуруллина килгән. Иртәнге поездан төшеп, уены белән барысын да шаккаттырып, кичкесе белән кайтып та китте ул. Мәскәү театры җитәкчесе Диләфрүз апа турында язмый калсам, Мәскәү татарларын тулаем аңлавы кыен булыр. Театрда ул үзе дә, аның безнең халыктан булмаган ире дә, татарлыгы чыкылдап торган оныгы да менә дигән итеп уйнадылар.

Тамашаның монысы, "Энҗе бөртекләре" дигән балалар фестивале, Мәскәү мэриясенең конференц-залында бара. Сәхнәдә йөздән артык татар баласы.

Залдагы урыннарның алгы рәтләренә татар байлары урнашкан. Арттарак балаларның әти-әниләре, туган-тумачалары, дуслары. Һәр чыгыш ясаучыга—алкышлар, кыйммәтле бүләк, татар баеннан ярдәм-конверт. Китаплардан укып белгән элекке татар байлары искә төшеп, күңелләр тулды. Мәскәүнең үзәгенә, нәкъ йөрәгенә урнашкан сәхнәдән өч сәгатьтән артык милләтеңнең "энҗе бөртекләре" яусын да, ничек шатланмыйсың ди. Балаларын гына күр әле син аларның. Ник берсенең авызыннан мәхәббәт темасына уралган шырдый-бырдый җыр чыксын. Барсы да туган илем, туган телем, Казаным, Ватаным Татарстан дип җырлый, шигырь сөйли. Мәскәү тамашачысы үзе дә затлы. Бу аларның киеменнән, сөйләшүеннән, манераларыннан да күренә...

* * *

Архивта эшләвебезне, татар язмышын чагылдыручы документларны өйрәнүне дәвам итәбез. Рәсәйнең нинди ил икәнлеген аңларга тырышудан беркайчан да баштан чыкмаган сорауларга җавапларны күпләп табып була монда. Рәсәйдә сәяси темаларга һәм җитәкчеләрдән көлүче, аларны бурлыкта гаепләүче анекдотлар сөйләргә яраталар. Аларның да тарихи тамырлары бик тирән икән. Бер генә мисал китереп узам. Петр I белән карак турында сөйләгән анекдоты казак Иван Кукаланың башына җиткән (эш N 969, 1745 ел). Архив фондларында сакланучы меңнәрчә донослар исергәч үзләрен император дип санап йөрүчеләрне фаш итә. Аларның иң бәхетлеләре генә, үлем җәзасыннан котылып, Себер киткәннәр...

Югарыда утыручылар бүгенгеләре кебек үзләренчә тилергән. Моны дәлилләүче мисаллар, документлар да адым саен очрап тора. 16 нчы фонд, 1 нче тасвирлама, 369 нчы эш кенәгәсе. Инородецларга Россиядән чыгарга рөхсәт бирергә ярамау турындагы инструкция. Әлеге тыю православие диненә күчмәүчеләргә кагыла. Шул ук фондның 1768 елга караган 372 нче эш кенәгәсе. Губерналарда түбән дәрәҗәдәге катламлар өчен аерым паспортлар бастыру өчен типографияләр төзү карары. Кешенең рухын төшереп, ирексезләп милләтсез Рәсәй паспортларын бирүләр искә төшә. Шулай да бу чорда яулык ябып йөргән хатын-кызны закон аша кимсетү түбәнлегенә төшмәгәннәр әле. Шул чорның "служилый" татарлары да, бүгенге чордагы хәрби хезмәттәшләреннән үзгә буларак, мәчетләрдән мөселманлыкны раслаучы кәгазь соратмаганнар.

Борынгы документларда әле бүгенге Рәсәй түрәләренең башына килмәгән фикерләр дә бар. Мәсәлән, шул ук фондтагы эштә кемгә шигырь язарга яраганын, кемгә ярамаганын билгеләүче белешмәләр саклана. Шагыйрьләр, язучылар белеп торсын, дөньясын үзгәртергә өлгермәсәк, Рәсәй түрәләренең бу карарларны да эзләп табулары ихтимал.

* * *

Бүген 18 апрель, музейлар көне. Без дә Мәскәү музейлары белән танышырга чыгабыз.

Мәскәү кремленә килеп җиткәч, имәнеп киттем. Керү юлында кырык ямаулы хәерче карчык басып тора. Кулында яртылаш киселгән пластмасс шешә. Түшендә язу: "Мин патшабикәбез Екатерина оныгының оныгы. Авыр хәлдә калдым, ярдәм итегез!". Шаяру гынамы бу? Бәлкем, әби артисткадыр? Юк алай түгел. Күз карашында чагылган чарасызлык чоңгылын артист халкы болай ук күрсәтә алмас ла. Аннан, урысларның, чарасыз калудан тыш, кайчан үзләрен мескен итеп күрсәткәннәре бар әле. Артист булса, "Әби патша" үзе дә күренер иде. Әнә ун метр читтәрәк Ленин бабай тора бит. Монысы—артист-коммерсант. Тук йөзле. Аның белән сурәткә төшәргә халык чиратка баскан. Янәшәсендә һәр сурәткә 100 сум алучы кассиры да бар...

Дәүләт музеена керү насыйп булмый. Бүген бәйрәм уңаеннан керү бушлай икән. Ә бушлай булганда безнең халык агыла инде ул. Су буе чират. Болганып-чолганып йөрибез, йөрибез дә, кайту ягына борылабыз. Кызыл мәйданнан чыкканда безне кабат әби патшаның оныгы каршы ала. Шешәсендәге ба-

кыр акчаларның саны әллә ни артмаган. Мәскәү күз яшьләренә ышана димени ул. Әби белән сурәткә төшүчеләр дә, үзен төшерүчеләр дә күренми. Мин исә шунысына үкендем: Мәскәүдә без гаҗәпләнерлек нәрсә калмагандыр инде дип бу юлы фотоаппаратны кунакханәдә калдырган идем. Мәскәүнең чын йөзен сезгә сурәтләрдә күрсәтә алмадым инде, хәерле булсын.

* * *

Вакыт су кебек ага. Командировка вакыты да бетеп килә. Соңгы атнада көнне-төнгә ялгап чабабыз. Мәскәүдә тарихыбызга ачыклык кертүче архивлар күп. Мәсәлән, Рәсәй дәүләтенең хәрби-тарихи архивы (РГВИА), Корал Палатасы архивы (АОП), Ленин исемендәге китапханәнең архивы һәм башкалар. Әле күрәсе, очрашасы килгән күренекле милләттәшләребез дә бар. Беренче саваплы эш итеп остазыбыз Шамил абый Мөхәммәдьяровның хәлен беләбез. Быел 80 яшен тутыруга да карамастан, ул һаман хезмәттә. Очрашкан көннең икенчесендә үк безне Россия фәннәр академиясенә чакыра. Төмән өлкәсеннән килгән милләттәш кызыбыз Себер татарларында табиблык белән шөгыльләнү тарихы буенча диссертация яклый икән. Без дә, теләктәшлек күрсәтеп, диссертация яклау утырышына барабыз. Танышып, таныш булганнары белән аралашып кайтабыз. Татар дөньясы без белгәннән күпкә киң икән! Мәскәүдә татар тарихын төрле яктан өйрәнүче төрки кардәшләребез, бигрәк тә яшьләр арасында, шөкер, күп икән.

Шулар арасында гадилеге, белеме, сәләте белән таң калдырган Сәгыйть әфәнде Фәизовны укучым белән таныштырмыйча кала алмыйм. Ул, Мәскәүдәге татар тарихчылары, аларның эшләре турында күп мәгълүмат биреп, безнең өчен татар дөньясының офыкларын киңәйтте. Безне төрле архивлар, китапханәләр белән таныштырганда һәр кеше аның белән үзебезчә ике куллап исәнләште. Мәскәүдә белемлеләрне, кулыннан эш килгәннәрне, сүзендә торучыларны, үзен хөрмәт итүчеләрне генә таныйлар. Аннан ул һәркайда татар телендә сөйләшеп йөрүе, табыннан киткәндә иркенләп догасын укуы һәм кече күңеллелеге, ярдәмчеллеге белән истә калды.

* * *

Мәскәү белән саубуллашабыз. Без кайту юлында. Поезд тәгәрмәчләре һәрдаим тукылдавын белә. Кайтканда поезд тәгәрмәчләре җырны башкача суза. Әйтерсең лә, алар да Мәскәүне күреп, аның бар гыйбрәтләрен җыеп, татар баласына шул турыда сөйләргә ашкына: "Аларча уй-ла-ма, аларча я-шә-мә, аларга та-бын-ма!!!...".

Иртәнге як. Татар иленә кергәндә таң беленә башлый. Казанга җиткәндә кояш чыга. Бу таңны, кояшны Мәскәү—Казан арасында йөрүче Татарстан поездының һәр юлчысы каршылый. Яңа көн тууны күрү һәркемдә өмет уята. Шул өмет саклый, яшәтә дә инде безне.

*Казан—Мәскәү—Казан.*
*2004 ел.*

*Адлер Тимергалинга 75 яшь*

**Равил Рахмани**

# ФӘН ҺӘМ ХЫЯЛ КАНАТЫНДА

Чорыбызның актуаль һәм четерекле проблемаларын, философик идея һәм әхлакый үлчәмнәрен, үзенчәлекле психологик, эстетик чагылышын укучы күз алдына тулы китереп бастыра алуы, аларга кыю анализ ясарга омтылуы белән фәнни фантастика бүгенге әдәбиятта, һичшиксез, үзәк урыннарның берсен алып тора. Әлегәчә күзгә-башка артык чалынмаган, көндәлектә без балалар, яшүсмерләр, "технарьлар" әдәбияты дип кенә санарга гадәтләнгән "җиңел холыклы" бу жанрның соңгы берничә дистә ел эчендә мондый югары абруй казануын очраклы дип булмый. Фәнни фантастика укучыларны заман мәсьәләләренә оригиналь һәм кыю чишелеш табуы белән таң калдырган бер жанр гына түгел, ул — әдәби процессның бөтен тармакларына бик җиңел үтеп кергән заманча рухлы сәнгатьчә фикерләү чарасы буларак та җитди игътибарга лаек. Күптөрле фантастик элементларның бүген иң мохтәрәм әдипләребез иҗатында актив кулланылуы да бик табигый. Табигать фәне терминын файдаланып әйтсәк, әлеге жанрны хәтта бүгенге әдәби процессның үзенчәлекле катализаторы дип тә бәяләргә мөмкин булыр иде.



Фәнни фантастика үзенең килеп чыгышы белән кешелек дөньясының ерак үткәненә, аның фольклорына һәм беренче язма классик әдәбияты үрнәкләренә үк барып тоташа. Бигрәк тә аның әкият жанры белән уртак яклары күп булуын ассызыклап үтәргә кирәк. Әкияттә тасвирланган хәлләр "борын-борын заман"нарга караса, фәнни фантастикада игътибарыбыз киләчәк көннәр ягына юнәлтелә. Беренчесендә җир асты патшалыгы, кара урманнар, җиде диңгез артындагы атаулар тасвирланса, икенчесендә төп вакыйгалар шулай ук күз күрмәгән, колак ишетмәгән чиксез галәм киңлекләренә, ерак йолдызларга күчерелә. Әкияттә без еш кына дию пәриләре, аждаһалар белән эш итсәк, фәнни фантастикада — шул ук хыялый затлар: башка планета вәкилләре, хикмәтле гакыл ияләре, кибернетик автомат, роботлар, компьютерлар белән очрашабыз. Тылсым дөньясы да охшаш: беренчесендә тылсымлы балдак, серле тартма, хикмәтле чыбык, икенчесендә җаның теләгән нәрсәләрне "материализатор", кибернетик аппаратлар барлыкка китерә... тик "әфсен укып" түгел, ә логик гипотезалар, табигать фәннәре законнары нигезендә. Әкиятләрдә — ерак тарих төпкеленнән чыгып бүгенгегә килеп җиткән хыял, фәнни фантастикада — бүгенгедән киләчәккә төбәлгән хыялый өмет. Күрәбез, хыялый шартлылыкка һәм шулай ук реальлеккә таянуда да аларның принцип-характерлары шактый охшаш.

Фольклорда гына түгел, классик язма әдәбиятта да фантастик элементларның бик иркен файдаланылуы күзгә ташлана ("Кыйссаи Йосыф" поэмасында Зөләйха мәхәббәтеннән камчы сабына дөрләп ут кабынуы яисә Зөләйханың яшь кызга әверелүен искә төшерик).

Әмма шунысын искәртеп китик — һәрбер хыялый әсәр яисә хыял элементы кергән әсәр ул әле фәнни фантастика жанрына карый дигән сүз түгел. Әлеге жанрның абруйлы белгечләре күрсәтүенчә, фәнни фантастикада гайре табигыйлек материаль көчләр — табигать һәм кеше тарафыннан, фәнни-техник казанышлар

җирлегендә барлыкка китерелә. Димәк, фәнни фантастика хыял һәм чынбарлыкның кушылуы гына түгел, ул бер үк вакытта сәнгатьле һәм фәнни фикерләүнең аерылмас синтезы да икән.

Дөнья әдәбиятында фәнни фантастиканың беренче классик үрнәкләрен француз язучысы Жюль Верн тудырды. Татар әдәбиятында исә ул жанр буларак XX гасыр башында гына формалаша башлый. Бирегә без бу уңайдан Ф. Әмирханның "Фәтхулла хәзрәт" (1909), "Балалар атавы" (1919) әсәрләрен атап үтәр идек. Ә инде фәнни фантастиканың чын мәгънәсендә мөстәкыйль жанр булып яши башлавы тагын да соңрак чорга – илленче елларның азагына карый. Яңа космик чорга аяк басу, фән-техника революциясе фантастикада әдәбият өчен яңа сулыш, яңа мөмкинлекләр ача. Фантаст әдипләр кешене кояш системасының чын хуҗасы итеп күрәләр, йолдызара очышлар турында ныклы фикер йөртәләр. Беренче урынга шушы яңа шартларда яшәячәк заманның яңа кешесе: аның үзенчәлекле психологиясе, характеры, әхлакый йөзе, җәмгыятьтәге роле күрсәтелә башлый. 1957 елда И. Ефремовның совет фантастикасында зур яңарыш тудырган "Андромеда томанлыгы" әсәре басылып чыга. Әлеге җанлануны без татар әдәбиятында да сизми калмыйбыз. 1958 елда А. Расихның "Хәвефле сынау" повесте дөнья күрә. Шушы ук елда "Идел" альманахында Адлер Тимергалинның "Роберт, уян, сөеклем!" исемле беренче фәнни фантастик хикәясе басыла. Шуннан соң үткән 50 елга якын вакыт эчендә әдип әлеге жанрга тугрылыклы булып калды. Иҗат диапазонын нәкъ әнә шушы жанрда елдан-елга киңәйтә барып, үз укучыларына дистәгә якын китабын бүләк итте. Бу жанрда ул үзен талантлы язучы итеп танытты, югары сәнгать дәрәҗәсендәге әсәрләре белән фәнни фантастика жанрын татар әдәбиятында чын мәгънәсендә мөстәкыйль очыш орбитасына чыгарды. Аның "Адашкан йолдыз", "Хәерле юл", "Кайтыр юллар", "Көрәшү", "Кабул булсын теләгең", "Фермада", "Кибернетикларның хыялы" кебек әсәрләре, һичшиксез, әдәбиятыбызның зур казанышы саналырга лаеклы.



*Татарстан китап нәшрияты хезмәткәрләре. Сулдан уңга (басканнар): Ф. Хәсәнов, Г. Солганик, А. Тимергалин; алгы рәттә: Г. Харисова, Н. Фәттах, С. Ибраһимова. 1957 ел.*

Шунысын да әйтеп үтик, Адлер Тимергалин инде ничә дистә еллар дәвамында әдәбиятыбызда бердәнбер дип әйтерлек фантаст язучы булып кала килә. Бу факт, күңелдә ирексездән кайбер борчулы фикерләр дә тудыра. Татар әдәбиятында фәнни фантастиканың киң җәелеп үсеп китә алмавы, чыннан да, шактый хәвефле бер симптом ул. Әллә соң пар канатыбызның икенчесе – галимнәребез, фәнебез юкмы безнең? Алай дисәң, исемнәре бөтен дөньяга мәгълүм мәшһүр академикларыбыз, член-корреспондентларыбыз, профессорларыбыз да аз түгел лабаса. Хәтта фәнни фантастиканың "үз" сферасы – космик тикшеренүләр, астрономия, физика, кибернетика, механика, химия, биология кебек фән өлкәләрендә дә...

Бәлки бу ике сыңар канатның бергә кушылуы җитмидер? Бит дөньяның иң күренекле фантастларына әнә шул сыйфат хас. Бәлки ул кушылуның нигезендә яткан халык рухын тоеп яшәмәү төп сәбәпчедер?

Хәтергә халкыбызны чын-чынлап мәгърифәтле итәргә омтылган, гуманитар өлкәдә генә түгел, табигать фәннәре үсешенә дә иҗади килеп кушыла алган һәм аларны популярлаштыруга да зур көч куйган К. Насыйри бабабыз искә төшә... Үзенең механикадагы ачышлары белән бөтен дөньяга билгеле, хезмәтләре әле дә булса әһәмиятен җуймаган беренче татар математигы Х. Мөштәри искә төшә... Г. Ибраһимов белән бергәләп "Мәгариф" журналы чыгаручы, математикадан,

физикадан мәктәп дәреслекләре, брошюралар язучы, терминологик сүзлекләр төзүче Мөштәри! Фән белән халык мәнфәгатьләрен бербөтен итеп күрә белгән өченче бер танылган галимебез Г. Камай искә төшә... Кызганыч, әлеге традицияләр алга таба өзелеп калган. Галимнәребезнең бүген халык рухы, халык культурасы, бигрәк тә туган телебез белән бәйләнешы юк дәрәҗәсендә, алар халыкара телләрдә эш итүне өстен саныйлар. Кыскасы, фән кадрлары да, фәнни терминология дә рус һәм чит илләр традициясе нигезендә генә үстерелә. Халыкның фән әһелләре генә түгел, зыялылар катламы да (димәк, фантастиканың төп укучысы да) акрынлап милли культурадан аерыла, еракләша. Халкыбызның потенциаль энергиясен алып үскән яшьләребез, шулай итеп, дөнья фәне һәм культурасы офыгында "эри" бара.

Язучыларның үзләренә килсәк, хәлнең нәкъ киресе белән очрашырбыз. Алар тулысы белән диярлек гуманитар белем-тәрбия алган һәм авылдан чыккан кешеләр. Димәк, фәнни фантастиканың ни өчен алар иҗатын әйдәп баручы үзәк бер жанрга әверелеп китмәве дә аңлашыла булса кирәк. Аннан килеп, фән кешеләре һәм табигать фәннәре белән тыгыз бәйләнештә тормау да язучылар өчен файдага түгел. Иҗат темаларының



*Нәшрият бинасында Вакыйф Нуруллин һәм Яхъя Халитов белән. 1979 ел.*

чикләнгәнлеге, чынбарлыкның сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачык күзалламау, күп кенә проблемаларга эмоция-интуиция белән генә җавап эзләү, еш кына тар милли кысалардан чыга алмау, ахыр чиктә, шәхеснең тиешле заман югарылыгына күтәрелмәве — болар барысы да, миңа калса, теге яки бу дәрәҗәдә "гыйлем җитмәүгә" барып тоташа. Бүгенге татар әдәбиятының төп кимчелеге дә, минемчә, нәкъ шунда.

А.Тимергалин иҗаты исә, фәнни фантастикада гына түгел, фән белән әдәбият арасында әлеге уртаклыкны-бөтенлекне табу ягыннан да күп кенә язучыларыбыз өчен үрнәк булырлык. Аның эрудициясе, белем тирәнлеге, фикер йөртүенең масштаблылыгы — әдәбиятыбызның дефицит сыйфатлары түгелмени?! Ә күпме эзләнүләр, тырышлык һәм хезмәт аша килгән ул аларга! А. Тимергалинның "галимлеге" һәм "технарьлыгы" Казан университетының астрономия бүлегендә, Ташкент укытучылар әзерләү институтының физика-математика бүлегендә укуында гына түгел бит. Гыйлемгә сусаган студент кебек, ул гомер буе китап җыя, аң-белемен күтәрә; тарих, әдәбият, табигать фәннәрендә ясалган ачышлар белән һәрвакыт хәбәрдар булырга тырыша, соңгы фән казанышлары югарылыгыннан торып фикер йөртергә омтыла. Аның Татарстан китап нәшриятының фән-техника әдәбияты редакторы буларак 25 елга якын вакыт эчендә 200 дән артык китапны укучыга илтеп җиткерү эшендә турыдан-туры катнашуы да, тәрҗемәчелек эшчәнлеге һәм автор буларак дистәгә якын сүзлекләр, фәнни-техник кулланмалар чыгаруы да — болар һәммәсе әдип иҗатының гаять киң планда алып барылуы хакында сөйли. Без аларда, беренчедән, халыкка хезмәт итүне — зур "мәгърифәт" эшен күрсәк, икенчедән, алар әдипнең үз әсәрләре өчен дә кыйммәтле әзерлек булып тора. Язучы иҗатының саекмас чыганагы да әнә шундадыр, күрәсең.

Татар әдәбиятын тематик киңәйтүдә, телебезне яңа сүз-терминнар белән тулыландыруда, чынбарлыкның фәлсәфи, психологик, эстетик чагылышына иркенлек, тирәнлек, канатлы шигъри очыш бирүдә, аны лирик моңсулык һәм юмористик аһәң белән баетуда Адлер Тимергалинның, һичшиксез, кабатланмас үз йөзе, лаеклы үз өлеше бар. Шуңа да аның иҗаты бер тармак-жанр булып кына түгел, зур талант

һәм хезмәт куеп табылган җитди иҗат җимеше итеп, бер үк вакытта татар әдәбиятының үзенчәлекле бу яңа өлкәдә эзләнүләре һәм казанышы итеп тә кабул ителәә.

Хәзер бу әсәрләрнең эченәрәк кереп, аларның үзенчәлеген җентеклебрәк күзалларга тырышып карыйк.

Фәнни фантастика әсәрләрен укый-укый ук безнең гадәти Җир дип йөргән туган йортыбыз Киек каз юлының уң канаты, сары йолдыз системасы, өченче планета рәвешендә ерак галәм киңлекләре берлегеннән чыгып күзаллана башлый. Без, үзебез дә сизмәстән, астрономга, географка, физикка, биологка, кибернетик механикка, космонавт-пилотка, гыйльми экспедиция әгъзасына әвереләбез. "Үзәктән куу көче", "Гравитация кыры", "Кеплер законы", "термодинамика кануны", "дүрт үлчәнешле урын-вакыт яшәеше", "бионика", "генетика", "үзара тоташкан галәмнәр идеясе" кебек төрле фән тармаклары, фән терминнары һәм законнарының асылын күзалларга омтылабыз. Кешелекнең, фән дөньясының киләчәккә төбәлгән өмете—өр-яңа фәнни гипотезалары, интуитив фараз итүләр һ.б. белән очрашабыз. "Адашкан йолдыз" повестенда әнә коточкыч көчле моторлы "Дзета" корабле ике янәшә дөнья арасын бер мизгелдә үтәргә сәләтле. "Мәңгелек" хикәясендә карт профессор тереклек организмындагы картаю процессын туктату белән генә чикләнеп калмый, аны хәтта киредән яшәртә торган махсус препаратлар да уйлап табуга ирешә. "Хәерле юл"да исә җылыдан салкынга күчүне генә түгел, салкыннан җылыга күчүне китереп чыгарган термодинамика законы бәян ителә һ.б.

Әнә шундый гипотезаларны үз эченә алган фәнни-фантастик аргументлар белән берррәттән, фәнни-фантастик әсәрләрнең чынбарлыкны танып белү өлкәсендә ясалган реаль ачышларны пропагандалауга да гаять зур хезмәт күрсәтүен биредә аерым ассызыклап үтәргә кирәк. Алда саналган фәнни термин һәм төшенчәләр, закон һәм алшартлар безне бит турыдан-туры шушы табигать фәннәренең теоретик һәм техник лабораториясенә алып керә. Каһарманнар белән бергә без дә киеренке ситуацияләрдә калып, ватылган аппаратларны төзәтергә керешәбез, схемалар ярдәмендә берәр хәбәрләшү җайланмасы ясарга алынабыз. "Фермада" хикәясенең төп герое студент-галим музыканың үсемлеккә һәм тереклеккә тәэсир итүен нигезгә алып, авыл хуҗалыгы өлкәсендә зур уңыш китерерлек музыкаль система ясап куя. "Ерак планета" әсәрендә кибернетик автомат үсемлек һәм хайваннар дөньясының уртаклыгы турында фәнгә билгеле булган мәгълүматлар белән таныштыра.

Шулай да фәнни фантастика жанры ул—барыннан да бигрәк сәнгать әсәре. Димәк, матур әдәбиятның башка бик күп жанрлары кебек үк ул да эстетик законнарга буйсына дигән сүз. Аның алдына без барыннан да элек сәнгать әсәренә куйган таләпләрне куябыз. Яңа гипотеза-идеяләрнең әйтелүе, инде фәндә билгеле булган ачышларны пропагандалау аның төп хасияте һәм максаты түгел. Фән-техника законнары, идея-гипотезалар биредә үзенчәлекле алшарт, ягъни сәнгати шартлылык, әсәрнең тышкы тасвир механизмын хәрәкәткә китерүче бер башлангыч көч һәм тышкы тасвир җирлеге, үзенчәлекле тематик фон булып хезмәт итәләр. Әсәрнең төп эчтәлеге үсеш механизмы исә турыдан-туры кешенең һәм кешелекнең үз эчке проблемаларына барып тоташа.

Фәнни-фантастика шартлылыгы, һичшиксез, иң элек әсәрләрнең тасвир объекты чикләрен киңәйтеп, аны төрләндереп килүе белән кызыклы.

Вакыт ягыннан чыгып карасак та, шул ук хәл: "Рәшад эффекты" хикәясенең нәни герое, әнә, ерак тарихка сикереш ясый, ә башка күпчелек әсәрләрдә вакыйга нигездә киләчәк заманнар күзлегеннән чыгып тасвирлана. "Әфсен түгел" хикәясен искә төшерсәк, монда без үзебезнең киләчәгебез һәм ерак үткәнебез белән берьюлы очрашкандай булабыз. Бу өч төрле заманны (үткәнне, киләчәкне һәм әлбәттә инде бүгенге көнне) бергә органик берләштереп торучы көч нәкъ менә фәннифантастика жанрының шартлылык хасияте тарафыннан башкарыла.

Дөрес, А. Тимергалинның бөтен әсәрләре дә фәнни-фантастик шартлылыкка нигезләнеп язылмаган. Аның иҗатында без фәнни-фантастик, фантастик, детектив һәм шул исәптән гадәти реаль сәнгать шартлылыгы белән дә ("Укытучы язмалары" һ.б.) очрашабыз. Әмма әсәрләрдә хыялый якны гына түгел, реальлекнең чагылу үзенчәлеген дә онытырга ярамый. Димәк, әкияттәге кебек үк, теләсә нинди башка жанр әсәрләрендәге кебек үк, фәнни фантастикада да хыялый һәм реаль шартлылыклар үзара тыгыз бәйләнештә тора. Шушы бөтенлекне барлыкка китергән башлангычларның үзенчәлегеннән һәм аларның үзара керешүеннән чыгып

теге яки бу жанрның төп хасиятләре ачыклана да бит инде.

Сүзне әкиятләрдә нык үсеш алган һәм фәнни фантастикада да кыю дәвам иттерелгән тылсымлы башлангычларны барлаудан башлыйк. Белгәнебезчә, тылсым көче кеше өметенең, кеше хыял-теләгенең шигъри метафора, шигъри метаморфозалар аша үтеп чынлыкка әверелүе ул. Әмма әкиятләрдәге тылсым белән фәнни фантастика әсәрләрендәге тылсымның үзенчәлекле бер аермасы да бар. Беренчесендә ул ниндидер бер серле рухи көч ярдәмендә туса, икенчесендә чынбарлыкны танып белү җимеше буларак, фәнни-логик аргументка, табигать фәне кануннарына, фән-техника казанышына таянып, материаль көч җирлегендә барлыкка килә. Тылсымлы чыбык урынында монда — кибернетик автомат, робот, компьютерлар; оча торган палас урынына — космик корабльләр.

Әсәрләрнең мажаралы башлангычка корылуын без әкият жанрында ук инде бик ачык күрәбез. Әмма аның тагын да үзенчәлеклерәк үскән бер тармагы булып, һичшиксез, мажаралы (детектив) әсәрләр тора. Сүз уңаенда А. Тимергалинның бу башлангычка махсус мөрәҗәгать итеп язылган әсәрләре дә булуын әйтеп үтик. Аның "Таш алиһә" повесте әнә шундыйлардан. Фәнни-фантастика мажаралы башлангычның чын-чынлап үз стихиясе. Сюжетның тармаклы иркен үстерелеше белән ул детектив әсәрләрдән һич кенә дә калышмый. Фантастик шартлылык аның үсеше өчен монда тулы мөмкинлек-шартлар тудыра. Димәк, әлеге иҗат юнәлеше дә А.Тимергалин иҗатында махсус эшләнгән өлкә. Тикмәгәмени аның әсәрләре һәрвакыт мавыктыргыч һәм җанлылыклары белән аерылып тора. Шартлылыкның көчле энергиясе хәрәкәткә китергән сюжет сызыгы, андагы көтелмәгән текә борылышлар укучыны һәрвакыт киеренке хәлдә тота.



*Кызы Алсу Тимергалинаның шәхси күргәзмәсендә. 2005 ел.*

Гаять әһәмиятле тагын бер шартлы башлангычка — әсәрнең үзегендә аның билгеле бер "катализаторы" булып торган драматик башлангычларга да тукталып үтик.

А. Тимергалин иҗатындагы иң таралган герой-типларның берсе — чиксез галәм киңлекләре тормышын өйрәнүче Җир планетасы белгечләре, астронавт, космонавтлар. Әсәрләрдәге драматик мөнәсәбәтләр үзәктә тора: алар чит йолдыз вәкилләре белән контакт урнаштырырга омтылалар ("Адашкан йолдыз"), алар белән үзара аңлашалар, тәҗрибә уртаклашалар ("Ерак планетада"), үзләренә карата тәкәбберлек, гаделсезлек күрсәтүчеләргә каршы әче нәфрәтләрен белдерәләр ("Баскыннар"), алардагы кешелексез яшәү принципларын күреп, кискен көрәшкә ташланалар ("Кайтыр юллар").

Димәк, әлеге Җир кешеләренә капма-каршы як буларак көрәш мәйданына чит цивилизация вәкилләре куела. Ә, белгәнебезчә, алар барысы да: компьютермы ул ("Адашкан йолдыз"), роботлармы ("Баскыннар"), "фикерләүче материянең яңа формасы булган сәер урманны хәтерләткән глорийлар җәмгыяте"ме ("Ерак планетада"), гуманоидлар ("Кайтыр юллар"), яисә бөтенләй кешедән аерылмаган затлармы ("Әфсен түгел") — барыбер, алар тулысынча авторның хыял җимеше. Ә менә драматик мөнәсәбәтнең нигезен инде бары тик Җир кешесенең реаль өмете, реаль шик-шөбһәләре, уй-борчылулары гына тәшкил итә.

Драматик көрәшнең күп төрле аспектлары гына түгел, драматик башлангыч үзе

дә әсәрдәге башка — алда карап үткән тылсым һәм мажара башлангычлары белән бергә үрелеп килә.

Фәнни фантастика реаль шартлылык башлангычлары белән дә тыгыз бәйләнештә. Психологик, эстетик һәм юмористик башлангычларның тулы канлы үстереше әнә шул хакта сөйли

Фәнни фантастика жанры үзенең каһарманнарын башлыча драматик мөнәсәбәтләр күрәше аша чагылдыра. Драматик механизмны хәрәкәткә китерерлек психологик мотивлар белән канәгатьләнеп, ул еш кына каһарманнарның күңел тирәнлекләренә төшеп җентекле анализ ясауны кирәк тә тапмый. Шуңа карамастан, психологиядән башка сәнгать әсәре була алмый, психологизм фәнни фантастика жанрының үзенчәлеге саналмаса да, ансыз ул үзенең максатына ирешә алмас иде. Бигрәк тә бүгенге чор әдипләре иҗатында психологизмның тирәнәя баруы нык күзәтелгән бер вакытта. А. Тимергалин иҗатында да без аның күп төрле күркәм үрнәкләре белән очрашабыз.

Әнә "Адашкан йолдыз" әсәрендә "Тургай" корабльнең массасы үзеннән мең тапкырга зуррак булган — ят цивилизациядән килгән дип фаразланган — билгесез җисем ээәрлекләп килеп, каһарманнар үлем куркынычы алдында торып кала. Шунда аларга җибәргән бомбалы ракеталары түгел, ә бәлки каһарманнарның психологик үзенчәлекләре ярдәмгә килә. Моннан соң корабльнең язмышы белән җитәкчелек итү эше дә капитаннан психоаналитик кулына күчә. Әлеге киеренке мизгелдә без бөтен игътибарыбызны бу өч космонавтның әлегә кадәр һич әһәмияте сизелмәгән чиста индивидуаль психологик хасиятләренә, шәхес үзенчәлекләренә юнәлтәбез. Шунысы әһәмиятле, психоаналитикның эчке сизгерлеге аларны котылгысыз үлемнән алып калса, капитанның ныклыгы һәм сакчыллыгы, штурманның самими күңеле аларга авырлыкларны җиңеп чыгарга һәм чит корабль белән контакт урнаштыруга ярдәм итә. Аның компьютеры ахырда нәкъ менә штурманны үз итә. Машина "салкын тәҗрибәгә караганда дуамал яшьлек"не өстен күрә. "Яшьлек — дуслашу, кешеләр белән танышу һәм аңлашу чоры... Ә өлкәннәрдә инде тәнкыйть күзе аша үткәрү теләге көчлерәк. Бу сыйфатлар икесе дә әйбәт, икесе дә кирәк, югыйсә..." — дигән фәлсәфи нәтиҗә чыгарыла әсәрдә. Дөрес, психологик анализда автор бу өч типны ачу белән генә чикләнми, кыю төстә шәхси мөнәсәбәтләр дөньясына да алып керә. Бу яктан бигрәк тә штурман белән психоаналитик арасында барган хисләр күрәше бик истә калырлык.

Шулай итеп, профессия, дәрәҗә, махсус психологик әзерлек, характер, темперамент төрлелеге, яшь аерымлыгы, шәхси тойгы-кичерешләр, интим мөнәсәбәтләр һ.б. бер ноктага килеп керешәләр. Чит цивилизация вәкилләре "дзета"лыларда да чын дуслык, алар тормышыннан читтә калган мәхәббәт, спорт-ярыш рухы, чын сәнгать әсәре бүләк итү теләге туа. Авторның әйтергә теләгән фикере әнә шулай психологик катламнар аша узып укучыга табигый ышандырырлык итеп, тәэсир көчен һәм яшәеш эчкерсезлеген югалтмаган көе илтеп җиткерелә. Бөтен йолдыз системасында, галактикада, метагалактикада дуслык, туганлык, мәхәббәт, бәхет урнашачагына, киләчәккә өмет-ышаныч тудырыла.

Психологик эзләнүләренең зур бер тармагы буларак, авторның балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты белән тыгыз бәйләнештә торуын да биредә ассызыклап үтәргә кирәктер. Фәнни фантастика жанры — ул, гомумән, билгеле бер дәрәҗәдә балалар һәм яшүсмерләр дөньясы. Мондагы кыю һәм тәвәккәл йөрәкле илгизәрләр, табигатьнең иң нечкә серләренә үтеп керә алган талантлы галимнәр, сәерлеге белән безнең күңелне җәлеп иткән чит планета вәкилләре, гаҗәеп акыллы робот-компьютерлар, көтелмәгән тылсымлы күчешләр, мавыктыргыч мажаралар, күңелне тулысы белән үзенә яулап алган кискен драматик бәрелешләр, тыелгысыз омтылыш, чиксез хыял, канатлы романтика, тылсымлы шигърият, чиксез оптимизм... — болар барысы да аны балалар һәм яшүсмерләр рухы белән аваздаш итә. Димәк, шушы жанр вәкиле булган өчен генә дә авторны һич икеләнмичә яшь буын язучысы итеп санарга мөмкин булыр иде.

Әмма аның күп кенә әсәрләрендә балалар турыдан-туры төп каһарман буларак катнашалар ("Мәңгелек", "Без вакытны ничек туктаттык", "Рәшад эффекты", "Киләчәктән елмаю" һ.б.). "Мәңгелек хатирәләр" повестенда, "Әфсен түгел", "Рибб Локсның үлеме" хикәяләрендә дә нәни герой образлары гаҗәп дәрәҗәдә яратып, аларның эчке дөньясын тирән белеп иҗат ителгәннәр. Аларның төгәл психологик бирелеше, һичшиксез, бу әсәрләрне тагын да җанлырак һәм тулы канлырак итә.

"Мәхәббәт һәм тәҗрибә", "Фермада" хикәяләрендә исә әсәр үзәгендә без яшүсмерләр һәм аларның тормышы, психологик үзенчәлекләре белән очрашабыз.

Шунысын да әйтеп үтик, балалар психологиясен тасвирлауга алынуы авторның бер фәнни-фантастик әсәрләренә генә карамый. "Таш алиһә" повесте аның тулаем балалар тормышын гәүдәләндерүгә багышланган.

Авторның иҗаты башында ук язылган "Укытучы язмалары" әсәрендә яисә "Мәңгелек" һәм "Сюар мәктәбенең фаҗигасе" кебек фәнни-фантастик хикәяләрендә балаларны укыту проблемаларын күтәрүе, яшь буынны аңлау һәм аның белән уртак тел табудагы тәҗрибәләре белән уртаклашуы ягыннан кызыклы. Иҗатында бала һәм яшүсмер психологиясенә күп төрле аспектлардан торып якын килүе — чын мәгънәсендә балалар язучысына әверелүе үзе үк аның нечкә психолог булуына бер дәлил булып тора.

А. Тимергалин иҗатының тагын бер характерлы үзенчәлеге, һичшиксез, аның юмор-сатирага булган мөнәсәбәтендә ачык күренә. Аларның беришеләрен, мөгаен, гадәти җир юморы дип атарга мөмкин булыр иде. Икенче төрләре җир тормышының фантастика элементлары белән керешүе нәтиҗәсендә барлыкка килә.

Беренче төрдәге юмор белән без авторның "Таш алиһә" повестенда очрашабыз. Биредә әнә Мәмәт бабай балаларга үзенең яшь чагында (1926 елда) авыл яшьләре белән җыелышып халыкка театр куюларын искә төшерә. "Пьесаны әзерли башлагач, күрәбез, — ди ул, — китап текстында урыны-урыны белән әллә ниткән Пауза да очрый бит. Исеменә карасаң, Пауза хатын-кыз булырга тиеш... Рауза шикеллерәк. Берәр җиңгиме ул? Кыз баламы? Нигә теләсә кем арасына килеп керә, ник авыз ачып бер сүз дәшми үзе? Мөгаллим дә бу хакта берни дә кистереп әйтә алмый. Шулай да аның киңәше белән бу рольне мәктәпнең иң чая малае Җиһангирга тапшыралар. Аңа хатын-кыз киеме кидереп сәхнәгә чыгарырга булалар.

"Бер заман суфлерыбыз "Пауза! Пауза керә!" — дип пышылдый. Биек үкчәле ботинкалары белән черт-черт кенә атлап, сәхнәгә Пауза-Җиһангир чыгып баса... Шул чакта театр куючыларның башына "Пауза... керүен керә, тик кайчан чыга икән соң, ул каһәр?" дигән әкәмәт бер сорау оеша. Җитмәсә, аңа сүз дә юк. Әмма Җиһангир "халык белән аңлашу җаен үзе таба — авылдагы төрле-төрле тискәре типларны сүзсез генә уйнап күрсәтә. Аның бу сүзсез роле халык арасында шундый зур шөһрәт казана ки, соңыннан "гыйлем яклары ныгып..." Паузаны сәхнәгә чыгармый башлагач та әле халык: "Нигә Пауза юк? Паузаны нигә катнаштырмыйсыз? Әллә чирлиме?" — дип аптыратып бетерәләр.

Әмма А. Тимергалин иҗатында юмор-сатираның иң күпчелеге, әлбәттә, фәнни-фантастика җирлегендә барлыкка килә. "Кибернетиклар хыялы" хикәясендә шикле кеше — кибернетика фәннәре магистры Френч — шефы боерыгы белән кибернетик автоматлар ясаучы көндәшләренең эше турында яшерен мәгълүматлар алып кайтырга җибәрелә. Әмма аны шымчылык эшендә тотып алалар һәм ул револьвер белән профессорны да, аның хезмәтчесен дә атып ега... — тик алар, кешегә охшатып ясалган роботлар гына икән, ул үзе чын профессор кулына килеп эләгә. Менә профессор аның өстенә атланып утырып кесәсеннән келәшчәләр, боргычлар, ачкычлар чыгарып... колакларын борып... ныклап торып өйрәнергә керешә:

"Ходай хакы өчен бормагыз, профессор әфәнде, — дип ялынды Барри Френч.

— Кара син шайтан! Чын кеше кебек кылана бит, дип башын чайкады профессор. — Мин уйлаганча ук надан булып чыкмады болар: авыртуны сизә торган әгъзалар ясап куйганнар.

Барри Френч шыңшый ук башлады:

— Мин тере кеше, чын кеше мин, профессор!

Барри Френч елап җибәрде.

— Алдашырга да өйрәткәннәр. Шәп! Шәп! — диде профессор. — Булдырганнар бит. Ләкин каянрак ачыла икән соң бу?..

Ул иң зур келәшчәне алды да кибернетика фәннәре магистры Барри Френчның борынына үрелде...

— Җибәрегез, зинһар! — дип ялварды Френч. Бөтенесен сөйлим, бөтен серебезне ачып бирергә риза, җибәрегез генә.

— Эх, булдыксызлар, — диде профессор. — Шундый эшкә кеше җибәрәләр димени! Ярый алайса. Сөйлә үзегезнең серләрегезне".

Әлеге пародия алымы белән барлыкка килгән көлкеле ситуациядә юмор гына

түгел, әлеге эшкуар көндәшләренең чын җинаятьчел йөзе дә, аларның куркаклыгы, икейөзлелеге, капитал дөньясының асылы булган кискен конкуренция принципы да бик үткен сатира утына алына.

"Космостан кунаклар" хикәясендә башка йолдыз системасыннан килгән "өчәр күзле, кул саен җидешәр бармаклы, кырмыскадай нечкә билле затлар"ның җир тормышын өйрәнүдәге беренче адымнары җанландырыла.

Әнә алар караңгы төннәрнең берсендә җир халкының аланлыкта урнашкан "торак йортларын" өйрәнергә дип умарта ояларына якынлашалар. Бу планетаның тормыш-көнкүреш үзәкләреннән берсе булса кирәк, дигән нәтиҗә чыгара алар рәт-рәт булып тәртип белән тезелешеп торган ояларга карап. Бер читтә яхшы ук зур корылма да караеп тора. "Монысы йә дини йолалар үти торган урындыр, йә булмаса гомуми җыелыш бинасыдыр", — дип уйлый аларның башлыклары. — Ә, бәлки, идарә үзәгедер?

Сәяхәт башлыгы, колак телефоннарын киеп, микрофонны бинаның кечкенә генә "ишегенә" якын китерде. "Мотор гөрелтесе кебек шуылдап торган тавыш башкаларга да аермачык ишетелде.

— Тәрәзә булмагач, түбәләренә өзек-өзек сигналлар рәвешендә шакып карасак ни булыр икән? — дип киңәш бирде биолог.

Алай да эш чыкмагач, биолог... тәвәккәлләп... "җиденче номерлы бармагын" йортның ачык ишегенә илтеп тыга.

"Биологның ачы итеп кычкырган тавышына штурман тәгәрәп китә язды. Капитан исә, бина түбәсенә тотынып калды. Дүрт казыкта гына утырган умарта оясы авып та төште, өч-дүрт кисәккә таралып та китте, ул да булмады, боларны меңләп бал корты сырып алды..."

"Угры" хикәясендә исә юмор геройның эчке фикерләвендәге үзгәреш нәтиҗәсендә барлыкка килә. Монда Киб кушаматлы "бөтен ягы белән кешегә охшатып эшләнгән робот" "туры әйткән котылыр, ялганлаган тотылыр", "усаллык җиңмәс, тугрылык җиңәр" кебек хакыйкатьләрне миенә сеңдергән робот, угрылар башлыгы Вик Дрей кулына төшеп, тиздән "кул кулны юа, ике кул битне юа", "хәйләсез дөнья файдасыз", "урла — тотылма" кебек сүзләр сөйләргә керешә һәм вакытлыча гына булса да үзе дә куркыныч җинаятьче булып ала. Роботның үз-үзенә каршы килеп, болай җиңел генә үзгәрүе, һичшиксез, елмаю уята. Әмма Вик Дрейның бу җиңел уңышы азактан үзе өчен бик кызганыч тәмамлана — робот аны полицейскийларга тотып бирә.

"Сәнгать бакчасында" исә без "Үр менеп басма чыкканда" китабының авторы белән очрашабыз. Бирэдә ул билетка бер тәңкә түләп әдәби әсәрләрнең каһарманнары яшәгән сәнгать бакчасына кереп эләгә. Һәм аны бу хикмәтле бакчада гарипгорабә геройлар иҗат иткәнлеге өчен шактый гына оялтып һәм кисәтеп чыгаралар. Чыгу капкасына аны Шүрәле озатып килә — илле тиенгә контрамарка да алып бирә. "Баегач, бер түләрсең, — дип кисәтте ул шулай да. — Чамала, һәр әдипнең хисап көне була...

Контрамарка тотып килгәч, капка үзеннән-үзе ачылып китте һәм мин гади дөньяга чыктым. Артыма борылып карасам, анда сәнгать бакчасының эзе дә юк, ә үзем чәчәкләр таптап басып торам икән.

Миңа бер сум штраф түләттеләр".

Хикәя әнә шулай көтелмәгән ачкычта, шаян рухта тәмамлана. Әмма әлеге хыялый да, реаль дә булган тормыш ситуациясе безнең күңелгә онытылмаска кереп кала. "Хисап көне булу", "Үлән таптап тору" кебек гыйбарәләр инде гадәти сүз булып түгел, ә бәлки җитди һәм көлкеле булып, реаль һәм символик булып, күп кенә заман әдипләренә нечкә сатирик бәя һәм кисәтү сүзе булып та яңгырыйлар.

Йомгаклап шуны әйтә алабыз, югарыда карап узган әсәрләрдән күренгәнчә, А.Тимергалинның фәнни-фантастикасы гаять күпкырлы. Күләме белән артык зур булмаган, ягъни 50 табактан артмаган (күрәсең, бу авторның роман кебек зур жанрларга мөрәҗәгать итмәве белән дә бәйледер) әлеге иҗат гаҗәеп дәрәҗәдә төрле юнәлеш, төрле башлангыч-тармакларга бүленеп яши. Әдипне без, һич икеләнмичә, универсаль фантаст дип тә атый алабыз. Аның татар әдәбиятында менә ярты гасырга якын инде бу жанрны берүзе диярлек баетып, үстереп килүе дә — шуңа этәрәдер, мөгаен. Җаваплылык хисе һәр тармакны игътибарсыз калдырмау теләген тудырадыр. Әлеге универсальлек тема һәм идеяда гына түгел, ә характер һәм психологик анализда да, эстетик формаларда да бик ачык күзгә ташлана.

Кыскасы, монда без фантастикадагы чиста хыяллануны да, оригиналь фәнни идеяләрне дә, галимнәребез иҗат лабораториясен дә, киләчәкнең хыялый матур тормышын күрсәткән утопияне, күпкырлы, күп юнәлешле кисәтүне дә күрәбез.

Чынбарлыкны фәнни-фантастик шартлылык аша күзаллап, аны үзенчәлекле психологик һәм эстетик образлар ярдәмендә танып белүдә, актуаль тәрбия-әхлак проблемаларын күтәрүдә, ерак тарихка җитди уйланып, киләчәккә якты өмет белән карарга өйрәтүдә, укучыда яшәүгә көчле омтылыш һәм ныклы ихтыяр көче тәрбияләүдә бу иҗатның әһәмияте бәһасез.

Инде фәнни-фантастика жанры кысаларыннан күпмедер читкәрәк чыгып, А. Тимергалинның икенчерәк төрдәге иҗат эшчәнлегенә дә берникадәр тукталып үтик.

Шундый аерым игътибарга лаек булган яңа әсәрләренең берсе, минемчә, аның "Казан утлары" журналында басылып чыккан "Игезәкләр" хикәяте. Автор аны асылда реаль материалга таянып яза. Әсәрнең төп каһарманы Азат — 1937 еллар корбаны. Җаваплы эштә эшләгән әти-әнисе кулга алынгач, аны, ике энесе белән бергә, ерак Украинадагы махсус балалар йортына озаталар. Сталин камарильясе төзегән "бәхетле" илгә Һитлер урдасы басып кергәч, Азат энеләрен югалта (берсе исерек фашист пулясыннан һәлак була, кечерәге туберкулездан үлә). Язмыш Азатны Германиягә илтеп ташлый... һәм ул әсәр ахырында мең киртәләр аша узып... үләргә дип үз иленә кайта... Ифрат талантлы булган Азат үзенең потенциал мөмкинлекләрен ача алмыйча, аны "дөньяга ят яраткан" керле җирдән мәңгегә китеп бара...

"Игезәкләр" хикәяте асылда тоталитар режимга каршы протест булып яңгырый һәм аны Адлер Тимергалин — әлеге вәхшилекләрне үз бәгъре аша кичергән олы шәхес, олы каләм иясе — язмыйча булдыра алмый иде. Яңа алымнар белән иҗат ителгән әлеге әсәр әдәби тәнкыйтебездә дә шулай ук бәяләнми калырга тиеш түгелдер.

145 басма табаклык материалны үзенә туплаган, авторның гомере буена туктаусыз эшкәртеп килгән "Миллият сүзлеге" исә Адлер Тимергалин иҗатының нәкъ менә икенче юнәлеше, ягъни фәнни эшчәнлегенең бер тармагы булып тора. Ул "әдәби юнәлеш"тән аерылып торса да, чынлыкта аның белән үрелеп яши. Кайчагында хәтта аны шуннан шытып чыккан дияргә дә була. Бу бигрәк тә "Сүзлек"нең гомумфәлсәфи концепцияләренә кагыла. Әйтик, "Тәмугта бер көн" хикәясендә Алла идеясенә нисбәтле башкатыргыч парадокс телгә алына ("Һәрнәрсәгә кодрәте җитә торган Алла үзе күтәрә алмастай таш барлыкка китерә аламы?") Авторның кырык еллар элек язылган фантастик хикәясендә бу сорауга җавап табылмаган. Чөнки философлар аны хәл итә алмаудан гаҗиз иделәр... ә менә яңа "Юл чаты" хикәясендә А. Тимергалин моңа җавабын бирә. Автор үзе "Миллият сүзлеге"ндәге "Алла" мәкаләсендә (аның кыскарак версиясе "Фән һәм тел" журналында дөнья күрде) Алланың потенциаль мөмкинлекләренә кагылышлы әлеге мәсьәләне (шулай ук четерекле кайбер башка сорауларны) хәл итә алдым дип, Алла идеясен, динне фән белән килештерә алдым дип уйлавын әйтә.

"Минем фантастик хикәяләрем Космос турында булса, "Миллият сүзлеге" татар Галәме, татарның тарихы, рухи дөньясы, теле һәм идеаллары турында. Китап уйлап чыгарган кеше — бөек, Сүзлек уйлап чыгарган кешелек дөньясы — даһи", — ди әдип.

"Мирас" журналында басылган "Фәтхулла хәзрәтләре" хикәятендә автор Фатих Әмирханның үлемсез каһарманын кабат терелтүгә ирешә. Фәтхулла хәзрәт белән Сынчы образлары аша ул үзенең иң эчкәреге фикерләрен якты дөньяга чыгара.

Кыскасы, Адлер аганың мул уңдырышлы, оригиналь рухлы иҗатында уртага салып җитди сөйләшерлек мәсьәләләр аз түгел. Әмма, ни хикмәт, мондый әтрафлы сөйләшү яки мәкаләләр һаман күренми, "Тимергалин архипелагы" ни өчендер әдәби тәнкыйть игътибарыннан гел читтә кала килә.

Ә без исә әлегә киң катлам укучылары исеменнән олуг әдибебез Адлер Тимергалинга күпкырлы әсәрләре һәм хезмәтләре белән безне ярты гасыр буена сөендереп килгәне өчен тирән рәхмәтебезне җиткерәбез һәм киләчәктә дә татар әдәбиятын өр-яңа ачышлар, яңа әсәрләре белән баетуына тирән ышанып, аңа озын иҗат гомере, бәхет, исәнлек теләп калабыз!

Адлер
Тимергалин

# ӘЛИФБА, ИМЛА, ФӘННИ ИСТИЛАХ

Бу искерәк сүзләрне мәкаләгә баш итеп сайлавымның сәбәбе, кат-кат кузгатылып, инде искерә төшкән темабыз укучыда күбрәк кызыксыну уятмасмы дип өмет баглавымда гына, һич тә модага ияреп гарәби сүзләр белән уйнау теләгеннән түгел.

Вакытлы матбугатны хәл кадәри күзәтеп барырга тырышсам да, соңгы вакытларда әлеге темага, бигрәк тә алфавитны үзгәртеп, кырык корамалы кириллицадан латин графикасына күчү (кайту) темасына зурдан кубып язылган мәкалә күзгә чалынмады. Бу мәсьәләне яшьтән үк төптән белгән һәм заманында янып йөргән галимнәребез олыгайдылар, басылдылар, ихтимал, көрәшә-көрәшә, җинелә-җинелә, алҗып та беткәннәрдер. Өметләре тәмам өзелсә дә гаҗәп түгел, хәтта татар хоруфатына кул селтәсәләр дә...

Юк, мин аларны гаепләргә ашыкмыйм. Эчкерсез энтузиастлар башында хөкүмәт тарафыннан куелган "пешмәгән" "житәкчеләр", фактта кадими большевиклар һәм битараф демагоглар торганда, иң изге милли идеяләр дә тормышка аша алмый.

Милләтпәрвәрлек—әйбәт шәйдер, әмма ул башкаларны кимсетү, рәнҗетү һәм буйсындыру хисабына булмасын. Безнең байрактагы шигарь—әүвәлгеләр әйтмешли, бихаккый милләтпәрвәрлек, үз вөҗүден саклау өчен көрәшә торган тәдафигый милләтчелек. Без башкалар өлешенә кермибез. Шагыйрь әйтмешли, "Без болай да бәләкәй түгел".

Шулай булары.

Ләкин, милләттәшләр, бүген кулыбыздагы милли мәгърифәт факелыбыз сүнәрсүнмәс пыскып кына яна, ә максатыбыз—"иске яналиф"—әүвәлгечә офык артында, моннан бер гасыр элек булгандагыча ерак, тагы да арырак... Менә 65 ел инде без залимнәр тарафыннан көчләп тагылган әлифба кулланабыз. Әлифбадан файдаланабыз дип язарга кул бармый, чөнки аның файдасына караганда зыяны күбрәк, чөнки ул безнең ана телебезнең тамырын корыта. Шәһәрдә яшәүче яңа буыннар инде татарча дөрес сөйләшми, татар теленә хас авазларны тамга-символына карап танымый (къ, гъ, һ, н хәрефләре), аларны адәм рәтле итеп әйтә дә белми. Бездә Швейцариядәге кебек билингвизм (ике теллелек) дип шапырынган арабызда, бөтен Казанга бер татар мәктәбе торып калып, хәтта авыл мәктәпләрендә дә әсасый (нигез) фәннәрне "үги ана телендә"—русча укыту тәртибе тормышка ашырыла башлаган иде. Бу темага манкортлар тарафыннан ничәмә-ничә китап нәшер ителгәндер, ничәмә-ничә "мөтәдиссертация" яклангандыр,—вакыты житкәч, кызык өчен генә булса да, бер очына чыгылыр әле.

Татарда латинчылыкның шактый озын тарихы бар. Мәсәлән, гарәп хәрефләрен ташлап, латин хәрефләренә күчәргә дигән тәкъдимне бездә беренчеләрдән булып Сәгыйть Рәмиев кертkән.

Яңалиф гамәлгә ашырылганчы, 1920 елда ТАССР Халык Комиссарлары Советы декреты белән Яңа имля гамәлгә керә. Бу язу системасы иске имляны ("Искәлифне") беркадәр гадиләштереп, кайбер хәрефләрне бетереп, сузык авазларны белдерүче гарәби хәрефләр (а, ә, и, у, ү, ы һәм е) өстәүгә нигезләнгән.

1926 елда исә Казанда латинга нигезәнгән "Яңалиф" җәмгыяте оеша. Аның

рәисе Ф.Сәйфи-Казанлы, әгъзалары арасында Г.Нугайбәк, Ш.Камал, И.Рәмиев, М.Фазлуллин һ.б.лар булган. Җәмгыять 1930 ел башына кадәр шул ук исемдәге журнал да чыгарып килә.

1928 елның 24 гыйнварында ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты бюросы яналифкә күчү чараларын көчәйтүне бурыч итеп куя. Төрки яналифнең рус алфавиты белән чагыштырганда өстенлекләре булуы турында "Красная Татария" газетасы да язып чыга (1928, 9 декабрь). 1929 елның 8 маенда Татарстан Советларының сигезенче съезды республикада яналифкә күчү турында карар кабул итә.

Татарстанда латин алфавитының тантанасы турында "Совкино" хәтта киножурнал да төшергән (1929, дүртенче номер).

Ә татар авыл клубларында "Яналиф" дигән бию көе аеруча популярлашып киткән иде. Әгәр кулымнан килә торган булса, мин перспективадагы өр-яңа "Яналиф" җәмгыятенең гимнына нигез итеп шушы бию көен алыр идем. Латин әлифбасы кебек гади һәм аңлаешлы ул.

Яналифчә язу берничә ел эчендә шактый камилләшеп, татар халкына (һәм СССР дагы күп кенә башка халыкларга) 1939 елга кадәр хезмәт итеп килде. Аннары, Мәскәү күрсәтмәсе буенча, аяз көнне яшен суккандай, рус графикасына нигезләнгән алфавит кабул ителә. Картлар сөйләвенә караганда, яңа орфография кагыйдәләрен эшләп, рус графикасы нигезендәге татарча орфографик сүзлек төзүгә нибары берничә көн генә вакыт биргәннәр. Ашык-пошык эшләнгәнгә һәм бигрәк тә татар теленә хас "гъ" һәм "къ" авазларын чагылдырмаганга күрә, аның җитешсезлекләрен "косметик" чаралар белән генә бетерергә мөмкин түгел.

Дөрес, үткән гасырның илленче еллары ахырында гамәлдәге татар графикасына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе кузгатылып, матбугатта шактый киң яктыртылган иде. Нәтиҗәсе аянычлы булды, хәтта борынгы төрки рун язмаларында ук очрый торган "къ" һәм "гъ" авазлары өчен махсус хәрефләрне кайтару турындагы тәкъдимнәр дә һавада эленеп калды. Аларының ни өчен үтмәгәнен адәм аңлаешлы итеп әйтүче дә булмады.

Заманалар үзгәреп, "какшамас" СССР бүселеп, илдә демократия җилләре исеп, "нацмен" халыклар иркен сулыш алып җибәргәч, бездәге алфавит мәсьәләсе ансат кына хәл ителер сыман тоелган иде. Хәтерлисездер, Ельцин әфәнде Казанга килгәч: "Мөстәкыйльлекне кабып йота алган кадәр алыгыз" дибрәк әйткән иде бит. Өлгермәдек.

1997 елның 20 гыйнварында кабул ителгән Татарстан республикасы законы нигезендә Татар алфавитында Ә, Ө, Ү, Җ, Ң, Һ хәрефләренең алфавиттагы урыннары үзгәртелде. Хәзерге алфавитта алар үз аналоглары янында, ягъни табигыйрәк урнашканнар. Ләкин "бөтен казанышыбыз" шул булды.

1997 елның 27—30 августында Казан шәһәрендә үткәрелгән Икенче Бөтендөнья татарлары конгрессы татар алфавитын кириллицадан латиницага күчерү мәсьәләсен дә карады. Латин графикасына күчү хакында Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевка мөрәҗәгать кабул ителде.

Әмма тагын барып чыкмады ошбу эш, һәм бу юлы үзебез дә гаепле. Алфавит турында кирәгеннән артык сөйләштек, озын-озак сүз куерттык, бәхәсләштек, үзара тәмсезләнешеп беттек. Демократия һәм мөстәкыйльлек булгач, бөтенесе дә үзеннән-үзе эшләнер дип уйлаганбыз, тарихны онытканбыз. Хәер, тарих бернигә дә өйрәтми, адәмнәрнең "арт сабакларын" гына укыта, ә иртәгесен алар бу сабакны да оныталар...

Үткән гасырның егерменче еллары ахырында—утызынчы еллары башында, латин графикасына ("Яңалифкә") күчүгә хәзерлек чорында Яңа төрки алфавит буенча Бөтенсоюз үзәк комитеты Баку шәһәрендә "Культура и письменность Востока" ("Шәрык мәдәнияты һәм язмачылыгы") исемле калын гына җыентыклар чыгарып килгән. Алардан күренгәнчә, дәүләт органнары яклавына да карамастан, ул вакытта да латинчыларның эше җиңел генә бармаган. Хәтерегездә булса, 1926 елның февралендә тюркологларның Баку шәһәрендә үткәрелгән беренче бөтенсоюз сьездында төрки халыклар өчен унификацияләнгән алфавитка каршы чыгыш ясаучылар арасында татар делегациясенең җитәкчесе, әдип, галим, Хезмәт Герое Галимҗан Ибраһимов та була. Ул Татарстан республикасы шартларында

латинлаштыруны гамәлгә ашыру мөмкин түгел дип саный. Галимнен дәлилләре саллы, ләкин шул ук Ибраһимовнын инде Бакудан Казанга кайткач, татар-совет инквизиторларының басымына түзә алмыйча, Галилео Галилей шикелле, әүвәлге карашларыннан ваз кичәргә мәҗбүр булуын да без яхшы хәтерлибез. Ә бит ул күптән түгел: "Бүген латин язуын кабул итсәк, тагы ун елдан безне рус алфавитына дүндерәчәкләр!"—дип белдергән иде.

Пәйгамбәр еллар хисабында ялгышмаган диярлек.

Ун ел үтәр-үтмәс, Хезмәт Героен авыру килеш татар-совет зинданына китереп ташлыйлар, ә 1927 елда ВКП(б)нын Татарстан өлкә комитеты Пленумы исеменә гарәп графикасын яклап язган татар интеллигенциясенең "82 протесты"на кул куючы Касыйм Хәмзинне, шактый сонарып булса да, 1948 елда барыбер "утырталар".

Хәмзин ага бәхетле булган әле. Ә менә химик Әхмәд Галиевне (ТАССРнын атказангын укытучысы Мәхмүд Галиевнен туганы, философия фәннәре докторы Булат Галиевнен агасы) башта латиницага каршы булганы өчен ун елга Воркутага сөрәләр (химия белгече анда радий казый), аннары сөргеннән Казанга латин хоруфаты белән хат язганы өчен, ана тагын ун ел өстиләр, чөнки инде буыны какшаган Казан, латиницаны ташлап, кириллицага күчеп өлгергән була, ә мәхбүс шахтер Галиев кара җир астында моны белми кала...

Кара эчле Сталин бернәрсәне дә онытмый, берәүне дә гафу итми, анын хәтере явыз (руслар "злопамятный" диләр). Ул хәтта үзенең әнисен дә гафу итә алмаган (генсек башы белән аны "себерке" дип атаган), исерекбаш әтисенен дә үлеме гаять дәрәҗәдә шикле, гаять дәрәҗәдә...

"Даһилар даһисы" Иосиф Сталин, кызы Светлана сүзләренә караганда, инде руслашып беткән һәм илнең төп халкы булган русларга ярау, шул ук вакытта грузиннарны да артык рәнжетмәүне күздә тотып, үзенчәлекле грузин һәм, бер очтан, әрмән әлифбасын да саклап калырга тиеш була, аннары инде бер кат билләре сындырылган төркиләрне җинел генә, боеру тәртибендә, рус графикасына күчәргә мәҗбүр итә. Каршы булганнарның күбесе "лагерь тузаны"на әйләнгән. Минем хәтер төпкелендәге "ихтыяри-мәҗбүри" дигән сүз шул заманнардан калгандыр...

Боларны шуна тәфсилләбрәк сөйләвем,—ул заманда да алфавит мәсьәләсе асылда бөек мәмләкәтчел сәясәтне күздә тотып хәл ителгән, чын фән һәм милли рух арткы планда калган.

Н.В.Юшмановнын "Ключ к латинским письменностям земного шара" китабына (1941) бирелгән бер кушымтада әлифбалары баштан ук рус алфавиты нигезенә корылган телләр исемлеге китерелә (белорус, украин, болгар, серб телләреннән тыш, мари, коми-зырян, мукшы-мордва, удмурт, карел, чуаш, якут һәм осетин белән абхаз телләре). Игътибарлы укучы монда алфавит мәсьәләсенең саф сәяси аспектларын күрми калмастыр. Рус алфавиты кертелү халыкларны аеруга, бүлгәләүгә бер-береннән (абхаз һәм осетиннарны грузиннардан, башкаларын, әйтик, төркиләрдән) ераклаштыруга хезмәт иткән һәм монын нәтиҗәләре бүген күзгә ташланып тора.

1938 елнын 30 декабрендә ВКП(б) Үзәк Комитетынын Политбюросы "Татар язмачылыгын рус нигезенә күчерү турында" карар кабул итә. Ике көн үтүгә үк ВКП(б)нын Татарстан өлкә комитеты бюросы утырышында әлеге карарны гамәлгә ашыру турындагы мәсьәлә тикшерелә. Күрәсезме, нинди өлгерлек!

Шунысы аермачык, бүгенге Дәүләт Думасы анлы рәвештә Сталин сәясәтен тота.

Касыйм ага Хәмзинне телгә алган идем. Без аны "Гарәпчә—татарча—русча алынмалар сүзлеге"нең (1962) төп авторы буларак беләбез. Берия лагерьларында Алла рәхмәте белән исән калган бу кешенең тыйнак, мөлаем елмаюын беркайчан да онытырлык түгел. Хәмзиннәрнең чит илләрдә дә унай бәя алган сүзлеген кулга тотканда мин Касыйм ага белән кул биреп күрешкәндәй булам. Гыйльми дәрәҗәләрдән мәхрүм булган бу зат татар фәнендә җуелмас эз калдырган,—моны без бүген бик яхшы анлыйбыз.

Әйе, бүгенге көн югарылыгыннан торып караганда, әлеге ике зыялыбыз татар алфавиты мәсьәләсендә хаклы да түгелләр, ләкин алар милли йөзебезне, вөҗүдебезне саклап калу өчен шаһидләрчә көрәшкәннәр. Халык өметсезлектән ынгырашкан

хәерче заманда бал-май эчендә йөзүче аерым галимнәрнең гырлый-гырлый йоклап яткан вөжданын шушы затларның якты күләгәсе генә уятса уята алырдыр.

Милли әлифбабыз булмый торып, бездә яна Тукай тумаячак, әдәбият буенча Нобель лауреатлары да булмаячак, чагыштыргысыз бәләкәй бүләк иңләре белән канәгатьләнергә туры киләчәк...

Без—бүгенге көн белән генә яшәүче җыбыткылар—пәйгамбәр Горькийның адәмнәр өчен шәһид киткән риваяти Данкосын онытгык. Без Иманыбызны дәһриләр аяк астына салып таптаганга да түздек. Моның өчен Мәңгелек Хакыйкать безнең үзебезне онытылуга хөкем итмәсмени? Фазыйлебез Ризаэддин Фәхреддиннең: "Хөррияте матбугат бетте, милли хәрефләребез ташланды, халкыбызның олуг бер кыйсьме иртидад кыйлды (мөртәд булды—А. Т.), хәзерендә төрки телебез беркадәр дәвам итеп киләдер, ләкин монысы да инкыйраз алдында", дигән пессимистик сүзләре искә төшә...

Инде әйткәнемчә, беренче латинчыларыбыз, әле Сталин көч алганчы һәм "даһи галим" булып "җитлеккәләгәнче", хакимият канаты астында эшләгәннәр һәм өстәвенә нәкъ менә шушы чорда "Главнаука каршында рус алфавитын латинлаштыру буенча подкомитет" та зур эш җәелдергән. "Культура и письменность Востока" җыентыкларының VI китабында проф. Н.Ф.Яковлевның тезислары шушы подкомиссия кабул иткән "Рус алфавитын латинлаштыруның зарурлыгы турында" дигән карар рәвешендә китерелә.

Тезисларның берничә пунктына күз салыйк әле.

"3. Рус алфавиты 1917 елгы өлешчә реформадан соң да,—ә моның максаты сыйнфый язмачылыкны массакүләм грамоталылык коралына әверелдерү иде,—һаман милли-буржуаз бөек рус идеологиясе алфавиты булып кала бирә. Бу элек рус графикасыннан файдаланып килгән милләтләрнең (осетиннар, абхазлар, коми халкындагы хәрәкәт һ.б.) идеологик яктан нейтральрәк булган латин графикасына күчәргә омтылышларында аеруча ачык чагыла.

Шул ук сәбәпләр аркасында, гарәп әлифбалы милләтләр аңа алмашка рус графикасын түгел, бәлки латин графикасын аңлы төстә сайладылар, хәтта латин алфавитын рус алфавитыннан алынган аерым хәрефләр белән тулыландыру да яраксыз дигән принципны күтәрделәр...

4. Хәзерге вакытта латин алфавиты инде халыкара графиканың нигезе булып җитлекте, бигрәк тә совет Шәрыгында һәм өлешчә шәркый чит илләрдә ул культура революциясенең бер лозунгысына әйләнде (совет Шәрыгында, Төркиядә, Персиядә гарәп алфавитына каршы хәрәкәт тарихы, инглиз шәрыкшинасы Дэнисон Росcның Тәһранда гарәп һәм латин алфавитлары турындагы докладын). Совет шәрыгында милли латин алфавитларын унификацияләү (НТА, НДА, НГА) бердәм халыкара алфавит төзү юлында реаль адым булып тора...

6. Хәзерге рус алфавиты, башка милли графикалар (еврей, грузин, әрмән һ.б.) кебек үк, Союз эчендә милләтләрнең тел ярдәмендә аралашуын һәм культура алмашуын кыенлаштыра, аерым алганда, барлык телләрдә үсә барган халыкара терминологиядән файдалануга комачаулый...

8. Рус алфавитының график формасы гына түгел, аның орфографиясе дә, хәтта реформадан соң да, революциягә кадәрге сыйнфый язмачылыкның җитешсезлекләрен саклап калды. Бер үк авазны берничә хәреф белән белдерү (мәс., "j") һәм бер хәреф белән берничә авазны сурәтләү (мәс., "е" һ.б.), бер хәреф белән тулы бер иҗекләрне күрсәтү ("я", "ю", "ей" һ.б. һ.б.)..."

Әлеге подкомиссия якын киләчәктә русларның латинга нигезләнгән бердәм халыкара алфавитка күчүе зарури дип саный һәм 1930 елның 14 гыйнварында бу турыда күләмле карар чыгара. Карарда яна рус алфавитының өч төрле үрнәк проекты да күрсәтелгән. Бу проектларны сурәтләгән язылыш мисаллары безгә бүген дә файдалы, латин алфавитына күчкәннән соң татар телендә йөри торган рус сүзләрен ничек язу мәсьәләсен шушы мисалларга карап җинелрәк хәл итәргә мөмкин булыр иде.

Подкомиссиягә рус теле укыту буенча белгечләрдән проф. А.М.Пешковский,

проф. Н.М.Каринский, С.Н.Абакумов, башка милләт вәкилләреннән В.И.Лыткин (угро-финновед), Юманкулов (ВЦК НИДА); тел белгечләре—проф. Л.И.Жирков, проф. Н.Ф.Яковлев, А.М.Сухотин, уйлап табучы инженер Ездаков һәм полиграфия белгечләре проф. М.И.Шелкунов, В.В.Николаев, А.В.Горшковлар кергән.

Рәис итеп әлеге проф. Н.Ф.Яковлев, секретаре итеп В.И.Лыткин билгеләнгән.

Бүген бу энтузиастларның биографиясен күздән кичерү рус алфавитын латинлаштыру идеясенең язмышын һәм ничек итеп сүнү-сүрелү тарихын ачыклауга ярдәм итә алыр иде. Тоталитар режим шартларында болар да, чын шәхес булганлыклары сәбәпле, Сталин камарильясенең канлы тырнагына эләкми калмаганнар.

Шушы ук елларда, мәсәлән, яна тат (тау-еврей) һәм көрд алфавитларынын да проекты төзелгәнлеген әйтеп китсәк, укучылар өчен кызыклы булыр. "Культура и письменность Востока" җыентыгының IV китабында нәкъ шул хакта К.В.Юшмановның "Бөтендөнья алфавиты тәҗрибәләре" дигән мәкаләсе урнаштырылган.

Латин графикасы—бөтен кешелек дөньясының иртәгесе көне ул. Киләчәк Кытай яки япон иероглифларыныкы да, еврей, грузин, әрмән һәм гарәп яки рус графикасыныкы да түгел.

Хәзерге компьютер программалары нигездә латин графикасы өчен җайлаштырылган (система шрифты латинча), башка хәрефләр белән эш иткәндә ул ялгышларны ешрак җибәрүчән булганга, теләсә кайсы телдәге биремнәрне гадәттә латин хәрефләре белән язарга тырышалар.

Рус яки татар хәрефләре куелган язу машинкасын ясау кыен булмаган (заманында Казанның үзендә "Яналиф" маркалы язу машинкалары җитештерелә иде), ләкин компьютер программасын тулысынча руслаштыру өлкәсендә безнең программистлар коточкыч артта калган булып чыкты. Өстәвенә компьютер техникасына караган терминология рус телендә дә эшләп җиткерелмәгән. Бүген компьютердан файдаланучы миллионнар, ә иртәгә миллиардлар, телиләрме, юкмы, латин алфавитын өйрәнергә һәм инглиз телен үзләштерергә тиеш булачаклар.

Тагын шунысы кызык, күренекле татар галиме һәм сәясәтчесе Садри Максудиның кызы Адилә Айда (Төркия) борынгы этруск халкы әлифбасын төрки этрускларның элгәрләре—турсакалар яки пеласклар Урта Азиядән Италиягә алып килгәннәр дип исәпли. Шушы иске төрки әлифба әкренләп латин әлифбасы булып үзгәргән. Әгәр дә галимәнең фаразлары дөрескә чыкса, төркиләрнең латин әлифбасына кайтуы асылына кайту шикелле вакыйга ул.

Ярар, монысын да калдырып торыйк.

Бүген безгә нишләргә соң?

Безгә янә активлашу зарур. Матбугатта, радио һәм телевидениедә кабат һәм кат-кат чыгышлар ясау кирәк. Бу чыгышлар тыныч академизм белән генә сугарылган булмасын,—ялкынлы һәм дәлилле публицистикага кытлык хәзер. Әмма матбугатны җыен чүп-чар белән, кырык тапкыр кабатланып инде таушалып беткән фикерләр белән тутырмау хәерле. Безгә чабаталы патриотизм да, чалмалысы да кирәкми! Әйтик, кире гарәп хоруфатына кайту турындагы регрессив "идея" безнең файдага эшләми, эшли дә алмый. Думада утырган бөекмәмләкәтчеләргә ишетелерлек һәм йоклап утыручыларын да сискәндерерлек үткен чыгышлар, көчле дәлилләр, күмәк (ачык һәм ябык) хатлар кирәк, елак шикаятьләр түгел, бәлки кискен тәгъризат (протестлар) кирәк.

Әлбәттә, җәмәгатьчелегебез тик кенә ята бирә дип әйтеп булмый. Әле күптән дә түгел (2005 ел башында) Татар ПЭН-үзәгенең киңәйтелгән утырышында "латин имлясына кайту мәсьәләсенең бүгенге торышы" да каралып, утырыш "һәр халыкның үз телен файдалану, шул исәптән үзенең язу графикасын билгеләү буенча халыкара оешмалар раслаган үз хокукы булуын билгеләп үтте". Бөтендөнья Татар конгрессы Башкарма комитеты исеменнән "латин проблемасы"на нисбәтән ЮНЕСКО Генераль директорына мөрәҗәгать җибәрелгән. Әлеге утырышта катнашкан хокук эксперты, юридик фәннәр кандидаты Борис Пантелеев (Мәскәү) Россия

Федерациясе Конституция судының татар язуында латин графикасын куллануны тыю турындагы карарына (16 ноябрь, 2004 ел) җентекле анализ ясап, проблеманы хәл итү өчен кеше хокукларының Европа судына мөрәҗәгать итү тәртибен тәфсилләп аңлаткан.

Европа судының объектив булачагына өметебез бар, ул бөек мәмләкәтчел шовинистларның борынына чиертер дип уйлыйк. Ләкин хокуксызлык хөкем сөргән криминаль җәмгыятебездә бу гына җитмәячәге дә көн кебек ачык.

Безгә бүген бердәмлек аеруча кирәк. Без арбаны, Крылов мәсәлендәге кебек, төрлебез төрле якка тартабыз. Бердәмлек дигәндә мин милләттәшләребезне генә түгел, бәлки бөтен ил, элеккеге СССР чикләрендә булган барлык мөстәкыйль дәүләтләр һәм, гомумән, бөтен дөнья күләмендәге латинчыларны да күздә тотам. Әйтик, табигатьтә башкорт латинчылары бармы? Бәлки без күршеләребез белән һич югында шушы юнәлештә аркадаш булып, уртак тел, уртак мәнфәгатьләр таба алырбыз?

Ләкин, беләсезме, башкорт галимнәреннән бигрәк, рус галимнәренә исәп тотыйк әле. Әйе, безгә латинчылык идеясен тергезү һәм аякка бастыру өчен исән калган рус латинчылары белән берләшү мөһимрәк. Шик тә юк, бу көрәштә "эчке дошманнарыбыз" саны бермә-бер артачак, ләкин дөнья күләмендә тарафташларыбыз һәм көрәштәшләребез дә күбәер дип уйларга батырчылык итәм.

Милләтәшләребезнең дә төрлесе бар икәнен күреп торабыз.

Әле бик күптән дә түгел, Россия һәм Европадагы БДБ илләре мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте мөфтие Тәлгать ибне Сафа Таҗетдин хәзрәтләренең татар язуында кулланыла торган рус графикасын яклап, безләр өчен "кириллица"ның алыштыргысыз булуын дәлилләп, алай-болай алыштырсаң, Татарстаннан читтә яшәүче мөселманнарыбызның татар матбугатыннан мәхрүм калачагы турында кайгыруын Мәскәү телевидениесе аркылы ишетеп тә гаҗәпсенгән идек.

Мөфти, әлбәттә, бу өлкәдә белгеч түгел. Ләкин, рухани җитәкче буларак, аның фикере татар колагында саллырак яңгырар дип уйлаганнар, ахры.

Бер төркем татар мәдәнияте әһелләренең рус графикасын сакларга өндәп язган күмәк хатын да укыган идек. Хәзер инде хәтерләп бетермим, хатка кул куючылар арасында берничә Ринат булуы гына истә калган.

Кызганычка каршы, Казандагы рус мәктәпләрендә татар теле укытучыларыннан да шундыйрак пессимистик сүзләр ишеткәнем бар... Дөресен әйткәндә, алар үзләренә дә янабаштан сабак укырга туры киләчәген сизенеп, күбрәк шуннан куркалар шикелле.

Безне үгисеткән теге күренекле карендәшләребезнең күмәк хатына җәмәгатьчелегебезнең җавап реакциясе тиешенчә кискен булмады. Үзебезнең дин әһелләре дә, йөрәкләре җитеп, дустанә рәвештә сыйпаштырып кына булса да, Тәлгать Таҗетдин хәзрәткә кайбер хакыйкый нәрсәләрне төшендерсәләр әйбәт булыр иде дә...

"Бөтендөнья латинчылары, берләшегез!" дигән лозунг астында Казанда егерменче еллардагы кебек рәсми латинчылар җәмгыяте ачарга һәм ул җәмгыятьнең бөтен Россиягә таралган челтәрен булдырырга кирәк. Табигый, бу җәмгыятьнең фондлары һәм мөстәкыйль матбугат органнары (журнал, җыентыклар, татар һәм рус телләрендә газеталар), шулай ук интернетта үз сәхифәсе булырга тиеш. Бүгенге "Яңалиф" нәшрияты исә эшен активлаштырыр дип өметләнәбез. Милләтпәрвәрләрне кузгата алсак, мондый чыгымнар капланыр иде.

Ә могтәбәр галимнәребез һәм милләтпәрвәр түрәләребез үз хезмәтләре буенча гайрәтлерәк эш йөртсеннәр. Соңгылары турыдан-туры Дәүләт думасына, Россия Конституциясенең гаранты булган илбашына, ахыр чиктә Халыкара мәхкәмәгә, БМО га чыга алалар.

2005 елның гыйнвар аенда "Казан утлары" журналында "Җәмәгатьчелек фикере" дигән баш астында дистәгә якын җәмәгать һәм фәнни оешмаларның, Татарстан Язучылар берлегенең, ПЭН-үзәкнең һ.б.ның "Латин әлифбасына кайтуны яклыйк!" дигән мөрәҗәгате басылып чыкты. Әйбәт һәм кирәкле адым бу. Шунысы гына кызганыч, бу мөрәҗәгать журнал санының ахыргы битләрендә, вак хәрефләр белән басылган.

Мескенләнмәскә! Баш имәскә, буйны сындырмаска! Җинүнең бердәнбер шарты шул.

Тимер әле суынып җитмәгән, кызуында сугарга вә кат-кат сугарга кирәк! Әйткәнемчә, империя чаннарын үзебез каксак, ераккарак ишеттербез.

Рус (кириллица) хорефатындагы куш авазларны белдерүче тамгалар (щ, ц, е—йо, йэ, ю—йу/йү, я—йа/йә)—болар иҗекләп язу ысулына кире кайту, иероглифларга таба чигенү дип бәяләнергә тиеш. Һәрхәлдә без латин һәм грек алфавитларын белер-белмәс бозып, бутап төзелгән хорефатны ихтирам итә алмыйбыз, өстәвенә ул аннан сон да кат-кат үзгәртелгән (чиркәү тарафыннан да антихрист дип ләгънәтләнгән Петр патшаның рус алфавитына тыкшынулары үзе бер фаҗига бит). Ә без? Ә без рус агайлар үз алфавитларына һәм орфографияләренә керткән һәр үзгәртүне берсүзсез үзебезнекенә кабул итәргә мәҗбүрбез. (Дөрес, кайчагында бу үзгәртүләр татар өлгесенә бик туры килгән очраклар да була. Мәсәлән, озак вакытлар буена руслар "матрац" дип язып килделәр, хәзерге сүзлекләрдә дөрес язылыш—матрас.)

2004 елда Думада утыручы "акыллы затлар" "бума" закон кабул иттеләр: Россия Федерациясендәге халыкларның алфавиты кириллицага нигезләнгән булырга тиеш, һәм вәссаләм! Бу мәҗбүри канун башка мөстәкыйль илләрдәге татарларга да кагыла дип уйласалар, думачылар бик нык ялгышалар, бусы аларның көченнән килми.

Думачы русификаторлар Н.Ильминский башлап җибәргән һәм рус-татар мәктәпләрендә татарча текстларны транскрипциядә бирү турында патша хөкүмәтенең 1906 ел 31 март боерыгына туры килә торган сәясәтне дәвам иттерүләрен белмиләр кебек. Бүгенге Думада Мольер каләменә лаек җаһил мешчаннар буа буарлык бит.

Баксаң, Н.Ильминский да үзенең сәясәтен буш җиргә кормаган икән. 1878 елда Санкт-Петербург университетының Шәрык телләре факультеты үзенең өч утырышында мондый фикергә килә: "а) бүген төрки-татар халыкларда гамәлдә йөргән гарәп әлифбасы төрки-татар гаиләсенә караган телләрнең авазларын төгәл чагылдыру өчен башка барлык алфавитларга караганда да яраксызрак, б) Европа һәм Азия алфавитлары арасында иң байларыннан берсе булган рус әлифбасы төрки-татар телләрендәге авазларны бирү өчен гарәп әлифбасына караганда чагыштыргысыз дәрәҗәдә кулайрак."

Күрәбез ки, татар әлифбасын руслаштыру турында рус голямасы әллә кайчаннан бирле хыялланып яткан икән. Хәтта күренекле тюркологыбыз Н.Ф.Катанов та бу мәсьәләдә рус миссионерлары тегермәненә су коя. 1897 елда ул түбәндәгеләрне язган: "Татарлар ислам динен тоткан һәм мөселман шәрыгыннан килгән китапларны укуларын дәвам иткән вакытта татар теле чит тел—гарәп, фарсы һәм төрек сүзләре белән чуарланган булачак."

Асылда руслашуга, милләтебезнең, Исхакый әйтмешли, чит халык мигъдәсендә каймак кебек эреп йотылуына илтә торган омтылышлар искә төшкән саен, күнел тетрәнеп китә. Заманында татар алфавитын кириллицага күчерүдә актив катнашкан "кызыл профессор", ТАССРның атказанган фән эшлеклесе М.Фазуллин (1883—1964) "И.В.Сталинның тел гыйлеме буенча хезмәтләре нигезендә орфографик грамоталылык өчен көрәш" дигән хезмәтендә (1953) татарча Әхмәт, Әхмәт улы, Әхмәтов урынына Ахмет, Ахмет улы, Ахметов дип язарга тәкъдим иткән иде... Ышансаң—ышан, ышанмасаң—юк. Шушы "эшлекле" затның 1926 елларда латин графикасын кертү белән шөгыльләнүче "Яналиф" җәмгыятендә әгъза булып торганлыгын әйткән идем инде. Күрәсез, совет чынбарлыгы анның флюгерын 180 градуска борган да, "Мухаммедхан Ашрафзянович Фазуллинның" үзенә "Ибан Ибаныч битлеге" каплаган икән.

Сүз дә юк, дошман як көчле. Ул бүген XIX гасырдагыдан да, XX гасырдагыдан да көчлерәк. Шовинистларга ярдәмгә Я.А.Кеслер, Г.С.Гриневич кебек манкортлар килде. Алар славян һәм рус алфавитының беренчел булуы, латиницаның икенчеллеге, хәтта грек алфавитының да, иврит (!) аркылы, праславян азбукасына барып тоташуы турында "теория" уйлап чыгардылар. Сулдан уңга таба язу да праславян алфавиты йогынтысында барлыкка килгән имеш. Ул гынамы соң! Я.А.Кеслер, "сирриятле славян җаны" һәм "сирриятле еврей җаны" кебек томанлы

сүзләр куллана һәм асылда еврейләр белән русларның (славяннарның) Алла тарафыннан сайлап алынган (сайланмыш, мостафа, өстен) халык булуы турындагы реакцион идеяне алга сөрә. Мәскәүнең "бума" думачылары исә шушы ялган фән әһелләренең бармактан суырып алынган "фөкер"ен кабатлыйлар.

Бүген панславянизм (бөтендөнья славянпәрвәрлеге) элекке СССР чикләрендә, ә бәлки географиясе бераз киңрәк тә булыр әле, аяусыз халыкара террорчы кебек эш итә, һәм кириллицаны, башка милләтләрнең телен корыту максаты илә, 33 патронлы (хәрефле) автомат "калашников" сыйфатында куллана. Халыкара "разбуй" салырлык эш бу, турысын әйткәндә. Моны ачык аңларга кирәк.

Бүгенге күренекле зыялыбыз Рафаэль Хәким үзенең 2005 елда гына басылып чыккан "Метаморфозы духа" дигән этрафлы хезмәтендә татар теленең интернет челтәрендә куллану өчен яраклы "Inəlif" алфавитын кушымта итеп биргән.

"Inəlif" 34 хәрефтән тора. Анда нечкә сузыкларны чагылдыру өчен латин хәрефләре янына куелган апостроф билгесе хезмәт итә. Ч, калын Г һәм калын К, шулай ук Х, Ш, Н, Ш хәрефләрен куш билгеләр белән, ә рус телендәге Ц авазын куш билге һәм Щ авазын өч билге белән бирү күздә тотылган. "Яңалиф-2" дән кайбер башка аермалар да бар.

"Inəlif"тән файдалану бернинди матди чыгымнар түгүне сорамый,—бусы да мөһим.

Шулай да "Inəlif"не тулаем кабул итү кыен, минемчә. Ләкин эзләнү үрнәге буларак, бу алфавитны гәзит-журналларда яктырту кирәкле шәй дип уйлыйм. Татар укучылары һәм компьютерда татарча текст белән эш итүчеләр Рафаэль Хәкимгә үз фикерләрен әйтерләр иде. Авторның әлеге саллы хезмәте белән танышырга теләүчеләр дә күбәер иде...

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында саклангaн кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

# “СИСКӘНДЕРЕП ГАМЬСЕЗ КӨННЕ...”

(Харрас Әюпов иҗаты турында уйланулар)

Соңгы егерме елдагы татар поэзиясендә фәлсәфи характердагы әсәрләр еш күренә башлады. Мондый эчтәлекле шигърияттә Яшәеш, анда Инсанның урыны, роле турында уйлану һаман кинәя бара. Шушы юнәлештәге шигырьләре белән Харрас Әюпов иҗаты да игътибарны җәлеп итә.

Аның шигырьләре артык кычкырып, “мин” дип тормый, рифма һәм ритм ягыннан да алар гадәти кебек. Әмма шигырьнең эчтәлеге безне шундук үзенә беркетеп куя, чөнки ул бүгенге укучы оныта башлаган хакыйкатьне “уятырга”, күрсәтергә тырыша, бер дә булмаса, шулар хакында уйлап алырга чакыра. Мәсәлән, “Яшен вакытында язылган шигырь” (Әюпов Х. Җәяүле буран: Шигырьләр һәм поэмалар.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1996). Бирелә шагыйрь кешелек тарихында онытыла башлаган кыйммәтләрне—Хаклык, Чынлык, Намус, Нәсел рухын күтәрә. Яшен яшьнәү бер генә адәм баласын да тыныч калдырмый. Автор менә шушы күренешнең фәлсәфилеген күрә һәм аны Кешелек, Инсан тормышының рухи асылын яктырту өчен куллана.

*Сискәндереп гамьсез көнне кинәт*
*Телеп узды яшен...*

Яшен кешене яшәү белән үлем чигендә калдыра, чөнки кеше хәтерендә гөнаһлары өчен “яшен сугу” дигән хикәятләр саклана.

*Син кайттыңмы, үлем белән гүргә*
*Томаланган Чынлык?—*

дип сорый ул галәмнән.

*Ялгыштыммы, буталдымы юлым,*
*Дөрес яшәмимме?—*
*Нәселем рухы! Әллә шулай миңа*
*Син соң дәшәсеңме?*

Һәм ахырда, шагыйрь кешенең бу дөньяда кылган гамәлләрен, яшәү рәвешен истә тотып: “Яшен булмастыр ул—сукса беркөн” дигән нәтиҗә ясый. Адәм баласының бу тормыштагы кодрәте, аңа бирелгән миссия хакындагы “Язмыйм инде...” дигән шигырь дә кызыклы. Шагыйрь үзенә килгән шигъри илһамның чыганагын, үзе башкарган гамәлне ачык күрсәтә, рәвешен билгели:

*Каян алып,ниләр язам,*
*Ничек язам?—*
*Беркем белми.*
*Язмыйм инде... Тыңлыйм бары*
*Дөнья шавын, көн-төн дими.*

Димәк, шагыйрь бу дөньяны сурәтләгәндә үзе уйлап чыгармый, ул бары тик дөньядан төсләр, сүзләр, көй ала һәм шуны кәгазьгә төшерә генә, чөнки аның төп вазифасы—дөньяның, яшәешнең “көен” кәгазь яки тукыма аша башкаларга җиткерү.

*Ифрат җиңел кайчак миңа*
*Сүзләр әзер, көй сибелгән...*

Дөньяның сурәтен тудырганда рәссам барлык җан иясе исеменнән "сөйли" һәм хәтта бу дөньяда яшәү авыр булып, аннан ваз кичәргә уйлаган вакытта да аннан "китәргә" аңа әлеге "миссия" комачаулый.

*Җырлыйм бит мин җиремдәге*
*Һәрбер яфрак исеменнән.*
*.......................................*
*Дәшәлмисең—болыннарда*
*Риза түгел тик бер үлән...*

Харрас Әюпов иҗатында кешенең жирдә яшәү рәвеше белән генә түгел, аның "кан хәтере" белән бәйле фикерләрне дә очратырга була. Мәсәлән, "Минем яшем" дигән шигырендә лирик герой үзенең аерым бер чор кешесе генә түгеллеген искәртә дә, милләтенең дәвамчысы икәнен хәтерендә халык, милләт, нәсел хатирәләрен йөртүе хакындагы идеяләр аша дәлилли. Аның бу идеясе кешенең гомерен туган халкы яши башлаган чордан ук санарга кирәклеге хакындагы көчлерәк икенче бер фикергә кадәр үстерелә. Бу фикерен дәлилләү өчен ул: "Бик фәкыйрьдер кеше, Гомерен әгәр Тик үз яше белән үлчәсә",—дип кискенләштерә дә, "Бүтән гомер безгә нигә кирәк?—Халкым белән бит мин бер яшьтә",—дигән нәтиҗә ясый.

Шушыңа охшаш идеяне авторның "Ташлар жыйдык истәлеккә..." дигән шигырендә дә күрергә була. Монда ташлар аша кешелек тарихын, хәтерен ачыкларга мөмкин дигән фикер белән очрашабыз. "Салып карыйм уч төбемә Жирнең миллион елын: Килеп кушылды ул ташка Минем дә барыр юлым".

Автор фикеренчә, ташлар адәм баласының гомерен үзләренә сендереп баралар һәм аны киләчәккә илтәләр. Димәк, "кемнәр белән"дер янәшә язылган, кемнеңдер язмышына кулы кагылган "миллион еллык чал тарих кисәкләре" аунап ята яр буйларында. Кеше тормышын шул рәвешле галәм масштабында карау адәм баласының үз гамәлләренә җаваплылык тоюы кирәклеген искәртә.

"Тирәндәрәк әле..." дигән шигырендә исә автор гомумиләштерү аша яшәү асылының кайда икәнлеген күрсәтергә алына. (Автор аны философларча "энҗе-мәрҗән" дип атый.)

*Ата-баба нигезенә кайттым...*
*Мин халкыма килдем.*
*Эзләгәнем*
*Шушында дип башым игәндәрәк,*
*Яңгырады кебек әлеге өн:*
*—Тирәндәрәк, улым, тирәндәрәк!...*

Яшәешнең кыйммәте Яшәү дигән вакыт аралыгының үзендә дигән фикер саркып кала шигырьнең ахырында.

Х.Әюпов иҗатында Алласыз дөнья, аның асылы хакындагы фикерләр дә чагылыш таба. Мәсәлән, шундыйларның берсе—"Тел тидерү түгел Ходайга" шигыре. Әлеге шигырьдә динсезлекнең нәтиҗәсе, адәм баласының рухи һәм жисми алашуы турында сүз алып барыла.

Туры юлдан тайпылып яшәгән дәвердәге сыйфатлардан арыну авыр адәм баласына. Әмма хак юлдан тайпылмыйча бару тагын да авыррак. Чөнки тормыштагы ялтыравык, тышкы яктан матур тоелган күренеш-әйберләр кешене һәрчак ымсындырып, алдап тора.

Алласыз, имансыз бу илдә ижтимагый яшәү өчен кирәк булган тел, милләт кебек кыйммәтләрне яклап та тавыш бирә Харрас Әюпов. Аны "милләт мәнфәгатен яклаучы" дип әйтү генә иҗатының фәлсәфилеген тарайту, гомумкешелек масштабта фикер йөртүеннән игътибарны читкә юнәлтү булыр иде. Шулай да шагыйрьнең татар халкы язмышын кайгыртып, җан атып язган шигырьләрен күрсәтми үтү аның иҗатының тирәнтен эчтәлекле, актуаль проблемалы булуына күз йому кебек килеп чыга. Харрас Әюпов милләтенең фаҗигале язмышын авыр кичергән шагыйрьләрнең берсе. Мәсәлән, "Ачыгыз капка" дип исемләнгән шигырендә автор бер татар вәкиле исеменнән генә сөйләми. Күпләрнең җаны татар теле, татарның киләчәге турында әрнегәндә, Х.Әюпов үзләренең кыйммәтле хәзинәсен "дөнья капкасы" артында

кирәксезгә ташлап калдырган милләтнең уллары-кызларының битараф күңелләрен уятып: "Ачыгыз капка" дип "кычкырып йөри":

*Туган телегез торадыр*
*Бөрешеп чатта.*

Әйе, "кешелеген җуйган" бу кемсәләр "дәвернең хәтәр җилләре куырган чакта", нәкъ безнең татарларча итеп, "бикләнергә өлгергәннәр җитешеп алдан". XX гасыр башында бөек шагыйребез Тукай татар халкын битарафлык, мәнсезлек йокысыннан уятырга теләгән кебек, Х.Әюпов та "уяныгыз ла тизрәк" дип җан ачысы белән кычкыра: "Ачы-ы-ы-гыз". Татарның ин кадерле нәрсәсе—туган теле һәм аның йөртүче рухы—кирәксез, кадерсез булып урамда ятим булып кала түгелме соң?! Ятим калган йөрәк төшенчәсендә әнә шул милли рухны чамалау авыр түгел:

*Беркайчан бирмәгез Моңны,*
*Бирмәгез ятка...*
*Йөрәкләрегез урамда...*
*Ачыгыз капка!*

* * *

Татар халкын юртак аттан яки эш атыннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Гәрчә бүген илнең әзмәвердәй улларын чит ил "атлары" тартып йөрсә дә, ир-ат дигәндә генә түгел, "татар" дигән сүзне әйткәндә дә төпле, тыйнак холыклы, монсу күзле зиннәтле бу малкай күз алдына килә. Ул һаман да безнең каныбызда, геннарыбызда, милли кодларыбызда архетип булып яши. Х.Әюпов менә шушы архетипны "Атланалмый калган атыбыз" шигыренең нигезенә салып, татарның атны оста җигә һәм йөртә белгән дәверләрен искә төшерә. Ат образына әлеге шигырьдә тагын бер мәгънә салынган—дәвернең үзе. Монда татар халкына берничә тапкыр "атның сыртына ныклап менеп утыру" мөмкинлеге булган "алтын яллы гасыр"—XX гасыр турында сүз бара.

"Ә без әле дә Иртә таңнан бирле ат тоталмый Азапланган малай хәлендә"—"өстерәлә илем тезгендә". Шагыйрьдән артыграк итеп, образлы итеп әйтү кыен. Ватанның хөрлеге юлында башкарасы калган хисапсыз эшләр, гамәлләр "атланалмый калган атыбыз"ны хәтерләтә бүген...

"Дөнья яратылу" шигырендә Х.Әюпов һәр кеше өчен анык хакыйкатьне ачып сала: "...Тик нигәдер миңа бу тереклек Башланадыр сыман безнең өйдән". Асылда, чыннан да, һәммәбез өчен әйләнә-тирә белән, тормыш белән танышу нәкъ менә үз "бишегеннән" — үз йорты, гаиләсеннән башлана. Билгесез дә, беренче карашка, чиксез дә тоелган дөньяда иң якын, иң таныш кеше — ул Әнкәй. Шушы якты, нурлы йөз яктылыгында "әткәй әрчеп биргән бәрәңгеләр", "уенчыклар... идән... ишегалды... яшел хәтфә урам... аннан өйләр" "туа" барган. Нәкъ менә шушы туган нигез яктылыгында, шуннан торып күңелләрне якты, нурлы итү өчен "сайрар кошлар", кечкенә адәм баласын батыр, көчле итү өчен "усал маэмайлар" яратылган.

Яшәешнең асылы хакында һәр иҗат әһеле уйламый калмыйдыр, уйланадыр һәм үзенчә җавап та табадыр. Моның хакында калын романнар, озын повестьлар да язарга була. Әмма Х.Әюпов аңлы, акыллы кешене гомеренең ахырына кадәр борчый торган әлеге сорауга җавапны поэтик фикерләү теле белән "Үз-үземне белә башлаганда" дип исемләнгән бер шигырьгә сыйдырып бетерә алган. Әлеге әсәрдә "хәтер" категориясе кулланыла һәм ул "яшәү" дигән якты вакыт аралыгының кабатлануын күрсәтә. "Әүвәл яшәвемдә кем идем соң?" дигән фәлсәфи сорау бу шигырьдә инде ачыктан-ачык яңгырый. Ул Х.Әюповның "Ташлар җыйдык исәлеккә", "Дөнья яратылу", "Минем яшем" кебек шигырендә төп мотивка әверелә. "Нидер җитми җирдә... Кемнәрдер юк—Үзәк өзгеч моңсу булып китә...". Лирик герой әнә шулай Үткән белән Киләчәк арасында газаплы халәттә гомер кичерә. Гүя, ул яшәми, ә үткәннән киләчәккә узып барышлый "бүген" дип аталган мизгелдә тукталган да, киләчәккә җитә алмау куркынычы белән хәвефләнә.

*...Бу юлы да яшәп бетерә алмыйм,*
*Узып барам инде, булмый туктап.*

Харрас Әюпов лирикасы фәлсәфилек белән сугарылган, чөнки ул нинди генә

халәт (яратумы ул, сагынумы, ялгызлыкмы) яки нинди генә вакыйга турында уйланса, язса да, фәлсәфи планда уйлана, аның асылына төшенергә тырыша. Мәсәлән, "Болгарга кайту" шигырен алыйк. Әсәрнең башында ук шагыйрь кеше күңеленең бер бүгенге белән генә бәйле түгеллеген, ерак гасырлар белән тоташканлыгын әйтә.

*Ачык булса күңел капкалары,*
*Үткәннәргә һәрчак юл бар ла...*

Гади бер вакыйга кебек тоелган Болгар каласына сәфәрнең Бүгеннән Үткәнгә сәяхәт икәнен укучы символик образлар, метафорик фикерләү аша ача. Бу кайту— милли тарихка кайту, Иманга кайту! Төшенкелеккә бирелә башлаган кавемгә Х. Әюпов "кара таңны ал җырлары белән ертып килеп" чыккан Кол Галине маяк итеп куя. Димәк милли тарихын белүче бүгенге буын, Болгар кавеме вәкилләре, тарихның төп туктальшларыннан берсе булган Болгарга сәяхәт кылып, зур хатирәләр, тәэсирләр белән киләчәккә кереп бара.

* * *

Адәм баласының хәвефле, "очы чуалган" дөньяда Илаһыннан аерылган ялгызы булуы, әмма беренче карашка ялгыз тоелса да, Кешенең Хәтер аша Илаһият белән бәйлелеге Х. Әюповның алдагы шигырьләрендә әйтелгән иде. "Гомер юлым кая юнәлсә дә..." дип исемләгән икенче бер шигырендә шагыйрь адәм баласының җирдә яшәү рәвешен, һәр адымын күзәтеп торучы Затның барлыгын искәртә:

*Адымымны минем чамалар да,*
*Меңә-меңә берәр сүз әйтер;*
*Ялгыш кына читкә тайпылсам да,*
*Күз карашы белән төзәтер...*

Әлеге Затны автор бик матур, фәлсәфи исем белән атый — "истән чыкмый торган уй сыман". Кешене нәкъ менә шушы зат һәрвакыт саклап, яклап килә. Аның һәрчак янәшәдә булуын автор кат-кат тәкърарлый:

*Кемдер килә, килә минем арттан –*
*Сулышлары бәрелә аркама...*
*Кемдер килә, килә янәшәмнән*
*Иңнәремә иңе кагыла...*
*...Кемдер бара, бара минем алдан –*
*Юк, булмыйдыр аннан калышып...*

Димәк, инсан тормышта кузгалып киткән мәлдән бирле салкын, мәрхәмәтсез тоелган бу дөньяда Ялгызы түгел. Ул Рәхимле һәм Рәхмәтле Кодрәтнең туктаусыз күзәтүе астында. Аны исә язмыш яки саклаучы фәрештә дип кенә кабул итеп булмый. Бары тик шушы Кодрәте Кәрим генә адәм баласына яшәү максатын күрсәтә. Автор әнә шундый экзистенциаль, фәлсәфи идеяне яктырта.

Х. Әюповның сөю, мәхәббәт турында шигырьләре дә образлы сүрәтләү, фәлсәфилек белән характерлана.

*Мин бит күптән туфрак идем сиңа,*
*Күңелемнең и беренче гөле!*

Монда Хәйям-Низамиларча яну да сизелми түгел. Гашыйк шагыйрь җавапсыз мәхәббәтне үзенчә тасвирларга алына һәм аны кабатланмый торган тәэссорат дәрәҗәсенә җиткерә:

*Читкә күчердем мин, белә торып*
*Иң кадерле гөлем булуыңны.*

Шигырьнең фәлсәфилеген үзенчәлекле стильгә әверелгән метафорик фикерләү тәэмин итә:

*Яшереп сулар сибәм һәм иркәлим,*
*Синдә елыйм да мин, синдә көләм.*

Автор сөюне күңелемнең "беренче гөле" дип атый, ә үзенең үлеп гашыйк

булуын—"туфрак идем сина" дип тасвирлый. Яшерен дә, газаплы да бу сөюне лирик герой һаман саклап килә: "Кагылдырмый саклап киләм ләкин Ничә еллар инде, ничә еллар!.."

Беренче мәхәббәт—кешенең яшерен хисе, әгәр дә ул тормышка ашмый калса, аны инде сөйгән ярдан башка һичкем дә белмәскә мөмкин. Әмма бу сөю адәм баласына һәрвакыт ләззәтле хисләр, жылылык биреп, ана өмет булып тора. Х.Әюповның лирик герое да менә шуны таный. Әмма тормышка тирәнгәрәк керә барган саен чынга ашмаган әлеге тойгы (хис-өмет) кешене сөюдән-сөелүдән мәхрүм калган ятим дип хис иттерә түгелме?!

Х.Әюпов "мин сине яраттым"", — дип әйтмәс, ул күнеле хисләр жепселеннән торган чын шагыйрьләрчә: "Мин бит сине бер жыр итеп язмакчы булдым", — дип әсир итәр,

*Ничә еллар табалмыйча*
*йөрим мин сине,*
*Ничә еллар эчтән генә*
*Көйлим мин сине!,–*

дип өметләндерер һәм:

*Иң матур жырым идең син—*
*тик отналмадым,–*

дип үкенечле итеп бер елмаер.

Х.Әюповның сөю турындагы шигырьләреннән тагын "Бу буран—минеке" шигыре образларның, сәнгать детальләренең ярсу, калку булуы белән, пафосның Мәжнүн хисләрен бөтен дөньяга әйтеп, кыю расларга омтылуы белән кызыклы.

Замананың авырлыгы, кешегә бу дөньяда яшәү кыенлыгы "Бәрелде жанга замана" дигән шигырьдә саркыла:

*Бәрелде жанга замана,*
*Сугылды алагаем!*
*Башкайларымны алыйм да,*
*Чыгыплар олагаем...*

Гәрчә автор торган жире хакында әйтмәсә дә, дөньяның авырлыгы әлеге әсәрдә туган жир һәм торган жир паралеллеге аша ачыла. Хәсрәт, сагыш монда туган илдән аерылуның туры нәтижәсе кебек кабул ителә. Бу авырлык хәтта сынмас, сыгылмас имәндәй ирләрне дә елата алырлык дәрәжәдә:

*Утырып елар идең дә,*
*Исем бар "ирләр" дигән.*

Хатын-кызга авырлык килгәндә, ул утырып бер елый да—жанын бушата, хәсрәте басыла. Әмма илдә ир-ат елаган замана гади-гадәти генә замана түгел ул, алар чарасызлыктан "ах!" иткән чор бу:


*Иленда ирләр еласа,*
*Жилләргә нишләргәдер?—*
*Кая барып бәрелергә,*
*Кайларга исәргәдер?*

Дөньяның авырлыгын заманага сылтап елаганнарга, сөюләрдән бәхетсез-нәүмиз булып калганнарга яшәргә дәрт алу өчен Х.Әюповның "Без бит ул..." (1993) әсәрен шигарь итеп алырга кирәк. Шигырь оптимистик рухта язылган, ул Кешенең бөеклегенә дан жырлый: "Мәңгелек буенча дөньяга Кабынган—без бит ул! Без бит ул!"

Гомумән алганда, аның шигырьләре әхлакый кануннар жимерелгән бер чорда КЕШЕ буларак яшәргә омтылуны тасфирлый. Шагыйрь киеренке экзистенциаль фикерләр, фәлсәфи мотивлар ярдәмендә үз хәятын һәм милләт язмышын аңларга, ачыкларга омтыла; ижтимагый катаклизмнар чорында кешелекнең һәм кешенең рухи асылы жимерелү сәбәпләрен күрсәтергә алына.

**Алсу ШӘМСУТОВА**

*Остаханә*



# Рашат Низами

## КАЛӘМ АЛДЫМ КУЛЫМА...

ЭССЕ

(язучы хезмәте турында уйланулар)

*Кешеләр сине начар белә дип хафаланма,*
*мин үзем кешеләрне начар беләм*
*дип күбрәк борчыл.*

Конфуций.

### Кереш сүз

Балачакта мин берәр китап укыдыммы, сихерләнеп кала һәм "Моны кем, нинди тылсымчы язды икән?" дип уйлый торган идем. Әнә шундый хис бик күпләребезнең күңелендә әле дә булса сакланадыр, мөгаен.

Яшүсмер чакта китап уку—айны койма ярыгыннан күзәтү шикеллерәк бер гамәлдер. Чөнки чын-чынлап китап уку, андагы хәл-әхвәлләрне аңлау, геройларның кылган гамәлләренә төпле бәя бирү өчен яшь кешедә тормыш тәҗрибәсе җитенкерәми әле.

Инде үзем дә каләм иясе һәм дистәгә якын китап авторы буларак, хәзер әдипләрне өр-яңа күзлектән карап укыйм икән, бу бер дә гаҗәп түгел. Әдәбият ул, гади генә итеп әйткәндә, кешелек яшәешенең серләрен, тормышны һәм андагы бихисап тетрәнүләрне аңлау һәм аңлатырга тырышу. Тәҗрибә зуррак булган саен күңел таләпләре дә арта бара.

Ә шулай да... борынгы китаплар аңлатуынча, иң әүвәле галиҗәнап Сүз булган лөбаса! Димәк, атомнардан тыш дөнья әле сүздән дә яралган. Ә сүзләр кәгазьгә, китапка төшергәч кенә бар кодрәтенә яши башлый. Әлеге илаһи миссияне каләм башкарган. Ислам дине аңлатуынча, каләм дөнья яратылганчыга кадәр үк яратылган. Бу хакта хәтта Коръәндә дә әйтелә. Кулына каләм алу белән, кешелек үзенең тарихында өр-яңа баскычка күтәрелгән.

Язучылык эше, язучылык хезмәте әнә шулайрак башланган. Кошлар тумый канатсыз, сүзләр тумый сәбәпсез, ди мәкаль. Ягъни язучылык сәләте—бер дә бүтән түгел, ә бәлки Ходай биргән бүләк. Дөрес анысы, хәзер компьютер-роботлар катлаулы математик мәсьәләләрне чишә, шахматта гроссмейстерларны да җиңә ала, әмма мондый "акыллы" машиналар беркайчан да һәм берничек тә чын әдәби әсәр яза алмаячаклар. Чөнки тормыш—шахмат тактасы түгел, ә кеше күңеле исә тапкырлау таблицасы ише генә түгел.

Иҗат эшенең индивидуальлеген, язучы шәхесенең кабатланмас булуын истән чыгарырга ярамый. Пушкин һәм Тукай, Толстой һәм Галимҗан Ибраһи-

---

Рашат НИЗАМИ (1950) — *шагыйрь, прозаик, публицист; "Йолдыз яңгыры", "Кызыл җәй", "Ут һәм Җыр" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

мов аша без биниһая зур дөнья белән танышабыз, үзебезне борчыган күпме сорауларга җавап таба алабыз.

Бер генә әсәр дә үзеннән-үзе күктән тамып төшми. Яисә чуртан кушуы буенча язылмый.

Кулыма берәр китап алдыммы, минем өчен әсәрнең баш герое—иң әүвәле язучы үзе. Әдәби әсәр тәэсир итә, тәм-шатлык һәм эстетик ләззәт бирә икән, мин авторның сәләтенә, талантына, күңел байлыгына, уй-фикерләренең тирәнлегенә сокланам.

Әдәби иҗат шундый да катлаулы нәрсә ки, ул үзенең серләрен бөтен кешегә дә ачып бирергә атлыгып тормый. Ә шулай да... Аның төп чыганаклары кая барып тоташа, язылмаган кануннары бармы, булса—ул нинди сүзләр-табышмаклар белән тамгалана ала икән? Әдәби кыйммәтләр тудыру процессының психологик һәм диалектик закончалыклары нәрсәдә, сүз художнигының эшчәнлеге нинди факторларга бәйләнгән? Әсәрдә авторның шәхесе, биографиясе, җәмгыять белән мөнәсәбәте ничек, ни дәрәҗәдә чагылыш таба икән?

Кызыксынуыбызның тагын бер җитди сәбәбе—әсәрнең туу тарихы; авторның биографиясен һәм тормышындагы төрле-төрле сикәлтәләрен ныграк өйрәнү әлеге әсәрне, андагы герой язмышын тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Әйтик, Достоевский үзенең "Бертуган Карамазовлар" романының яисә Гаяз Исхакый "Ике йөз елдан соң инкыйраз" дигән әсәренең туу тарихын сөйләп яки язып калдырсалар, без никадәр кыйммәтле мәгълуматка ия булган булыр идек. Дөрес анысы, күп кенә әдипләрнең көндәлекләренә яисә әдәби язмаларына иҗат процессына кагылышлы кызыклы уй-фикерләр дә "саркып" керә. Ләкин болар—диңгездән бер тамчы гына...

Сөйләшеп утыруларның берсендә шагыйрь Нәҗәр Нәҗми бер фикере белән шаккатырган иде. Совет космик аппаратлары Айның теге ягын фотога төшергән чаклар бу. Менә, ди, Айның Җиргә күренгән ягы һәм күренмәгән ягы бар. Айның күренгән ягы шикелле, китаплары аша язучының иҗаты, аерым әсәрләре безгә билгеле. Ә инде аның шәхси тормышын, әсәрләренең язылу тарихын Айның күренмәгән ягына охшатырга мөмкин.

Тукай, килер вакыт, һәр әдипнең тәрҗемәи хәлен җентекләп өйрәнерләр әле, дигән фикер әйтеп калдыра. Бу җәһәттән аның "Исемдә калганнар"ы әле дә булса кызыклылыгын һәм әһәмиятен җуймый. Шушы кыска гына автобиографик әсәр белән танышмый торып аның иҗатын тулысынча аңлау мөмкин түгел.

Бервакытны миңа, университет тәмамлаган һәм юллама белән эшкә җибәрелгән яшь-яшь укытучыга, сигезенче класс укучылары мондыйрак сорау биргәннәр иде: "Фәлән-фәлән язучының биографиясен сөйләттереп нигә безне болай интектерәсең, абый? Физика һәм химия дәресләрендә без Ньютон һәм Менделеевларның тормыш юлын өйрәнмибез бит. Гагарин кебек космонавтларның биографияләре дә дәресләр программасына кертелмәгән". Җавабымның төп мәгънәсе шуннан гыйбарәт иде: "Әдәби әсәрләрне фәкать язучының биографиясе һәм ул яшәгән чор аша гына ныклап аңлау мөмкин". Әлеге фикеремнән мин хәзер дә бер карыш та чигенмәс идем.

Бу хезмәт—әдәби әсәр белән аның иҗатчысы арасындагы күзгә күренмәс бәйләнешләрне ачу омтылышы. Моны әдипләрнең иҗади индивидуальлеген өйрәнүдәге бер тәҗрибә дип кабул итәргә кирәк.

Әлеге хезмәтне язу теләге миңе 1970 еллар башында ук биләп алган иде. Тарихы болай. Безгә, студентларга, диплом эше темаларын игълан иттеләр. Мин, бер дә икеләнмичә, "Тәрҗемәнең шигъри фикерләүгә йогынтысы" дигән теманы сайлап алдым. Фәнни җитәкчем, әдәбият галиме Нил Юзиев миңа беренче эш итеп Эккерманның "Разговор с Гёте" дигән китабы белән танышырга киңәш бирде.

Менә шуннан соң китте инде эшләр! Мавыгып, әсәрләнеп күп кенә китаплар укыдым, язучылар белән аралаша башладым. Шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннең Шекспир сонетларын татарчага тәрҗемә итеп дан тоткан чаклары. Ул—диплом эшенең үзәгендә.

Әле дә булса үкенәм: диплом эшен яклаганда Мәхмүт абыйны чакырырга

"курыктым", дөресрәге, аның хәтерен калдырасым килмәде. Чөнки, Шекспир сюжетларын тәрҗемә кылганда, ул гел форма ягын гына үзенә үрнәк итеп куя, эчке агым, төп юнәлеш исә ничектер читтәрәк кала иде. Мин, моны турыдан-туры әйтеп, үземчә дәлилләп язган идем. Ул бит—егет кеше, утны-суны кичкән фронтовик, чакырган булсам, бәлки, студент егетнең кулын да кыскан булыр иде әле.

Тагын менә нәрсә хәтергә төшә. Һаман да исемдә: инеш сукмагы, тыкрык яисә болын хәтфәләрендә дисеңме—кайда гына булмасын, әбием үзенең бер шөгылен һич кенә дә исеннән чыгармый иде. Кошлардан, каз-үрдәктән коелып калган йомшак каурыйларны, йон-җилпәзә кебек нәрсәләрне очраган саен алъяпкыч кесәсенә җыя торган иде ул. Менә шулар, келәттәге ситсы капчык кадәре тулганнан соң, көннәрнең берендә йомшак мендәргә әверелә иде. Әбием тырышлыгының нәтиҗәсен һәм фәлсәфәсен мин мендәргә баш куеп йоклаганда бик яхшы аңлый идем. Карлыган җыйганда да шулай: сабырлык җитеп бөртекләп-бөрәмтекләп җыя торгач, савыт мөлдерәмә тула да куя ләбаса!

Минем белән дә шулайрак булды. Хөрмәтле остазларым Нил Юзиев һәм Ибраһим Нуруллинның хәер-фатихасы белән ул чакта диплом эше темасына гына түгел, өр-яңа бер дөньяга да атлап кердем. Кая барсам, кемнәр белән очрашсам да әңгәмәдәшләремне һаман шушы темага "куып кертергә" тырышам. Кыскасы, шушы сәер теләк, язучы хезмәте турында язу нияте бер генә көнгә дә исемнән чыкмады. Мин, үзем дә сизмәстән, әбиемнең "һөнәри калыбына" кердем. Тик минем күзәтүләрем, укыган китапларым алъяпкыч кесәсенә генә сыешлы түгел, алар киңрәк мәйданны сорый иде.

Күңелемнең шушы хәрәкәте һәм гамәлләре "Татарстан яшьләре" газетасында, "Ялкын" һәм "Казан утлары" журналларында эшләгән елларым белән дә ныгытылды. Күренекле әдипләр белән якыннан аралашу, үземнең дә иҗади тәҗрибәләрем мине әлеге максатка тагын да якынайта төште. Балык сусыз тора алмаган шикелле, мин инде алга таба шундый әзләнүләрсез яши алмый идем.

Бу хезмәт әдәбият сөючеләргә, яшь әдәбиятчыларга да адреслана. Ләкин аны язучы булырга өйрәткән кулланма дип кабул итәргә ярамый. Асылда мин үз-үзем белән сөйләшәм, үз уйларым белән бәхәсләшәм. Шул ук вакытта минем каршыда таләпчән укучы—әңгәмәдәшем басып тора һәм мин аның күзгә күренмәс хуплавын да, кырыс хөкемен дә аермачык сизеп торам. Ләкин, ничек кенә булмасын, ул әлеге хезмәтемдә укыганнарны дөрес аңлаячак. Мин моңа ышанам.

Хәерле сәгатьтә!

## БЕРЕНЧЕ БУЛАСЫМ КИЛДЕ!

*Стиль—кеше ул.*
Бюффон.

Әлмисактан бирле шулай килгән: кемдер туа да, кояш һәм зур дөнья каршына таба тәпи атлап китә. Булачак язучы да нәкъ башкалар күк елап-кычкырып, кислород-һаваны ирене белән тешләп туа. Ләкин Ходай Тәгалә аның чипчиста маңгаена үзенең мөһерен сугып куйган була инде: алда сине зур сынаулар көтә, син язарга, киләчәктә халкыңа үз сүзеңне әйтергә тиешсең.

Син менә ничек язучы булып киттең? "Чишмә башың" кайда?—татар әдипләре белән очрашкан саен мин әнә шул сорауларга җавап табарга тырыша идем. Хәзер, әйдәгез, без аларның үзләрен тыңлап карыйк.

**Батулла:** *"Иң башта, сабый чагымда, әбием Мәгъсүмә карчыкның бәетләрен, әкиятләрен, изгеләр турындагы хикәятләрен, аның курай, кубыз, сорнай уйнаганнарын, авылым риваятьләрен тыңларга кирәк булгандыр. Аннан соң Мәскәүдә артистлыкка укуым, татар, рус, дөнья әдәбияты-сәнгате белән*

*танышуым этәргеч булгандыр. Ләкин тумыштан, Аллаһтан бирелгән табигый сәләтең юк икән, болар гына сине язучы итә алмый.*

*Юри генә мин дәһи булуның сөлдәсен* сызып чыккан идем. Ул болайрак килеп чыкты:*

*Нәсел чаткысы + тырышлык = сәләт. Сәләт + тырышлык = куә (талант). Куә + тырышлык = дәһи.*

*Бик гади. Чаткысы булмаган бәндә тырыша-тырыша сәләтле булырга мөмкин. Ләкин ул куәле дә, дәһи да була алмый. Тумыштан музыкаль тавышларны ишетү-аеру сәләте булмаса, никадәр генә тырышса да, ул кеше композитор да, җырчы да була алмый."*

Әйе, тормыш һәм табигать, тирә-юнебез бетмәс-төкәнмәс матурлыклар һәм могҗизалар белән уратып алынган. Боларны күрү-тою һәм башкаларга җиткерү өчен аерым бер күз карашы, җете сизгерлек һәм сүзләрне "эшләтә белү" кирәк. Ә мондый талант теләсә кемгә бирелми. Максим Горький, һәр кеше үз гомерендә бер китап яза ала, дигән фикерне шартлы рәвештә әйткәндер дип уйлыйм.

Балачакта һәрбер кеше—кечкенә бер язучы. "Кечкенә" дип әйтү бу очракта һич кенә дә кечерәйтеп яисә түбәнсетеп әйтү түгел. Моны—уйланучы, үзе күргән вакыйгаларга, кешеләргә, табигать күренешләренә карата үз мөнәсәбәтен белдерүче, шулардан мәгънә чыгарырга омтылучы актив бер шәхес дип тә аңларга кирәк.

Бөтен дөньяда танылган язучы Чыңгыз Айтматов 2003 елда 75 яшен тутырды. Ләкин язучылык хезмәтенә килүнең юллары, алшартлары турында сөйләгәндә, ул нәкъ менә балачагына кайтып төшә:

— Минем балачагым ерак бер авылда узды. Әбием каршына утыртып та, тез башына утыртып та гел әкиятләр сөйли торган иде миңа. Шул әкиятләр аша мин өр-яңа дөньяга килеп эләгә идем. Ә инде ундүрт яшем тулганда, сугыш вакытында уку-язуны белгән сирәк кеше буларак, мине авыл советы эшенә билгеләп куйдылар. Фронтка ярдәм, акча кирәк. Җыелган акчаларны мин җигүле ат белән район үзәгенә ташый идем. Берсендә...

Аның сөйләвенчә, вакыйга болайрак була. Җигүле ат, мескен арба, киндер капчык төбендә—халыктан җыелган хәләл акчалар... Менә шул чакта дилбегә тоткан яшүсмергә ялгызак бер кеше очрый. Ябык, фәкыйрь кыяфәтле бу бәндә аңардан ашарга сорый, капчыкны ачарга куша. Сугыштан ни сәбәпледер качып киткән ач дезертир һәм фронт файдасына тапшырасы акчалар. Капчыкны бирмәгәч, әлеге бәндә аңа таш ыргыта һәм ләгънәтләп кала...

Бу вакыйганың киләчәктә әдәби әсәр булып ("Йөзгә-йөз" дигән повесть) дөньяга туачагын укучы, шөт, аңлагандыр.

Әгәр диңгез җилләрен, аның ачы һәм татлы романтикасын, җәмгыятьтәге гаделсезлекләрне, язмыш чыбыркысын үз җилкәләрендә татымасалар, Джек Лондон—"Мартен Иден"ны, Миргазиян Юныс "Тозлы җил" романын, ай-һай, яза алган булырлар иде микән?

Без әле алга таба әдәбият титаны Лев Толстойның байтак кына уй-фикерләре белән танышырбыз. Ләкин бу очракта Алексей Толстойның иҗат белән шөгыльләнүнең максатын аңлатып әйткән "Мин үз-үземне белергә телим" дигән сүзләре бик тә урынлы яңгырый. Һәм бу сүзләр астына теләсә кайсы язучы үзенең култамгасын салыр иде.

— Син иҗат эшенә кайчан, ничегрәк кереп киттең?—дип сорагач, шагыйрь Равил Фәйзуллин ике дә уйлап тормыйча:

— Мәктәптә беренче буласым килде!—дигән иде.

Бу—аның холкына, теләк-омтылышларына бик тә туры килеп тора. Ә тормышта кемнең беренче буласы килмәс икән? Сабан туенда да бит, балалар яисә өлкәннәр көрәше булсын, мәйданга, гадәттә, әнә шундый хис -теләк белән чыгалар.

---

* сөлдә—склет, схема.

Урманда чикләвек җыйган чак искә төшә. Олы-олы керфекләрен ачып-йомып торган кишәнкеләрне берәм-берәм капчыгыңа тутырасың. Зурлыгы имән чикләвегеннән кайтыш, ләкин бик тә чибәр һәм йомры "күчтәнәч"ләр магнит сыман гел үзенә тартып тора. Куак арты куакны сыгып төшерәсең. Дүрт чикләвекле... бишле... алтылы... һәм менә шулчак кемдер: "Миндә сигезле!"—дип тирә-юньгә сөрән сала икән, ул дустыңа сокланып та, бераз көнләшеп тә карыйсың.

Әйе, беренче булуның үз ләззәте, үз рәхәте бар. Әдәбиятта да әнә шулайрак түгелме соң? Беренче булып яңа сүз әйтәсе, яңа ачышлар ясыйсы, образлар тудырасы килә. Үзе беләме-юкмы, язучы кешенең күзәнәкләрендә, кан тамырларында югары бер халәт, энергия посып ята. Вакыты җиткәч, ажаган булып уйнаячак энергия!

Зур гамьнәр, борчулар белән яшәү, әйтер сүзең булу шулай ук мөһим. Юкса буш сүз очырудан, чыпчыктай туктаусыз чыркылдаудан, графоманлыктан файда юк. Бака кычкыра башласа, сандугач сакаулана, дип әйтәләр ич халыкта.

Аңлы рәвештә яисә аңнан тыш булсын, язганнары белән һәрбер язучы үзенең шәхесен, тормыштагы урынын расларга омтыла. Үз-үзеңне ярату, үзеңнең көчеңә һәм сәләтеңә ышану, олы максатлар, яңа фикер өчен көрәш—могҗизалар тудырырга сәләтле.

Фикер иясе буларак, язучы мәхәббәт һәм нәфрәт арасында яши. Вольтер сүзләре белән әйтсәк, аның кулында патшалык таҗын гәүдәләндерүче таяк-скипетр түгел, ә бәлки тылсымлы каләм. Әдәбият-сәнгать дигән мәртәбәле йөкне дә бары тик кодрәтле шәхесләр генә үз җилкәсендә күтәреп бара ала.

Әйдәле, каләм, күрсәт әле кодрәтеңне, тылсымнарың күбрәк ач син безгә!..

## СУНЫ ДИҢГЕЗ ЧИШМӘЛӘРДӘН АЛА

*Фикер—шулай ук биографиянең бер өлеше.*
Е.Евтушенко.

Каләм иясе үзенә кирәк материалны каян ала соң? Болар—шәхси биография, ишеткән-белгәннәр һәм фантазия! Менә шулар өчесе бергә кушылып киткәннән соң әдәбият дигән могҗиза барлыкка килә дә инде.

Биография... Аның беренчел, иң кызыклы һәм мавыктыргыч өлеше балачакка һәм мәктәп елларына карый.

Балачакта һәркемнең курку кичергәне, нишләргә белми бәргәләнгән чаклары булгандыр. Менә үземнән бер мисал.

Минем әни хат ташучы булып эшли иде. Көн саен биш чакрым ара узып, күршедәге Төбәк авылыннан күн сумкасын тутырып хат һәм газета-журналлар ташый. Атнасына бер тапкыр диярлек чүпрәк яки фанер тышлы посылкалар да килә. (Безнең татар бит, Сталин хөкүмәтенең заем-салым ише авырлыкларына түзә алмыйча, матур вәгъдәләргә алданып, Себер, Донбасс, Үзбәкстан кебек якларга чыгып киткән. Ул чактагыча әйтсәк, "язылып, семьем" киткәннәр. Авылдагы туган-тумачасына әнә шундыйлардан килгән күчтәнәч-посылкалар була инде бу).

Бераз үсеп кул астына керә башлагач, әни урынына күрше авылга мин дә йөргәли идем. Берсендә... Ни арба, ни чана дигәндәй, язгы пычрак вакытлар булгач, ат атланып сәфәргә чыктым. Кайтканда миннән дә бәхетле кеше юк иде: иярдә җай гына юыртам, күн сумкам тулы—хатлар, гәҗитләр, конфет һәм алма исләре аңкып торган кечерәк кенә фанер тартма. Аяк астындагы язгы күлләвекләрнең күзенә тояк белән басып, су чәчрәтеп, теркелдәп кенә кайтабыз шулай. Үр артыннан алагаем бер йөк машинасының калкынып чыгуы булды, "Чалкан" кушаматлы атым өркеп кинәт читкә ыргылды! Җиргә мәтәлеп төшкән малай, аның янәшәсендә бер почмагы ватык посылка... Юл читендә әле генә борынны кытыклап барган түм-түгәрәк кызыл алмалар тәгәрәшеп ята...

И курыктым, еладым шул чакта. Әнигә, авылыбызда усаллыгы белән даны

чыккан Ф. апага ни дип җавап бирермен? (Бу вакыйганың да әдәби әсәргә керәчәген—“Хат ташучы малай” дигән хикәямә нигез итеп алынды—укучы, шәт, аңлагандыр).

Балачак, мәктәп еллары димәктән, менә тагын кайбер фикерләр.

**Сибгат Хәким:** *“Татар язучыларының кайсын гына алма, аларның зур әдәбиятка юллары мәктәп бусагасыннан башланып киткән. Биографияләрен укып карагыз. Беренче иншаларны укытучылар яздырткан. Нәкый Исәнбәт, Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзиләрнең архивларында үз куллары белән чыгарган журналлар хәзер дә саклана. Журналны үзләре бизәгән, исемне үзләре кушкан. Шуңа күрә минем укытучыларга: Сизгер, игътибарлы булыгыз. Дөньяга сирәк килә торган Тукайларның яшьлеге сезнең кулда! диясем килә.”*

**Илдар Юзеев:** *“Бер мәктәптә миннән укучылар: Шигырь язарга иң беренче кем өйрәтте?—дип сорадылар. Әни!—дидем. Шагыйрьлекнең чишмә башы—әнкәйнең бишек җырында. Ә хыялланырга безне беренче класстагы укытучыбыз Тимергази абый Сафин өйрәтте. Дәрестән соң калып, кышкы кичләрдә без аның үзе уйлап чыгарган әкиятләрен йотылып тыңлый идек.*

*Әгәр дә әйләнә-тирә мохит, укытучылар коллективында тартылыш, көчле мәхәббәт булмаса, безнең сәләтебез дә кояш нурыннан мәхрүм калган гөл кебек шиңәр иде.”*

**Фәүзия Бәйрәмова:** *“Моның «чишмәбашы», әлбәттә, балачагымда эчкән чишмә суларына барып тоташа, табигать баласы булып, дөньяның бар матурлыгын кечкенәдән күреп, тоеп үскәннән киләдер... Авыл баласы, әгәр ул нечкә күңелле, кызыксынучан, тере бала икән, бар табигать җырлап, көйләп, шаулап торганда, моңа җавапсыз кала алмый... Ул дөньяны күзләре белән генә түгел, күңеле белән дә күрергә өйрәнә... Аның күңеленә табигатьнең мең төрле күренеше, сурәте, тавышы, хәтта кыргый исләренә хәтле үтеп керә, саклана... Яңа чапкан печән исләрен, көзге урманда таралган соңгы яфрак исләрен, кышкы эңгергә күмелеп утырган авыл өйләрен, язын беренче булып авылга килгән кошларның дәртле тавышларын, үкереп аккан язгы ташуларны, җәйнең табаннарны кытыклаган җылы туфракларын ул беркайчан да онытмый, оныта алмый, шулардан гомер буе рух алып яши...*

*Мин дә нәкъ әнә шундый бала идем...*

*Мин үзем дә кечкенәдән такмаклар, бәетләр чыгара идем, авыл халкы аларны миннән капка төбендә сөйләтә иде... Бераз үсә төшкәч, шигырь-хикәяләремне Саба, Казан газеталарына да җибәрә башладым, аларның кайберләре басылып та чыкты. Бик яхшы укуымны һәм күп язуымны искә алыпмы, әле 16 яшем дә тулмаган килеш, мине Саба районында чыга торган «Җиңү байрагы» газетасына хәбәрче итеп алдылар. Бу әле язучылык булмаса да, шуңа таба бер адым иде...*

*Әмма минем, күпчелек совет заманы хатын-кызлары кебек, ир хатыны, бала анасы, производство колы гына булып калу мөмкинлегем дә бар иде... Тормыш шактый катлаулы булды, яшел болыннардан килгән хисле авыл баласын беркем дә таш шәһәрләрдә колач җәеп көтеп тормады, капкаларын да ачарга ашыкмады... Шуңа күрә зур иҗатка да мин шактый соңлап, шактый урап килдем... Язмыйча түзә алмаганга яза башладым...”*

Ишеткән-белгәннәр... Болар да һәммәсе—тәрҗемәи хәлеңә, дөресрәге, бу очракта инде хис һәм күңел биографиясенә килеп кушыла, өстәлә бара торган нәрсәләр. Язучылык сукмагына ничек аяк басулары турында сүз чыктымы, әдипләр бишек җыры көйләүче әниләрен һәм әкият сөйләүче әбиләрен һәрвакыт иң беренче итеп телгә алалар.

Һәр авылның телгә-сүзгә оста бер кешесе була. Аның авызыннан нинди генә тапкыр сүзләр, мәзәк хәлләр, гыйбрәтле вакыйгалар ишетмисең. Мон-

дый гыйбрәтле хәлләрне эштә, юлда яисә ял вакытларында, сүз иярә сүз чыгып, бөтенләй таныш булмаган кешеләр дә сөйләргә мөмкин.

Лев Толстойның "Крейцер сонатасы" дигән повесте әнә шундый алымга корылган булуы белән кызыклы. Әсәрдә ике герой—сөйләүче һәм тыңлаучы бар. Вагонда баручы алпавыт Позднышев озаклап үзенең мәхәббәт кыйссасын сөйли. Бу ачы һәм гыйбрәтле вакыйганы авторның кемнәндер ишеткән булуы бәхәссез. Ат турындагы икенче бер әсәрендә Толстой аның сюжеты кемнән алганлыгын ачыктан-ачык әйтә һәм эпиграфка "М.А.Стахович истәлегенә багышлана" дигән сүзләрне язып куя.

Әмирхан Еники дә күп кенә хикәяләрен ишеткән-күргәннәрдән туган әйберләр дип аңлата.

Үзеңә кадәр булып узган вакыйгалар турында язганда мондый әзерлек, ишеткән-белгәннәреңне бер максатка юнәлтә белү—бигрәк тә мөһим. Алтынны юып тапкан шикелле, тормыш-көнкүреш һәм фактлар елгасыннан язучы үзенә кирәк табышларны сайлап, сөзеп ала.

"Казан утлары" журналының проза бүлеге мөдире буларак, Мәхмүт Хәсәновның "Язгы аҗаган" дигән романын миңа беренчеләрдән булып укырга туры килгән иде. Халкыбызның әле якты-бәхетле, әле караңгы-аянычлы сәхифәләрен яктырткан күләмле бу әсәр миндә көчле тәэсир калдырган иде. Автор миңа кирпеч калынлыгы кәгазь папкасын ачып күрсәтте. Анда татар һәм рус телләрендәге газеталардан җыйналган бихисап кисемтә бар иде. Күбесе кызыл яисә зәңгәр карандаш белән ермачланган. Саргая төшкән газета битләренә караганда, язучы аларны озак еллар буе җыйнап барган булса кирәк. Романга кирәге чыгар дип, бөртекләп туплаган ул аларны.

Укучы хәтерлидер: тарихыбызның утыз биш елын эченә алган бу романның баш герое—окопларда революция каршылаган, кызылармеец булган, тырышлыгы белән авылда инде бөтәеп-ныгып киткән, ахыр чиктә "кулак" дип тамгаланып Себергә сөрелгән Иргали. Автор аны шулкадәр белеп, яратып, җентекләп сурәтләгән ки, ул—күршең яисә туганың кебек тере бер кеше буларак күз алдына килә дә баса.

Романның чыгуы уңаеннан Азнакайда укучылар конференциясе бара. Укыганнар—сораулар да байтак ява, чыгып сөйләүчеләр дә күп. Шулвакыт утыз яшьләр тирәсендәге бер укытучы ханым:

— Әгәр тормышта Иргали дигән кеше бар икән, мин ике дә уйламыйча аңа кияүгә чыгар идем!—дип әйтеп ташлады.

Сәхнә артына чыккач, Мәхмүт абый безгә зур күзлегенең пыялалары аша балаларча хәйләкәрлек белән елмайды.

— Соң... Иргали мин үзем бит инде,—диде ул.

Үзенең героен автор әнә ничек яратып өлгергән!

Язучы буласы кешегә, биография һәм ишеткән-күргәннәр өстенә, төпле белем дә кирәк. Сүз дә юк, хәзерге яшьләр—укымышлы, белемле, эрудицияле, күп нәрсәдән хәбәрдар. Прозада булсын, шигъриятьтә булсын, кайчакны әнә шул "эрудиция табасы"ннан төшкән, ләкин чын тормыштан ерак торган әсәрләрне дә очратырга туры килгәли. Гакыл, хис, йөрәк иҗат эшенә күбрәк тартылсын иде дигән теләк туа.

Ибраһим Нуруллинның да бервакыт, Мәхмүт абый кебек, Флобер сүзләренә ияреп, ахры: "Тукай мин бит инде ул!"—дигәне истә калган. ("Тукай" романы турында сүз бара иде).

Язучы Нурихан Фәттах—безнең әдәбиятта уникаль шәхес. Аның беркая диярлек чыкмыйча, дөнья белән аралашмыйча, үз-үзенә бикләнеп яшәп һәм иҗат итеп ятуы күпләргә аңлашылып бетми иде. Хәтта күпне күргән, күпне кичергән Миргазиян Юныс та аңа, "Мәгарә әдибе" дигән тамга сугып, үзенең гаҗәпләнүен белдерде.

Әгәр дә шулай аскетларча яшәп, үз куллары белән туплаган шәхси китапханәсендә көне-төне казынмаса, татар "Әтил суы ака торур", "Сызгыра торган уклар" дигән соклангыч тарихи романнарга һәм "Шәҗәрә" дигән тарихи-лингвистик тикшеренүгә, ай-һай, ия булыр иде микән?

Нурихан ага каләме тергезгән бу чорлар—ерак заман. Ә менә татар халкы тарихындагы соңгы бернничә гасыр турында язарга омтылучы бармы, көч-җегәребез җитәрлекме икән моңа?..

**Аяз Гыйләҗев:** *"Мәсәлән, без халкыбызның Казан ханлыгы чорын яхшы беләбезме?.. Алай ук ерак барасы да юк, халкыбызның, шәһәрләребезнең Октябрь революциясе чорынданиләр кичергәнен дә тиешле дәрәҗәдә белмибез әле. Шул чорның бер пәрдәсен күтәреп роман язган кеше буларак, мин моны бик дөрес аңладым."*

Язучы кешегә шәхси тәҗрибә генә җитми, шуның өстәвенә тормышны, үткәннәрне, тарих сулышын өйрәнүнең мотлак икәнлеге бәхәссез. Ватан сугышы көннәренең кайсы да булса әсәр язганда кирәк булачагын күздә тотып, мин үзем яхшы белгән ветеран-фронтовиклардан үзләренең тормыш юлын аерым дәфтәргә яздырып алганым бар. Бик кызыклы детальләргә, хәрби вакыйгаларга бай әлеге дәфтәр. Кайсы да булса хикәя яки повестька кереп китәсе бу "кыйпылчыклар" үзләренең сәгате сукканны көтеп ята...

Балачакта укыган китаплар да эзсез узмый. Китапларга дөнья кадәр фикер, бәһасез мәгълүматлар, акыл һәм хис хәрәкәте, гыйбрәтле язмышлар теркәлеп калган. Китапның һәр бите кардиограмма язмасы шикеллерәк. Анда язучының йөрәк тибеше теркәлгән—укы, эзлә, серен тап шуның.

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукай китапның зурлыгы, кешенең рухын күтәрүе хакында бик матур әйтеп калдырган:

*Шул вакытта мин кулыма китап алам,*
*Аның изге сәхифәләрен актарам...*
*Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем*
*Була минем юл күрсәтүче йолдызым.*

Гали затлар китап белән һәрвакыт дус булганнар. Пушкинны гына искә төшерик. Дуэльдән яраланып кайткан шагыйрь үләр алдыннан моңсу күзләре белән киштәсендәге китапларга текәлә һәм алар белән: "Хушыгыз, дусларым..."—дип саубуллаша.

Хәреф таный башлагач та мәктәп китапханәсеннән алып укыган беренче китабым Тукайның "Күңелле сәхифәләр"е иде, дип искә ала Шәүкәт Галиев. Тукай җыентыкларының солдат биштәрендә Берлинга кадәр барып җиткәнен дә беләбез.

**Фәүзия Бәйрәмова:** *"Сугыштан соңгы авыр елларда ун балалы гаиләдә, ул чакларда әле электрсыз, радиосыз, телевизорсыз бер кечкенә генә татар авылында туып үссәм дә, балачагым минем күңелемә мәңгелек илаһи нур булып кереп калды. Мин иркен үстем, тыю-кыйнауны белмәдем, кечкенәдән бик кызыксынучан, тере бала идем. Минем алга таба язучы, иҗат кешесе булып китүемә балачагымнан ике нәрсә нык тәэсир итте, берсе—үзем үскән авыл табигате, икенчесе—яшьтән укыган китапларым... Китап мине уйларга, хыялланырга, гаҗәпләнергә өйрәтте, дөньяның серен ачты... Ташлар турында укып, мин геолог булам, дидем, йолдызлар турында укып, космонавт булам, дидем, китаплар аша җир миңа үзенең мең серен, күк мең капкасын ачты... Авыл китапханәсендә беткәч, мин аларны, арыш капчыгына салып, күрше авылдан агач чана белән ташый идем... Лампада керосин санаулы булганга, мин ул китапларны ай яктысында укый идем... Җәйләрен исә көтү көткәндә кулымда гел калын китап була торган иде..."*

Әйе, китап—кешелек уйлап тапкан могҗизаларның берсе. Безнең халык арасында Пушкин яисә Тукай булып уянган чаклар булгалый түгелме соң? Сәбәбе бик аңлаешлы: яки аларның иҗаты, китаплары безгә нык йогынты ясаган, яки "мин кемнән ким?" дигән яхшы мәгънәсендәге көнләшү бәреп чыккан. Шагыйрь Зөлфәт бервакыт, студент чагында ук инде, кайнар әңгәмәләре-

безнең берсендә, "Нәрсә, әллә мин Пушкиннан ким язаммы?" дигән сүзләре белән мине шаккаттырган иде. Кайта-кайта аңлыйм: бу бит инде—үз-үзеңә ышану яки үз-үзеңә көч бирергә тырышуның бер чагылышыдыр.

Шушы ук фикерне, ләкин бүтәнчәрәк кимәлдә, Батулла да сиздереп куя: "Мин яшь чакта татар язучыларының уртакул әсәрләрен укып, чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, болай итеп мин дә яза алам бит, дип каләмгә тотындым шикелле. Бәлки, әнә шул "көнчелегем" мине язучы иткәндер".

Тормышны җентекле күзәтә белү, ишеткән-күргәннәр—язучы өчен тормыш материалы. Әлеге байлык кемнең хәзинәсендә күпме—монысы инде бүтән мәсьәлә. Әйтик, Мөхәммәт Мәһдиев тормышны шулкадәр күп һәм яхшы белә ки, шул сәбәпле ул еш кына үзенең материалына кереп бата. "Перенасыщение опытом" (Максим Горький сүзләре, тәҗрибә муллыгы дип тәрҗемә итсәм, кайбер төсмерләре югалыр шикелле). Укучыга факт-вакыйгаларны истә калдыру кыенлаша.

Пришвинның бер бик гыйбрәтле сүзе бар: "Янып барган учакка утынны күбрәк ташласаң, ул сүнеп калырга мөмкин". Чама хисе, тормыш материалын сайлап ала белү осталыгына карата әйтүе.

Талантлы кеше тема һәм тормыш материалы дигәндә, миңа калса, беркайчан да кытлык кичерергә тиеш түгел. Дөнья безне дүрт яктан гына түгел, дүрт йөз яктан урап алган. Агачтан өзелеп төшкән гап-гади бер яфрак—шагыйрь өчен Ньютон башына төшкән алмага тиң булырга мөмкин!

Франц Кафка, әдәби хакыйкать чынбарлыктан ерак тора, дигәнрәк фикер әйтә. Бер дә гаҗәпләнәсе юк бу сүзләргә. Даһи рәссам Пикассоның пумала белән бер селтәнүдә ясаган символ-күгәрчене чүплектә казынган яисә электричка платформасындагы көнбатыш кабыклары белән туенган күгәрченнән йөз тапкыр көчлерәк, матуррак, дөресрәк түгелме?

Бервакыт "Новый мир" журналына башлап язучы үзенең хикәясен китерә. Хикәяң бигрәк тә инде уйлап чыгарылган, тормыштан алып яз син, дип киңәш бирә редактор. Тагын китерә бу. Хикәяң бигрәк тә инде тормыштан алып язылган, син фантазия һәм уйлап чыгарудан бер дә курыкма, дип киңәш бирә бу юлы редактор.

Теге яшь автор егылып китә яза. Чөнки беренче хикәянең сюжеты—тормыштан алынган, икенчесе нәкъ менә уйлап чыгарылган сюжет икән. Күрәсездер, тормыш чынлыгы белән фантазия арасында бик зур аерма да, бик зур бергәлек тә бар, алар бергә укмашкан.

Язучыда бик күпләрдә булмаган бер сыйфат бар, ул—фантазия, хыял көче, хыял яктысы. Бу сыйфат язылачак әсәрнең максатына, юнәлешенә, тәэсир көченә хезмәт итә.

Иҗат остаханәсенең бер утырышында Илдар Юзеев яшьләр колагына әйткән сүзләре белән шаккатырган иде мине: "Әдәбият ул—асылда уйлап чыгару. Ләкин тормыш тәҗрибәсе мул булган кешенең уйлап чыгаруы бөтенләй башка төрле була".

Майн Рид үзенең маҗаралы романнарын фәкать өендә утырып язган диләр.

Балчыктан чүлмәк ясауның, сүзләрдән әсәр коюның аерым серләре, кануннары бар, билгеле.

***Фатих Хөсни:*** *"Ни әйтергә, ничек әйтергә?*

*Менә шушы ике сорау, язучының бөтен аңлы гомере буена тынгы бирмичә, аны эзәрлекләп килә. Әйе, әйе, мин бу сүзне курыкмыйча әйтәм: эзәрлекли. Ник дисәң, язу эше—гаять дәрәҗәдә читен һәм җаваплы эш, бу йөкне гел генә җилкәңдә күтәреп йөртү, ай-һай ла, бер дә бәйрәм түгел... Әнә шуннан инде әлеге газаплы сораулар килеп туа да. Ни әйтергә? Ничек әйтергә?"*

Роман, повесть һәм хикәяләр остасы Фатих Хөсни, мондый сорауны куйганда, каләм кыштырдатуны кәсеп итеп алган салкын һөнәрчеләрне түгел, табигый талант көченә ия булган язучы-художникны күздә тота.

"Ни әйтергә?" дигәндә ул башлыча язучының гражданлык йөзен, дөньяга

карашын, әхлак сакчысы икәнлеген күз уңында тота. "Ничек әйтергә?" дигәнне турыдан-туры художникның сәләтенә бәйли. Колачлы, бик зур сораулар һәм боларны бер-ике сүз белән генә аңлатып булмый.

**Туфан Миңнуллин:** *"Заманында кемдер Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләрендә сюжет сызыгы аксый, детальләр белән артык мавыга, дип язып чыкты. Ә мин аның повестьларын нәкъ менә детальләргә бай булганы өчен яратам. Мине әдәбият калыплары, төрле измнар кызыксындырмый, шуны гына тәгәл беләм—проза әсәре иң беренче чиратта укылырга тиешле."*

## БИОГРАФИЯ ЯКИ ӘДӘБИ ЧЫНБАРЛЫК

*Бөек кешеләр бу дөньяда, миңа калса,*
*бөек бер моңсулыкны тоярга тиешләр.*
Федор Достоевский.

Язучылык хезмәте—теләсә кемгә бирелә торган һөнәр түгел, дидек. Билгеле бер шәхескә моның тамырлары Табигать һәм Ходай тарафыннан әллә кайчан салынган була. Биография. Менә шушы нәрсә булачак әдипнең язмышында хәлиткеч роль уйный да инде. Моңа өстәп, тагын җәмгыять бишеге бар әле. Кайда, ничек тирбәлеп, нинди җырлар тыңлап үсәсең бит...

Сүзне барыбер Тукайдан башлыйсы килә.

Аның "Исемдә калганнар" дигән мәгълүм автобиографик әсәрен искә төшерик. Бик саран, хисләргә бирелмичә язылган ул. Ләкин шагыйрьнең тормыш юлын, беренче тәэсирләрен аңлаткан, аның иҗатына ачкыч табардай күпме хәл-әхвәлләр теркәлгән биредә.

Кеп-кечкенә сабыйның балачактан ук ятим калуы, кулдан-кулга күчеп йөрүләре тыенкы-сабыр гына язылган. Гаҗәп хәл бит: Тукай үзенең кыен ашап үскәнлегеннән иҗатында беркайчан да зарланмый. Ул зур мәсьәләләр, милләтнең киләчәге турында уйлана.

Тукай үзенең бер җыентыгын юкка гына "Күңел җимешләре" дип атамагандыр. Балалар өчен дә яза, әле без төп мәгънәсен аңлап та бетермәгән "Шүрәле" поэмасын иҗат итә һәм иҗтимагый-сәяси тормыштагы вакыйгаларга һәрвакыт үзенең шигъри-образлы мөнәсәбәтен белдерә килә. Сирәк талант, сирәк шәхес—моны киләчәк буыннар аңлатсын.

Тагын бер язучының фаҗигасенә күз салыйк булмаса.

Иван Бунинның көндәлегендә (1917 ел, 21 ноябрь) менә мондый юллар бар: "Төнге сәгать унике. Берьялгызым утырам—шәраб миңа кыюлык, сизгерлек, төрле хисләрнең кайтавазын бирә. Минем алда император фамилиясенә кагылышлы 24 нче номерлы печатьле, герблы шешә. Бар иде Россия. Кайда соң ул? И Ходаем..."

Бунин Октябрь революциясен әнә шулай каршылый. Ул аны кабул итми, шуңа күрә чит илгә чыгып китә. Нечкәлекләренә кермик, ләкин ул, теләсәтеләмәсә дә, мәңгелек эмигрант елларында барыбер Россияне сагынып, аның иң яхшы кешеләре, аларның күңел дөньясы турында ачынып-яратып иң яхшы әсәрләрен яза. "Легкое дыхание", "Солнечный удар" дигән хикәяләрен укыган саен мин аның талантына таң калам.

Чит илдә яшәгәндә Бунин "Арсеньев тормышы" дигән роман да яза. Үзе турында түгелме?—әдәби җәмәгатьчелектә ул әнә шундый сорау тудыра. Бунин бик дөрес җавап биргән: "Һәрбер ихлас роман—автобиографик. Һәрбер әсәремдә минем тойгыларым чагылыш табачак".

Лев Толстой кебек катлаулы шәхесне шәбрәк күзаллау өчен, әйдәгез, аның тормышындагы бер фактка мөрәҗәгать итик әле.

Ясенки дигән бер рус авылында солдат Шибунин өстеннән суд булырга тиеш. Ике ат җигелгән коляскада полк командиры килеп туктый. Адъютант аңа рядовой Шибунинның конвой белән китерелүе турында хәбәр итә.

— Ә граф Толстой биредәме?—дип сорый полковник, ак кителендәге тузанны каккалап.

— Так точно, господин полковник!

Хөкемгә тартылачак солдатның “Севастопольские рассказы” дигән хикәяләр авторы, аны якларга җыенган граф Толстой белән очрашып сөйләшкәнен инде белеп өлгергән полковник бик сүрән генә әйтеп куя: “Менә монысы кирәкмәс иде”.

Судьяларга кызык: офицерга кул күтәргән солдатны яклап граф-язучы нәрсә әйтер икән?

Утыз сигез яшьлек Толстой әйтәсе сүзен әйтә, тик моңа колак салучы гына булмый. Офицерына кул күтәргәне өчен рядовой Шубининны саф алдында аталар...

Толстойның “Балдан соң” дигән хикәясен искә төшерик. Сюжеты бик гади һәм хикмәтле. Хикәянең герое бик тә дәрәҗәле балда бер кыз белән танышуы, аның белән исерткеч вальс биюе хакында сөйли. Үзе дә шушы балда катнашкан полковникның кызына колагыннан узып гашыйк була бу. Ләкин... икенче көнне менә нинди фаҗигале хәлне күреп тора ул: армия хезмәтеннән тайпылганы өчен бер солдатны (татар кешесе) строй алдында таяк белән суктыралар!

Әле кичә генә мәҗлестә затлы-килешле утырган полковник егетне күрмәмешкә салыша, таякны җәлләп кенә сукканы өчен бер солдатны кыйнап та ташлый.

Толстой көндәлегендә әйтелгәнчә, бу хикәя әүвәл “Әти һәм кыз” дип аталган икән. Ләкин солдат Шибунин белән булган хәлнең әсәргә нигез булып ятуына тамчы да шикләнмәскә мөмкин.

Шәхес никадәр зуррак икән, аның язганы да әнә шулкадәр кыйммәтлерәк була. Аяз Гыйләҗев болай ди: “Ә уртача иҗат кешесеннән ни көтәргә мөмкин? Үзләренә юкны алар каян алсыннар?”

Чын, зур әдәбият һәрвакыт ялганга каршы көрәшкән, гаделсезлекне фаш иткән, изелгәннәргә теләктәш булган.

Радищевның “Сәяхәтләр...” китабы белән танышып чыкканнан соң Әби патша: “Бу бунтовщик Пугачевтан да яманрак!”—дип җикеренә...

Яшь чагында мине Михаил Пришвинның сүзләре гаҗәпкә калдырган иде. Ул анда балачагының һәм тормышының җиңел узуыннан зарлана.

Әйе, язучының шәхесе һәм иҗаты биографиясенә бик нык бәйле. “Нәрсә эшләргә?” дигән романны Шлиссельбург төрмәсендә ике ел тоткынлыкта яткан Чернышевский гына яза ала иде.

Нәрсә, зур язучы булып китәр өчен миңа да, яисә Иванов белән Вәлиевкә дә төрмәдә булып чыгу, фаҗигаләр кичерү мәҗбүри микәнни? Юк, әлбәттә. Тормыш биографиясеннән тыш күңел биографиясе дигән әйбер дә бар бит әле дөньяда. Минем үзем өчен, мәсәлән, татар халкының дәүләтчелеген югалтуы, әтинең Ватан сугышыннан кулсыз килеш кайтуы, фашист төрмәсендә Муса Җәлилнең башы чабылу, Хәсән Туфанның Сталин төрмәсендә һәм сөргенендә иза чигүе—шәхси фаҗига, биографиямнең бер өлеше түгелмени?

Гомумән, кешелек фаҗигасе язучы йөрәге аша яшен уты кебек яндырып узарга тиеш. Менә шул чакта гына чын, көчле, йогынтылы әсәрләр туа алачак.

Язучының үзе белән аның әсәре арасына тигезлек билгесе куярга мөмкинме?

Әйе һәм юк. Әйе, чөнки ул—бу әсәрне бар иткән индивидиум. Юк, чөнки ул үзенең язганнарыннан әллә ничә башка өстенрәк тә булырга мөмкин. Һәм—киресенчә.

**Батулла:** “*Шәкертем, танылган артист, режиссер Шәмси Закир белән аның өендә кунак булып утырам, Шәмсинең хатыны Галия ханым иҗат иткән тәмле ризыклар белән сыйланабыз. Безгә кызык: җырлыйбыз, шаярабыз, биеп тә алабыз. Мин кайтып киткәч, Галия ханым иренә әйтә икән: синең остазыңның китаплары үзеннән акыллырак, мәҗлестә ул шыр тиле икән ләбаса, дигән. Миңа моннан да олы мактау сүзе әйткән кеше булмады. Остазыңның әсәрләре үзеннән дә ахмаграк икән, дисә, җир тишегенә кер дә кит, вал-*

*лаһи! Әсәрләремне яхшы һәм акыллы дисәләр, мин җүләр булырга да риза."*

Әдәби тәнкыйть яшь язучыларны еш кына тормышны җитәрлек белмәүдә гаепли. Хаклык бар бу сүздә. Әйе, алар барыннан да бигрәк үткән заманны, тарихны, Гражданнар һәм Ватан сугышы вакыйгаларын, шуларга бәйле вәзгыятьне белеп бетермәскә мөмкиннәр. Әмма кулыңа каләм алдың икән, үзең язачак материалны ныклап өйрән, геройларыңның күңел халәтенә үтеп кер, психологик кичерешләрен художество көче белән тирәнтен тасвирла. Менә шул чакта могҗиза туа да инде! Америка язучысы Уильям Сомерсет әйтә: "Яза башлаганда кеше—кош ничек очса, үрдәк ничек йөзсә, үзен әнә шулайрак хис итәдер, мин моңа ышанам!"—ди.

Нурихан Фәттахның "Әтил суы ака торур" һәм башка романнарын укыгач, без ук һәм соңге тавышлары ишетелеп торган заманга килеп эләгәбез, үзебез өчен күп кенә хакыйкатьләр ачабыз түгелмени? Ркаил Зәйдулланың "Хан һәм шагыйрь" дигән тарихи хикәясен укыганнан соң да үзең өчен байтак гыйбрәтләр аласың.

Гомумән, язучы язган чакта ике вакыт аралыгында, ике вакыт кысасында яши. Ул үзенең иҗади-кайнар талпынышы белән Мисыр пирамидаларына хәтле дә барып җитәргә, кирәксә, бүгенге көн хакимнәренең эшчәнлегенә дә үтеп керергә мөмкин.

Без барыбыз да—замана балалары. Капитализм яисә социализм дип аталамы ул, без барыбыз да шуның иҗтимагый бишегендә тирбәлеп үскәнбез. Безнең уйлаган һәм язганнарыбыз—күпмедер дәрәҗәдә әнә шуның бер чагылышы.

Холык-фигыльне дә беркая куеп булмый.

Без—йөз төрле, мең төрле кайчакта.

Бер-ике мисал. Шагыйрь һәм фикер иясе Шопенгауэрны үзенең замандашлары өнәп бетермәгәннәр (һәм дөрес эшләгәннәр!). Ул—вакчыл, көнчел, мактанчык, даһилык чире белән интегә һ. б. Бүтән кешеләрнең интегү-газаплары аның өчен берни түгел... Менә шушы кеше тормыш-яшәеш хакында бик акыллы фикерләр әйтеп калдырган. Шулардан берсе: "Даһилар күпме генә боргаланмасын, алар пессимист була алмый, чөнки алар иҗтиһат итәргә һәм киләчәккә ышаныч белән карарга тиешләр".

Болай булгач, әйдәгез, кеше күңеле белгече Бальзакны да тыңлап китик инде. "Берәү мине дан сөючән, мал туздыручы, беркатлы, җилкуар, аумакай, холыксыз, ялкау, чикләнгән, лыгырдык, тәрбиясез, тупас, әдәпсез, сәер һәм үзгәрүчән дип бәяләп торганда, икенче берәү—тыйнак, йорт җанлы, кыю, максатчан, энергияле, шат күңелле, эш сөючән, әдәпле, төгәл, ышанычлы, ачык йөзле дип раслый икән, аларның икесе дә бер дәрәҗәдә хаклы булачак".

Шагыйрь Илдар Юзеев—җырлар, драмалар, җитди трагедияләр язган кеше. Тормышта ул шактый шаян, уенчак, тапкыр телле юморист буларак та билгеле. Ул үзе моны болай аңлата: "Минем тормышымда драматик вакыйгалар балачактан бирле күп булды. Әткәйнең сугышта үлүе һәм башкалар. Оныттылып торыр өчен мин тормышта еш кына юморга мөрәҗәгать итәм. Бу миңа җиңеллек китерә. Бигрәк тә каләмдәшләр белән аралашканда..."

Шәүкәт Галиев—шаян, төрткеле, кételмәгән юморны чәпәргә маһир. Мөхәммәт Мәһдиев—рәнҗетмичә генә "чеметкәләп" алырга ярата. Шул ук вакытта ул бик җитди, фәлсәфи дә. Аяз Гыйләҗев—Платон кебек акыл иясе, сүзен өздереп әйтә, һәммә нәрсәгә үзенең ачык-аек бәясен бирә.

Равил Фәйзуллин—шактый катлаулы шәхес. Мин аңарда ике "мин" яшәвен сизәм: берсе шигырь яза, берсе просто тормыш тәмен тоеп яши булса кирәк. Ә нигә, Хода бәндәсенә гаеп эш түгел бит бу.

Марсель Галиев—оста психолог. Ул сине бер күрүдә әллә нинди сыйфатлар белән бәяләп ыргыта. Шактый дөрес һәм усал әйтә бит шушы татар малае! Авызы да пешкәләде үзенең...

"Минем тормышымда фаҗигаләр булмады, менә шуңа күрә мин зур язучы була алмадым".—Михаил Пришвин кайсыдыр дәфтәрендә әнә шулай дип язып калдырган. Бәлки, хаклыдыр да?

Бу уңайдан Эрнест Хэмингуэйның да бәхәсле, ләкин кызыклы фикере бар әнә. "Язучы кешенең балачагы бәхетсез булырга тиеш".

Язучының хезмәте, бик гадиләштереп әйткәндә, дүрт "элемент"тан тора: урындык, өстәл, каләм һәм ак кәгазь. Кайсы да булса яңа әсәрен язар өчен аңа фәкать тынычлык һәм ялгызлык кирәк хәзер. Боларны язар өчен ул инде әллә кайчаннан әзерләнгән була: уй-фикерләре һәм тормыш тәҗрибәсе белән, дип әйтүем.

Менә шунда, язу өстәле артында, күзгә күренмәгән бик каты көрәш башлана да инде! Яки син әйтер сүзеңне тел ачкычлары ярдәмендә укучы күңеленә үтеп керердәй итеп язачаксың, яки зәгыйфь бер әсәр тудырачаксың.

Канның кайнарлыгы, уй-фикернең үткенлеге, үзеңнең геройларыңа яшәү бүләк итүләр әнә шуннан башлана да инде. Бу газаплы халәтне әдипләрнең үзләреннән дә ныграк аңлаучылар юктыр, мөгаен. Менә кайбер мисаллар.

Бервакыт Максим Горький үзенең эш бүлмәсеннән елап чыга. Сорагач: "Минем әле генә героем үлде",—дип җавап бирә ул.

Михаил Шолохов редакциягә килеп керә, күзләре дымлы, тавышы калтыравык. "Ни булды, Михаил Александрович?" дип сорыйлар редакциядәгеләр. "Давыдовны үтерделәр",—дип, Шолохов елый ук башлый. "Кемнәр, кайсы Давыдовны?" дип сорыйлар аптыраган кешеләр. "Күтәрелгән чирәм" романының каһарманы Давыдовны",—дип, Шолохов тагын да катырак елый башлый. Редакция кешеләре эшне аңлап ала. "Соң, Михаил Александрович, син аны үтертмә, соңыннан терелт, үтертмәү синнән тора ләбаса", дигәнгә каршы Шолохов: "Аны мин терелтә алмыйм, аны үтерергә тиешләр иде, ул исән калалмый",—дип җавап бирә. Әдәби каһарман авторның ихтыярыннан башка да яши башлаган, дигән сүз бу.

**Нурихан Фәттах:** *"Иҗат процессында әле син йә җырлап җибәрергә, йә булмаса торып биеп китәргә мөмкин. Хәтта күзне яшь баскан чаклар була. Болар—иҗат психологиясенең серләре".*

Габриэль Маркес та, үзенең яраткан герое үлгәннән соң, ике сәгать елый, тынычлана алмый. Иван Бунин көндәлегенә үз кулы белән язып калдырган: "Сан-Франциско әфәндесе" дигән хикәянең азагын язганда ул да утырып елаган икән.

Шопенгауэрның кеше шәхесендәге кичереш-газаплар хакында психологик тәгълиматы бар. Ул анда турыдан-туры әйтә: газаплы кичерешләр кешене иҗат эшенә, иҗади активлыкка этәрә, ди.

Иҗат газабын Франц Кафка тагын да усалрак итеп сурәтли: "Хөкем" дигән хикәям шулкадәр авырлык белән туды ки, мин моны... бала табу белән тиңләр идем. Йоклый алмыйм, саташам, бәргәләнәм..."

Ә Флобер болай дип өсти: "Язачак романым мине кыя мәгарәсенә илтеп ташлый һәм менә шуннан соң дөньяда нилэр барганын тәмам онытамын".

Зур максат зур энергия тудыра, дип кабатларга яратам мин үзем. Көчле язучылар зур максатсыз яши алмый.

**Туфан Миңнуллин:** *"Минем бөтен гомерем, яшәү рәвешем иҗат эшенә буйсындырылган. Әгәр язуга комачаулык итә икән, мин хәтта мәхәббәттән дә баш тартырга ризамын. Әгәр дә иҗатыма ярдәм итә икән, маймыл колагын барып үбәргә дә ризамын.*

*Язучыны иҗатыннан аерып карап булмыйдыр. Аның рухи дөньясы, идеаллары әсәрләренең тукымасына салынгандыр. Әгәр дә аның рухы камил үк түгел икән, ул ничаклы яшерергә тырышса да, язганнарыннан сизелә."*

Чыңгыз Айтматов сүзе: "Язган чакта мин үземне гел икенче кеше итеп сизәм. Һәрбер китабың белән үләсең дә яңасын яза башлар өчен өр-яңадан туасың шикелле."

Хикәя остасы Әмирхан Еники дә әнә шундыйрак фикерләр әйтә. Бу хакта аның белән әңгәмәне алдагы бүлектә укып китәрбез әле.

Әдәбият дөньясында үз-үзеңне иҗатка, хезмәткә мәҗбүр итә белү дигән

нәрсә дә бар бит әле. Әйтик, шул ук Бальзак үзен каторжникка тиңли. Эш бүлмәсен көндезен кара пәрдәләр белән томалап, кофе-кәхвә эчә-эчә көнетөне яза белгән бу әдәбият гигантының эшчәнлегенә сокланмый мөмкин түгел шул.

Виктор Гюго сакалын һәм чәченең бер өлешен кайчы белән кисеп ташлый да (урамга чыкмас өчен!) ике-өч атна буе үзенең хөҗрәсендә бикләнеп язып ята. Тормышта уңга-сулга сибелгән Джек Лондон өстәл артында унбишәр сәгать утырып язарлык көч тапкан үзендә. "Көнгә кимендә ике мең сүз язарга!" дигән девизы да бар бит әле аның.

Биографиясе кыенлыклар белән тулы һәм чирле Чехов 5 ел эчендә 300ләп хикәя язган!

Ак кәгазь каршына утырган әдип үзенең барлык көчләрен, яшәешен шунда түгеп ташлый. Үз-үзеңне раслау хакына чын язучыга берни дә жәл түгел. Локман Закир дигән әдип, усал телле публицист әнә гаражын һәм машинасын сата һәм шул акчага төрле "самиздат"ларда китапларын бастыра. Тыйнак һәм сәер кеше, мактануны белми, дан дигән нәрсәнең итәгенә ябышмый.

Иҗтимагый тормыш чынбарлыгын һәркем үзенчә кабул итә һәм үзе тойганаңлаган хәлдә сурәтләп бирә. Табигать турында, кеше һәм җәмгыятьтәге тетрәнүләр хакында әдәбиятта инде күпме язылган—иге-чиге юк! Теге заманнарда ук борынгы грек философы әйткәннәрне, үзе дә белмичә, гап-гади бер авыл агае да әйтеп бирергә мөмкин. Язылмый калганга күрә генә дә бу дөньяда күпме билгесез философларның фикерләре үзе белән бергә каберroutes кереп югалгандыр.

Язучы өчен үз сүзеңне, уй-фикереңне беренче булып әйтү мөһим. Юкса сине кемнедер кабатлауда гаепләргә мөмкиннәр. Гомәр ага Бәширов сөйли: "Менә өлкән яшьтәге бер героемны, аның коргаксыган һәм кан тамырлары беленеп торган кул аркасына кояш нурлары килеп төшкәнен сурәтлим... Шушы табышыма балаларча куанам! Ләкин бераздан шикләнә башладым, кемдәдер бар иде түгелме соң бу, дим. Эзләнә торгач таптым, Максим Горькийның бер әсәреннән килеп чыкты бу".

Үземнән дә бер мисал китерсәм, шәт, укучы мине гаепләмәстер. Тапкан детальләрне куен дәфтәренә язып бара торган гадәтем бар. "Ай—галәмнең сыңар алкасы..." дигән табыш ярый әле берәр шигыремә кереп китмәгән. Студент чакта чит ил әдәбиятыннан имтиханга әзерләнәбез. Низами Ганҗәвинең "Хәмсә" поэмасын укыганда теге "деталь"не очраткач, күзем маңгайга сикереп менде! 800 елдан соң нәкъ менә шундый тәңгәллек, образлы күзаллау азәрбәйҗан шагыйренең ерак бер "оныгында" кабатлансын әле...

"Миндә бик күп сюжетлар бар. Ләкин сәгате сукмыйча мин аларга тотына алмыйм". Моны миңа хикәяләр остасы Мәгъсүм Хуҗин әйтте. Үзем дә күптән бер хикәя язарга җыенам, тик һаман тәвәккәллек җитми. Шәп кенә темага, исеме дә табылган инде, югыйсә: "Нинди төстә син, хамелеон?" Тик Чеховның бу темага язылган мәгълүм хикәясе ("Хамелеон") һаман да итәктән тартып-йолкып тора бит, шайтан алгыры! Кабатланудан куркам. Бу хикәямнең сәгате сугармы-юкмы—белмим.

Язучы, һичшиксез, үзе каршында укучы барлыгын күреп-тоемлап тора, ул бит аны күпмедер дәрәҗәдә әлеге потенциаль укучы өчен яза. Чиләгенә күрә капкачы дигәндәй, авторның шәхесенә күрә укучысы да иҗат процессында ачык төсмерләнә. Менә шуңа күрә язучы үзенең җөмләсе, сүзе, хәрефе өчен генә түгел, кайчакны хәтта бер өтере өчен дә үзен җаваплы хис итә. Язучыфронтовик Владимир Богомолов үзенең инде китап булып чыккан әсәрләрен дә кайчакны берничә тапкыр күчереп яза торган була. Лев Толстой да калын-калын романнарын кабат күчереп язарга беркайчан иренмәгән. Хэмингуэй исә "Прощай, оружие" романының соңгы битен 29 тапкыр өр-яңадан күчереп яза!

Үзебезнең әдәбияттан берничә мисал.

Баштарак әсәрнең язылу тарихына тукталыйк. Ул чакта Бауман урамына урнашкан Язучылар берлегенең бүлмәсендә дүрт-биш кеше гәпләшеп утырабыз. Шулвакыт ишекне җай гына ачып берәү карый безгә. Бер сүз дә дәшми, бары тик бәхетле һәм мөлаем елмаю белән елмая гына. Аяз Гыйләҗев бу.

Остазыбыз Мөхәммәт Мәһдиев шундук аңлап алды моны, берничә сүз белән аңлатып та бирде:

— Элегрәк татар сәүдәгәрләре, Мәкәрҗә ярминкәсе тотканнан соң, җиңүчән кыяфәттә Казанга әнә шулайрак кайтып төшкәннәр. Мөгаен, Переделкинода берәр яңа әсәрен тәгәлләп кайткан бу...

Чыннан да, шулай булып чыкты. "Җомга көн, кич белән..." повестен тәмамлап, шуның рәхәтендә йөзгән чагы икән.

Язучы хатыннары үзләренең ирләрен аңламаска яки шактый дөрес аңларга мөмкиннәр. Менә шуларның көндәлекләре яисә истәлек язмалары аша без иҗат процессының күзгә күренеп тормаган шактый кызыклы серләренә үтеп керә алабыз.

Нәкыя апа Гыйләҗева нәкъ менә шушы повестька кагылышлы бер эпизодны сөйләп китте. Аларның җәйге бакчасына бер кунак килеп төшә. Галимлеккә дәгъва кылучы бу кунак сүз арасында болай дип әйтеп куя:

— Әсәрнең "Җомга көн, кич белән..." дигән исемендә ни өчен өтер куелганы аңлашылып бетми. Әсәр исеменә өтер кую урынлы микән? Аннан башка да бөтенесе аңлашыла ич...

Аяз абый артистланып утыра торган кеше түгел, уйлаганын туп-туры әйтә дә сала:

— Менә монысын инде, галим буласы кешеләр, сез үзегез аңлатып бирегез.

Моның белән автор ни әйтергә теләде икән? Чыннан да, татарның иң мөгътәбәр—изге җомга көне ул таң яралган минутлардан башлана, аннары кичкә кадәр дәвам итә. Өтер куйсаң, көн вә тәүлек озынлыгы сизелә, ә инде кинәт һәм тоташтан укып китсәң, кичнең билгеле бер вакыты гына төсмерләнә. Автор, әсәргә исем кушканда менә шуны ассызыкларга теләгән булса кирәк.

Русның "казнить нельзя помиловать" дигән хикмәтле гыйбарәсе шап итеп искә төшә бу урында. Өтерне икенче сүздән соң куйсаң, кеше исән кала, беренче сүздән соң куйдыңмы,—гомере өзелә.

Язучы Габделхәй Сабитовның хатыны Фәтхия ханым да үзенең истәлекләрендә шушы хакта әйтеп китүне кирәк саный: "Редакцияләрдә аның әсәрләренең берәр сүзен төзәтсәләр яки алмаштырсалар, ул чыгырыннан чыга иде. Хәтта басылган китабын да укып, аны сызып-төзәтеп утырган чаклары күп булды".

**Фәүзия Бәйрәмова:** *"Язучының иң көчле коралы, әлбәттә, Аллаһ биргән сәләт, ягъни, табигый талант. Шул булмаса, үҗәтлек белән генә дә, эгоизм белән дә яхшы әсәр тудырып булмый, ул тырыша-тырыша язган коры схемага гына әйләнеп калырга мөмкин. Әмма шул Аллаһ биргән сәләт-талант өстенә язучыдан зур тырышлык, зур гыйлем дә сорала. Язучы хезмәте—даими рәвештә тормышны өйрәнү, кешеләр белән аралашу, материал туплау, әсәреңә кирәк икән, айлар, еллар буе архивларда утыру, бик күп белү, күп уку, күп йөрү, еллар, хәтта гомер буе ак кәгазь каршында иелеп утыру, күз нурларыңны түгү дә бит әле ул... Ялкау кеше язучы була алмый. Иманы зәгыйфь кеше язарга ашыгырга тиеш түгел, чөнки, хакыйкатьне белмәү сәбәпле, зур ялгышлар җибәрүе бар. Үзең адашкан-саташкан булу бер хәл, ә инде әсәрләрең белән артыңнан башкаларны да ияртәсең икән, башкаларны да озак елларга саташтырасың икән, монысы инде куркыныч хәл. Сүз белән бик сак эш йөртергә кирәк, чөнки аның өчен Аллаһ каршында җавап бирергә туры киләчәк. Шуңа күрә, Аллаһ биргән талантны буш сүзгә, буш геройларны тасвирлауга әрәм итәргә ярамый, ә кешеләргә хак юлга чыгарга ярдәм итәрлек, тормышында файдасы тиярлек, иманлы әдәбият тудырырга тырышырга кирәк. Татар әдәбиятында бүген гадел кешеләр, иманлы, көчле рухлы көрәшчеләр, әдәп-әхлак үрнәге булырлык образлар аз. Бәйсезлеге булмаган милләткә, аның язучыларына, сәнгать эшлеклеләренә дәүләт өчен көрәшә алырлык каһарманнар тудыру турында уйларга кирәк, тормышта да, иҗатта да... Югыйсә, әкренләп мәңгелек коллык килүе бар!"*

# КИТАП НИЧЕК ЯЗЫЛА?

Бу сорауга һәрбер язучы, галим, әдәби тәнкыйтьче шактый үзенчәрәк җавап бирер иде, мөгаен. Чөнки һәрбер язучы—үзе индивид, аерым тәҗрибә иясе.

Планлы яки плансыз эшләү мәсьәләсен берничек тә истән чыгарырга ярамый. Йомыркамы, тавыкмы—беренчел, дигәндәй.

Язучының күңел мөнбәренә башта илһаммы, әллә уйлап-планлаштырып куелган сюжет, ниятме бәреп чыга икән?

Чыңгыз Айтматов: "Язган вакытта язучылар үз өстеннән контролен югалта".

Шулай ук проза остасы Флобер болай ди: "Бүген бер генә рәтле җөмлә дә яза алмадым, аның каравы аксак-туксак сүзләр белән дистәләгән битне тутырдым. Никадәрле газап!"

Безнең бер хөрмәтле язучыбыз еш кына: мин плансыз-нисез язам, геройлар үзләреннән-үзләре туа, яши, хәрәкәт итә башлыйлар, дип әйтергә ярата иде.

Күпләребезнең хәтерендәдер әле: журналист Рәфикъ Юныс әдәбиятка соңлап, ләкин бик җитди әзерлек белән килгән галим-укытучыдан беренчеләрдән булып интервью алды. "Татарстан яшьләре"ндә чыккан әңгәмәнең иseme матур иде: "Иң әйбәт ял—иҗат". Ошады бу әңгәмә безгә, яшьләргә дип әйтүем. Ләкин һәр әйберне энә күзеннән үткәрүчеләр—өстәгеләр дә бар бит әле дөньяда! Шушы интервью уңаеннан Мөхәммәт Мәһдиевне партия газетында тетеп чыктылар. Габдрахман Минский башкарды моны. Партиячел олуг эш—әдәби иҗатка ничек шулай, ялга тиңләп, төкереп карарга мөмкин—зур гына мәкаләнең үзәгендә шушы фикер ята иде.

Онытмыйк: репрессияләнгән мулла баласы буларак, Мөхәммәт абый һәрьяклап кысрыкланып килде.

Мин әдәбият бүлеген тәмамлаган япь-яшь укытучы әле. Биектау районыннан килеп төштем. Тамак ялгарга "Татар ашлары йорты"на кердем. Әллә ничек шунда сул ягыма туры килде Габдрахман Минскийның урындыгы. Бик чибәр, мөлаем кеше бу—фронтовик, Язучылар берлегенең партоешма секретаре.

Баштарак бик матур гына сөйләшеп киттек. Бераздан сүз әдәбиятка күчте.

— Син татар теле һәм әдәбияты укытучысы? Вәт шәп. Йә, кемнәрне, кайсы язучыларны ныграк яратасың?

— Мөхәммәт Мәһдиевнең "Без—кырык беренче ел балалары" һәм "Фронтовиклар"ы ошый безгә.

Менә шуннан соң Габдрахман аганың аксыл-калын кашлары икесе ике якка сикереп китте дә: "Тапкансың яхшы язучы",—дип, ул үпкәләп-ачуланып икенче бер өстәлгә күчеп утырды.

Ярый, болары үзе бер тарих.

Ә Флобер болай дип бик хаклы мактанадыр: "Планны озак айлар әзерләдем. Минем роман әзер, миңа аны хәзер утырып язарга гына кирәк".

Миңа калса, язылачак гади бер хикәянең дә күзалланган якынча бер планы булырга тиеш. Ә инде повесть, роман кебек катлаулы композициягә корылган күләмле әсәрләр язганда—бигрәк тә.

Язучының план-ниятләре, сюжет сызыклары ташкүмердәй катып калган бер нәрсә түгел. Иҗат процессында ул бик күп үзгәрешләргә дучар ителергә мөмкин. (Без алдагы бүлекләрдә бу хакта шактый гына гыйбрәтле мисалларга тукталып киттек инде). Кайчакта геройлар да, аларның кылган гамәлләре дә төрле-төрле үзгәрешләргә дучар ителә икән—бу бик табигый хәл. Чөнки автор үзенчәрәк уйлый, ә менә баш биргесез геройлар үзләренчә хәрәкәт итә, шушыларның уртасында тагын тимер мантыйк күсәге эленеп тора...

Рус әдипләре Максим Горький белән Алексей Толстой да план төзеп бик интекмәгәннәр икән.

Хикәяләр остасы Әмирхан Еники исә болай ди: "Гәрчә язмача план төземәсәм дә, күңелемдә аның планы һәрчак әзер була". Монда иҗат стихия-

сенең зур көч, йогынты икәнен дә истән чыгарырга ярамый. Геройның эчке дөньясын һәм ул эшләгән эшләрне дөрес чамалый алсаң, каһарманың чын кеше булып чыга. "Ситуацияне үзең сайлыйсың, герой да сиңа булыша",—дип яза бу хакта Нурихан Фәттах.

Менә мин, мәсәлән, әгәр беренче татар балетын язган композитор Фәрит Яруллинның шәхесен, иҗатын ихластан яратмасам, Ватан сугышында үлгән һәм тормышындагы фаҗигаи хәлләрен йөрәк аша уздырмасам, аның хакында "Ут һәм җыр" дигән роман-хрониканы, ай-һай, яза алган булыр идем микән? Шунысын гына әйтим: 5-6 еллык хезмәт дәвамында миңа Казан, Уфа, Мәскәү, Подольск, Киев һ.б. шәһәрләрнең архивларында эшләргә туры килде, 200ләп кеше белән хат алышырга кирәк булды. Иң тетрәндергече—аның сугышып йөргән урыннарында булу, зираттагы һәр агачны сыйпау, каберенә Татарстан туфрагы салу иде...

Драматург Туфан Миңнуллин болай дип сөйли: "Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында "Моңлы бер җыр" исемле пьеса язып яткан чак. Ашыгам, беркая чыкмыйм, үземне өстәл янына "кадаклап" куям. Өч-дүрт көндә өйдә шәп кенә эшләп утырдым. Менә шуннан соң бармый гына бит эш.

Бер җөмләне дә рәтләп яза алмыйм. Язганымны сызып ташлыйм, килеп кенә чыкмый бит, әкәмәт! Җитмәсә, пьесаның иң җаваплы урыны: Муса Җәлил көрәштәшләре белән үлем камерасында дөньяда яшәүнең мәгънәсе турында сөйләшергә тиешле сәхнә һәм җәза бүлмәсенә юнәлү күренеше бу.

Язганымны сызам, ботарлыйм, шактый озак азапландым. Арыдым, туктале, мәйтәм, бераз һавада йөреп керим. Башны ял иттерим. Ваннага кереп әйбәтләп кырындым, юындым. Матурлап киендем. Чыгып китәр алдыннан кәгазьләрне тәртипкә китерә башлаган идем, карасам—аякта таушалганрак иске бер чүәк! Тоттым да караңгы бүлмәгә ташладым моны. Шунда, үзем дә сизмәстән, языла башлады. Гаҗәп хәл. Ни язасымны миңа, әйтерсең, кемдер әйтеп тора. Әйтерсең, мин инде әзерне генә язып барам. Эш беткәч, шатлыктан кычкырып җибәрдем..."

**Мөдәррис Вәлиев:** *"Заман кемнең заманы?" дигәндәй, үткән гасырның 80 нче еллары әле бездән әллә ни еракта калмаса да—килешәсездер, бу—ил әдәбиятындагы шактый ук кызыклы, мәгънәле чорларның берсе иде. Ул елларның күгенә күтәрелеп карасак—башлар әйләнеп китәрлек.*

*Гомәр Бәширов һәм Әмирхан Еники, Хәсән Туфан һәм Сибгат Хәким, Нәби Дәүли һәм Салих Баттал, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Аяз Гыйләҗев... Әле болар—азмы-күпме аралашып калган, инде бакый йортка күчкән каләм ияләренең кайберләре генә.*

*Шуңа күрә, бер караганда, аз гына җил исеп кую белән кабынырга торган учак янында кебек хис итәм үземне".*

Аһ, никадәр мәгънәле, сагынулы, борчулы сүзләр сыенып ята бу юлларда!

Эрскин Кондуэль юкка гына болай дип язмагандыр инде: "Тормышта мин бик күп гаҗәп хәлләрне күрдем һәм шулар турында язмыйча түзә алмыйм".

Л.Леонов болай дигән: "*Бу бит нәрсәдер алырга омтылу түгел, киресенчә, кешеләргә фикер бүләк итәргә тырышу. Үзеңнең язганнарыңны кабат-кабат күчереп бик күп артык әйберләрне төшереп калдыру мөмкин.*"

*Ахыры бар.*

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# Б

**БАБИЧ** (Бабичев) Шәехзадә Мөхәммәтзакир улы (2.1.1895, Уфа губ., Бөре өязе Әсән а. - 28.3.1919, Башкортстан АССР Зилаир кантоны Зилаир а.), татар-башкорт шагыйре, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Авылда әтисе мәдрәсәсендә, аннары «Галия»дә (1911-16, Уфа ш.) белем ала. 15 яшьтән казакъ авылларында һәм Троицк шәһәрендә мөгаллимлек итә. «Аң», «Шура», «Кармак», «Акмулла», «Хөр милләт», «Сүз», «Тормыш», «Ирек» г-та - ж-лларында язышa. 1917 елның көзеннән башкорт милли хәрәкәтендә катнаша, Башкорт шурасының сәркәтибе итеп сайлана, «Башкорт» г-тасының мөхәррире була. Милли аңны тәрбияләү, әдәби талантларны бергә туплау, башкорт телен һәм әдәбиятын үстерүне максат итеп куйган «Тулкын» әдәби оешмасын төзүдә башлап йөри, үзе дә башкорт телендә яза башлый. 1919 елның 25 февраленнән Башкортстан ревкомының матбугат бүлегендә эшли.

Шигырьләре 1913 елдан матбугатта күренә башлый. Аның иҗатында татар, башкорт һәм казакъ әдәбиятларының традицияләре органик рәвештә үрелеп бара. Б. - Тукай мәктәбе шагыйре: Тукай әсәрләренең романтик рәвештә эшкәртелгән темалары, мотивлары, образлары, сюжетлары, әдәби алымнары, стилистик детальләре аның иҗатында чагылыш таба. Поэзиясендә шулай ук Дәрдемәнд фәлсәфи лирикасы йогынтысында туган аллегорик образлар да күзәтелә. С.Рәмиевнең гыйсъянчылык романтизмы да Б. өчен якын була.

Б.ның романтик поэзиясенә хас темалар: табигать, мәхәббәт, сәнгать культы, шәхес ирекен һәм милли-азатлык хәрәкәтен дәртле яклау; кадимчелек идеологиясен һәм феодаль торгынлыкны инкарь итү. Аның шигырьләрендә һәм поэмаларында лирик геройның җәмгыятьнең әхлакый кыйммәтләреннән өмете өзелүе чагылыш таба: «Дөньяга» (1915), «Таң вакыты» (1915), «Мин» (1915), «Миндаһи» (1916), «Миндә—көч» (1917) һ. б. шундыйлардан. Мәхәббәткә, хатын-кыз матурлыгына багышланган шигырьләре арасында: «Гашыйк дустыма» (1910), «Бәнем фәрештәм» (1912), «Кыз» (1916), «Сәҗидәгә» (1916), «Тешсез кыз» (1916), «Мәхәббәт токсыны» (1917), «Матур сыннар» (1917), «Әкълимәгә» (1917), «Мәхәббәт җырлары» (1917), «Кил, чибәр» (1917), «Зөһрәгә» (1917), «Шәмсекамәргә» (1917), «Гыйшык» (1918) һәм «Исемнәр бакчасында» (1917) шигъри циклы бар. Б. героиняларга фольклор һәм классик шәрекъ поэзиясенә хас исемнәр бирә (Сара, Сәрвәр, Маһирә, Нәфисә, Мәрьям һ.б.). Б.ның романтик поэзиясендә музыкаль тематика аерым бер урын алып тора. Ул сатира һәм юморга корылган халык җырларын, такмакларын җыя, аларга интерпретация ясый. Кайбер шигырьләре халык көйләренә җырлана: «Шатлык җыры» (1917), «Мәхәббәт җырлары» (1918), «Дим буе җырлары» (1918). Б.ның музыкага карата мөнәсәбәте «Мандолина» (1914), «Скрипка» (1915), «Канун тыңлаганда» (1918) исемле шигырьләрендә ачык чагыла.

1915-17 елларда Б. зур иҗади үсеш кичерә. Әлеге чорда ул татар поэзиясенең җәүһәрләренә әверелгән әсәрләрен иҗат итә. 1916 елда язылган «Кандала» һәм «Газазил» поэмалары - югары дәрәҗәле сатирик әсәрләр. «Газазил» поэмасы - Газазил фәрештәнең җәннәттән куылуы (куылганнан соң Иблис дип атала) һәм аның кешеләрне изге юлданяздыруы турындагы дини легенданы сәнгати яктан эшкәртеп, гаять дәрәҗәдә үзенчәлекле итеп язылган әсәр. Аллаһ һәм Иблис образларында Б. мәңгелек теманы - Изгелек һәм Яманлыкның үзара көрәшен тасвирлый. Поэмада тормышның искергән якларына, догматик схоластикага карата тәнкыйть яшертен акыллы көлү, сатира һәм агулы сарказм, үткен юмор һ.б. аша бирелә. Кыскача әйткәндә, болар барысы да «карнавал көлүендә» чагылыш таба.

Поэма шат күңелле романтик ирониясе, дини-мифологик образларны реаль тормышка бәйләп тасвирлавы б-н кызыклы. «Китабеннас фихәккыльхаувас» исемле, ике йөздән артык танылган шәхескә багышланган эпиграммалардан торган һәм 20 йөз башы татар зыялыларының шаян портретын тудырган җыентыгы Б.ның сатира һәм юмор өлкәсендә зур уңышы булды.

Б. иҗаты татар һәм башкорт халыкларының милли-азатлык хәрәкәтеннән аерылгысыз. «Хөррият бүләге» (1917) шигырендә революция нәтиҗәсе буларак татарларның ниһаять иреккә ирешүенә ышаныч чагыла. Башкорт Респ.-касы төзелү идеясен Б. хуплый, башкорт халкы тарихының якты сәхифәләрен күз алдыннан кичерә («Көтмәсдән», 1918 ; «Байрам», 1918; «Гаскәр маршы», 1918; «Башкортостан», 1918 ; «Салауат батыр», 1918), Ленин образына мәдхия җырлый («Әй, большевик!», 1917). Милли-сәяси хәрәкәтләр һәм партияләр пропагандисты буларак, Б.халыкны гади кешене яклаучы, «башкортлар өчен бәхетле ил» вәгъдә итүче социалистлар өчен тавыш бирергә өнди («Тупрак», 1917; «Беренсе номерлы список», 1917; «Список N9», 1917), җәмгыятьнең төрле катлауларының илдә булган революцион вакыйгаларга карата мөнәсәбәтен күрсәтә («Кызыл вәгазь», 1917), канкойгыч сугышны гаепли («Сугыш», 1917; «Кан шәүләләре», 1917).

1918 дән Б. поэзиясе икенче төрле төсмерләр ала. Күтәренке пафосны ирек һәм милли бәйсезлек идеалларының чәлпәрәмә килүе нәтиҗәсендә дөньяны трагик рәвештә кабул итү алмаштыра («Сау бул, бәйрәм», «Тапмадым йолдыз», «Юк», 1918). Башкорт халкының башына төшкән авыр сынаулар, башкортларның милли-азатлык хәрәкәте турындагы «Большевиклар белән килешү турында башкорт халкына көйле хитаб» (1919) исемле мөрәҗәгате - Б.ның соңгы зур күләмле публицистик әсәре. Ул анда башкорт милли хәрәкәтенең каршылыклары, Россиядә 1917-19 елларда хакимият бөлүгә юнәлтелгән бәрелешләр турында ачыктаначык сөйли. Башкорт халкының азатлык өчен көрәшенең тарихи юлын күзәтеп чыгып, Б. башкортларга кызыллар ягына чыгу хәерлерәк булыр дигән фикергә килә. Шул ук вакытта ул большевиклар тарафыннан оештырылган кызыл террор хакында да әйтергә онытмый. Башкорт социалистларының һәм милли хәрәкәт тарафдарларының Дутов һәм Колчак ягында чыгышларын «Красная гвардия вәхшәтендән Башкортстан канга баткан-га!..» дип аңлата. Шушы кызыл террорны фаш итүче юллар Б.ның язмышында хәлиткеч роль уйнаган дип фаразлана. «Хитап...» чыгып, бер ай узганнан соң Б. үтерелә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1958; Һайланма әсәрзәр. Өфө, 1958; Зәңгәр җырлар. К., 1990; Избранная лирика. Уфа, 1966.

Әд.: Исәнбәт Н. Шәехзадә Бабич // Казан утлары. 1967. N6; Ибраһимов Г. Вакытсыз һәлак булды // Әсәрләр. 5 т. К., 1978; Халит.Г. Шәехзадә Бабич // Татар әдәбияты тарихы. 3т. К., 1986; Миңнегулов Х. Шәехзадә Бабич. Олуг талант // Мирас. 1995. N9.

*Р.К.Ганиева.*

**БАБУР** (Бабир) Заһретдин бине Мөхәммәд (14.2.1483, Әндиҗан ш., хәзерге Үзбәкстан Респ-касында - 26.12.1530, Агра ш., Һиндстан), шагыйрь, тарихчы, Һиндстанда Бөек Магуллар империясенә нигез салучы. Аксак Тимер нәселеннән; 1494 елда әтисе вафатыннан соң Фәрганә тәхетенә утыра. 1504 тә Урта Азияне Шәйбани хан (Үзбәкләр дәүләтенә нигез салучы) яулап алгач, илдән куыла. Аз санлы гаскәре б-н Әфганстанга, аннан Һиндстанга юл тота. 1526 да Дәһли шәһәре солтаны Ибраһим гаскәрен тар-мар итеп, Һиндстанның төньяк өлешен үзенә буйсындыра.

Төрки телдә һәм фарсыча язылган күп санлы шигъри әсәрләр (газәлләр, робагыйлар), фикъһ (ислам хокукы), сугыш сәнгате, шигърият, музыкага караган трактат-китаплар һәм автобиографик, тарихи язмаларны эченә алган «Бабурнамә» авторы буларак билгеле.

Әсәр.: Бабер-Наме, или Записки султана Бабера. К., 1857; Бабур-наме. Записки Бабура. Ташкент, 1993.

Әд.: История всемирной литературы. М., 1985. Т. 3; Маллаев Н.М. Узбек адабиёти тарихи. Биринчи китоб. Тошкент, 1976.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**БАГДАНОВ** Идрис (1886-1916), драматург, тәрҗемәче. Тормышы турында

мәгълүматлар сакланмаган. Сембер губернасына кергән бер авылда туганлыгы, Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлагач, Мәскәү ун-тының юридик факультетында укуы мәгълүм. Аеруча танылган комедиясе «Помада мәсьәләсе» 1908 елда басыла, әмма цензураның каршы торуы һәм сәхнәләштерү мәсьәләсендә кайбер кыенлыклар килеп чыгуы аркасында пьеса «Сәйяр» труппасы тарафыннан 1911 дә генә куела. Г.Камал, Г.Кәрам аңа югары бәя бирәләр. Пьеса гражданлык пафосы, кадимчеләргә һәм татар буржуазиясенең реакцион өлешенә каршы кискен сатира рәвешендә юнәлтелүе сәбәпле Г.Камалның «Банкрот» (1911), Г.Исхакыйның «Кыямәт» (1910), «Җәмгыять» (1911) пьесалары б-н бер рәттә тора. «Зөләйха белән Фатыйма» пьесасы 1908 дә сәхнәләштерелә. Б. билгесез рус авторларының «Хуҗа һәм приказчик», «Югалган хатын» исемле пьесаларын, А.С.Пушкинның «Каменный гость» («Таш кунак») трагедиясен, Л.Н.Толстойның «Крейцерова соната» («Крейцер сонатасы») повестен татарчага тәрҗемә итә. Б.ның тарих б-н кызыксынуы, гыйльми бер утырышта «Казан һәм Казан ханнары тарихы» турында чыгышы «Казан мөхбире» г-тасында хәбәр ителә (1906).

Әд.: Мәһмүтов Һ., Илялова И., Гыйззәт Б. Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Татар пьесалары. Антология. 1 нче китап. К., 1987.

*Н.Г.Ханзафаров.*

**БАГДАНОВА** Мәдинә Искәндәр кызы (26.12.1908, Бохара ш. - 6.5.1962, Мәскәү), төрколог, фольклорчы, филол. фән. канд. (1940). Урта Азия ун-тын тәмамлый (1931, Ташкент). 1931-34 елларда Шәрекъ хезмәт ияләренең Коммунистик ун-тында төрки телләре укыта, шул ук вакытта яңа алфавит буенча оештырылган Бөтенсоюз үзәк к-тетының төрки телләр секторында эшли. 1935 елда Төрекмәнстан ССРга күчеп китә. 1936 дан Төрекмәнстанда Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. Төрекмән теленең алфавитын төзүдә, терминологиясен эшләүдә катнаша, төрекмән фольклорын җыю буенча экспедицияләр оештыра. 1940 та СССР ФАнең М.Горький исем. Дөнья әдәбияты ин-тының СССР халыклары әдәбияты секторында эшли. 1941-44 елларда Кыргыз пед. ин-тында укыта, шул ук вакытта Кыргыз тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү ин-тында (Фрунзе) фольклор һәм «Манас» эпосы секторында эшли. Аның кыргыз фольклорына багышланган хезмәте аерым бүлек булып «Кыргыз совет әдәбиятының очерки» (Фрунзе, 1943) китабына керә. 1944 тән Мәскәү ун-тында укыта, 1953 тән СССР халыклары әдәбияты кафедрасы мөдире, шул ук вакытта 1957 дән Дөнья әдәбияты ин-тының фольклор секторы мөдире. Анда Б. җитәкчелегендә «СССР халыклары эпосы» («Эпос народов СССР», 1993 елдан - «Эпос народов Евразии») сериясен туплау эше оештырыла. Б. хезмәтләрендә Урта Азия халыклары әдәбиятларында реалистик традицияләр урнашуда татар һәм рус әдәбиятларының классик әдипләре иҗатларының йогынтысын тикшерә.

Хезм.: Очерки киргизской литературы. М., 1947; От фольклора к литературе // Вопр. литературы. 1957. N 1; Роль русской литературы в становлении социалистического реализма в тюркоязычных литературах народов СССР // Взаимодействие и взаимообогащение литератур народов СССР. М., 1961;

Әд.: Кыргыз совет энциклопедиясе. Фр., 1943. Т. 1.

*В.Х.Ганиев.*

**БАГЫШЛАУ**, әдәби жанр. 1) автор тарафыннан әсәрнең кемгә, кемнең истәлегенә атап язылуын күрсәткән юллар; 2) аерым кешеләрнең шәрәфенә багышланган поэтик жанр. Әсәрне кемгә дә булса конкрет адреслап махсус Б.лар язу дөнья әдәбиятында киң таралган күренеш. Борынгы заманда һәм Урта гасырларда, мәс., күп кенә әдипләр, матди һәм мораль яклы күздә тотып, үз әсәрләрен еш кына төрле хөкемдарларга багышлый. Б.ның татар әдәбиятында борынгы традицияләре бар. Котб «Хөсрәү вә Ширин» исемле шигъри романын Тәнибәк ханга, Харәзми «Мәхәббәтнамә» поэмасын Мөхәммәд Хуҗа бәккә, Мөхәммәдъяр «Нуры содур» поэмасын Сәхибгәрәй ханга багышлаган. Соңгы дәвер Б.лары адресатларының төрлелеге белән аерылып тора. Күренекле кешеләргә, галимнәргә, хакимият ияләренә, аерым төркемнәргә, сөйгән ярларга, дус яки дошманнарга, төрле вакыйгаларга һ.б. атап язылган әсәрләр бар. Шуңа бәйле аларның эчтәлекләре һәм стильләре төрле була (мәс., иҗтимагый, сәяси,

интим, юмористик, житди, ироник, сатирик һ.б.). М.Җәлил «Дуска» шигырен А.Алишка, «Бүләгем» шигырен А.Тиммерманска багышлый.

*Х.Й.Миңнегулов*

**БАДЮГИНА** Әзәлия Исмәгыйль кызы (29.5.1933, Алма-Ата ш.), әдәби тәрҗемәче. Казан ун-тын тәмамлый (1957). 1964-89 елларда Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият бүлеге мөхәррире. Г.Гобәйнең «Без үскәндә» («Когда мы росли», 1964) повестен, Ә.Фәйзинең «Аучы Мәргән белән Болан кыз әкияте» («В стране смельчаков», 1966), Х.Мөҗәйнең «Сугыш язмалары»н («Летопись войны», 1978), Ә.Еникиның повесть һәм хикәяләрен («Повести и рассказы», 1982), Ш.Камалның «Таң атканда» («На заре», 1983) романын, Ә.Еникиның «Соңгы китаб»ын («Страницы прошлого», 1999). Г.Әпсәләмов, К.Тинчурин, И.Гази, Г.Бәширов, Г.Минский, Г.Гали, А.Расих, Ф.Яруллин, Л.Ихсанова һ.б. аерым әсәрләрен, татар халык әкиятләрен татарчадан русчага тәрҗемә итә. Соңгы тәрҗемәсе — һ.Атласиның «Себер тарихы» («История Сибири», 2005) тарихи хезмәте.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

**БАЙЧУГАВИ** Гали (19 йөзнең 1 нче яртысы, Казан губ., Лаеш өязе Байчуга а. - ?), шагыйрь-чичән. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. Дала тормышы б-н яшәгән казакъ халкының милли гореф-гадәтләрен, үзенчәлекле сыйфатларын реалистик төстә тасвирлаган «Кыйссаи әхвали казакъ» («Ушбу кыйсса казакъның әхвалләрен бәйан идәр» исеме б-н дә мәгълүм) поэмасы авторы. Поэма 1841 дә языла һәм 1879 елда Казанда басылып чыга.

Әд.: Татар халык мәкальләре. К., 1959. Т. 1; Васильев А.В. Материалы к характеристике взаимных отношений татар и киргизов с предварительным кратким очерком этих отношений. Оренбург, 1898.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**БАЙЧУРИНА** Заһирә Гали кызы (1890, Вятка губ. Алабуга өязе Тирсә а. - 26.12.1977, Махачкала ш.), шагыйрә. Иж-Бубидагы кыз балалар мәктәбендә укый (1901-06); Уфа, Пермь шәһәрләрендә укыта (1907-14). Беренче шигырьләре 1913 елда «Сөембикә» ж-лында басыла. 1913-17 еллардагы иҗаты татар хатын-кызының язмышына багышлана, сугышка каршы юнәлеш ала. 1918 дә Казанга күчеп килә. Иҗатының аеруча актив чоры 1918-25 елларга карый. «Кызыл Армия» г-тасында, «Безнең юл» ж-лында басылып килгән күпчелек шигырьләренең тематикасы — азатлык, революция, кызылармиячеләрнең батырлыгы, яңа тормыш төзүче хезмәт кешесе. Беренче «Шигырьләр мәҗмугасы» 1923 тә басылып чыга. Аерым шигырьләре «Көрәш җырлары» (1923) күмәк җыентыгына да керә. «Ана сүзе» сайланма җыентыгы 1959 да нәшер ителә.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986; Өмет йолдызлары. К., 1988; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. Т.2.

*М.С.Мәһдиев.*

**БАКИР** (Бакиров) Госман Фәтхулла улы (12.3.1896, Казан губ., Казан өязе Югары Курса а. - 12.3.1982, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1966). Казан педагогия ин-тын тәмамлый (1940). 1918-22 елларда Арча төбәге мәктәпләрендә, 1923 тән Казанда укытучы. 1929-37 елларда «Мәгариф» ж-лының җаваплы сәркәтибе, 1940-42 дә Татарстан дәүләт нәшриятының дәреслекләр һәм методик кулланмалар секторында җаваплы мөхәррир. Беренче Бөтендөнья (1915-17) һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша, 1942-45 тә туп командиры, «Ватан намусы өчен» фронт газетасы хәбәрчесе. 1945-56 елларда Татарстан китап нәшриятында бүлек мөдире. Б. ның әдәби әсәрләре 1923 елдан басыла. Аның тәүге хикәяләре «Урак өсте» (1930) җыентыгында, пьесалары «Беренче җиңү» (1928), «Яшәсен яшьләр» (1934), «Сафа балалары» (1935) китапларында басылып чыга, аларда авыл укучыларының тормышы сурәтләнә. Фронт көндәлеге, сугыш кичерешләре «Сугышчы истәлегеннән» (1949), «Утлы тегермән» (1966) исемле хикәя җыентыкларында, «Партизан малай» повестында (1953) чагылыш таба. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Пьесалар. К., 1965; Бормалы юллар. К., 1982; Моя учительница. К., 1975.

Әд.: Шәрифуллин Ф. Укытучы, жур-

налист, язучы // Совет мәктәбе. 1966. N3; Шакир С. Сез әле дә уң флангта // Казан утлары. 1975. N3.

**БАКИРОВ** Марсель Хәернас улы (10.12.1933, Мөслим р-ны Мөслим а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1999), проф. (2002), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1956). «Кызыл таң» г-тасында эшли (Уфа ш.). 1966 елдан Казан ун-тында укыта. Хезмәтләре төрки шигыренең теориясенә һәм тарихына, төрки-татар шигырь төзелешенә, гомумтөрки шигыренең генезисына һәм борынгы формаларына, фольклор жанрларына, борынгы төркиләрнең этник һәм этномәдәни тарихына карый.

Хезм.: Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе (автордаш). К., 1979; Гомумтөрки поэзиясенең ялалуы һәм иң борынгы формалары. К., 1999; Шигърият дөньясына сәяхәт. Фольклордан классик язма шигырьгә күчеш тарихыннан. К., 1999.

Әд.: Российские фольклористы. Справочник. М., 1994.

**«БАКЫРГАН КИТАБЫ»**, 12-18 йөзләр төрки-татар поэзиясенең антологиясе. Якынча 18 йөзнең ахыры - 19 йөзнең башларында Урта Идел төбәгендә төзелгән. 20 авторның 144 шигъри әсәре тупланган. Авторлар арасында Әхмәд Ясәви, Колшәриф, Касыйм Шәех, Кол Гобәйди (Гобәйдулла), Тагый, Фәкыйри, Гарибы, Шәмседдин (Шәмси Гасый) һ.б. бар. Әмма шигырьләрнең күпчелеге Сөләйман Бакырганиныкы, шунлыктан җыентык тора-бара «Б.к.» исеме б-н йөртелә башлый. Китапта урнашкан шигырьләрнең гади, җиңел телдә язылуы, муз. аһәңле булуы «Б.к.»н халык арасында бик популяр иткән, аны заманында «Кол Сөләйман көе»нә көйләп укый торган булганнар. «Б.к.» күп кенә татар шагыйрьләренә (Аллаһияр Суфи, Мәүла Колый, Утыз Имәни, Г.Тукай һ.б.) тәге яки бу дәрәҗәдә уңай йогынты ясаган. «Б.к.» басмада беренче мәртәбә 1846 елда Казанда дөнья күрә, шуннан соң аның дистәдән артык яңа басмалары чыкканы мәгълүм.

Чыганаклар: Бакырган китабы. К., 1846; Бакырган китабы: XII-XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре. К., 2000.

Әд.: Исмәгыйль Н. Бакырган китабы // Ватаным Татарстан. 1993. 15 май.

*М.И. Әхмәтҗанов*

**БАКЫРГАНИ** Сөләйман (Кол Сөләйман, Хәким Ата) (вафаты 1186 елда), суфи шагыйрь. Урта Азиядә яшәгән һәм төрки телдә язган. Биографиясенә кагылышлы төгәл мәгълүматлар аз сакланган, булганнарының күбесе риваять характерында. Тәхәллүсенә нигезләнеп, Харәзем дәүләтендәге Бакырган кылагында туган дип фаразлана. Гоманланганча, Яссы шәһәрендә (хәзерге Казакъстан Респ-касындагы Төркестан ш.) Әхмәт Ясәвидә укый, аның вафатыннан соң гомере буе остазы завиясен (хөҗрәсен) саклаучы булып яши. Мәккәгә хаҗ сәфәре кыла. «Бакырган китабы» антологиясендәге бик күп шигырьләр, ш.у. «Китаб Хәким ата» («Хәким ата китабы»), «Ахырзаман китабы», «Хәзрәти Мәрьям китабы» (1878) исемле риваять характерындагы чәчмә әсәрләр авторы. Б. иҗатының тел һәм жанр үзенчәлекләре төрки әдәбиятлардагы халыкчан поэтик традицияләргә якын тора. Шигырьләре хисси-экспрессив тәэсир көченә ия. Б. иҗатының татар шигъриятенә йогынтысы урта гасырлар болгар-татар әдипләрендә дә (Кол Гали, Мәүла Колый һ.б.), яңа заман шагыйрьләрендә дә, ш.и. Тукай иҗатында нык сизелә. Төрек галиме Фуад Күпрелезадәнең фикеренчә, Б.шигырьләре Идел буе татарлары арасында гына киң таралган булган. «Бакырган китабы» 1846 да беренче тапкыр басылып чыкканнан алып 1917 гә кадәр Казанда дистәләрчә мәртәбә кабат нәшер ителә, мәдрәсәләрдә дәресек сыйфатында кулланыла.

Әд.: Күпрелезадә Ф. Төрек әдәбиятында элек мөтәссәвефләр. Истанбул, 1919; Яхин Ф. Бакырган китабы // Әдәбият чыганакларын барлаганда. К., 1994.

*М.В.Гайнетдинев.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Фатих Әмирханның тууына 120 ел*

# БУЫННАР ХӘТЕРЕ— МИЛЛӘТ ТАЯНЫЧЫ

Ислам динендә, татар халкының язылмаган әхлакый кануннарында җиде буын бабанны белү—изге гамәл, зыялылык һәм нәселлелек билгесе санала. Советлар режимы чорында вак милләтләрне йоту сәясәте нәсел-нәсәбәнне яшерүне, онытуны, хәтерсезлекне, манкортлыкны хуплады. Сыйнфыйлык хасияте ярлы, хәерче кешеләрне күтәрде, ата исеме фамилиягә әйләнү нәселсезлеккә, буыннарны бәйләүче җанлы җепләрне өзүгә алып килде. Демократия җилләре исеп, ирекне буып торган тимер пәрдәләр алып ташлангач, укый-яза белгәннәр тарихка сәяхәткә "чыкты", шәҗәрәсен торгыза, ерак бабаларын эзли башлады. Нәтиҗә озак көттермәде: әле күптән түгел батрак, кол, сорануччы кавеменнән булулары белән масаеп, күкрәк киереп йөргән бәндәләр ханнар, морзалар, Идегәйләр, һич югында дини руханилар нәселеннән чыгуларын игълан итеп, уйдырмаларына үзләре ышанып, татлы мизгелләр хозурына чумдылар. Коммунистлар вәсвәсәсенә бирелмәгән, аларның ялтыравык шигарьләренә ышанмаган, килеп чыгышларын яшермәгән, шуның өчен хакимият тарафыннан рәнҗетелгән, изелгән зыялы нәселләргә чишмә башын эзләү ихтыяҗы юк иде, тарих хәтере аларны онытмады. Татар халкының горурлыгы, мәдрәсәләр, мәчетләр салдырган, матбугат тудырган хәтәр елларда рухи таяныч булган Алкин, Апаков, Апанаев, Акчурин, Баязитов, Бурнаев, Рәмиев, Хөсәенов, Юнусов, Яушев кебек еракттан килгән асыл фамилияләрне милләт зиһененнән бернинди җил-давыл, зилзилә кысып чыгара алмады. Шулар арасында заманында "Әмирхания" мәдрәсәсенә нигез салган, халкыбызның йөзек кашы булырдай Әмирханнар нәселе аеруча ихтирамга һәм хөрмәткә лаеклы. Телдән Әмирхан сүзе төшүгә "Хәят", "Урталыкта", "Фәтхулла хәзрәт", "Яшьләр" кебек татар әдәбиятының алтын фондына кергән әсәрләр авторы, публицист, җәмәгать эшлеклесе, 21 яшендә аяксыз калып, гомерен коляскада уздырса да, фаҗига рухын, ихтыярын сындыра алмаган, туган халкының мәнфәгатьләре, киләчәге белән яшәү үзенә Алып батырлар көчен индергән олы шәхес күз алдына килә. Б.Урманче Фатих Әмирханны дөньяның алдынгы мәдәниятенә йөз тоткан татар зыялыларының идеал моделе дин саный, Х.Туфан ана "аяклары бәйле Прометей" диган метафора белән мөрәҗәгать итә.



Соңгы чорда әдипнең архивларда яткан, үткенлекләре, большевиклар сәясәтенә, гражданнар сугышына биргән кыю бәяләре белән В.Короленконың шул чордагы мәгариф министры А.Луначарскийга язган хатлары, И.Бунинның "Окаянные дни" кебек атаклы язмалары белән бер рәттә торган, күп нокталарда аваздаш публицистикасы табылды һәм бер өлеше басылды. Татар әдибе чит илләрдән кайтып, төрмәләрдән чыгып хакимиятне кулларына төшергән һәм илне озак елларга караңгылык упкынына ташлаган, үз халкының зыялыларына каршы сугыш башлаган фирка әһелләрен фаш итә. Кыскасы, Әмирханнар нәселе Фатих эшчәнлегендә, табигатькә яктылык, ямь, яшәү дәрте алып килгән кояш зәңгәр күкнең кыл түбәсенә менгәндәй югары, ноктасына күтәрелде.

Атаклы дин әһелләрен биргән нәсел (Фатихның әтисе дә мөлкәтле мулла була) XX гасырның беренче яртысында большевиклар режимы тарафыннан бик нык рәнҗетелә. Фатих Әмирхан мирасын вульгар социологизм иләгендә талпулар,

бозулар, ярлыклар тагу 30-40 нчы еллар дәвамында гадәти күренешкә әверелә. Татар әдибенең бертуган энесе, гаярь дипломат Ибраһим, туганнан туганы Гомәр коммунистлар терроры корбаны булалар. Мәгәр тирән, кин җәелгән тамырлы, җиргә береккән агач кебек көчле, зыялы Әмирханнар нәселен корытырлык көч дөньяда юк иде. Дәһшәтле XX гасырнын икенче яртысында Әмирханнар нәселенең яна буыны үзе турында хәбәр бирә. Милләткә бирелгән, эшчән, булдыклы Әмирханнар нәселенен дәвамчылары хакында китап, мәкалә, эссе язып булыр иде. Әмирханнар нәселеннән, урыс мохитендә белем алса да (Казан дәүләт педагогика институтынын урыс теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый), милли җанлы, бөтен көчен, табигый талантын татар тарихын өйрәнүгә багышлаган Госман улы Равил Әмирхан турында гына берничә сүз әйтеп үтәсе килә. Нәселдәше Фатих Әмирхан белән "күктән ингән" уртак яклары шактый: икесе дә татар җире акка күмелгән ел башында, гыйнварь аенда дөньяга килгәннәр, 2006 елда беренчесенен тууына 120 тулса, икенчесе алтмышын бәйрәм итәргә әзерләнә. Аралары алтмыш ел булса да, икесе дә талантлы, намуслы язмышларын туган халкы тарихын, бүгенгесен өйрәнүгә, анын киләчәге белән яшәүгә багышлаганнар.

Равил Әмирхан иҗат юлын үткән гасырнын 70 нче елларында мәктәп-мәдрәсәләр, Казан урамнары тарихын, хатын-кызлар хәрәкәтен фәнни өйрәнүдән башлап җибәрә. Риза Фәхретдин, Галимҗан Баруди кебек дөньякүләм танылган дин әһелләренең тарихи мирасын, Тукай, Исхакый кебек бөекләребезнең иҗатын тикшерә, һәртөрле бозуларга, ялгыш аңлатуларга каршы чыга. Равилне ерактан җемелдәп, күзне үзенә тартып торган маяк уты кебек Әмирханнар нәселе, шәҗәрәсе үзенә әйдәп тора. Мәшһүр дин галиме, тарихчы һәм философ Хөсәен Әмирхан турында фәнни-публицистик мәкаләсен бастыра. Әмма анын өчен ин газиз, якын мирас—Фатих Әмирхан иҗаты. Абыйсынын вакытлы матбугатта югалып калган чыгышларын, мәкаләләрен, анын турында истәлекләрне җыйнап, бастырып чыгару белән генә чикләнмичә, татар классигын һәртөрле бозулардан, берьяклы, ялгыш аңлатулардан арындыру юнәлешендә зур эш башкара ("Классик мирас турында уйланулар"). Татар демократик вакытлы матбугатына (1905-1907) багышланган хезмәте өчен тарих фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алды, кин колачлы галим буларак танылды.

Фатих һәм Равил Әмирханнарны олуг юбилейлары белән котлыйбыз. Татар халкы яшәсә Әмирханнар агачы корымас, ул фидакарьләрнең эшчәнлеге милләтебезнең барыр юлын яктыртып, кодрәт биреп торыр!

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы, профессор*

## ЯШӘЕШ ҺӘМ ИҖАТ КОЛАЧЫ

...Бездә сәер үзенчәлекләр бар инде ул. Ни хикмәттер, Фатих Әмирхан юбилее вакытында да сизелә алар. Мәгълүм булганча, әдипнең туган елы (1886) 6 санына тәмамлана. Ләкин менә бәла: шул ук 6 саны тагын ике олуг шәхес—Габдулла Тукай һәм Муса Җәлилнең туган елларына да хас. Юбилей вакыты житкәч, төрле сәбәп-сылтаулар килеп чыга, өч шәхеснең берсе, ягъни Ф. Әмирхан тавыш-тынсыз гына "күмелеп" кала. Җанлы әдәби хәрәкәттән, яд кылудан читләштерелеп, халкыбызның мәшһүр әдибе нахакка рәнҗетелгән бер үксез баланы хәтерләтә башлый.

Ан булыйк, бүген татар әдәбиятынын "рухи Әмир-ханы"на (Х. Туфан) 120 яшь тулды. Килешәсездер, шактый түгәрәк сан. Шул олуг датаны искәртеп куйыйк та, башка олпат затлар хозурында ким-хур итмичә, анын да иҗтимагый-мәдәни, рухи тормышыбызда тоткан урынына, иннек-кершәннәр якмыйча, ялтыратмыйча гына хәл кадәренчә бәя бирергә тырышыйк.

"Үгезне мөгезеннән" алып, башта ук шуны искәртеп куйыйк. Татар әдәбияты классигы Фатих Әмирхан—мәдәният тарихыбызда лаеклы урын тоткан иң калку, күренекле шәхесләребезнең берсе. Төрле елларда укытучы-педагог, революционер

көрәшче, оппозицион шәкертләр хәрәкәте җитәкчесе, милли театр, прогрессив матбугатны оештыручыларның берсе, публицист, драматург, әдип, җәмәгать эшлеклесе буларак, ул XX йөзнең беренче чирегендә татар халкының иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында якты эз калдырды. Ф. Әмирханның әдәби мирасына килгәндә исә, ул үзенең егерме еллык нәтиҗәле эшчәнлеге дәверендә искитмәле сәнгать әсәрләренең бөтен бер бәйләмен иҗат итте. Бу әсәрләр үзләренең тирән мәгънәсе, композициянең камиллеге, нечкә психологизмы, стиль гүзәллеге, тел күркәмлеге, натураларның бөтенлеге, кискен сатирасы һәм җинелчә юморы белән укучыларны бүгенгәчә хәйран калдыра. Әмма атаклы язучы булып киткәнче Ф. Әмирхан зур һәм гыйбрәтле тормыш мәктәбе үтә.

Булачак әдип 1886 елның 1 (13) гыйнварында дөньяга килә. Шәһәр җирендә туып-үскән санаулы гына каләм осталарыбызның берсе. Алты яшь ярымда Фатих мәктәп бусагасын атлап керә, әтисе хәзрәт җитәкләгән уку йортында беренче гыйлемнәрен ала. 1895 елның көзендә ул заманындагы иң атаклы мәдрәсәләрнең берсе булган "Мөхәммәдия"гә күчә. Биредә укыган чорда Ф. Әмирхан үзенең яшьтәшләреннән эрудициясе, карашының киңлеге, тормышның төрле якларыннан хәбәрдар булуы белән аерылып тора. Яшь шәкерт һәрвакыт яналыкка омтыла, урта гасырчылык һәм торгынлыкка каршы килешмәүчән көрәш алып баручы шәхескә әйләнә.

XX гасырның тәүге елларында ук шәкертләр арасында яшерен җәмгыятьләр төзелә башлый. Аларның эшчәнлеге нигездә милли тормыштагы патриархаль торгынлыкны тәнкыйтьләүгә юнәлгән була. 1901 елда "Мөхәммәдия" шәкертләре арасында яшерен "Иттихад" ("Берлек") оешмасы төзелә. Аның төп максаты—бөтен Казан шәкертләрен кадими (иске) мәдрәсәләрне үзгәртеп кору өчен хәрәкәткә туплау. Фатих әлеге җәмгыять җитәкчеләренең берсе була һәм шул ук вакытта оешманың басма органы—кульязма "Әл-Мәгариф" газитен дә җитәкли. Газит битләрендә булачак классикның беренче мәкаләләре басыла. Аларда үз заманының мәгариф өлкәсендәге казанышлары пропагандалана, өлге итеп еш кына очракларда Исмәгыйль Гаспралының "Тәрҗеман" ("Тәрҗемәче") газите алына. Каләм сынау уңышлы үтә, һәм яшь шәкерт зур дәрт белән журналистлык эшенә чума. Бу эшчәнлек 1905-1907 елгы инкыйлаб елларында аеруча киң колач ала.

"Иттихад" комитеты һәм "Әл-Мәгариф" газитләрендәге эшчәнлек яшерен эшләрнең башка төрләре белән дә үрелеп бара. 1902-1903 елларда "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә яшерен әдәби түгәрәкләр оештырыла. Алар шәкертләрнең үзаның үстерүдә, аларны уртак максатларны тормышка ашыру өчен туплауда әһәмиятле роль уйный. Бу чорда түгәрәкләрнең башында һәрвакыт диярлек Ф. Әмирхан тора. Түгәрәкләрдә шәкертләрнең үзләре тарафыннан иҗат ителгән әсәрләре укыла, төрле музыкаль инструментлар кулланып җырлар (шул исәптән "Марсельеза") өйрәнелә һәм җырлана, традицион өс-башны инкяр кылып, европача костюм модельләре күрсәтелә. Бу өлкәдә иң актив рольне, әлбәттә, Фатих үзе уйный. Тора-бара түгәрәкләр җирлегендә әдәби-музыкаль кичәләр оештырыла башлый.

Түгәрәкләр яшерен кульязма газитләр дә чыгарган. Алар үзләренең актуальлеге, азатлык рухы таратулары белән укучы яшьләрдә тирән кызыксыну, теләктәшлек хисе уяткан, аларны гомуми көрәшкә өндәгән. Ф. Әмирхан җитәкчелегендә, мәсәлән, "Күстәргеч" ("Күрсәткеч"), "Телчән", "Изгеч", "Бәнд" ("Бәйләм") исемендәге кульязма басмалар гамәлгә куела. Аларда иске карашлы руханилар, мөдәррисләр, кадими мәдрәсәдә хөкем сөргән тәртипләр тәнкыйтьләнә, искергән гадәтләр, зәвыклар ачы көлүгә дучар ителә.

1901 елда Казанда Г. Исхакый, М.-Ф. Туктаров, Х. Ямашев һ. б. сул көчләр җитәкчелегендә "Тәрәкъкый" ("Прогресс") исемле җилем басма газит нәшер ителә. Аны чыгарышуда Ф. Әмирхан да катнаша. Газит шулай ук иске мәдрәсәләрдәге тәртипләрне камчылауга зур әһәмият бирә. Аның битләрендә сатира үзенең иң югары ноктасына җитә. 1903 елның көзендә Казанда М. Алмаев, Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов җитәкчелегендә "Җөмһүрият" исемле җилем басма газит эшчәнлек җәелдерә. Шәкерт Ф. Әмирхан бу басманың эшлекле хезмәткәре хисаплана. "Җөмһүрият" газите исә, замандашларының истәлекләренә караганда, социаль-

демократик "Урал" газитен чыгаруда хәзерлек этабын үти. Шуна күрә 1905-1906 елларда Әмирханнар йорт-каралтыларында РСДРПның Казан комитеты типографиясе кирәк-ярақларының вакытлыча сакланып торуын гайре табигый хәл дип булмый. Тагын шунысы да мәгълүм, полиция эзәрлекләүләреннән качып, Фатихлар йорты тирәсенә РСДРПның Казан комитеты күчмә китапханәсе килеп чыккалаган. Күренә ки, Ф. Әмирханның рәсми көндәлек матбугатта басылган беренче әсәре очраклы хәл түгел. Ә ул әсәр "1871 ел Коммунасы" дип атала һәм 1906 елда Уральскидагы "Әлгасрел-җәдид" ("Яна гасыр") журналында дөнья күрә.

Гасыр башларында социаль-демократларның йогынтысы астында булган, алар белән элемтәдә эшләгән Ф. Әмирханның "Иттихад" җәмгыятенең варисы—яшерен "Әл-Ислах" ("Реформа") укучы яшьләр комитетын җитәкләве хакында да әйтми китеп булмый. 1904 елның 20 февралендә Фатих мәдрәсәдәш дусты Р. Алушига язган хатында болай ди: "Хәзердә бөтен мәдрәсә шәкертләреннән мөрәккәб (торган) бер җәмгыять тәшкил ителде. Хәзердә 75 кадәр әгъзасы бардыр. (Яшерен тотылсын)". Бу 1905 елның көзендә тулаем формалашып җиткән мәшһүр "Әл-Ислах" комитетының беренче үрнәге булырга кирәк. Социал-демократлар комитетка һәм аның әгъзаларына зур йогынты ясый. Шәкертләр шәһәрнең татар ягында прокламацияләр ябыштыра, ә студент-революционерлар аларны бушлай урысча укыта. Шуны да искәртеп китик, 1904 елның җәендә үк инде Фатих, энесе Ибраһим белән берлектә, Самарага барып урысчадан дәресләр ала. Студентлар арасында Ф. Әмирханга урыс теле дәресләре биргән социал-демократ С. Н. Гассар да була. Гассар җитәкчелегендә "Әл-Ислах" җитәкчесе революцион прокламацияләр басуда һәм таратуда катнаша.

1905 елның ноябрендә РСДРПның Казан комитеты "Шәкертләргә" дигән татарча прокламация бастыра. Ул укучы яшьләрне, революция байрагы астына тупланып, иске тормышка каршы бердәм көрәшкә кушылырга өнди. Шул көннәрдә, төгәлрәге, 29 ноябрьдә, Ф. Әмирхан җитәкләгән "Әл-Ислах" комитеты шул ук исемдә җилем басма газит чыгара башлый. Казан социал-демократлары нәшер иткән прокламация (ә бу эшне мәдрәсә шәкертләре башкара) белән "Әл-Ислах" газитенең дөньяга килүе арасында бәйләнеш булуы бәхәссез. Әлеге яшерен басма күтәргән төп тема—шәкертләрнең таркау көчләрен гомуми азатлык өчен көрәшкә туплау, мәгариф эшенең барлык өлкәләрендә дә прогресска, дөньявилыкка йөз тоту була.



*«Әль-Ислах»чылар. Сулдан уңга: редактор Вафа Бәхтияров, тәнкыйтьче Кәбир Бәкер, Фатих Әмирхан, редакция хезмәткәре Ибраһим Әмирхан һәм Габдулла Тукай. 1908 ел.*

Беренче революция шартларында татар халкының милли-азатлык хәрәкәте көчәя, үзбилгеләнү идеясе яңа сулыш ала. 1906 елның 15-23 гыйнварында ил башкаласы Санкт-Петербургта Русия мөселманнарының II ярым яшерен съезды җыела. Казанның мең ярым шәкерте арасыннан бу съездга вәкил итеп 20 яшьлек Фатих җибәрелә. Әтисенең энесе Мөхәммәднәҗип хәзрәт Әмирхан да төшкән күмәк фотода Ф. Әмирхан яшьтәшләре белән иң алдагы рәтне "хасил итә". "Әл-Ислах" җитәкчесе съездда төпле чыгышлар ясый, игътибарны милләттәге сыйнфый каршылыкларга, мәгариф эшенә мулрак чыгымнар тоту, шәкертләргә ярдәм итү тиешлегенә юнәлтә. Сәләтле шәкертне күреп алалар, "милләт аталары" татар яшьләренең шул дәрәҗәгә җитүенә куана, Исмәгыйль бәк Гаспралы үзе, егетнең артык "радикальлеген", кискенлеген тәнкыйть иткән хәлдә, Ф. Әмирханга зур өметләр баглавын белдерә.

Илдә гомумдемократик хәрәкәтнең кызган чорында, ягъни 1906 елның февраль-март айларында, Казан шәкертләре "Әл-Ислах" житәкчелеге астында гомуми забастовка ясый. Дәрес ташлауларда мең ярым чамасы шәкерт катнаша (Казанның барлык мәдрәсә шәкертләре диярлек). Забастовка көрәше Русиянең татарлар яшәгән башка төбәкләрендә дә яңгыраш таба. Ф. Әмирхан да вакыйгаларның үзәгендә кайный, мәдрәсәләрне ташлап чыккан шәкертләргә матди һәм рухи ярдәм оештыручыларның берсе була.

Инкыйлаб хәрәкәтенә торган саен ныграк тартыла барган Фатихның эшчәнлегенә, күрәсең, полиция дә игътибар итә башлагандыр. Аның баш өстендә дә шомлы болытлар куера, чөнки даирәсендәге шәхесләрнең байтагы кулга алына. Үзенең бу хактагы шөбһәләнүләре турында ул дусты Р. Алушига 1906 елның 6 мартында болай дип яза: "Йосыф Акчуринны арестовать иттеләр, хәлфәм Гассарны арестовать иттеләр, бәлки, үземне дә ошбу көннәрдә итәрләр..." [1]

"Әл-Ислах" эшчәнлегенең әһәмиятле этапларыннан берсе—аның 1906 һәм 1907 еллардан Казанда татар шәкертләренең ике яшерен бөтенрусия съездын үткәрүе. Аларның карарлары татар укучы яшьләре тормышында әһәмиятле вакыйгага әверелә. Съездларның эше белән аларның программаларын төзегән һәм эшчәнлегенә юнәлеш биргән Ф. Әмирхан житәкчелек итә.

Татар милли театрының нигез ташларын салышуда да Ф. Әмирханның роле зур. Билгеле булганча, сәхнә сәнгате реакцион көчләр тарафыннан аяусыз эзәрлекләнә һәм 1906 елның азагына чаклы рәсми төстә яшәү хокукыннан мәхрүм була. Әмма милли театрны гамәлгә кую өчен көрәш XIX йөзнең соңгы чирегендә үк башлана һәм XX гасыр башында аеруча зур колач ала. 1903 елның ахырларында Казанда укучы яшьләрнең "Шимбә" исемле түгәрәге төзелә. Татар шәкертләреннән тыш аңа башкорт, казакъ яшьләре йөри. Түгәрәкнең максаты, яшь көчләрне берләштерүдән тыш, шәрык, башлыча татар әдәбиятын өйрәнү була. "Шимбә" әгъзалары арасында Х. Ямашев, М. Вахитов һ. б. белән берлектә аеруча активлыгы белән Ф. Әмирхан да аерылып тора. Түгәрәктә татарча спектакльләр кую мәсьәләсе дә күтәрелә, нәтижә буларак, өй спектакльләре оештыру эшләре башланып китә. Бу эштә Ф. Әмирханның да катнашуы белән иң беренчеләрдән булып "Мөхәммәдия" шәкертләре уңыш казанган. 1903 елның декабрендә "Мөхәммәдия"дә Г. Камалның "Бәхетсез егет"е сәхнәләштерелә. Ф. Әмирхан—уенда гримлаучы һәм суфлер, беркадәр режиссерлык вазифасын да үти.

Спектакль сыйфатындагы "фетнә"не оештыручыларның берсе буларак, Фатих мәдрәсә житәкчелегенә чакырыла һәм аннан каты кисәтү ала. Әйтергә кирәк, шушы рәвештә мәдрәсә тәртипләрен "бозган" өчен өлкән сыйныф шәкертен еш кына "Сахалин" дигән символик исем белән йөртелгән, ягылмый торган изоляторга да урнаштыралар, кайвакытларда ул гомумән шунда яши. Ләкин тыю һәм эзәрлекләүләргә карамастан, югарыда телгә алынган пьеса мәдрәсәдә янадан, 1904 елның апрелендә куела. Көчләрен һәм хәзерлекләрен сизеп алган Ф. Әмирхан вә иптәшләре кайбер кунакханә номерларында (әйтик, "Сарай"да), хосусый өйләрдә дә репетицияләр үткәрә, спектакльләр уйный. "Бәхетсез егет"тән башка Г. Ильясиның "Бичара кыз", Ф. Халидинең "Рәдде бичара кыз" дигән әсәрләре сәхнәләштерелә. Татар кызлары сәхнәгә әле менәргә жөрьәт итмәгәнлектән, спектакльләрдә һәм ир-ат, һәм хатын-кыз рольләрен шәкертләр үзләре генә башкара. Ф. Әмирхан үзе дә тиздән спектакльләрдә жаваплы рольләрдә уйный башлый. Мәсәлән, прогрессив төрек драматургы Нәмикъ Кәмалның "Кызганыч бала" әсәрендә ул Хәлил, ә "Гыйшык бәласе"ндә Габдессамат рольләрен башкара.

Ул вакытларда татар алдынгы яшьләре өчен үзенә күрә салон сыйфатын үтәгән Габитовлар, Терегуловлар өйләрендә Ф. Әмирхан, Г. Мостафин, С. Рахманколый, К. Коләхметов, апалы-сенелле Коләхметовалар, Габитова, Терегуловалар катнашында татар телендә 1906 елга кадәр язылган барлык драма әсәрләре дә диярлек сәхнәгә куела. Фатих һәм иптәшләре Казан клубларының берсендә рәсми спектакль кую турында хыяллана. Рөхсәт сорап губерна администрациясе бусагасын таптаулар башлана. Үз дигәнендә нык торучан, эшлекле, сәхнә сәнгатенең татар халкы өчен гаять зур әһәмиятен аңлаган Ф. Әмирхан биредә дә башлап йөрүчеләрнең берсе була.

Ниһаять, 1906 елның 5 маенда Казанның Приказчиклар клубында булачак әдип катнашында "Кызганыч бала" һәм "Гыйшык бәласе" спектакльләре уйнала. Бу татар мәдәни тормышында күренекле вакыйга була, татар гына түгел, урыс матбугаты тарафыннан да хуплап каршы алына. Һәвәскәр артистлар, татар халкының үз милли театры турындагы хыялын тормышка ашырып, төрле клубларда тагын берничә спектакль уйный. Әлеге уеннар, һәм бигрәк тә 5 майда куелган спектакльләр, 1906 елның 22 декабрендә уйналган әсәрләрнең генераль репетициясе ролен үти. Ә декабрь спектакльләре исә—тарих сәхифәсенә татар милли театрының туу акты буларак теркәлә.

Ф. Әмирхан яшь чагыннан ук укытучы-педагог та булган икән әле. Әйтик, аның әнисе мәктәбендә 1901-1902 елларда география, "Әмирхания" мәдрәсәсендә кызларга урыс теле укытуы мәгълүм. Шунысы кызык, урыс теле дәресләрен ул факультатив рәвешендә, анда да пәрдә артына яшеренеп алып барган. [2] Бик тере, аралашучан, актив шәкерт "Мөхәммәдия"дә күп яктан калку фигура була. Ул тарих, география, астрономия һ. б. фәннәр буенча бик күп әдәбият укый, төрле темаларга рәхәтләнеп диспутлар оештыра һәм бу бәхәсләрдә иптәшләреннән генә түгел, еш кына тәҗрибәле хәлфәләрдән дә өстен чыга. Фатихны яшьтәшләре генә түгел, өлкәнрәк иптәшләре дә үз итә. Өлкән классларда укыган чорда ул кече сыйныфларда география дәресләре алып бара. Аның дәресләре балаларда зур кызыксыну уята. Ф. Әмирханның география һәм астрономия белән кызыксынуы берникадәр вакыттан соң ул чыгарышкан "Тәрбияи-әтфаль" ("Балалар тәрбиясе") журналында мәкаләләр циклы буларак чагылыш таба.

Кинкырлы талант иясе, Ф. Әмирхан—татар вакытлы матбугатын оештыручыларның, юлга салучыларның берсе дә. Алда инде без аның кулъязма яки җилем басма гәзитләрне чыгарудагы роленә беркадәр тукталган идек. 1906 елның ахырында ул татарча беренче балалар журналы "Тәрбияи-әтфаль"не оештыру һәм анда сәркятиблек вазифасын үтәү өчен Мәскәүгә чакырыла. Журнал 1907 елның гыйнварыннан чыга башлый (биш саны дөнья күрә). Шушы басманың җаваплы секретаре буларак, Ф. Әмирхан журналны нәфис, мавыктыргыч итүгә зур көч куя, аны балалар тормышында тантаналы бер вакыйга итәргә омтыла.

"Тәрбияи-әтфаль" 1907 елның апрелендә чыгудан тукталгач, яшь журналист яңадан Казанга кайта. Җәйне ял итеп, үзенең элекке иптәшләре, "ислахчылар" белән бергә көздән рәсми "Әл-Ислах" гәзитен чыгарырга карар бирә. Шул арада басманы гамәлгә кую турында рөхсәт тә алына. Ләкин 1907 елның 15 августында Ф. Әмирхан зур фаҗигага тап була: көтмәгәндә аны паралич суга. Ике аягы йөрмәс, ике кулы хәрәкәтләнмәс, бер күзе күрмәс була 21 яшьлек егетнең. Бик тиз тотып дәвалау аркасында куллары һәм күзе элекке халәткә кайта, әмма аяклары бөтен гомергә параличлы булып кала. Аларга бернинди им-том, дәва ярдәм итми.

Көчле ихтыярлы, милләтенә хезмәт итү дәрте белән янган, демократик идеалларга тугрылык саклаган Фатихны бу бәхетсезлек сындыра алмый. 1907 елның 25 ноябрендә дусты Р. Алушига клиникадан язган хаты менә нык дәлил. Менә ул хаттан кайбер юллар: "Авторның берникадәр файдасы да булды: өч ай эчендә күп нәрсә укып чыктым вә "Әл-Ислах" газетасында сәркятиблек хезмәте иттем һәм хәзер дә итәм. "Әл-Ислах" сезгә барып ирешкән булса, баш мәкаләләр вә "Дамелла" имзалы мәкаләләрне аяксыз дустым Фатих кулы белән язылган дип укырсың! Вә шуларга карап авыруның миңа рухани тәэсире булганмы-юкмы икәнене белерсең. Әүвәлге номерда "Казан шәкертләре" имзасы белән язылган "Печән базары татарларына ачык хат" та авыруымның куәтле вә көчкә-көчкә генә утырып тора алган вакытымда минем кулым белән тәртип ителмештер". [3]

Авыруны яшерә белүе, төшенкелеккә бирелмәве өстенә Фатих җөр сүзгә, мәзәккә бик оста шәхес була, аның хәлен белергә килгән дуслары аяксыз әдипне юатасы урынга, ул аларның боек күңелләрен үзе күтәрә, сызлаган калебләренә оптимизм орлыгы салып җибәрә.

1907 елның 3 октябреннән чыга башлаган "Әл-Ислах" гәзите әдипнең үзе үк гамәлгә куешкан рәсми басмаларның икенчесе. Ул аның фактик мөхәррире дә, рухи яктан җитәкчесе дә. Ф. Әмирханның ялкынлы публицист буларак таланты

шушы гәзит битләрендә чәчәк ата (1907-1909). Биредә ул татар тәнкыйть жанрына нигез салучыларның беренчеләреннән була, дистәләгән рецензияләр бастыра, тирән эчтәлекле публицистик әсәрләре белән татар әдәбиятының чәчмә фондын баета. Нәкъ менә шушы гәзит тирәсендә аның Г. Тукай белән дуслыгы һәм хезмәттәшлеге ныклы нигезгә салына. Шуңа күрә дә бөек шагыйрьгә күп яктан шифалы йогынты ясаган әдипне заманында Х. Туфан образлы рәвештә "Тукайның Фурмановы" дип атаган иде. [4]

Шул ук чорларда Ф. Әмирхан Г. Тукай, Г. Камал һәм башкалар белән берлектә "Яшен", "Ялт-йолт" кебек үткен сатира журналларын гамәлгә кую, юлга салуда төп рольләрнең берсен уйный.

1909-1915 елларда Ф. Әмирхан проза әсәрләренең гүзәл үрнәкләрен биреп, "Татар кызы", "Танымаганлыктан таныштык", "Фәтхулла хәзрәт", "Рәхәт көн", "Хәят", "Кадерле минутлар", "Бер хәрабәдә...", "Урталыкта", "Габделбасыйр гыйшкы" һәм башка әсәрләрен иҗат итә. Әдип бу хезмәтләре белән татар әдәбиятында реалистик стильне үстерүгә, аны формалаштыруга зур өлеш кертә. Әлеге әсәрләргә характерларның җанлылыгы, үзенчәлеге, теленең сәнгатьле, милли төсмерле булуы хас.

Ф. Әмирхан мәгълүм күләмдә татар театры репертуарын билгеләгән драматург та. Аның образларының камиллеге, психологиясенең нечкәлеге белән сугарылган "Яшьләр" (1909), "Тигезсезләр" (1914) кебек драмалары инкыйлабкача чорда милли сәхнәдән төшми. 1922 елда, инде совет чорында, ул шул исемдәге мәшһүр проза әсәре нигезендә "Фәтхулла хәзрәт" комедиясен иҗат итә. Әсәр тамашачылар алдында уңыш казана.

Әдипнең "Аң" журналы (1912-1918) битләрендә басылган әдәби әсәрләре, тулаем алганда, иҗатының сыйфат ягыннан тагын да үсү, камилләшү үрнәкләре булып тора. Җаваплы сәркятиб һәм публицист буларак, ул "Кояш" гәзитендә актив эшли, аның демократик тәрәккыятне кыйбла иткән, милләт мәнфәгатьләрен алга сөргән юнәлешен билгеләүдә төп рольләрнең берсен уйный, башка матбугат органнарында да даими басылып килә. Гомумән, "Кояш" гәзитен, "Әл-Ислах" белән берлектә кыю рәвештә әдипнең публицистик, өлешчә сәнгать әсәрләренең антологиясе дип атарга мөмкин.

Замандашларының истәлекләренә караганда, 1913 еллардан башлап Ф. Әмирхан Казанның милли-мәдәни тормышында төп фигурага әйләнә, хәтта башкалар Г. Исхакыйга мөкиббән киткән вакытта, ул аңа да, "вакыт"чыларга да баш ими, "Кояш" тирәсендә Ибраһим Биккулов, Заһит Нуркин, Фәхрелислам Агиев, Шиһаб Әхмәров кебек язучыларны, журналистларны үз тирәсенә туплап, бер үзәк оештыра. М. Гали сүзләре белән әйтсәк, "гәрчә гаязчыларга үзен каршы куймаса да, бу чорда инде ул, Тукай үлгәннән соң, галимҗанчылар тарафыннан үзенә бирелгән "Казан короле" дигән исемне чын-чынлап тормышка ашырырга тырыша башлый". [5]

Ләкин Фатих өлкән замандашы, күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Исхакыйны хөрмәт итмәгән икән, дип уйларга ярамый. Әмирхан гомеренең азагына кадәр каләмдәшенең иҗатын бик югары бәяли, эшчәнлеген башкаларга үрнәк итеп куя. Моны без бик күп мисаллардан күрәбез. Әйтик, Ф. Әмирхан журналистлык эшчәнлегенең таңында ук Мәскәүдә чыккан беренче балалар журналында Исхакыйның эшчәнлегенә багышлап, "Гаяз" исемле мәкалә белән чыгыш ясый. [6] Үзе җитәкләгән "Әл-Ислах" гәзите битләрендә Фатих күренекле әдипнең "Алдым-бирдем" драмасына һәм "Солдат" повестена рецензияләрен бастыра. [7] Соңрак Әмирхан Исхакыйның "Мөгаллим" дигән драмасы буенча куелган спектакльгә бәя бирә. [8] "Фәрештәләр юатсыннар сине!" дигән мәкалә исә Исхакыйның "Ике йөз елдан соң инкыйраз" әсәренең төп каһарманы Җәгъфәрнең рухи фаҗигасен ачуга багышланган. [9] Бу бәяләмәләрендә Фатих каләмдәшен олуг әдип буларак тәкъдир итә, аны "зур мөхәррир", "зур талант" дип атый.

1916—1917 елларда Әмирханның Исхакый иҗатына, шәхесенә биргән бәяләре тагын да калкурак, җетерәк төс ала. Фатих Һади Максуди белән Гаяз Исхакый арасындагы иҗтимагый-фәлсәфи бәхәс буенча да үз сүзен кистереп әйтә, бу хакта аның "Йолдыз" һәм Гаяз Исхаков" исемле мәкаләсе аеруча бер урын алып тора. [10]

Әмирхан, Гаязның шәхесенә, эшчәнлегенә теләктәшлек белдереп, аны "сүнә белми торган бер ялкын" дип атый, бу шәхесне милләт өчен үтә зарур бер зат итеп күз алдына китерә: "Гаяз—шарлатан", ди Һади әфәнде. Әгәр шарлатан дигән сүз Гаяз шикелле кешеләр тибына әйтелә торган булса, мин Алладан сорыйм, милләт әфрады (милләттәшләр) арасында шарлатаннар күбрәк булсыннар. [11]

"Ут күршесе" Сафия апа Локманованың искә алуы буенча, егерменче еллар уртасында да Әмирхан үзенең иң хөрмәт иткән әдипләре арасында беренче итеп Исхакыйны атый торган була.

Алда искә алынган очракта, Исхакыйны никадәр генә ихтирам итсә дә, үтә горур Ф. Әмирханның беркем алдында да бил бөгәргә теләмәве хакында гына бара. Ике олпат әдипнең хат алышулары да мәгълүм.

Милли хәятнең, тәрәккыят хәрәкәтенең үзәгендә кайнаган әдипнең тынгысыз эшчәнлеге, әлбәттә, хакимият, көнчеләр, шымчылар тарафыннан игътибарсыз калмый. Аның өстеннән хөкүмәтнең төрле даирәләренә язылган әләкләрнең саны хәтсез. Шуларның берсендә: "Ультранационалисты" во главе с Фатыхом Амирхановым и другими известными лицами устраивали "меджлисы", икенчесендә Ф. Әмирханны һәм ике фикердәшен: "среди татарской молодежи особо влиятельными являются" дип искәрткән сүзләр бар. Иң кәттә әләк хәтта С.—Петербургтагы Полиция департаментына кадәр барып җитә. Департамент таләбе буенча Казан губернаторы 1912 елның 13 ноябрендә полицмейстерга мондый күрсәтмә юллый: "По полученным мною сведениям, сбором пожертвований в пользу Турецкого Красного полумесяца занимается в Казани Фатих Амирханов, которым уже собрано этих пожертвований до 200 руб..." [12]



*Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан. 1908 ел.*

Әдип өендә кичекмәстән тентү ясарга боерыла. Ләкин Төркия кызыл аена дип җыелган акча табылмый. Ф. Әмирханның кесәсеннән гонорар сыйфатында Ә.-Г. Хәсәнидән алынган 60 тәнкә акча гына килеп чыга.

Әдип Төркия кызыл ае файдасына акча җыюда катнашканмы, юкмы? Бу хакта кистереп әйтүе кыен. Мөгаен, әлеге ыгы-зыгы шәхси дошманнарының чираттагы провокациясе белән бәйле бер гамәл булгандыр. Аннары мөселман кардәшләренә симпатиясен яшермәгән Әмирханның бу эштә катнашуы хак булган тәкъдирдә дә, аның үзен гаепләүче язуларны өендә саклавы бик сәер булыр иде. Заманының бөтен эзәрлекләү механизмын үзендә тоемлап-татып торган әдипнең башына тай типмәгән ләбаса!

Ф. Әмирханның карашлары, татар җәмгыятендә, аерым алганда, милли матбугатта тоткан урыны белән аеруча Казан губерна жандарм идарәсе (КГЖУ) кызыксына, бу хакта зурдан кубып язышулар оештыра. Мәсәлән, жандарм идарәсе башлыгы губернаторга болай дип хәбәр итә: "Пользуется влиянием среди мусульман и составляет центр, вокруг которого группируется местная молодежь... Помимо этого, являясь лишь секретарем газеты "Кояш", он оказывает большое влияние на ее направление". [13] Шул уңайдан жандармерия "Кояш"ның Русия-Төркия мөнәсәбәтләренә карашын тәнкыйтьли һәм газетнең хөкүмәт сәясәтенә лояль булмаган юнәлешен Ф. Әмирхан йогынтысында күрә. Әлбәттә, әдип 1912 еллардан башлап, һәм бигрәк тә 1914 елдан соң, "мода"да булган дежур "җинаять"ләрдә, ягъни панисламизмда һәм пантюркизмда бик тырышып гаепләнә. Полициянең даими күзәтүе астында торган Ф. Әмирхан КГЖУ белешмәләрендә "убежденный панисламист-пантюркист" [14], "несомненный панисламист" [15] дигән бәяләмәләр белән йөри.

Күрәсең, Ф. Әмирханның мондый яки шуңа охшаш карашлары хакында охранкага түкми-чәчми әдипнең үз даирәсендәге "дуслары" хәбәр итеп торган. Шуның ише "ахирәт"ләргә һичкайчан кытлык булмавы—татар иҗтимагый тормышының бик аяныч вә чирканыч бер күренешедер.

Тынчу сәяси шартларда һәр адымы һәм эшчәнлеге даими күзәтү астында торса да, Ф. Әмирхан бик актив иҗтимагый-мәдәни тормыш алып бара, Казандагы бер генә прогрессив милли башлангыч та аның катнашыннан башка узмый диярлек. Әйтик, унынчы еллар дәвамында ул татар кызлары өчен махсус гимназия ачу юлында зур тырышлык күрсәтә, Фатиха Аитова мәктәбе, Ләбибә Хөсәенова гимназиясен гамәлгә куюда байтак эшләр башкара, яшь зыялыларны, алдынгы карашлы егет-кызларны үз тирәсенә туплый, "яшьләр колагына бер сүз" әйтүләрдән туктамый.

Ф. Әмирхан проза һәм драматургия остасы гына түгел, бәлки үз заманының актуаль вакыйгаларына карата шәхси мөнәсәбәтен даими белдереп барган киң диапазонлы, эрудицияле җәмәгать эшлеклесе, каләм остасы да. Ул Октябрь түнтәрешенә кадәр үк татар мәдәниятенең (әдәбият, сәнгать, мәгариф, тарих фәне, тел һ. б.) үсешен тирән кызыксыну белән күзәтеп килгән, аңа гуманистик караштан чыгып әледән-әле юнәлеш биреп торган зур тәнкыйтьче, җәмәгать хадиме, телче, педагог булып та таныла...

Ул чорның күп кенә алдынгы эшлеклеләре кебек үк, әдип тә Февраль революциясен шатланып каршы ала. Самодержавие гыйфритен мәтәлдерүне ул "Богаулар өзелделәр" ("Аң") дигән мәкаләсе белән тәбрик итә. Биредә Ф. Әмирхан царизмның мөселман халыкларына, шул исәптән төрки-татарларга карата үткәрелгән реакцион сәясәтен кискен тәнкыйтьли. Русия җәмгыятенең демократик, гуманистик юнәлештә үсешенә өмет баглап, ул милли мәсьәләнең дә гадел чишелүен көтә. Әмма аның өметләре Вакытлы хөкүмәт чорында да акланмый. Ә инде хакимияткә большевикларның килүе, аларның бөтен халык сайлаган Учредительное собраниене куып таратуы, ирекле матбугатка карата үткәрелгән берсеннән берсе котсыз чаралар һ. б. язучының тәмам гайрәтен чигерә. Бу "чаралар"га каршы үзенчәлекле протест авазы булып аның "Ирекле матбугатны буарга теләүчеләр" мәкаләсе тора. Яңа хакимияткә карата үзенең карашын ул әлегәчә тулысынча басылмаган көндәлекләрендә (1921-1926) ачты. Бу язмалар системаны фаш итү һәм якынлашып килүче тираниядән кисәтүләре белән Ю. Фучикның "Элмәк муенда килеш репортаж" һәм М. Җәлилнең "Моабит дәфтәрләре"н хәтерләтә. Менә шундый хисләр чолганышында ул үзенең туганнан туган сеңлесе Зәйнәпкә язган хатында мондый юллар терки: "Ярый әле әти белән Нәҗип абый (әтисенең энесе—Р. Ә.) үз үлемнәре белән үлеп калды". Шушы ук сүзләрне әдипнең үзе турында да әйтергә ярыйдыр. 35-36 яшьләрендә инде аның иҗаты бернинди ташламаларны белмәгән "вульгар социологизм" дөмбесе белән дөмбәсләнә башлый.

Бер-ике мисал. 1923 елның 16 июлендә Ф. Әмирхан, алдан килешенү буенча Татарстан китап комбинатына "Беренче сөю", "Мәет озатканнан соң", "Чәчәкләр китерегез мина!" исемле әсәрләренең кульязмасын тапшыра. Ләкин кульязмалар Г. Толымбайскийның тискәре рецензиясе нәтиҗәсендә авторга кире кайтарыла. Әдипнең әлеге әсәрләрендә "дини фикер белән кочаклашу, мистицизм тойгылары" табып, Толымбайский, "хәзерге көндә боларны басып тарату сәяси җинаять булачак", дип белдерә. Һәм бу фикер ачык матбугатка чыгарыла. [16]

1925 елда Х. Вәли дигән берәү "Безнең юл" журналында болай дип язып чыга: "Фатих Әмирхан буржуазный язучы булу гына түгел, яңа буржуаның тормышы, идеологиясен кристаллаштырырга тырышучы буларак мәйданга атыла. ...Фатих Әмирхан кадәр сәнгатьне буржуазный тенденциячелек өчен корбан иткән һичбер татар язучысы юктыр". [17]

Бүтән елдам адәмнәр дә, "сыйнфый уяулык" күрсәткән булып, ягъни үз тиреләрен саклап, "теге дәвер" вәкиленә каршы кискен һөҗүмгә күчә. Бу өлкәдә Г. Толымбайскийдан кала, текә үрләрне Г. Гали, Г. Нигъмәти, Ф. Сәйфи-Казанлы һ. б. "яулый". Г. Ибраһимов исә, әдипнең йөзенә бәреп, "син—контрреволюционер!" дип нәгърә ора... Мондый тукмаклаулар инвалид әдипнең гомерен озайткандыр дип булмый.

Нәтиҗә буларак, әдип әсәрләре янадан басылмый, татар театры репертуарыннан пьесалары чыгарып ташлана, матбугат идарәләре ана аркан борыла. Ә бит Ф. Әмирхан әле 1920 елда гына "Чәчәкләр китерегез миңа!" дип шагыйрәнә күңел самимилеге белән җырлый. Ә ана чәчәкләр алып киләсе урынга шайтан таягының саргайган көлтәсен ыргыталар. Бер тизләнеш алгач, язучыдан "карачкы" ясау зарури бер йола төсен ала һәм, төрле фасылларга кереп, бер көчәеп, бер чигенеп, 50 нче елларның азагынача дәвам итә...

Әмма эшлекле һәм актив шәхес буларак, Ф. Әмирхан җебеп төшми, үзенең хәятен иҗат эшеннән башка күз алдына китерә алмый. Совет матбугаты үзенең сыйнфый-идеологик асылы белән язучының дөньяны танып белү системасына нигездә кырын карап килсә дә, ул (күпчелек очракта ихтыяри-мәҗбүри рәвештә) кайбер газит-журналларда ("Кызыл Армия", "Татарстан", "Татарстан хәбәрләре", "Безнең юл", "Шәрык кызы", "Сөембикә") язышa, рөхсәт ителгән, рәсми инкяр ителеп бетмәгән тәгълиматлар кысасында укучыга милләтнең теле, менталитеты, бөтенлеге һәм үзенчәлеге саклануын шарт итеп, аның рухи һәм мәдәни кыйммәтләре турында каләм тибрәтергә, проблемаларын бәян итәргә тырыша.

Әмирхан әдип, публицист, җәмәгать эшлеклесе буларак гамәл кылырга омтылып, Татар театр техникумында әдәбият дәресләре алып бара (1923-1924), Татнаркомпрос системасында лекцияләр укый, конференция һәм кичәләрдә чыгышлар ясый, тәрҗемә эше белән шөгыльләнә, татар мәдәниятенең төрле өлкәләрендә хезмәт иткән эшлеклеләр белән тыгыз элемтә урнаштыра, әдәбиятта, чыгышларында, дәресләрендә армый-талмый дусты һәм каләмдәше, "рухани игезәге" Тукай мирасын пропагандалый. Аның беренче татар операсы "Сания"нең мәйданга чыгуында да өлеше бар, әдип операның комиссиясен җитәкли.

Ф. Әмирханның тәгәрмәчле арбага береккән килеш 20 еллар дәвамында кылган фидакяр хезмәтен иҗади каһарманлык дими, ни дисең?!

Егерме елга якын аягына баса алмыйча, һаман утырып торган кешенең организмы таза була алмавы, әлбәттә, табигый. Җитмәсә, тормыш, "дуслар" да башыннан сыйпамый. Ул үз гомерендә берничә мәртәбә нык-нык авырып ала, савыга, ләкин 1925 елның башларына таба шактый бетерешә. Анда үпкә туберкулезы галәмәтләре күренә башлый. Бөтен җәй-көз Кырымдагы "Гастрия" шифаханәсендә дәваланып, бераз көрәйсә дә, авыру арка сөягенә күчеп, әдип инде утырып тора алмаслык хәлгә килә. Көчле ихтыярлы, оптимист табигатьле Әмирхан әле 1926 елның 16 гыйнварында да, хәле начар булуга карамастан, "Сания" операсын тыңларга бара.

Бәхетсезлеккә каршы, 1926 елның февраль урталарында Ф. Әмирханга нык суык тиеп, температурасы күтәрелеп китә. Бу халәт көчле үпкә ялкынсынуына күчә, тора-бара монысына тагын да хәтәррәк эчәк һәм карын шешү авыруы килеп өстәлә. Тузып-таушалып беткән организм бу зәхмәтне инде җиңә алмый. Татар халкының классик язучысы, милләт вөҗданы Фатих Әмирханның күзләре 9 мартта мәңгегә йомыла.

Татарның бөек әдибенең, "соңгы могикан"ының вафаты, җеназасы киң яңгыраш ала. Җөмһүриятнең татарча үзәк басмасы "Кызыл Татарстан" газите бу югалтуга үзенең өч санын (NN 58, 59, 60—11, 12, 14 март) багышлый. "Красная Татария" дә кайгы белдерүләрдән читтә калмый, мәкаләләр урнаштыра.

Татар җәмәгатьчелеге әдипне җирләү мәсьәләсендә ике тарафка бүленә. Татарстан матбугат эшчеләре оешмасы, Гыйльми үзәк, "Гажур", Дәүләт нәшрияты гражданнарча, ягъни җеназа укымыйча күмүне алга сөрә. Хушлашу урыны итеп Театр мәйданы тәгаен кылына. Икенче тараф, башлыча гайре рәсми оешмалар, Ф. Әмирханның туганнары, якын дуслары әдипнең гәүдәсен җеназа укып җиргә индерүне өстен күрә һәм бу гамәл өчен татар ягындагы Вахитов (элек һәм хәзер Юнысов мәйданы) сайлый. Ике якның да ниятләре аталган мәйданнарда тормышка ашырыла. Рәсми матәм митингысын Татар дәүләт академия театрының директоры Ф. Бурнаш ача. Ул "Фатих Әмирхан татар халкы өчен бик кадерле булган бөек язучы һәм оста художник иде..." дигән сүзләр әйтә. Шуннан соң әдипнең якын дусты, журналист И. Биккулов, Татарстан мәгариф халык комиссары Н. Мөхетдинов, Сәламәтлек халык комиссары Ф. Мөхәммәдьяров, Гыйльми үзәк рәисе урынбасары

М. Корбангалиев, татар артистларыннан К. Тинчурин һ. б. сөйли, жылы, тирән мәгънәле хушлашу сүзләре әйтә. Театр мәйданына жыелган халыкнын саны ике менгә якынлаша.

Вахитов мәйданында сүз алып нигездә әдипнең бергә укыган иптәшләре, дуслары, Фатихның жизнәсе Габдулла мулла гына сөйли. Митинг тәмамлангач, бөтен шартын туры китереп, женаза укыла. Әмма халыкнын байтак өлеше женаза укыла башлагач та төрлесе төрле якка таралып бетә. "Сугышчан алласызлык" пропагандасы белән мингерәүләнгән кешеләрнең динле-иманлы, мөселман булып күренәселәре килми.

Шунысын искәртү мөһим: 1926 ел шартларында рәсми идеология кысаларында "иске заман" кешесе дип хисапланса да, чын интеллигент-зыялылар каршында Ф. Әмирханнын абруе, шәхси "имиджы" бик зур була. Шуна күрә дә үлгән көнне мәрхүмнең маскасы алына, өйдән чыгарганда, һәр ике мәйданда, юлда барганда, кабергә төшергәндә женаза фотога һәм кино тасмасына төшерелә.

Замандашы Жамал Вәлиди әдипкә вафатыннан соң ук мондыйрак бәя биргән иде: "Ф. Әмирхан—татар әдәбияты тарихында гына түгел, бөтен татар ижтимагый тарихында ин күренекле урын тоткан, вакыт буенча кечкенә, ләкин әһәмияте буенча чиксез булган бер буынның үзәгендә торган кеше. Ул бу буынны мәдрәсә дигән өйдән алып чыгучы, татар әдәбияты күгендә беренче очу тәжрибәләрен ясаучы иде... Бүген безнең арабыздан югалган Ф. Әмирханыбызны мин, рөхсәт итсәгез, мәшһүр немец шагыйрь Генрих Гейне белән янәшә куяр идем... Ф. Әмирханның әле гәүдәсе дә арабыздан китеп өлгермәгән. Аның әдәбият тарихындагы чын урынын тагын да дөресрәк итеп заман күрсәтер".[18]

Бәхетебезгә күрә, әдип ижатын бәяләү мәсьәләсендә хәзерге заман 1920—50 еллардан күпкә аерыла. Фатих Әмирханның көпчәкне арбага береккән килеш кылган рухи азаматлыгы ихлас тәкъдир ителеп кенә калмый, бәлки ана күп җәһәтләрдән мәдхия жырлана.

**Равил ӘМИРХАН,**

*тарих фәннәре докторы.*

## Искәрмәләр


1. Тәһси (ИЯЛИ) Фәнни архивы, 16-ф., 3-тасв., 1-эш.
2. Гасырлар авазы / Эхо веков.—2003.—№1/2.—Б. 180.
3. Тәһси (ИЯЛИ) Фәнни архивы, 16-ф., 3-тасв., 1-эш.
4. Соц. Татарстан.—1966.—13 гыйнвар.
5. Тәһси (ИЯЛИ) Фәнни архивы, 58-ф., 1-тасв., 282-эш,—24 б.
6. Тәрбияи-этфаль.—1907.—№ 1.
7. Әл-Ислах.—1907.—26 ноябрь; 1908.—26 октябрь.
8. Кояш.—1914.—27 гыйнвар.
9. Кояш.—1914.—7 февраль.
10. Кояш.—1916.—3, 4 март.
11. Кояш.—1916.—4 март.
12. ТРМА. 199-ф., 1-тасв., 2269-эш, 149 док.
13. ТРМА. 199-ф., 1-тасв., 3620-эш, 163 док.
14. Шунда ук, 165 док.
15. Шунда ук, 1961-эш, 10 док.
16. Безнең юл.—1926.—№ 5-6.—Б. 43-44.
17. Безнең юл.—1925.—№ 9-10.—Б. 55.
18. Кызыл Татарстан.—1926.—12 март.


**Редакциядән:**

*Журналыбызның даими авторы, тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Равил Госман улы Әмирхановка шушы айда 60 яшь тула. Аны олы юбилее белән кайнар котлыйбыз, ижат уңышлары һәм ныклы сәламәтлек телибез!*

Гыйлем
Фән

*Мәсьәләгә бер караш*

# КЕМНӘР УЛ СКИФЛАР?

Мәгълүм ки, антик дәверләрдә Кара диңгез төньягындагы далаларда һәм шәһәрләрдә яшәгән скифларның теленә һәм этносына кагылышлы мәсьәләләр әле хәзер дә тарих фәненең "баш авыртуы" булып кала бирде. Дөресрәге, менә ике гасырдан артык инде галим-голәмә даирәсендә бу хактагы бәхәсләрнең тынып торганы юк иде.

Әйтик, мәсәлән, бүгенге фәндә скифларның килеп чыгышын иран-фарсы тамырларына бәйләп карау гипотезасы өстенлек итә. Һәм, киресенчә, тюркологгалимнәр бихисап күп санлы тарихи материаллар нигезендә скифларның төрки телле булуларына басым ясап киләләр. Ә аларның чынлап та төрки телдә сөйләшкәнлекләрен дәлилләү өчен бары бер генә нәрсә—язма ядкяр генә житми иде.

Эзләгән табар дигәндәй, ниһаять исбатлау чылбырында житмәгән тоенне ачыклау юнәлешендә галимнәргә зур уныш елмайды һәм ул әлеге низагъка соңгы ноктаны куярга мөмкинлек бирәчәк. Сүз шул хакта бара: татар тел белеме галиме Фәрит Фәттах (ул академик Мирфатыйх Зәкиевнең шәкерте)—монарчы "укылмаган" урта гасыр төрки язмаларга ачкыч тапкан белгеч—скиф патшасы Скилның алтын балдагына грек хәрефләре белән язылган язуны укый алды.

Түбәндә урнаштырылачак мәкаләсендә ул үзенең әлеге ачышы турында тәфсилләбрәк тукталып үтә. Бу ачыш, әлбәттә, төрки халыкларның тарихына кагылышлы кайбер сәхифәләргә янача караш ташларга мөмкинлек бирер.

## Скифлар нинди телдә сөйләшкән?

Тарихтан мәгълүм булганча, скифлар Кара диңгезнең төньягындагы киңлекләрдә гомер кичергәннәр. Борынгы грек тарихчысы Геродат (б.э.к. 5 гасырда яшәгән) скиф патшалары турында сүз алып барганда, Скил дигән патшаның тәхеткә яу кырында ятып калган әтисеннән соң утыруын бәян итә. Әнисе тәрбиясендә вә йогынтысында үскән Скил грек телен һәм язуын да камил белгән. Геродот тарафыннан да телгә алып үтелгәнчә, Ольвия шәһәрендә аның иркен-зиннәтле патша сарае була (археологлар анда бизәнү әйберләренең бик тә үзенчәлекле төрләрен табып алдылар).

Скиф аллаларыннан ваз кичкәнє һәм грекларның шәраб алласы Дионниска табынганы өчен (бу аның вакх* шашынуларында да чагылыш тапкан) Скил патша тәхеттән куып төшерелә һәм ул Фракиягә, әнисенең туган шәһәре Истриягә качып китәргә мәжбүр була. Шуның нәтиҗәсендә Скилның туганы—Скифиянең яңа патшасы Октасамад, скиф гаскәрләренең башында торып, Фракиягә (Фракия дип хәзерге Болгария җирләре белән көньяк-көнчыгыш Румыния киңлекләре аталган) яу йөргән.

Әмма канкойгыч сугыш булмый кала. Фракия патшасы Ситалк һәм Скифия

---

*Вакх—борынгы Греция һәм борынгы Рим мифологиясендә үсемлекчелек, шәраб һәм кәеф-сафа кору алласы; ул йөзем үстерүчелекне һәм шәрабчылыкны үз канаты астына алган. Шуннан вакханалия килеп чыккан—борынгы Грециядә һәм борынгы Римда вакх хөрмәтенә үткәрелә торган шәраб бәйрәме; кыргыйларча кәеф-сафа кору, оргия.

патшасы Октамасад, туган-тумача булганлыктан, үзара солых төзүгә ирешәләр. Алар, шул ук вакытта, качкын туганнарын алмашуга да сүз куешалар. Бу килешү буенча Фракия патшасы, Скифиягә качып киткән бертуганын йомып алу бәрабәренә, Скилны Октамасад патша кулына тапшыра—ә тегесе ике дә уйлап тормастан качкын туганының башын чаптыра. Скил патшаның аянычлы язмышы кыскача шуннан гыйбарәт.


Алтын балдакка килгәндә, ул узган гасырның 30 елларында Добруджа (Румыния) тирәсендә, борынгы Истрия шәһәреннән 10 чакрымнар ераклыктагы дингез яры буйларыннан җир эшкәрткән вакытта крәстиәннәр тарафыннан табып алына. Балдак нинди юллар белән бер тарихчы кулына килеп эләгә, ләкин шуннан соң аның эзе югала. Гоманлаулар буенча, ул нинди дә булса берәр шәхси коллекциядә урын алырга мөмкин. Бәхеткә каршы дип әйтикме, аның фотосурәте сакланып калган.



Ә балдак дигәнебез, 28,5 грамм авырлыктагы алтын бождрадан гыйбарәт. Аның кашында,—калынаеп-бултәеп килгән алгы өлешендә,—уң кулына көзге тоткан килеш зиннәтле кәнәфидә утырып торучы хатын-кыз сурәте төшерелгән. Сул кулында—скипетр яки карышкыны хәтерләткән бер таяк кебек нәмәрсә. Сурәтнең аяк тирәсеннән башлап, балдак кашының—битлекнең түгәрәк сыман чиге буйлап грек хәрефләре белән һәм грек әйтелешендә скилио—"Скилныкы" дип язып куелган.

Сүзләр арасында аралар калдырмыйча язылып, егерме хәрефтән торучы икенче бер язу балдакны әйләнеп урнаштырылган, ә сыеп бетмәгән соңгы дүрт хәреф битлеккә табан дәвам иткән. Язу ачык таныклык итеп, шулай ук грек хәрефләре белән башкарылган. Без аны кириллицада бирәбез:

**КЕЛЕОЕАРГОТАНПАРИАНЕ**



Рус галиме Ю. Г. Виноградов бу язманы борынгы грек нигезендә шәрехләргә омтылыш ясап карый, моның өчен ана соңгы дүрт хәрефне кирегә—арттан алга табан укырга туры килә. Аның фикеренчә, язмада сүз Арготан патша турында бара булып чыга. Әмма Геродот хезмәтләрендә мондый исемдәге патша телгә алынмый, гәрчә "тарихчылар атасы" скиф патшалары династиясен җентекләп санап чыкса да. Кызганыч ки, мондый фактлар Ю. Л. Виноградовның әлеге текстны укыганда хаталар җибәрүе хакында сөйли иде булса кирәк...

Чынлап та, соңыннан ачыклаганча, текстның борынгы грек теленә бернинди дә мөнәсәбәте юк икән, чөнки ул, гап-гади генә итеп әйткәндә, скиф телендә башкарылган. Текстта таяныч сүзләр түбәндәгедән гыйбарәт: КЕЛ, Е... ТАНП АРИАНЕ. Моннан шул аңлашыла: тел белеменнән бөтенләй хәбәрдар булмаган, әмма нинди дә булса берәр төрки телдә сөйләшүче һәркем бу текстның төрки телдә башкарылганлыгын чамаларга мөмкин. Биредә бары тик ТАНП сүзендә сузык Ы хәрефе генә төшерелеп калдырылган, чөнки ул гомумән грек алфавитында юк.

Аннары, текстның мәгънәсеннән балдак хуҗасының кемгәдер мөрәҗәгать иткәнлеге тәгаенләнә. Шикләнми икърар итәргә мөмкин: балдакның битлек-йөзлегенә алиһә хатын-кыз сурәте төшерелгән булырга тиеш, Скил патша да нәкъ менә ана мөрәҗәгать иткәндер. Аның исеме ОЕАРГО формасында бирелгән. Борынгы төрки телдә ӨРГҮН сүзе "тәхет" дигәнне аңлата.

Геродот исә бер скиф алиһәсен Аргимпасы формасында бирә; димәк, ул төрки телдәге өргү+басы ("тәхет башы") булып укыла. Шул рәвешле, урын житмәү сәбәпле, текстта ачыклагыч "башы" сүзе төшерелеп калдырылгандыр һәм Скил патша алиһә исеменең башындагы өч сузык аваз аша грек телендә булмаган төрки сузык авазы "ө"не белгертергә омтылган булырга тиеш.

Моннан чыгып әлеге алиһәнең исеме ӨРГҮ формасында яңгырагандыр дип әйтә алабыз. Хәзер текстны түбәндәгечә укырга мөмкин булачак:

**КЕЛ, Е ӨРГҮ, ТАНЫП АРИАНЕ**

Рус телендә ул болай янгырар иде: "Приди, о Престольная, опознав ариа".

Күргәнебезчә, текст саф скиф телендә, ягъни төркичә язылган икән. АРИАНЕ сүзе башка берни дә түгел, хәзерге төрки телләрендәге иялек килешенең чагылышы гына. Язмада Скил патша үзен горуранә рәвештә "арий" дип атый. Борынгы төрки телдә аның төрлечә өслүбтәге янгырашы булган. Мәсәлән, "арыг" формасы "чиста, саф, әйбәт" мәгънәләрен анлаткан, "арыйу"—сафлану, чистарынуны белдергән. Кыскасы, төрки телләрдәге "ару" сүзе—саф, әйбәт, "ярый" формасы—ярыйсы гына, әйбәт кенә мәгънәләренә барып тоташа һ. б.

Анлашыла ки, "арийлар", "арийлылар" сүзенең тамырын төрки телләрдән эзләргә кирәк икән (үзләрен "арийлар" дип атаган фашизм идеологларына да бу хакта мәгълүмат туплау зыян итмәгән булыр иде). Һәм балдакка төшерелгән язма монын шулай икәнлеген бик ачык дәлилли. Шул ук вакытта язмадан Скил патшанын Аргимпасы алиһәдән скиф тәхетенә утыру өчен фатиха сорап ялваруы да ачыклана.

Скифларнын төрки телле булуларын археологлар тарафыннан Кырымдагы Казантип борыны тирәсендә балыкчы кирәк-яраклары арасыннан табып алынган батыргычтагы язулар да дәлилли. Язу ике сүздән тора, ул шулай ук грек хәрефләре белән башкарылган, хәтта сүзләр аралык калдырып та язылган! Ул түбәндәгедән гыйбарәт: САК ТАС. Бу очракта да шуны искәртеп үтәргә тиешбез: скифлар ТАШ формасын кулланcалар да, грек алфавитында Ш хәрефе булмау сәбәпле, аны С хәрефе белән алмаштырырга мәжбүр булганнар.

Батыргычнын скиф телендә САК ТАС формасында кулланылуы, әлеге балык тоту кирәк-ярагынын эчке мәгънәсен бик тә төгәл ачып бирә һәм ул Скил патша балдагындагы язма язунын төрки телдә икәнлегенә (читләтеп кенә булса да!) гарант булып тора ала.

Инде ахыр килеп мондыйрак нәтиҗә ясарга мөмкин булыр иде: әлеге балдактагы язунын биш кенә сүздән торуына да карамастан, анын төрки телдә башкарылганлыгы бәхәссез һәм бу нәүбәттән ачы язмышына нисбәтле рәвештә борынгы скифлар теле турында кире хаккысыз дәлил калдырганы өчен Скил патшага без—бүген көн төрки халык вәкилләре буларак—рәхмәтле хисләребезне әйтергә зарурбыз. Аннары, алга таба да скиф телендәге язулар табылмас дип кем әйтә ала! Монын өчен шәкли шәрехләнгән бик күп борынгы язуларны яңабаштан энә күзеннән үткәреп чыгарга кирәк; шул ук вакытта төрки тел нигезендә укырга тырышмау сәбәпле галимнәрнең теше үтмәгән язуларны да барлап чыгу зарур. Бу нәүбәттән, әлбәттә, Балкан илләрендә табылган грек хәрефләре белән язылган әйбер-предметлар зур кызыксыну уята.

Анлашылса кирәк, төрки һәм башка халыкларнын килеп чыгышында тарихи дөреслекне торгызу юнәлешендә эшләргә ниятләүче тел белгечлеге энтуазистлары өчен тикшеренү кыры ачык. Ә бу өлкәдә, күргәнебезчә, кайчак археологик яки этнографик материаллар түгел, ә бәлки язма ядкярләр зур роль уйнарга мөмкин икән.

Ә безнең белән булган очракта, тарих фәнендә беренче тапкыр без борынгы скифларнын бик тә кыска, әмма биниһая әһәмияткә ия булган язма ядкяренең серен ача алдык һәм ул, безнеңчә, төрки халыкларнын ерак үткәннәре хакында калыплашкан карашларга бөтенләй яна төсмерләр өсти.

**Фәрит ФӘТТАХ,**

*Татарстан Фәннәр академиясе*

*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*

*фәнни хезмәткәре*

**Адлер Тимергалин**

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ОРЕНБУРГ***– Иске татар китапларында-*Орынбур, Рынбурух.* И.Рәми Оренбургны *Үрән* дип тә атый, чыганакларда шәһәрне *Ур Кала* дип атау да очрый. Кайбер бүгенге китапларда *Ырынбур* һәм хәтта *Ырымбур* язылышы күзәтелә. Болары "татарчалык"ны гади сөйләм белән бутаудан, ягъни талымсызлыктан башка нәрсә түгел, әлбәттә. Тирәнгәрәк китсәң, атаманың татарчасында төрки "ур" яки "ор" сүзе катнашырга тиеш иде. "Салават бәете"ндә: "Җаек дигән җап йир-су, сай йирендә сөңге буйлайдыр, *Урунбуркайның* ягасында алтынлы тулар уйнайдыр." Икенче бер бәеттә бу шәһәр "Ранбур" дип телгә алына: "Яна икән саласы, *Ранбурдыр* каласы, Мәһди байның тәкъдирендә язган икән янасы."

Оренбург шәһәренә башта 1735 елда Орь елгасы буенда крепость буларак нигез салынган (хәзер анда Орск шәһәре) һәм ул немец үрнәге буенча исем ("Орь елгасы буендагы шәһәр") алган. "Орь" сүзе исә төрки чыгышлы, *ур / ор казылма / чокыр* яки *өем / өелмә* мәгънәсендә. 1739 елда шәһәрне Сакмар тамагына, 1743 елда исә баштагы урыныннан 280 км көнбатышка таба күчергәннәр. Ә шәһәрнең исеме аңа ияреп барган. 1744 елда Оренбургтан ерак түгел татар авылы *Каргалы,* ягъни *Сәгыйть бистәсе* төзелә. 1938 елдан алып 1958 елга кадәр Оренбург шәһәре *Чкалов* дип аталып йөрде.

Нигез салынып 30 еллап үтүгә инде Оренбургта руслар саны 5 меңнән дә артып китүе турында мәгълүматлар бар. Руслардан кала, шәһәрдә күпсанлы татарлар, казакълар, фарсылар, әрмәннәр, үзбәкләр, Малороссиядән килүчеләр, грузиннар, валахлар, гарәпләр яшәгән. Халкының чуарлыгы ягыннан ул Әстерханнан гына калышса калышкандыр. Шул ук вакытта "башкортларны" тынычландыруда да ул хәлиткеч роль уйнаган. Тиз арада казакъ җүзләре дә патша администрациясе даирәсенә кертелгәннәр һәм XIX гасыр башына инде җүзләрне формаль рәвештә бетерергә, аларның территорияләрен округларга бүлеп, яңа идарә урнаштырырга мөмкинлек туган.

1740 елда И.И.Неплюев сенатка хәбәр иткәнчә, Бохарадан һәм Һивадан Оренбургка берничә кәрван килгән һәм бу кәрваннарның төп йөген Персия көмеше тәшкил иткән (418 пот 23 кадак). Рәсми мәгълүматларга караганда, 1748 елдан алып 1755 елга кадәр генә дә Оренбургка Шәрыктән 50 пот алтын һәм 4000 пот көмеш һәм бик күп асылташлар китерелгән. Аларны Россия товарлары белән тәэмин итү өчен Мәскәүгә һәм эчке шәһәрләргә вәкилләр җибәреп, андагы сәүдәгәрләрне Оренбург базары белән кызыксындырырга туры килгән. Шушы вакытларда Казаннан күпләп татар сәүдәгәрләре дә килә башлаган.

Персиядән килгән алтын-көмешнең күпчелек өлеше Әстерхан сәүдәгәрләре кулына килеп кергән. Шуңа күрә, затлы металларның кире Персиягә китүен булдырмас өчен, сенат Әстерхан губернаторына ашыгыч төстә боерык җибәреп, моны күз уңында тотарга куша.

Оренбург сәүдәсе казнага 40-50 мең сумлык таможня җыемы биреп килә. Шәһәрдәге сәүдәгәрләр курасы ("гостиный двор") Россиядә иң зурлардан булып, анда 300 кибет исәпләнгән һәм алардан казнага ел саен 5000 сумлык керем алынган. Бу двордан тыш, шәһәрдән ике чакрымда гына Азиат һәм Бохара алмаш ярминкәләре дә эшләгән. Аларында сәүдә берничә йөз казактан торган кораллы каравыл күзәтчелегендә алып барылган, "меновой дворлар"ны туплар белән коралланган отрядлар саклаган.

Шәһәрнең үзендә берникди сәнагә булмаган диярлек. Шуңа күрә бирегә куллары һөнәр белгән җинаятьчеләрне сөрә башлаганнар, ә острогта яхшы җиһазланган остаханәләр булдырылган. Монда столярлар, слесарьлар, каретачылар, пыялачылар,

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче саныннан басылып килә.*

итекчеләр эшләгән. Острог карамагында чүлмәк һәм кирпеч житештерү фабрикалары булган.

Оренбург шәһәрендә мөселманнар, башлыча татарлар, күп булганга, берничә мәхәллә исәпләнгән.

Оренбург шәһәренең иске мәчетләре *(Шиһабетдин Мәржани буенча)*:

*Беренче мәчет.* Шәһәр эчендәге мәчетне кенәз Волховский гасырында Бохараның кәрван башы Иш төзеткән, аңа казна да күпмедер ярдәм иткән. Ишнең үзенә тарханлык дәрәҗәсе бирелгән. Бохарадан Оренбургка беренче тапкыр кәрван башы булып килүче кеше — шушы кеше диләр. Углы-хажи Назарбай-Оренбургта Габдессәлам мөфтинең кызына өйләнеп, аның кияве булган.

*Алмаш (Меновой) ярминкәсе* (Җаек суының аргы ягында-Азия халыклары белән сәүдә итү урыны) *мәчете.* Мелла Сөләйман сүзләренә караганда, бу мәчет Оренбург төзелгәндә, мәликә Катерина *(Чынлыкта Оренбург шәһәре 1743 елда Елизавета Петровна патшалык иткән вакытта төзелә башлый-Төз.)* вакытында казна ярдәме белән корыла, аңа ике имам һәм ике мөәззин, бер хезмәтче билгеләнеп, барысына бер елга 105 сум акча бирелә.

*Кәрван-сарай мәчете.* Оренбургтагы өченче мәчет Кәрван-сарай мәчете дип йөртелә. 1229 (1843) елда башкортлардан акча җыеп төзелә, 1262 (1845) елда ачыла. Бинасы-гүзәл, төгәл. Янында Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләре үрнәгендә ике катлы бүлмәләрдән торган "Кәрвансарай" исемле бер бинасы бар. Мәчет эченең әйләнәсендә алтын белән "Җомга" сүрәсе язылган. Мич һәм морҗасы юк иде, соңрак төзелде.

Патша хакимияте чорында Оренбург губернасында 595 мәчет, 152 мәдрәсә, 222 мәктәп эшләгән. Бүген исә өлкәдә 78 мәчет һәм 2 мәдрәсә эшләп килә икән (Ф.Бәйрәмова материаллары буенча). "Оренбург өлкәсендә рәсми рәвештә ике мөфтиәт теркәлгән. "Беренчесе — Оренбургның үзендә, аңа Габделбарый хәзрәт Хәйруллин житәкчелек итә. Икенчесе — Богырыслан мөфтиәте, аның рәисе — Исмәгыйль хәзрәт Шәнгәрәев. Өлкәдәге мәчет-мәдрәсәләр дә урталай бүленгән, Оренбург тирәләрендәгеләре — Габделбарый хәзрәт мөфтиәтенә карый, Богырыслан, Әсәкәй тирәсендәгеләр-Исмәгыйль хәзрәт мөфтиәтенә буйсына." (Ф.Бәйрәмова.) Кәрвансарай мәчетендә дини вәгазьләр башкорт телендә алып барыла икән, мәчетнең маңгаена да "Каруан-һарай" дип язып куелган. Ләкин Кәрвансарайның "Гостиный двор" дип йөртелгән башка биналарын башкортка да, татарга да кайтарып бирмәгәннәр.

***ӨЧЛЕ, ИЗГЕ ӨЧЛЕ(К)*** — Христиан динендә *святая троица* (керәшеннәр *"тройсын"* диләр), *триада.* Бу төшенчә христианнарда Бог (Алла), Изге Рух (яки Тын) һәм Исус Христосны (Алла улы Гайсә / Исаны) бер зат итеп берләштерә. (Керәшенчә-русча дини сүзлектә *"Бер көе өчле"* дигән гыйбарә бар.) Будди динендә *дә "Будданың өч тәне"* дигән төшенчә бар, болар — *Брахма, Вишну, Шива* (борынгы төркиләр аны "үч етүз" дип атаганнар). / / *Ул шулай язылды булса да, Синнән бизмәде, Син Өчле дип данлана торган Аллага, Атага, Святый Тынга шикләнми ышанды, дөрес җыен өйрәткәнчә, Алланы Өчле дип, Өчлене Бер Алла дип, калдык тыны чыкканчы әйтте; шуңар күрә аңар изгелек ит. (Керәшеннәрдә мәет өстендә укыла торган "Иман"нан.)*

"Изге Өчле(к)" 325 елда Никея соборында (керәшенчәдәге "дөрес җыен"?) һәм 381 елда Константинопольдә канунлаштырыла.

Мондый "Өчлек"не, мәсәлән, Лев Толстой күз алдына китерә алмый. 256-336 елларда Александриядә яшәгән рухани Арий да Алла Улын (Христосны) Ата Аллага тиң түгел, ул аңа ошаган гына дип санаган (арианлык). Гомумән, "Изге Өчлек" төшенчәсе христиан динендә аңлатылмас сер исәпләнә һәм христианнар бу идеяне Платоннан алган диләр (Поль Гольбах). Христиан фикер ияләре арасында "Изге Өчлек"не инкяр итә торган антитринитарийлар сектасы да булган, ягъни "Өчлек" төшенчәсе христиан аңында да җиңел генә урнашмаган. Дөрес, моны бүгенге көндә дә "фәнни" нигезләргә тырышулар күзәтелә (мәс., космик аппаратларны галәмдә ориентлаштыру, ягъни тиешенчә юнәлтү буенча белгеч академик Б.В.Раушенбах). Коръәндә, гомумән, христианнарның Христосны һәм Мәрьям-ананы алалаштырулары гаепләнә һәм, Коръән Кәрим күзлегеннән караганда, христиан өчлеге Аллаһыдан, Гайсә пәйгамбәрдән һәм Мәрьям-анадан тора икән дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Ислам бер Аллаһыны гына белә, аның

шәриге юк дип саный, шуңа күрә Гайсә пәйгамбәрнең Алла улы булуы да кире кагыла.

"Изге Өчлек" урын, вакыт һәм фәзаның өч үлчәмле булуын символлаштыра. Бөтенесен колачлый торган дөньяның христиан тәгълиматы яктылыгындагы иң тулы тасвиры шушы. Бу өч аспект бер-берсенә бәйсез рәвештә яши, һәм шулай да алар бердәм Алланы тәшкил итәләр, өч килеш бердәмлек символы күрсәткәнчә, ул шушы өч аспектта: Алла Ата, Алла Угыл һәм Алла Изге Тын буларак чагылыш таба. Ата-угыл түгел, угыл-Изге Тын түгел һәм Изге Тын-ата түгел". ***(Яхшы ук буталчык бу аңлатма "Энциклопедия символов" китабы буенча, тәрҗемә минеке-А.Т.)***

Христианнарда шушы өч затның һәркайсының үзенчәлекләрен характерлый торган төшенчә *"ипостась"* дип атала ("асыл", "нигез" мәгънәсендәге грек сүзеннән). Православие теологиясендә ипостась, сиррият буларак, логик анализга бирелми торган төшенчә, ләкин ул кешегә "Изге Өчле"не күзалларга ярдәм итә дип карала.

Кайбер тикшеренүчеләр триада/троица/өчле төшенчәсе күп аллалыктан (политеизмнан) бер аллалыкка (монотеизмга) күчештә аларны тоташтыручы буын буларак барлыкка килгән дип исәплиләр. Чөнки ул бик борынгы чорда, мәсәлән Борынгы Мисырда (Осирис, Исида, Гор), Борынгы Һиндстанда (Брахма, Вишну, Шива), Бабилда (Ану, Эа, Бэл) һ.б. урыннарда да оешкан. Аның барлыкка килүе моногамияле никах таралуның чагылышы булган дигән фикер бар. Мәсьәләгә болай караган очракта "Изге Өчлек" дини карашлар үсешендә бер арадаш баскыч кына булып кала, ә аны рациональ нигездә аңлатуның кирәге калмый.

Шулай да христианлык иртәсендә, яңа эра башларында, христиан чиркәве әһелләренең баштагы алты соборы ("җыены") шушы мәсьәләне ачыклауга багышланган. Библиянең үзендә бу хакта ачык күрсәтмәләр булмаганга, чиркәү аталары мөшкел хәлдә калганнар дияргә мөмкин.

Христиан диненә күчкән грек еврейләре V гасыр дәвамында эллинистик күзаллаулар белән тыгыз бәйләнгән Өчлек концепциясен эшләп биргәннәр.

Керәшеннәрдә *тройсын*—троица бәйрәме (кайбер керәшен авылларында *җапрак бәйрәме* дип йөртәләр).

Әбү Гали ибн Синаның эманация (фәйзъ) турындагы тәгълиматында да өчлек/триада төшенчәсе бар. Аныңча, "Әл-мәбдәә әл-әүвәл"дән (Беренчел принциптан) фәйзъ-Беренчел гакыл бүленеп чыккан. Ул триада (*таслис, өчлек*): соңгы (тугызынчы) күк сферасының гакылын, җанын һәм җисемен тудырган (бүген боларны информация, энергия һәм материя белән тәңгәлләштереп була шикелле).

Бекташи әдәбиятында суфиларның "сөйгән яры"—Аллаһ белән Мөхәммәд һәм Гали галәйһиссәлам сурәтләре бергә кушылып, үзенчәлекле "*өчлек*" яки "*өчләмә*" (Аллаһ-Мөхәммәд Пәйгамбәр-хәзрәте Гали) темасы барлыкка китерәләр (Әлфинә Сибгатуллина).

***ПАКЬ ҺӘМ НАПАКЬ БАЛАЛАР***—Шәригать буенча, әгәр атасы, анасы, бабасы һәм әбисе кяфирләр булса, бала *напакь* дип исәпләнә. Әгәр дә әлеге якыннарыннан берәрсе мөселман була икән, баланы *пакь бала* дип карыйлар. Ләкин пакь булу әле мөселман булу дигән сүз түгел. Әгәр дә кеше үзенең мөселманмы, әллә юкмы икәнлеген белмәсә, шәригать буенча ул пакь дип санала. Дөрес, аңа мөслимәгә өйләнү тыела, аны мөселман зиратында җирләргә дә ярамый. Ул шәригать нигезендә Исламны кабул иткәннән соң гына хак мөселман булып исәпләнә.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Йолдыз
Хәлиуллин

# САЛМАК АККАН ТИРӘН ФИКЕРЛӘР ИЯСЕ

Үткән гасырның соңгы чирегендә миңа күренекле әдип Әмирхан ага Еники белән якыннан аралашып яшәү бәхете насыйп булды. Әмирхан ага минем әтиемнең яшьтәше иде (алар бер үк елны, бер үк айда 90 яшьләрен тутырып вафат булдылар), без йә Мәскәүдә, йә Казанда очрашып, мин чит илләрдә хезмәт иткәндә даими хатлар язышып тордык.

Татар әдәбиятында Ә. Еникинең үзенә генә хас, күптән билгеле булган бер "почмагы" бар. Аны беркем белән дә чагыштырып та, бутап та булмый. Минемчә, тоталитар режим заманында Ә. Еники татар прозасында әхлаклы лирик төсмерләрне саклап калуга аеруча зур өлеш керткән әдипләрнең берсе. Ул, әлбәттә, төпле уйлану-кичерешләр, мәхәббәт һәм эстетик эзләнүләр остазы иде. Жанр байлыгы, сурәтләү алымнарының көчлелеге укучылар күңеленә сеңеп калырлык булды. Ул һәрвакыт "акыллы чама" белән иҗат итте. Шуңа күрә дә, аның әсәрләренең күбесе искерми, үзгәреп беткән хәзерге дөньяда да эчтәлек һәм жанр-композицион төзелешен югалтмый кебек тоела.

Мәскәүгә сугылганда Әмирхан ага баштарак "Москва" соңгарак "Россия" кебек абруйлы кунакханәләрдә туктый иде. Минем фатирда да берничә мәртәбә булганы бар. Казанга килгәндә Әмирхан ага һәрвакыт үзенә чакырып кунак итә иде. Мөлаем йөзле Мөршидә апаның һәм искиткеч тыйнак Нажия апаның (Ә. Еники хатыннары) милли ризыклары һаман да күз алдында тора. Озакка киткән фикер алышуларда Әмирхан аганы күбесенчә Мәскәүдәге сәяси тенденцияләр һәм чит илләрдә яшәүче мөселман халыкларының көнкүрешләре кызыксындра иде, ә мин исә Казан тормышының агымы һәм татар әдәбиятының яңалыклары турында сораштырам.

Шуны ассызыклап әйтәсем килә: утыз елга сузылган аралашу чорында Әмирхан агадан тегеләй яки бу татар язучысы йә галиме, гомумән, башка кешеләр турында берниндри тәнкыйть сүзе ишетмәдем. Хәер, ул мактау сүзләренә дә бераз саранрак, ә мактану сүзен һич тә белми кебек күренә иде. Мирсәй Әмир белән Гомәр Бәшировка карата сокланып әйткән сүзләре генә хәтердә сакланып калган. Әмирхан аганың үзенә караган шәхси мәсьәләләр турында минем белән киңәш иткән чаклары да булды. Үзе әйтмешли, бу "серләрне" ачып салырга вакыт килеп җитмәде әле, дөресрәге, кирәкми дә дип уйлыйм.

Сүз уңаенда, берниндри "серләргә" тоташмаган ике гадәти очрашуны искә алып китмәкче булам. 1978 йә 1979 елның кыш уртасы булса кирәк, Әмирхан ага ниндидер йомыш белән Мәскәүгә килгән иде. Аның чакыруы буенча "Москва" кунакханәсенә юл тоттым, рәхәтләнеп сөйләшеп утырдык. Күптәнге танышыбыз Мөнәвир Закиров та туган ягы Башкортстанны сагыну хисләрен шигырьгә салып остазга ләззәт сибеп утырды. Әмирхан ага: "Иртәгә иртүк Казанга китәм",—дигәч, без җәһәт кенә өйгә аяк тарттык. Ләкин икенче көнне көндез миңа эшкә шалтыратып Әмирхан ага болай диде:

—Йолдыз туганай, мин, билетны бер кешегә бүләк итеп, бер-ике көнгә Мәскәүдә калырга булдым. Ник дисәң, сина үзем өчен кадерле бер тарихи йортны күрсәтәсем килә. Әгәр синең планнарыңа каршы килмәсә, шунда бергә сөйләшеп утырыр идек, ничек уйлыйсың?

—Әмирхан ага, мин эш буенча бүген сәгать жидедә "Советская" кунакханәсендә булырга тиеш, чакыру кәгазендә жидедән тугызга кадәр дип язылган. Соң булмаса, сезне эзләп табармын.

—Бик яхшы, мин әйткән йорт (фәлән-фәлән фатир) нәкъ шул кунакханә артында гына. Кереп чыксаң, бик әйбәт булыр иде, мин көтәм.

Ул кичне мин Шри-Ланка компартиясенең Председателе Викремасингхене 70 еллык юбилее белән котлап, ул әзерләгән табында утырдым. Мәжлестә барлыгы дүрт кеше иде—юбиляр, мин һәм аның малае белән килене—булачак архитекторлар. Мин табында ярты сәгать чамасы гына утырдым да: "сезнең бүгенге мәжлес гаилә бәйрәме булырга тиеш",—дип хәйлә табып, Әмирхан аганың теге фатирына юл тоттым. Ул мине һәрвакыттагыча ачык күңел белән каршы алды. Бер касә әрмән коньягын чәкешеп алгач, Әмирхан ага "тантаналы белдерү" ясады:

—Минем яшьлегемнең иң матур, якты көннәре шушы йортта рояль тирәсендә уен-көлке, жырлап һәм серләшеп үтте,—диде.

Каршыдагы инструментның буяулары тоныкланган капкачын ачып, клавишларына бармакларын тигезде. "Ул да безнең белән бергә картайды инде, хәзер аның да дәрте-дәрманы юк",—дип йомшак кына көлемсерәп куйды Әмирхан ага.

Егерменче еллардан бирле бу фатирда Әмирхан аганың жизнәсе Шәриф Сүнчәләй гаиләсе яшәгән икән. Хәзерге хужабикә—Сүнчәләйнең оныгы Дилә ханым ул вакытта Пекинда СССР илчелегендә стенографистка булып эшләгән. Минем белүем буенча, Дилә ханым һаман да (2003 елның ахыры) Пекинда яши. Ул Рәсәйнең Кытайдагы илчесе И. А. Рогачевның (1992 елдан бирле бу хезмәтне башкара)—хәләл жефете (хатыны). Менә сиңа Еники токымнары кайларга барып житкән!

Ш. Сүнчәләй фатирында булган икенче очрашуны Әмирхан ага (ул сиксәненче еллар уртасында булса кирәк) үзенең инде язылып беткән автобиографик әсәренә багышлады диярлек. Сүз күбрәк әле исеме куелмаган ("Соңгы китап") зур әсәрнең йомгаклау бүлеге тирәсендә барды. Әмирхан ага китабын Ш. Мәржани, Дәрдмәнд, Ш. Сүнчәләй, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый һәм М. Жәлил исемнәрен тагын бер кат искә алып тәмамлаячагын әйтте. Әмма мина үз кулы белән бүләк иткән, 1987 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан "Соңгы китап"та нигәдер Г. Ибраһимов һәм Г. Исхакый исемнәре төшеп калганнар. Моны берәүләр Әмирхан аганың гадәти "саклык белән эш итүе" дип аңлыйлардыр. Мин башкачарак фикердә: Әмирхан ага бу ике шәхес турында аерым бер әсәр язып чыгару ниятләре белән йөрде. Китапны әзерләгәндә Әмирхан ага үзе белән аралашып яшәгән күп кенә язучылар турында да байтак кына мәгълүматләр туплаган булса кирәк. "Ләкин аларны хәзергә бу китапка кертеп булмый әле",—дип бик катгый рәвештә әйтеп куйды да, миннән нинди дер фикер көткән кебек озак кына сүзсез утырды.

—Ул байлыкларыгызны әрәм итмәгез инде, аларны сезнең булачак икенче томга кертеп жибәрүләр бик ләзем кебек тоела,—дип тәмамладым мин бу сөйләшүләрне. Ул моны яклап та, каршы килеп тә бер сүз әйтмәде, тик "алдагысын Алла белә",—дип кенә сүзен түгәрәкләде.

Әмирхан ага әдәбиятта ашыкмыйча, салмак кына хәрәкәтләнеп иҗат итә торган тирән әдипләрдән иде. Әмма ләкин илдәге сәяси тенденцияләрне ул бик тиз сизеп, алдан әзерләп куйган материалларын жәһәт кенә әдәби калыпка салып, укучыларга бер-бер артлы әсәрләрен "ыргытып" торды.

Минемчә, аның татар әдәбиятына кылган бер зур эше матбугат битләрендә тиешле урын тапмады һәм аны киң жәмәгатьчелек бөтенләй белмәде. Сүз менә нәрсә турында бара. XX гасыр татар әдәбиятының ике зур зөбәржәте—Галимжан Ибраһимов белән Гаяз Исхакыйны мәдәниятыбызга кире кайтару юлында беренче кыю адымнарны Әмирхан ага Еники ясады. "Мин бу эшләрне башлап жибәрдем

дә, читтән карап тордым: ничек башкалар Г. Ибраһимов һәм Г. Исхакый турында диссертацияләр һәм китаплап язарлар. Мәсьәлә чишелгәч, мин шунын белән канәгать булдым",—дигән иде Әмирхан ага, Казанда анын фатирында үткән озак сөйләшүләрнең берсендә.

Шул вакытта Әмирхан ага мина Г. Ибраһимовны аклау чарасын сорап илленче ел урталарында ук ЦК КПСС исеменә үз кулы белән язган кәгазьнең бер нөсхәсен күрсәтте. "Мин моны Гомәр ага Бәширов белән киңәшеп җибәргән идем, шуннан сон, Алланың рәхмәте булып, күренекле язучыбыз безгә кире әйләнеп кайтты",— дип горурланды Әмирхан ага. Анын архивында сиксәненче ел урталарында Гаяз Исхакый мирасына караган язулар да бар иде. Һәрхәлдә, Әмирхан аганың бу эшчәнлеген татар җәмәгатьчелеге ачык белергә тиеш дип уйлыйм.

Бәлки монын мин белмәгән башка сәбәпләре дә бардыр. Мәсьәлән, Әмирхан ага үз тирәсенә, озак еллар буе аралашкан, сыналган кешеләрне генә җибәрә иде. Мин дә биш-алты елга сузылган бу "карантинны" үттем, ахры. 1976 елда Ә. Еникинең "Саз чәчәге" җыентыгына кергән берничә хикәясен урду теленә тәрҗемә итеп Пакистан журналларында бастыру—минем өчен Әмирхан ага белән аралашуга соңгы имтихан булды кебек.

Әмирхан аганың чит илләрдә яшәүче мөселман халыкларының тормышы белән кызыксынуын искә алып, 1991 елны мин аны рәсми рәвештә Непалга кунакка чакырдым. Ун көнлек кызыклы программа әзерләдем. Ул Катманду шәһәренең уртасында урнашкан Җәмигъ мәчетендә Әмирхан аганы кабул итүдән башланып китәргә тиеш иде. Непалда ата-бабалары Һиндстаннан чыккан ике миллионга якын мөселман халкы яши. Берничә мөселман байларында кунакка йөреп, башка урыннар һәм патша йортынын храмнары белән танышкач, бераз таулар арасында ял итеп кайтканнан сон, Әмирхан аганы китәр алдыннан премьер-министр да кабул итәргә ризалык биргән иде.

Әмирхан ага загранпаспортлар алып, салмак кына Казаннан Катмандуга барырга "юл эзләп йөргәндә" (Миркасыйм Госмановнын әйтүенчә, ул бу хакта анын белән дә киңәшләшеп йөргән) көтелмәгәндә Мәскәүдә ГКЧП фетнәсе килеп чыкты да, Әмирхан аганың еракка барып кайту теләге сүнеп китте. Мине дә ярты елдан Һималай тауларыннан Һинд дингезенә "ыргыттылар"—Катмандудан Коломбога күчеп киттем. Шулай итеп, бу визит тормышка ашырылмый калды.

"Казан утлары" журналы укучыларының игътибарына Ә. Еникинең 1991—1992 елларда Казаннан Катманду шәһәренә язган бер "көлтә" хатларыннан тугызы тәкъдим ителә.

*декабрь 2003 ел, Мәскәү.*

# ӘМИРХАН ЕНИКИ ХАТЛАРЫ

Мөхтәрәм Йолдыз Нуриевич!

Сез җибәргән адрес белән мин күптән инде бер хат салган идем, ахрысы барып җитмәгән. Сәбәбе нәрсәдә икән? Почта бик озак барамы, әллә Мәскәүдә тотып калалармы? Миңа икенче хатыгызны алдым—шул ук адрес, ягъни Мәскәү аша җибәрергә (сез, әлбәттә, адресны белеп биргәнсездер инде). Бу хатны да шул ук адрес белән җибәрәм. Аннары бандероль итеп бер китап та салам. Сынап карыйк, барып җитәрләрме икән?

24 апрельдә без Переделкинога китәбез, барып урнашкач та мин кызыгызга шалтыратачакмын. Шуннан адрес мәсьәләсе ачыкланыр дип уйлыйм. (Беренче хат эченә мин бер мәкаләмне дә салган идем, әллә шуның аркасында барып җитмәде микән?)

*II/IV—91*

* * *

Йолдыз туган, Сезгә күпме генә рәхмәтләр әйтсәм дә аз булыр кебек. Яңа урында эшегез бик тыгыз булуга карамастан, миңа хат язу гына түгел, хәтта дару табарга да өлгергәнсез. Мин, әлбәттә, борынгыча әйтсәк, тәшәккердән гаҗизмен!

Бәхет сүзен без хәзер бик сирәк кулланабыз. Шулай да ул сүзне Сезгә карата кулланырга ярыйдыр дип беләм. Ихтимал, Сезнең эшегез бик авыр, бик җаваплы – төрле халыклар күреп яшисез, бу исә яшәүнең мәгънәсен һәм кадерен бик арттыра торгандыр. Димәк, кеше язмышыннан канәгать! Моны инде бәхет димичә мөмкин түгел.

Мин үзем дә яшь чакларда сәйях (сәяхәтче) булу турында хыяллана идем. Дөнья гизүнең, илләр, халыклар белән танышып йөрүнең никадәр кызыклы, мавыктыргыч булуын аңлый идем. Мәгәр заман миңа андый мөмкинлекне бирмәде. Гомер узды, хәтта күрше Финляндияне дә күреп булмады. Һәм өмет-хыял да сүнде.

* * *

Сез Казан хәлләре белән кызыксынасыз... Ни дип әйтергә? Илдә ни булса, бездә дә шул. Ә илдәге хәлне Сез Катмандуда торып та безгә караганда яхшырак беләсездер, мөгаен... Кыскасы, мактанырлык берни дә юк. Тукай үзенең бер шигырендә болай дип язган иде:

*Җанлырак тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,*
*Бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия.*


Безнең заманга да бик туры килә бу сүзләр...

Әдәбиятта дә телгә алырлык яңалыклар юк. Тиздән Тукай премиясе бирер көннәр җитә. Әдәбияттан дүрт кеше – Әбрар Кәримуллин, Роберт Миңнуллин, Әхәт Гаффар һәм Гөлшат Зәйнашева күрсәтелгән иде. Шуларның берсенә яки икесенә тиюе мөмкин. Мине дә комитет әгъзасы иткәннәр. Хәзер менә шуларны укып, баш ватып утырам.

Татарстан үзенең суверенлыгы өчен көрәшеп маташа. Ләкин аның булуы бик мәхәл. Мин бу хакта үз уйларымны "Татар мәсьәләсе" дигән зур мәкаләдә язган идем, тик ул "Идел" журналында бик соңга калып чыкты.

Хушыгыз! Үзеңә һәм җәмгатеңә күп сәламнәр белән: Әмирхан.

* * *



Йолдыз!

Бу минем Сезгә өченче хатым. Аерым бер китап та җибәрдем. (Мәрҗани турында) Ләкин шуларның барып җитүе турында Сездән бер хәбәр дә юк. Мин аптырабрак торам: Сезгә китаплар җибәрергә ярыймы-юкмы? Гаязның шактый калын әсәрләр җыентыгы чыкты. Нурихан Фәттахның телләр тарихы турында "Шәҗәрә" исемле китабы чыккан иде. Җибәрергә ярыймы?

Аннары минем мәкаләмне дә сорагансыз. Ләкин миндә татардан чыккан дипломатка татар мәсьәләсе белән кызыксынырга ярыймы икән дигән шик бар. Шулай да мин сезгә ике мәкаләмне җибәрәм. Барып җитсәләр, хәбәр итәрсез. Хәзергә шул. Яңа илне күп гиздегез шикелле, күргән-белгәннәрегез турында, вакытыгыз артса, тулырак язсагыз иде. Минем кебек гомерен "тимер пәрдә" артында үткәргән кеше өчен анысы да бик кызыклы.

Бик җаваплы эшегездә зур мөвәффәкат телим. Моның өчен һәрвакытта таза, нык булуыгызны телим.

Үзегезгә һәм җәмгатегезгә күп сәламнәр белән: Әмирхан.

*1 июнь, 1991 ел.*

* * *

Йолдыз Нуриевич!

Бүген I август, ә 29 июльдә Сезнең хатыгыз белән чакыру кәгазегез килеп җитте. Чакыру мине, билгеле, бик сөендерде, моның өчен Сезгә йөз кәррә рәхмәт! Әмма ул мине бик нык уйланырга да мәҗбүр итте. Нишләргә? Хикмәт шунда, без – мин, Нажия һәм кызым – 6 августта Юрмалага иҗат йортына очарга тиешбез. Путевкалар, билетлар күптән кесәдә. Шул ук вакытта гомеремдә беренче мәртәбә шундый көтелмәгән мөмкинлек – ычкындырырга ярыймы соң моны? Һәм мин тиз генә хәрәкәт итә башладым. Әгәр Совмин ярдәме белән 3-4 көн эчендә чыгып китеп булса, Непалга очарга, ә аннан туры Ригага кайтырга! Бер атна яки артыграк вакытны югалтам икән, бу бик кечкенә мәсьәлә. Непал өчен бер айны да рәхәтләнеп бирергә була.

Иң элек мин үземне даими карый торган врачка бардым. Ул Непалның кайда, нинди ил икәнен юньләп белми дә. Аңлатып бирдем: дөньяның иң биек таулары итәгендә, 12 сәгать очып барырга кирәк. Врач курка калды: "Юк, мин үзем генә сезгә андый ерак юлга чыгарга һәм бөтенләй башка климатка барырга рөхсәт итә алмыйм", – диде. Ул мине консультант-профессорга да күрсәтмәкче булган иде, ләкин анысы ялга киткән булып чыкты. Әлбәттә, минем яшьтәге кеше өчен кыска гына вакыт эчендә климат алыштыру да, ике тапкыр озын юл үтү дә хәвефсез түгел.

Шулай да мин кичә (31 дә) Совминның беренче урынбасары Мансур Хәсәнов янына да бардым. Чакыру кәгазен күрсәттем. Укып чыккач, ул болай диде: "Мин Сезнең китүегезне тизләтү өчен барысын да эшли алам, ләкин бик нык уйлагыз, рисковать итәргә кирәкме икән? Башта ял итеп кайтыгыз, аннан күз күрер", – диде.

Һәм менә шундый киңәшләрдән соң, бүген Сезгә хат язарга утырдым. Чынлап та, кайнар баштан рисковать итү ярамас дигән фикергә килдем. Мин әле яңарак кына Уфага барып, бер атна йөреп кайттым (Туган-үскән җирләрне карап). Шул да минем өчен шактый йөк булып чыкты. Дөрес, хәзергә үземне, шөкер, начар хис итмим, мәгәр Катманду Уфа түгел бит ул!

19 июньдә мин Сезгә хат салып, ике журнал һәм берничә газитәне бандероль итеп җибәргән идем. Күпмедер вакыттан соң журналлар белән газитәләр кире кайттылар. Күрәсең, хат та барып җитмәгәндер, чөнки Сезнең хатыгызда аның хакында бер сүз дә юк. Ә мин ул хатымда Сезгә бара алуымның бик икеле булуы турында язган идем. Барып җиткән булса, Сезгә бәлки мәшәкатьләнергә дә кирәк булмас иде. Аралар бик ерак шул. Бу хат та тиз генә барып җитмәс инде. Аннары китаплар-журналлар да җибәреп булмый икән. Бусы бик кызганыч!

Без Юрмаладан сентябрь башында кайтачакбыз. Шуңарчы Сездән хат килсә, мин үз планнарымны язармын.

Хәзергә исән-сау булып торыгыз! Чын хөрмәт һәм сәлам белән:

Әмирхан.

* * *

Хөрмәтле Йолдыз Нуриевич!

Латвиядән без 31 дә кайттык. Сезнең хат килеп, мине көтеп яткан. Укыдым һәм уйга калдым. Билгеле, Сезнең кат-кат чакыруыгыз мине бик дулкынландырды – мең кәррә Сезгә рәхмәт! Шул ук вакытта уйламыйча да мөмкин түгел иде. Бик еракта торсагыз да, Сез безнең илдә нинди хәлләр булып узганын миңа караганда да яхшырак беләсездер. Менә шундый буталчык, хәвефле бер вакытта ерактагы ят илгә чыгып китү ярар микән? Шулай да мин тәвәккәлләргә булдым, Сезнең бик ихлас чакыруыгызны тыңлыйсым килде. Иң элек Совминга шалтыратып ярдәм итүләрен сорадым (вәгъдә иттеләр). Аннары кызыгыз Гөлнарга шалтыратып, Сезнең хәл-әхвәлне, шулай ук юл шартларын сораштым. Кызыгыз: "Әтинең хәле әйбәт (все нормально), ләкин баруы җиңел түгел, мин үзем юлны авыр кичердем", – диде. Шуннан соң врачка киттем: яшь кызга авыр булгач, 82 яшьлек картка ничек

булыр икән—белергә кирәк иде. Врач мине бик әйбәтләп карады һәм: "Сезгә барырга ярый, кирәк булса справка да язып бирәм", —диде. (Ул үзе Вьетнамда эшләп кайткан икән). Врачтан мондый фатиханы алгач, мин тәмам канатланып, ОВИРга киттем. (Совминнан аларга шалтыратырга тиешләр иде). Барып, чакыру кәгазен күрсәткәч, һич көтелмәгән бер тоткарлык килеп чыкты: чакыру кәгазенә Сезнең МИДның "Согласен" дигән визасы кирәк икән. (Кәгазьнең югары почмагында андый виза өчен урын да бар). Мин, әлбәттә, бәхәсләшеп карадым, ләкин миңа аңлаттылар: "Чакыру посольствода эшләүчедән килгән, шуңа күрә МИДның визасы обязательно—бу хакта махсус күрсәтмә бар", —диделәр. Яңадан Совминга шалтыратып карадым, мәгәр алар да берни дә эшли алмадылар. Кыскасы, мин Мәскәүгә барып, МИДның "согласиесен" алырга, шуннан соң Казанга кире кайтып, калганын эшләргә тиеш идем. Мәскәүгә барып кайту күпме вакытны алачак, мин моны белмим, гомумән, мондый эшләр артыннан беркайчан да йөргәнем юк. (Әйтәләр, китүчеләр күп булу сәбәпле, һәртөрле рөхсәт алулар бик озакка сузыла, дип...) Шул рәвешчә минем юлым киселде һәм... хәзергә дәртем дә сүнде. Күрәсең, язмагандыр инде. Дөньяның бик буталган чагы, бездә дә хәлләр киеренке. Бәйсезлек тирәсендә һаман талаш-тартыш бара. Мондый чакта китеп йөрүләр дә читенләшә. Минем Үзбәкстанга барып кайтырга уем бар иде, белмим, ничек булып чыгар. Октябрьнең 20 ләрендә Мәскәүдә СССР язучыларының 9 нчы съезды ачылырга тиеш. Шуңа баргач, бәлки МИДка да кереп чыгармын. Ә хәзергә сүземне тәмамлыйм... Да, син үзең шул чакларда ялга кайтмыйсыңмы? Бер күрешеп сөйләшер идек.

Хуш! Күп сәламнәр белән: Әмирхан.

*7/IX-91.*

* * *

Йолдыз Нуриевич!

Ялдан кайткач мин Сезгә бер хат язган идем. Ул хатымда Сездән килгән чакыруны файдаланыр өчен нинди кыенлык чыгуын да хәбәр иткән идем (МИДның визасы кирәк диделәр). Мәгәр шул кыенлыкны уйламаганда гына җиңеп булды: безнең Союз рәисе, РСФСР депутаты Ринат Мөхәммәдиев чакыру кәгазен үзе белән Мәскәүгә алып китте дә, МИДтан виза салдырып, кире җибәрде. (Аңа бу эшне ерып чыгарга депутат булуы гына ярдәм иткән.) Шуннан мин чакыру кәгазен ОВИРга илтеп күрсәттем. Паспорт өчен кирәкле материалларны китерергә куштылар. Аларын да илтеп тапшырдым. Хәзер паспорт әзерләп биргәннәрен көтеп ятам. Ике атна үтеп китсә дә, алганым юк әле.

Хәер, паспорт кулыма керсә дә, мин аның белән хәзер генә файдалана алмам дип торам. Күп уйлаганнан соң, кыска гына вакыт эчендә шул кадәр озын юл үтеп, бөтенләй башка климат шартларында торып кайтуны күтәрә алмам дип куркам. Рисковать итәсем килми. Әлбәттә, Непалны күрү бик кызыклы булыр иде, ләкин 83 яшьтә түгел, мәсьәлән, 53 яшьтә. Нишлисең, ерак илләргә барып, кояшыннан, йә салкыныннан курыкмыйча йөрергә без инде соңга калдык. Чакыруың өчен сиңа, Йолдыз туган, бик зур рәхмәт, борынгыча әйтсәк, тәшәккердән гаҗизмен!

Шулай да минем якындагы илләрнең берәрсенә, бигрәк тә Төркиягә, барып кайтасым килә. Яңарак кына Төркиягә барып кайткан Мөхәммәдиев анда мине чакыру турында сөйләшкән. Менә шул чакыру булмасмы дип көтәм. Яки Татарстаннан бара торган берәр делегациягә эләгеп булмасмы дип торам. Менә шундый форсат өчен Сезнең чакыру белән алган паспортны сакламакчы булам. Безнең яшь, өлгер язучылар Төркиягә быел икешәр тапкыр барып кайттылар инде. Гомумән, йөрү көчәйде. Читтәге байлык кешеләрне бик кызыксындыра (тарта) булса кирәк.

Ә бездә хәлләр һаман начарлануга таба бара. Стабильность юк, иртәгә әллә нинди фетнәләр килеп чыгуы мөмкин. Безнең Татарстан хәле дә бик читенләште. Мөстәкыйльлеккә каршы хәрәкәт көчәйде. Рус демократлары Татарстанның Рәсәй эчендә калуын, хәзерге җитәкчеләрне алып ташлауны бик каты таләп итәләр. Алар арасында татарлар да аз түгел. Татар җәмәгать оешмалары суверенлыкны күкрәк

киереп яклап маташалар, мәгәр көчләр тигез түгел, бик ямьсез вакыйгалар туарга мөмкин.

Мин сиңа кайбер гәзитә материалларын җибәрәм, исән-сау барып җитсә, танышырсың. Хәзергә хатымны шушының белән тәмамлыйм.


Хөрмәт һәм күп сәлам белән: Әмирхан.

*29/IX-91.*

P.S. Язарга оныткканмын: I ендә Ташкентка очам, үзем кебек бер карт дустымны соңгы тапкыр күреп кайтасым килә.

* * *

Мөхтәрәм Йолдыз Нуриевич!


Мөхтәрәм Йолдыз Нуриевич!

Безнең хат алышуыбыз ничектер ялгышрак бара кебек: минем хат барып җитмичә торып, Сез язасыз, яки мин Сезнең хатка бик соңга калып язам, ахрысы... Сентябрьдә мин Ташкентка китәр алдыннан Сезгә бер хат язган идем, кайтуыма Сездән дә хат килеп торган. Ләкин ул минеке барып җиткәнче язылган икән. Хәерле булсын!

Без Ташкент якларына 1 октябрьдә киткән идек, 14 ендә исән-сау әйләнеп кайттык. Бу сәфәрдән мин тәмам туеп кайттым. Кая барсаң да – бөлгенлек, тәртипсезлек, рәхәтеннән бигрәк җәфа күбрәк. Хәзер беркая да барып йөрисем килми, быел болай да шактый җир урадым. Җитеп торыр!

...14 ендә кайттык, 15 ендә Татарстан Югары Советының сессиясе ачылды һәм шул ук көнне мәйданга җыелган татарлар белән милиция арасында каты бәрелеш тә булып алды. Үлүчеләр булмаса да, яраланучылар шактый булган. Милиция халыкны резин таяклар белән ярган. Татар егетләре милициягә байрак сабы, күсәкләр белән тондырганнар. Бу хакта орган җитәкчеләре сессиядә информация ясадылар, ләкин соңыннан аларның информациясе бер яклырак дип сөйләделәр. Бәрелешнең төп сәбәбе – сессиядән Татарстанга бәйсезлек таләп итү – мәйданга халык шуның өчен җыелган булган. Моны алдан оештырылган бер чара, диделәр. Чөнки ул көнне Чаллы якларыннан автобусларга төялеп күп кенә татар егетләре дә килгәннәр.

Мин үзем 15 ендәге сугышны күрмәдем, тик 16 да гына Ирек мәйданын карап уздым. Анда сессия барган йортны уратып алган, калкан тоткан резин таяклы милиция дә, аларга каршы торган, яшел байраклар күтәргән татар яшьләре дә күп иде. Бу яшьләр гел хәрәкәтләнеп, өзлексез "Азатлык!" дип кычкырып торалар. Атмосфера шактый кызу, хәвефле иде, ләкин, шөкер, ул көнне эш бәрелешкә барып җитмәгән. Депутатлар чыгып, халыкны тынычландырганнар.

Әмма шулай да Ирек мәйданында булып узган канлы вакыйга мине шактый борчуга салды. Берничә көн уйланып йөргәннән соң, мин ахырда уйларымны утырып яздым да, ул "Борчылу" исеме белән "Шәһри Казан"да тиз генә басылып та чыкты. Бу вакыйгаларга кагылышлы кайбер материалларны шушы хат эченә салып Сезгә дә җибәрәм. Барып җитәрме-юкмы – белмим.

Хатны тиз генә яза алмыйча торуым әнә шул хәлләр аркасында булды. Мин инде "таулар иленә" хәзергә бармаска булдым. Бу хакта үткән хатымда язган да

идем. Мәгәр кызыл тышлы паспортны 19 октябрьдә барып алдым. Непалга бару срогы 92 елның 27 сентябренә кадәр, диелгән. Ләкин минем бу паспорт белән файдаланып, кая да булса баруым бик тә икеле. Безнең өчен дигән поезд китеп барган шул инде.

...Җитте хәзергә. Күп сәламнәр белән: Әмирхан абзаң.

*28/X-91 ел.*

* * *

Хөрмәтле Йолдыз Нуриевич!

Көн дә Сезгә хат язу турында уйланам, ләкин шуңа һич кенә кулым җитми. Эшем күпкә күрә дә түгел, ахрысы үземне мәҗбүр итә белмим. (Мондый йомшаклык миндә элек тә бар иде.) Инде үземә ачуым да килә башлады.

Сезнең өченче хатыгыз без Мәскәүгә киткәч килгән. Без 24 апрельдән 19 майга кадәр Переделкинодагы иҗат йортында булдык. Китәр алдыннан мин каты салкын тидереп авырып алдым. (Гриппның бер әшәке төре тигән, диделәр.) Иҗат йортына баргач та мин ул зәхмәттән тиз генә котыла алмадым, һаман каефсезләнеп йөрдем. Ә ялыбыз болай әйбәт кенә узды.

Баргач, күпмедер вакыттан соң, кызыгыз Гөлнар туташ белән телефон аша сөйләштем. Мин аңа ике тапкыр шалтыраттым, һәм ул Сез җибәргән бик кадерле даваны без китәсе көнне, вокзалга төшеп, вагоныбызга кертеп бирде. Рәхмәт инде аңа! Һәм аеруча Сезгә рәхмәтемнең иң зурысы, иң ихласы. Хәзергә әле мин шундый ерак серле илдән килгән ул тылсымлы даваны кулланыргамы-юкмы дип икеләнебрәк торам (минем яшьтәге кешегә). Тартмасы эченнән язуы чыкты, инглизчә язылган булса кирәк, кызыма бирдем, ул телне белүчедән укытып алырга тиеш. Шуннан соң карармын инде, минем кебек картка ярый торган булса, бәлки истигъмал итәрмен дә.

Сезне, әлбәттә, Казан хәлләре кызыксындыра инде. Вакыйгалар күп, Казан кайный, мин аларның күбесен белеп тә бетермим. Мәгәр төп вакыйга һаман да әлеге шул Татарстанның суверенлыгы тирәсендә бара. Без Мәскәүдән кайтканда бу мәсьәлә тирәсендәге көрәш аеруча көчәйгән иде. Безнең Югары Совет 13 майда Татарстанда РСФСР президентын сайлауны да рөхсәт иткән карар чыгарган булган. Суверенлыкны яклаучылар менә шуңа каршы күтәрелгәннәр: Россия президентын сайлау бездә булмаска тиеш, диеп. Хәтта 16 кеше, шулар арасында Фәүзия Бәйрәмова да, ачлык игълан иткәннәр. Ике атна буена Ирек мәйданында элекке обком бинасы каршында алар ач утырдылар. Көн саен яннарына халык җыелды, зур демонстрацияләр булып узды. Муллалар, мәчет картлары, карчыклар килеп, яннарында намазлар укыдылар. Дингә таяну бик көчәйде, ай сурәте төшерелгән яшел байраклар һаман эленеп торды. Боларның барсын да Казан телевидениесе күрсәтеп барды. Ачлык игълан иткәннәр бары 27 майда гына бу эшләрен туктаттылар, чөнки шул көнне Татарстан Югары Советы баштагы карарына бераз үзгәреш кертте: ягъни Россия президентын сайлауга теләгән кеше генә катнаша ала һәм аның нәтиҗәсе Татарстан өчен юридик көчкә ия булмаячак.

Менә шундый хәлләр. 12 июньдә Татарстан президентын да сайлау булачак. Тавышка бер генә кеше – Шәймиев кенә куела. Үтәр дип торабыз.

* * *

Йолдыз Нуриевич!

Хатыгызны алдым. Хастаханәдән чыккан көннәрдә килде. Миңа операция булды, эчне ярып, полип дигән нииндидер шешне кисеп алдылар – берничә көн бик авыр хәлдә булдым. Шулай да исән калдым. (84 яшькә җитеп килгәндә операциянең авыр, хәтәр булуы билгеле инде.) Хәзер өйдә хәл җыеп ятам. Мәгәр көч-куәт бик әкрен кайта.

Бу хатны туры адрес белән җибәрмәскә булдым, чөнки барып җитүенә ышанмыйм. Почталар хәзер бик алама эшли. Аннары язарлык хәбәрләрем дә юк диярлек. Үземне дөньядан аерылган бер кеше итеп тоям. Әмма беләм: заман бик әшәкеләнде, тормыш гаять авыр, халык гаять интегә, түземе соңгы чиккә килеп

җитте диярлек. Әгәр былтыргы август вакыйгасы кабатлана калса, бүгенге хакимдарларны бер уч яңа миллионерлар, мафиозлар, базар жуликларыннан башка яклаучылар табылыр микән?! Ихтимал, демократияне бик теләүче күпмедер интеллигенция яклап маташыр, әмма алар бик аз шул, мин үзем дә чын демократияне җаным-тәнем белән тели идем. Ләкин, бәхетсезлеккә каршы, августтан соң властька килүчеләр барысы да иске партноменклатурадан күчкән ялган демократлар булып чыктылар. Шулар илне һәлакәт чигенә китереп җиткерделәр. Халык язмышы белән уйнау — ул демократлар эше түгел.

Безнең Татарстанда чагыштырмача тынычлык хөкем сөрә дияргә була. Ләкин бездәге "Милли мәҗлес" дигән нәрсә власть өчен каты көрәш алып бара. Теләкләре — Югары Совет урынын алу, президентны төшерү, хөкүмәтне алыштыру... Әмма барып чыкмас дип уйлыйм. Чөнки "Милли мәҗлес"нең хокукый әсәслары бик зәгыйфь (халык тарафыннан сайланган орган түгел бит). Аннары аларның максатларын аклаучылар һәм иярүчеләр дә күп булмаска тиеш. Хәзерге кебек гаять авыр һәм хәвефле бер вакытта власть даулап маташуны мин дә аклый алмыйм. Яхшымы-начармы, шушы җитәкчеләребез Татарстанда туклык һәм тынычлыкны тәэмин итәргә тырышалар. Димәк, аларга аяк чалмаска, ә булышырга кирәк. "Милли мәҗлес"кә башка эшләр дә җитәрлек. Халкыбызның яртысы туган теленнән аерылды, менә шул хакта күбрәк уйласын һәм хөкүмәтне дә кыюрак хәрәкәт итәргә мәҗбүр итсен иде.

Җитәр ахрысы, күпкә китте. Артык сүзләрем өчен кичерерсез! Күп сәламнәр белән: Әмирхан.

*24/X-92.*

• • •

Мөхтәрәм Йолдыз Нуриевич!

Тәбрик хатыгызны алдык — рәхмәт Сезгә! Мин үзем кайчан хат язуымны оныткан да идем, Сез искә төшердегез. Әйе, миңа сентябрь ахырында операция ясатырга туры килде. Шуннан соң инде мин үземне нык картайган, хәлсезләнгән, сакланып әкрен генә йөрүче бер бабай итеп тоя башладым. Күрәсең, вакыты да җиткәндер — бер айдан миңа 84 яшь тула. Гомер кояшы инде баеп бара.

Шулай да минем бүгенге хәлем артык зарланырлык түгел. Шөкер, чыгып йөрим дә, утырып эшлим дә, тән зәгыйфьләнсә дә, акыл-зиһен искечәрәк әле. Соңгы берике айда әйбәт кенә эшләп тә алдым. Газеталәрдә чыккан ике әйберемне Сезгә дә җибәрәм. Смоленская площадь аша, ләкин барып җитүенә ышанычым юк. Расходы котырып артуга карамастан, почта бик алама эшли. Гомумән, бездәге хәлләрне аңлап бетерү дә мөмкин түгел. Мафиоз белән яңа номенклатура бергә укмашып, халыкны кычкыртып талыйлар. Бернинди әдәп тә, оят та, иман да калмады. Элек кешеләр рухи кол булсалар да, тамаклары тук, өсләре бөтен иде. Хәзерге "хөрлек" аркасында алар тәмам кыргыйланып, ерткычка әйләнеп баралар. Исән-сау кайткач, үзегез дә күрерсез. Ахрысы, атларны алыштырыр вакыт җиткәндер.

Безнең Татарстанда хәерчелек аз гына җиңелрәк, тынычлык белән иминлек хәзергә саклана. Без шуңа мәмнүн булып, яшәп маташабыз.

Хушыгыз! Исәнлектә күрешергә язсын! Ихлас сәламнәр белән: Әмирхан.

*28/I-93.*

Kitap küzətü
Китап күзәтү

# ЮГАЛТМА, ДӨНЬЯ, ШАГЫЙРӘҢНЕ!

*Югалтма, дөнья! Асылташ—*
*Фирүзә минем исем...*

Фирүзә Җамалетдинова.

Фирүзә Җамалетдинованың 2004 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән беренче шигъри җыентыгын кулыма алган чакта, аннан, кыз баланың лирик хисләрен күбрәк укырмын дип уйлаган идем. Китапның "Толымлы ай" дигән исеме дә лирика вәгъдә итә кебек. Ләкин беренче шигыреннән башлап укый-укый дистәләгән бит үттем дә хәйран калдым: сөбханалла, милләтебез, аның ирке, җиһандагы урыны, хокуксыз бүгенгесе һәм хыялдагы дәүләтле киләчәге хакында олыларча борчылып, камил шигъри тел белән сөйләп бирә алырлык шагыйрә килгән икән бит татар дөньясына! Байтак ир-ат шагыйрьләр үзләренең хисләр көлендә актарынудан уза алмаган чорда бу! Ә бит көтелмәгән хәл түгел! Милләтнең бүгенге ихтыяҗыннан чыгып фикер йөрткәндә, безгә мондый шагыйрь-шагыйрә, һичшиксез, килергә, һәм ул нәкъ менә Чаллы якларыннан—Фәүзия Бәйрәмова, Айдар Хәлим кебек көрәшче әдипләр мохитеннән—үсеп чыгарга тиеш иде. Көенечебезгә күрә, Казан бүген ин-иң милли шагыйрьләребез дәвамчыларын да чит милләт әдәбиятына хезмәт итәрлек итеп "тәрбияли", без бу хакта сүз кузгатырга гына кыенсынабыз...




Китапның башындагы иң беренче шигырь үк ("Сигезенче могҗиза") укучыны шагыйрә күнелендә сынланган халкыбыз гамьнәренә бөтереп алып керә:

*Утка тотып караганнар,*
*Талчыбыктай сындырып,*
*Чукындырып караганнар,*
*Илне, йортны яндырып.*

*Дәүләтсез, динсез иткәннәр,*
*Телсез дә без диярлек.*
*Безгә тигән кайнар уктан*
*Тарих үзе көярлек.*

Әйе, көйгән шул, көйдергәннәр шул тарихыбызны! Кисәүләрне күрмәскә тырышабыз тырышуын да... Тарих белән бергә—милләт тә, татарның үзе төзегән дәүләте дә хәтсез көйгән-өтелгән. Ут салучылар да гел читләр генә түгел. Менә бүген, гапгадәти көндә, истә-оста югында, милләтне әйбәтрәк аңлаучы саналган җитәкчеләребезнең берсе радиодан татарның дәүләтчелекне кайтару өчен көрәш тарихына карата бик ямьсез сүз әйтте. Андыйны читләрдән генә ишетә идек әле. Тик безнең мона әллә ни ис китмәде, матбугатыбыз да "күрмичә" уздырды, чөнки аңнарыбызда—бу көннәрнең бүтән зур вакыйгалары. 25 март көнне Татарстанга "яңа" Президент билгеләнеп эшкә керешә, ә беренче апрельдән газ куллану бәясе тагын артты. Шаяралар гына, дип уйласак, каты ялгышкан булырбыз. Әле өч ай гына элек газга да, электрга да бәяләр берьюлы һәм байтакка күтәрелгән иде, югыйсә. Ешайттылар... "Россиядә бердәнбер" уен йортының чираттагысын төзү өчен акча җитми микәнни сон?..

*Нинди ил бу? Уттан тора*
*Тыныч чагы, көрәше.*
*Көне-төне, иртәгәсе,*
Тарих тулы күз яше,—

ди шагыйрә "Нинди ил бу?" исемле шигырендә. Күптән түгел генә мәгълүм Масхадовның мәетен, мәсхәрәләү дәрәҗәсенә төшереп, телеэкраннардан кат-кат күрсәткәч тә, кешеләр бер-берләреннән унайсызланып, үзалларына шундый сорау биргәннәр иде: "Нинди ил бу"?

*Бер акыллы затың бармы, дөнья,*
*Уң һәм сулны аерып бирерлек?—*

дип тә мөрәҗәгать итә Фирүзә-Асылташ "Юл кичүе" исемле шигырендә. Шигырь җаеннан әйтсәк, "бөек һәм бердәм" Рәсәебезнең бу "юл кичүе" дә артык озакка сузылды инде, ләкин без чыгасы "бәхет утравы" алда һаман шәйләнми әле. Ил бай-

Фирүзә Җамалетдинова. Толымлы ай.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.—174 б.

лыгын үзенеке иткәннәр генә андый утраударга гел барып-кайтып йөри. Өстәвенә, халык өстенә ишелеп төшкән бар авырлыкны "күчеш чоры" белән аңлатырга остарып киттеләр. Әллә шуның өчен юри сузалар инде бу кичүне? Ә бәлки "кая чыгасын белмәгән көймәгә бернинди жил дә юл унае була алмый" дигән гыйбарә төгәлрәк аңлатадыр илнең хәзерге хәлен? Әмма шагыйрә сеңлебез:

*Елыйм дисәң, бу язмыштан*
*Елый-елый үлеп була,—*

дигән юллары белән дә мең кат хаклы бит ("Изге Биләрдә"). Елаталар дип еламаска һәм үлеп бетмәскә иде бит! Бетүебезне теләүчеләр хәйран калсын иде. Бүген халыкка менә шушыны ничек төшендерергә?

*Халкым әле "СПИД-инфо" укый,*
*Кырын ятып кына диванга,—*

дип әрни Фирүзә сеңел ("Әрнү"). "Акылдан язып телесериал карый"—дисә дә хаклы булачак шагыйрә. Һай ул дәрьядай жәелгән бозыклык чирләрен шигырьләрдә тасвирлап бетереп булса иде дә халык шуны аңлап укыса иде канә! Халык укыса һәм аңласа, шагыйрәнең үз иңенә алган йөге дә жиңелрәк тоелыр иде. Ә хәзергә, әнә:

*Исе китеп карап тора дөнья*
*Иңнәремә салган йөгенә,—*

ди ул "Йөк" шигырендә. Чын шагыйрьләр жилкәсендә ил, дөнья йөгенең һәрчак авыры салына. Шуңа да аз алар—көрәшче чын шагыйрьләр. Андый шагыйрәләр исә һәр халыкта берәү-икәү дип кенә исәпләнерлектер. Халык гамьнәреннән төрелгән йөкләрнең бик зурларын күтәрә алуларына карамастан, нечкә жанлылар алар. Шуңа күрә иң гади теләктәшлеккә һәм аңлауга мохтаж чаклары да еш була:

*Көзге кояш гүя миңа пәрәвездән*
*Кер эләргә баулар суза. Кер эләргә!*
*Әллә нишләп жиңел булып китте менә,*
*Мохтаж чагым иде якын күруләргә.*

Шигырьләрендә дөнья белән сөйләшә, ил борчуларын үзенеке күреп борчыла белгән, халыкның тарихи хәтерен уятырга талпынган Фирүзә Жамалетдинованың хатын-кыз, килен, әни буларак язылган әсәрләренә дә фикер тирәнлеге, галәм иркенлеге, ак әбиләр мөләемлеге, ә сурәтләренә жылылык, ягымлылык хас. "Ап-ак итеп биләүсәләр юып элдем",—ди ул "Теләк" шигырендә. Гади генә кебек күренгән бер шигъри юлына яшь ананың сөенече һәм бәхете дә, борчылу катыш өмете дә сыя алган. Биләүсәләр юган бит ул, чөнки биләүсәгә төрерлек сабые бар. Ап-ак итеп юган, чөнки шулай юа алуына да куана, чөнки бәхетле кешенең генә һәр эше шулай уң була. Чөнки бу аклыкта аның ак көнеле, якты өмете, изге теләге чагыла:

*Ап-ак итеп биләүсәләр юып элдем,*
*Бар жиһанга ачылсын ла серле серем:*
*Жил-давылдан сакла, дөнья, сабыемны,*
*Минем изге теләгем ул—юган керем.*

"Чит тәрәзләр" шигырендә исә бөтенләй үзгә—ак көнелле һәм якты өметле сеңелләребез өчен ят булган күренеш ачыла. Ләкин шагыйрә "чит тәрәзләр" эчендәге "уңмаган килен"не хурламый, бәхетсезлеге өчен кызгана гына.

*Чит тәрәзләр күзәтергә яратам мин.*
*Буран оя корганы бар, карлылары.*
*Һай бу килен уңмагандыр, мескен бала,*
*Саркып чыккан пәрдәсенең сарылары.*

Төптәнрәк уйлап караганда, Фирүзә сеңелнең дөнья белән үз күреп, тиң санап сөйләшүе шагыйрьлегеннән генә дә түгел икән. Ул—хатын-кыз, ул—әни! Шуңа күрә аның хаккы һәм жаваплылыгы бермә-бер зур. Менә нәрсә шагыйрәне әледән-әле дөньяның үзенә, кешелеккә эндәштерә. Сеңлебез бит жанынңнан да кадерләп шушы дөньяга ул үстерә. Аның улы, һәм тагын меңнәрчә, миллионнарча аналарның уллары һәм кызлары—барыннан да элек, бу дөньяның киләчәге, кешелекнең дәвам итүе өчен кирәк. Дөньябыз гына бу хакта әллә уйлый, әллә юк. Югыйсә, шагыйрә сеңлебез бик дөрес язганча, нәкъ менә аналар күкрәге сөтеннән көч ала бит ул:

*Бүген дә дары исе һавада,*
*Туктаусыз ярыла ядрәләр.*
*Ярамас, димиләр, жан кыю,*
*Экраннар һәр өйдә—күрәләр.*

*Сискәнеп уянам ал таңда,*
*Айнымый дөм кара төненнән.*
*Югыйсә көч ала бу дөнья*
*Аналар күкрәге сөтеннән.*
*"Улым өчен куркам"—*

дип тәмамлана шигырь. Куркытадыр шул! Бу миһербансыз дөньяның сабыйларга өйрәтә торган уеннарына кадәр аналарны сагышлы уйларга батырырлык бит. Инде "бөек" дигән дәүләтләр дә сугыш "уен"ыннан башка яшь белми, әйтерсең, бөекләкләре әнә шул сугышта! Бу Жирдә балаларын сугыш өчен дип үстерүче әниләр дә бар микән әллә, нигә кайберләре улларын андый "уен"нардан тыярга да тырышып карамыйлар? Бу сорау, билгеле, шагыйрәне дә бик хафаландыра:

*Жан кыялар, кан коялар—*
*Мәскәүдә сугыш бара.*

*—Мин дә атам, син егыл,—ди,—*
*Абыйлар,—ди,—егылды.*
*Нигә өйрәтәсең, дөнья?*
*Күземә яшь тыгылды.*
*Нинди генә сүзләр табыйм,*
*Әйтсәм дә, тыңламый шул.*
*И сабый, сугышның уен*
Түгелен аңламый шул.

Сугышнын уен түгелен бу сәер илдә сабыйлар түгел, акыл утырткан ирләр, ил башлары да аңламый шул. Монда ату, шартлату коралы һәртөрле дипломатиядән алда йөри. Бик ачык мисалы—Беслан фаҗигасе. Балаларны да аямыйлар. Кыргызстан Президенты Әскәр Акаевның үз властен сугышсыз, кан коюсыз гына бирүен Мәскәү әле дә аңлый алмый. Аның урынында үзләре булсамы?!

Әниләрнең бәхетенә бу дөньядан әллә ни күп тә кирәкми бит инде. Бары тик өметләрен генә кисмәсеннәр дә, улларына-кызларына бәхет көтүдән мәхрүм итмәсеннәр.

*Куанабыз, дөнья буйлап дәвамыбыз*
*килгән өчен,*
*Яшәү өчен ана булып, тыныч күкләр*
*күреп кичен...*
*Һәм уйлыйбыз: гомер буе баламны*
*дип бәхет көтә...*
*Көтә белү—олы бәхет.*
Үзебезгә шул да җитә.

"Үзебезгә шул да җитә!" Укы әле аналар гына әйтә ала торган бу шигъри юлны, мәдәниятле саналучы дөнья! Туклыктан котыручы хакимнәрең дә укысын. Бер татар шагыйрәсе, ул үстерүче ана, үзе кебек меңнәр исеменнән сезгә дәшә! Ишетә һәм төшенә аласызмы сез аны? Юктыр шул... "Моң югалткан гавәм" дип исемләде сезне Халык шагыйре Илдар Юзеев. Бу "гавәм"дә шагыйрьне һәм шигырьне аңлаучылар отыры сирәкләнә. Яз көне узган Татарстан Дәүләт Советының ун еллыгы бәйрәмендә элекке депутат, Халык шагыйре Равил Фәйзуллинның иң арттагы рәткә генә утыртылуын "Звезда Поволжья" гәзите гаҗәпсенеп язды. Ләкин ник гаҗәпләнергә, Татарстанга мөстәкыйльлек яулашкан элекке Югары Совет депутатлары һәм милли фидакарьләр бүгенге көн батырлары, әдәбият каһарманнары түгел ич инде. Киресенчә, Татарстанның кәгазьдә генә булган иркен дә чикләп, империя киртәсенә кабат куып керткән прокурор татар матбугатының беренче каһарманына әверелде, хатын-кызлар журналына кадәр шунын күркәм сыйфатларын мактап яза. Шагыйрә сенлебез исә "бар дөньянын күзе" әниләрдә чагы турында хыяллана:

*Җиде җете нурын сузды кояш кинәт,*
*Бар дөньяның күзе бездә мәллә инде?*
*Җиһанымның ал нурларга чумган мәле:*
*Улым миңа тәүге тапкыр "Әннә" диде.*

Бу ананы да аңламыйсыңмы, "шигырьдән киткән" дөнья?! Ул бит синең мәрхәмәтеңә шундый ышана. Уйлары ак, күңеле нечкә булганга, әнә, ятим балаларынның тел белән әйтелмәгән теләген дә бөтен җаны белән тоя:

*Кар да җылы. Быелгы кыш*
*Ятимнәр кышымы соң?*
*Табигатьнең ана булып*
*Назлавы шушымы соң?*

*Ятимнәр йорты янында*
*Таулар айга тияр күк.*
*Юмарт кышка берәр сабый*
*Кинәт: "Әни!"—дияр күк.*

Фирүзә Җамалетдинова яшәешебезнең эреле-ваклы һәр күренешен шагыйрә һәм ана, үзе әйткәнчә, хатын-кыз булып бәяли, гади генә вакыйгадан да дөньякүләм гомумиләштерүләр ясый, хәтердә калырлык шигъри сурәт иҗат итә:

*Түтәл тулы суган тузгып ята,*
*Без ташыйбыз аны алмашлап.*
*—Бәйләм-бәйләм тезеп үрәлмәгәч,*
*Кияүгә дә сезне алмаслар...*
*—Кияүгә без бармыйбыз да әле!*
*Күрше әби көлә:*
*—Барырсыз.—*
*И балалар, әле бу гомердә*
Суган үрә-үрә арырсыз...

"Суган үрә-үрә" генә аруларга безнең сенелләр түзәр анысы, моңа кадәр әниләре дә, әбиләре дә түзеп килгән. Авырракларына да чыдаганнар, татар әниләре бик чыдам алар. Тарихтан бирле милләт белән кичергән фаҗигаләр шулай чыныктырган аларны. "Улларыбыз-кызларыбыз гына бәхетле булса иде", дип теләгәннәр. Бу бөек теләк—шагыйрәләребез иҗатының иң-иң үзәгендә. Син, дөнья, аларның шул өметләрен кисмә, аларны яшәүдән ардырма, ул-кызлар табып багудан биздермә, шагыйрьлектән мәхрүм итмә, бишек җырларын оныттырма. Югалтуларыбыз болай да чиктән ашты. Үзеннең үк алдагы көннәрең, шәфкатьлелегең өчен кирәк болар, дөнья! Шигырь аңламас җаннар упкынга тарта сине, дөнья!

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

*Юмор–сатира*

Камил
КӘРИМОВ

# САНСЫЗ ФИРГАВЕН

КЫЙССА

## I

Бу хикәя язылган арада Жир шарында яшәргә теләүчеләр саны дүрт миллиард ярым кешегә житте. Аларнын бер миллиарды мин уйлап чыгармаган сәбәпләр аркасында эш урыннарын алыштыру хакында хыялланып йөрер.

Бер эшсез профессор әйтә имеш, иренмичә эзләсән, планетабызда һәркемнең көзгедәге сурәте кебек охшаш тагын ике ише табылыр ди. Димәк, нәкъ минем кебек тагын ике кеше бар дигән сүз!..

Берсен беләм мин анын—Мәскәү Кирмәненен урам ягында, ягъни Кызыл Мәйданга салынган пирамида эчендә ята ул. Һәм ул Кызыл фиргавен мина шул тиклем охшаган ки, хәтта әтиемне Илья, әниемне Мария дип үртәп йөртәләр иде. Буем кечкенә, баш пеләш, танышларны күргән саен уң кулым каш өстендә кагына башлый, ә "Р" авазына бөтенләй исем китми—сөйләшкәндә әллә бар, әллә юк ул минем өчен. Хатын-кызлар белән мавыкмыйм... Шушы охшашлыкларнын ярдәме тиде—пионер яшемдә үк мине лектор иттеләр, студентлар театрында юлбашчы ролен башкарыр өчен генә өстәмә стипендия түләп тордылар. Диплом алу белән охшашымнын исемен йөрткән райкомга инструктор итеп билгеләделәр. Башыма гел кепка киям, ике кулым жилет түшендә. Таныклык, пропуск, паспорт ише дукаментларга фотографияне кызыл акчалардан кисеп кенә ябыштырам. Бер көйгә эшләп торам, артык тырышмыйм—чөнки ярамый, мина да совнарком председателе булырга димәгән, калын чәчле, куе кашлы аек башлыларны үстерсеннәр әнә...

Ә бер көнне безнең райкомны эшкә кертмәделәр. Хәтта кабинетымда онытылып калган кепкамны да бирмәделәр—партия мөлкәте дигән исемлеккә теркәгәннәр.

Эшсез дигән яңа статус өчен ике айлык пособие алырга килгәндә мина тиз арада йортлар идарәсенә кереп чыгарга куштылар, анда урам себерүче урыны бушаган, ләкин кичәге коммунист икәнлегеңне берүк сиздерә күрмә, диделәр. Эшкә дигән сүздән эчкә жылы керде. Мондый сөенечле хәбәрне юарга кирәк, минәйтәм...

Бүген пролетарийларнын өчәрләп-өчәрләп берләшә торган көне—заводларда узган квартал өчен хезмәт хакы өләшкәннәр. Муенымдагы галстукны салып тиз генә кесәгә яшердем—рюмочныйда бик өнәп бетермиләр аны. Тыпырдап торган чиратнын койрыгына бастым...

Ишек алдында өч борын тәмам туганлашып, аерылыша алмыйча торабыз. Аракынын арзан чагын сагынып башланган сүз шәрә кендекле кызлар тирәсенәрәк житеп килгәндә, капкадан шадра капитан килеп керде... Үз балаларын яраткандай аркабыздан сөеп, өчебезне дә тигез күреп, калай савытлы машинага төяделәр.

Бүлеккә китереп бушаткач мин чиратымны югалттым. Шадра капитан детсад баласы урынына кулымнан житәкләп түрдәге түрәнен аерым

бүлмәсенә алып керде. Керсәм—бөтен коньяк шешәләре бер кучкә өелгән диярсең—йолдызлы начальниклар утыра. Мине күргәч башта сагайдылар, аннан соң үзара пышылдаштылар. Туган елымның 1870 ел түгеллеген ишеткәч, ышанмыйчарак тордылар. Ә инде Петроградта бөтенләй булганым юк дигәч, күмәкләшеп егыла-егыла көлделәр. Татар икәнемне белгәч шым булдылар. Туганнарча сорау ала башладылар.

—Айныткычка җибәрикме? Әллә эш урынына протоколмы?

—Мин эшсез бит әле.

—Эшсез дисең, ә үзеннең кесәң тулы акча!

—Пособие ул, эшсезлек өчен,—дидем мин ярамаган статьялардан арынырга теләп,—эш белештем инде, әйе, белештем. Урам себерәчәкмен...

—Урам себерүче?!. Юләр! Синең бу башың белән акча күрәргә була хәзер. Күптән пеләшме?

—1991 нче елның егерме беренче августыннан...

—Горурлан! Без синең үзенә лаек эш таптык!

—Инструктор итеп җибәрсәгез бармыйм—мин беспартийный.

—Ерунда! Без сине һәйкәл итеп куябыз! Ирек мәйданына!

—Анда берәү бар ич инде.

—Урлаганнар шул, әле яна гына хәбәр иттеләр, күтәреп киткәннәр. Үч иткәндәй, иртәгә мәйданда митинг—халык суверенитет таләп итә. Әгәр һәйкәлнең юклыгын белсәләрме—өстәгеләрнең йолдызларын чүпләячәкләр!—Һәм сорау алучым "Өстәгеләр" дигәндә погон астыннан үсеп чыккан кулын шундый итеп күтәрде ки, хәтта имән бармагы түшәмгә тия язды...

Мин көзге каршына килеп бастым. Кулны алга суздым, башымны югары тотып күзләремне җәһәннәмгә төбәдем. Охшаган кәнишне...

—Охшамаган ич,—дигән булам үзем, юри генә.—Мыегым да кара, пеләшем дә алай ук зур түгел, буем кыскарак, аягым кәкре...

—Пеләшеңне зурайтыбрак кырабыз. Ә мыегыңны тотып карамаслар әле. Әллә син андагы халыкның һәйкәлгә исе китә дип беләсеңме?! Сине без таш өсте буш тормасын өчен генә бастырып куябыз. Һәйкәл каракларын тоткач алыштырырбыз.

—Кулын обком бинасына таба сузып тора идеме әле ул?

—Юк, кулыңны "Черек күлгә" таба сузарсың, ә обкомга артың белән борылып бас, һәйкәле шулай салынган иде. Килештекме?!

—Юк! Оклад мәсьәләсен сөйләшмәдек ич әле.

Йолдызлар тынып калды. Тимер чыбык тыгылган стаканда чәйнең шашып кайнавы гына ишетелә.

—Бер көн өчен инде...

—Бер көн эчендә нинди җинаятьне ачканыгыз бар соң әле сезнең? Иртәгә митинг башланса, һәйкәл эзләп йөрерлек рәтегез калмас. Так што, совнарком председателе окладын куегыз да, вәссәлам! Ник әллә шунда ел буе эзләмисез һәйкәлегезне. Теләмәсәгез ихтыярыгыз, мин барыбер Мәскәүгә китәргә җыенып тора идем әле. Анда һәйкәлләр дә күбрәк, акчасы да мулрак, мавзолей хакында да сөйләшеп була ди...

—Ярар, ярар, сиңа түләмибез дигән кеше юк бит әле.

Килештек, антлар биреште, эш урынын кабул итү—тапшыру турында журналлар ачтык. Түбәсендә ут уйнатып торган машина белән тупикка кадәр озатып куйдылар. Хатынга иртән иртүк уятырга кушып мендәргә капландым, яңа эш хакында ләм-мим. Юкса, ул авансы ал дип аптырата башлый.

## II

Уяну белән ярты чуен итсез борчак боткасын ялтыраттым. Чәй эчмәдем—юк-бар йомыш белән һәйкәлдән төшеп-менеп йөрү килешмәс. Эш җинеләйсен

дип, шадра капитан өйрәткәнчә, уң кулымны күтәреп гипска катыргач, хатын караватыннан тормаган килеш һушын югалтты. Кичә алган эшсезлек акчасын түшенә куйгач кына кашлары тартыша башлады җимешемнең.

Аллага тапшырып, таш нигезгә менеп бастым—күнелемне шундук бөеклек тантанасы биләп алды. Йөрәгемдә җыр ташый... Бер горурлык хисе яши миндә... Менә без дә үсеп життек, әни... Сөясеңме дип ник сорыйсың?.. Торам һәйкәл булып! Август аеның мәкерле кояшы шәһәр эченә кермәгән әле. Кичәге бәйрәм төненең калдык-постык йолдызлары сүнәргә азаплана. Үзәктән искән җилдә суверен болытлар безнең Иделдән су ташый. Торам һәйкәл булып! Акыллы уйларга чумып! Тәмәке кабыздым, сул куллап кына, уны каткан инде.

Тәмәкемне күкрәк киереп бер суырдым микән, килә берәү—зәңгәр бәрхеттән тегелгән кәчтүн-чалбар кигән, муенында алтын жепләр йөгертелгән тар кара галстук, аягында ялтыравык лаклы кара туфли, кулында скрипка футляры. Тәки уйнап минем аяк төбендә хәер сорашып утырыр микән? Ичмасам борчак боткасы эчне көйдерә, митинг башланганчы берәр стакан газлы су эчеп килермен дигән идем. Бу кеше жиргә куеп футлярын ачты һәм аннан җыелма саплы урам себеркесе чыгарды! Үзе бераз алышынган дип әйтимме—минем белән сөйләшә.

—Дөньяда күпме пеләш бар—берсе дә революция дип женләнми. Нинди зыяны тиде соң сиңа ул капиталистларның?! Ник безнең илдә тугансыңдыр син?! Башка дворниклар, әнә, яфрак кына себерә, ә миңа яфракка караганда партбилетлары күбрәк. Элегрәк хет иртән килүгә бәйләм-бәйләм чәчәк җыеп ала торган идек, хәзер анысы да юк—нәрсәгә дип тоталардыр карачкыны?! Кызык итәм бүген, җыештырмыйм, күрсеннәр утопистларын! Ну, фатир аласы булмаса...

Һәм ул барыбер түзмәде—аягым астындагы яфрак катыш билетларны борын төбемә китереп өйде. Ачуым чыкты, күч өстенә тәмәкемне ташладым.

—Җебегән,—дидем мин тавышымны күктән төшереп,—тәмугтагыларның гонаһын оҗмахтагыларга сылтама!

—Әй, Аллам, шырпы да ыргыт әле, пожалысты,—дип күккә табынды себеркеле скрипачым, сүнгән төпчегемне имезлектәй суыра-суыра... Күктән шырпы төшмәгәч, ул ут эзләп китеп барды һәм шуннан әйләнеп кайтмады.

Ике диннән коры калган шәһәрдә һәйкәл булулары җинел түгел икән. Мин моңа тора-бара гел ныграк ышандым...

Көн ачылышы мәйданга ыгы-зыгы өстәде. Башта машиналар... аяк астындагы җирне чылатырга су сипте, бәби тыкрыкларны ябарга тимер киртәләр ташыды, алҗыган аләмнәр китертелде, куян тавышын бүренекедәй итәрлек көчәйткеч аппаратуралар бушатылды.

Аннан соң ач торучы көрәшчеләрне чыгарып куйдылар. Митингка халык бик тиз җыелды, әйтерсең лә алар шушы тирәдәге бер ишек алдында гына төн кичергәннәр дә сәгатьләре житкәч тагын чыгып басканнар. Иртәнге мәлдә мине һәм мәйданны сакларга дип куелган ярымхәрбиләр белән митингтагылар саны тигезләшкән иде. Ә инде бункер эчендә сессия башлангач, эчке эшләрнең бөтен резервы тышка чыкты. Мин кыйбламны үзгәрттем—гипслы кулымны микрофон ягына төбәп "Черек күлгә" артым белән борылып бастым.

Митинг кинәт башланып китте. Ораторны—оратор, милләтне—милләт, аләмне—аләм алыштырды. Чыдасын колак, түзсен тел...

"Иптәшләр, Әфәнделәр!!! Бүген дә кояш чыкмаячак, чөнки аяз күгебезне һаман империя байрагы каплап тора. Без дүрт йөз ел буе Мәскәүгә алимент түләдек. Азатлык дигәннәрне талонга гына. Балтыйк буе республикалары талоннарын отоваривать итте инде. Гафу итегез, отоваривать дигән сүзнең

татарчасы юк, урыслар уйлап тапкан аны. Азатлыктан курыкмагыз! Күрми күргән кешегә генә куркыныч тоела ул, бер ияләшсәң аның берние дә юк. Ач булырбыз, ялангач калырбыз, әмма азатлыкны яуларбыз... Азатлыкка килеп життек инде, әфәнделәр! Азатлык! Азатлык! Азатлык! Митингны ачык дип белдерәм. Татарны күпме печәргә була инде, Әфәнделәр?!"

Урамдагыларга кушылып мин дә өч тапкыр "Азатлык" дип кычкырдым. Пьедестал биек минем, ишетмәгәннәрдер әле. Бөтен кеше кычкыра монда.

"Туганнар! Безгә өч президент кирәкми, икесе житә. Безнең жөмһүрият мөстәкыйль яши ала. Башкаларга караганда хәлебез авыррак... КамАЗны сатып бераз акция эшләдек, Акция татар сүзе ул, туганнар, ягъни мишәрчә акца-акча сүзеннән алынган. АЭСны сүтеп бераз төзелеш материаллары әтмәлләдек, нефтебез агып бетте дип тә пошынмыйбыз—жир астына күмелгән торбалары үзебезгә калды.—Алабуга заводында машина чыгара башласак, металлга ярап тора ул безгә. Мөмкинлекләр бар әле... Мари, Чуваш, Мордва, Удмурт, Башкорт дәүләтләре белән чиктәш авылларның көтүләрен суеп тапшырсак, партиянең мөлкәтен конфискацияләсәк, депутатларның окладын киссәк, Кабан күле төбендәге алтынны эзләп тапсак—финанс хәлләребез яхшырыр. Алдагы кышны исән-имин чыгарбыз, упшым... Аллага шөкер, чират торырга иренмәгән кешегә кибетләребездә ит тә, май да житәрлек. Америка татарларына үзебезгә кайтыр өчен рөхсәт бар, кайтучы гына юк әлегә..."

Урланган һәйкәлне тапсалар да көндез мине алмаштыра алмаслар инде. Митингның таралганын көтәрләр. Ә митинг кызганнан-кыза бара... Олы микрофонны вак микрофоннар сырып алды. Микрофон-мегофон житмәгәннәре болай гына кычкыра. Тегендә хор бәхәсләшә, монда—трио, анда—дуэт, кайдадыр солисткалар акыра.

"Яшәсен анархия! Бөтен байракларны бергә кушсаң—кара төс чыга. Автономияләрне союздаш итәргә, союздашларны союздан чыгарырга!"

"Мөселман кардәшләр! Дуңгыз фермаларын ябыгыз! Бөтен ирләргә никах иреге! Маржа хатыннарыгызны аерыгыз!"

"Яшәсен КПССка дан! Ленин идеяләре мәңгелек! Капитализм төзүчеләрнең мораль кодексы юк!"

"Яшәсен демократия! Илдә 1917 нче елгы ситуация. Россия 1919 нчы елгы чолганышта калып бара. Алда 21 нче елгы ялгышны кабатламаска! 37 нче елда кергәннәрнең хәзер илле ел партстажы бар. 41-45 нче елда кырылган самолетлары-танклары өчен дустыбыз Германиягә контрибуция түләргә! Тарих 85 нче елдан башлана. Безгә тагын 500 көн кирәк. 7 плюс I ничә белән бетте? 9 плюс I нең жавабы кайда? 15 не унбишкә бүлгәч ничә кала? 2 нче апрель I нче апрельне өшкерде..."

"Шалишь! Беләбез демократларны! Милли мәсьәлә турында сүз кузгалса эче киткән мәктәп баласы шикелле 93 демократ сессия залыннан чыга да китә, чыга да китә. Казан трамваенда утырып йөргән Рәсәй патшасы Иван Грозный нәселеннән! Безгә бердәмлек житми. Жөмһүриятебезнең яшь партияләре байракларны еш алыштыра. Һава торышына карап үзгәрә торган япон материалларын гына күтәрәсе калды инде. Ә безнең кибетләрдә байрак тегәрлек тә яшел чүпрәк юк. Халыкны ыштансыз калдырдылар. Мә сиңа алтмыш тәңкә—бир миңа меңне. Эт көне. Этләр белән гомер-гомергә тәжрибә үткәргәннәр. Павловлар әйтә, имеш, ач эткә ризык бирер алдыннан ут яндырып өйрәтсәң аның селәгәе ага башлый ди. Шартлы рефлекс, ягъни мәсәлән. Ахыр чиктә ризык бирмичә ут кына яндырсаң да селәгәе ага ди этнең. Павловлар теориясенең дәреслеген тикшерер өчен хәзер бөтенебез дә зәңгәр ут яктысына карап утырабыз. Тигезлек юк, тигезлек мунчада гына була, мөхтәрәм милләттәшләр, чөнки мунчада демократлар да ялангач..."

Көз озын килде быел. Аяк астында коелган яфраклар уйнашмаса тәки жәй дип белер идең. Августның егермеләрендә үк саубуллашып йокыга талган чебеннәр янадан уянып мәйдандагы эчке эшләләрнең күнитек балтыры тирәсендә бөтерелә. Микрофон тирәсендәге кансыз халыкны черки талый. Шөкер, мина черки каныкмый, алар да һәйкәл дип уйлыйлар ахрысы.

Кичкә таба акча эшләүләре кыенлышты... Кулның гипсы күтәргесез авырайды. Аяк арыды, алжыган гәүдәмне әле бер, әле икенче аягыма авыштырып басам. Мәйдандагыларның таралырга исәбе юк. Әле дә ярый бәхетем бар икән—сессия йокларга кайтып китте һәм ораторлар комарланып аларга иярде, көне буена янгыраган чыгышларның кыскача тезисларын депутатлар күз алдыннан таралганчы кычкырып бардылар.

Ирек мәйданы умартасы качкан оя кебек тынып калды. Мин жиргә сикереп төштем. Шадра капитан килгәнче шушы тирәдә йөреп торам. Кекин ашханәсенә кереп тамак ялгап чыктым, Тинчурин театры буфетына кереп кайнар кофе эчтем—арыганнарым онытылды. Эш урыныма кире килеп һәйкәлем төбендәге горзеленхоз түтәленә сузылып яттым. Шадра капитанын килгәндә йоклап ятма, хезмәт хакынны кисәр, дип әйтергә теләгәндәй, черкиләр ябырылды. Төнге сменада эшләүләре жинелрәк инде анысы... Төнлә белән һәйкәлләрнең бөтенләй кирәге юк, теләсәң бас, теләсәң ял итеп утыр, теләсәң пьедесталында ятып йокла...

Ятам шулай ял итеп, күккә карап, йолдызлар үзләрен санарга ирек бирми—җем-җем килә. Баш астымда өченче кат чабылганнан соң тырпаеп калган печән камылы. Бер кулым күкрәктә, гипслысы—читтә ята... Кинәт борын төбемдә өч пар спартак ботинкасы килеп туктады. Күземне ярым ачып ярыктан гына күзәтеп ятам тегеләрне: өчесенә бер калфак, ике чалбар, бер трико штан, бер күлмәк, бер футболка, бер майка...

—Бәреп төшергәннәр,—диде күлмәксезе.

—Монысын кечкенәрәк иткәннәр,—диде чалбарсызы, мине адымлап үлчәп,—безнең хәтлек кенә бу, култыклап алабыз да кеше итеп апкайтабыз.

—Нишләп җәяүләп? Таныйлар бит аны,—диде кепкалысы.—Тегесе шикелле самосвалга ыргытабыз. Син,—диде ул, күлмәк кигәнгә ымлап,—саклап тор, без хәзер машинаны алып киләбез.

Күлмәклесе үзе генә калгач, иптәшләренә эшне жинеләйтергә теләпме, мине аягымнан тотып юл читенәрәк сөйрәмәкче иде. Кеше-фәлән күзәтеп тормый микән дип як-ягына карануы булды, минем сикереп торып гипслы кулым белән инсәсенә тондыруым булды... Ул "үтерәләр!", дип бер якка, мин мыштым гына икенче якка тайдым. Куак аллеяларын чыгуга, пинжәгемне салып урталай бөкләгән килеш гипслы кулыма әллем дә берни белмәгәндәй, тамашаның дәвамын карарга дип янә һәйкәл янына килдем. Килсәм—юл читендә "ГАЗ" самосвалы, номеры хәтердә калырлык. Ә һәйкәл төбендә, шадра капитанга теге өч адәм... Юк, икесе дәшми, күлмәк кигәне генә тотлыга-тотлыга аңлатма бирә:

—Аны бәреп төшергәннәр, мин чәчәк бәйләме китергән идем. Кемдер арттан килеп күсәк белән томырды да пеләшбашны сөйрәп китте.

Мине күрүгә шадра капитан шаркылдап көлмичә чак түзеп калды.

—Ярар,—диде ул,—бу агайлардан тизрәк котылырга теләп,—төн озын әле, янасын койдырырбыз.

—Алайса сез аны көмештән ясагыз,—диде күлмәкле,—күтәреп китмәслек булсын. Юкса, бүгенгесе калай гына иде.

—Каян беләсең,—диде шадра капитан күлмәкледән мәзәк ишетергә теләгәндәй елмаеп.

—Белмәскә, шалтыр-шолтыр өстерәп киттеләр бит аны.

Өйгә кайтыр алдыннан бүлеккә кереп постны тапшыру турында журналга

кул куясы бар иде әле. Шадра капитан минем алда гаепле кеше кебек юл буе сөйләшмәде. Беләм инде гаебен—минем калай игезәкне тапмаганнар. Тиз генә тапмаслар да! Мин исә теге машина хакында ләм-мим... Әйтмим! Авырлыкка авыр булса да төшемле эшне тиз генә югалтасым килми. Хәзерге заманда җинел эш юк. Менә, митинглар беткәч бераз отпускы алырмын. Сессияләр, митинглар юк чагында минем дә кирәгем юк. Теләсәм һәйкәл булырмын, теләсәм—кеше. Тыныч көндә әллә бар син, әллә юк. Бик ялыктырса инде эш урынымны алыштырырмын, һәйкәлне түгел, урынын гына. Минем чырайга эш бетәсе юк, әйтәм ич, безнең калада гына да алтмышлап игезәк сыным бар минем. Теләсәм башка шәһәргә дә күчеп китәм, валютага кызыксаң, элеккеге дус дәүләтләргә чыгып керергә дә була. Кыскасы, мин үз гомеремә җитәрлек эш табам. Ә сез, үз җаегызны үзегез карагыз инде, иптәшләр, товарищлар, милләттәшләр, якташлар...

## III

Бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы кайдадыр себерелеп кайткач (хатын жаргоны, алга таба х. ж. дип кенә куярбыз), җитмәсә табындагы ризыкка ис китмәслек итеп тыгынып та кайткач (х. ж.), хатын иртә белән дә дәшмәде. Бик теләсә ул унбишәр көн буе сөйләшмичә түзә ала. Артыграк та түзәр иде—айга ике тапкыр коры зарплата (х. ж.) апкайтып өйрәттем үзен. Учына салган акчаны бер кат санап чыккач сораулары күбәя аның.

Коры-сары белән тамак ялгап көнозыны аяк өсте торырга чыгып киттем, әмма хатынга сер бирмәдем. Мин Ирек мәйданында һәйкәл булып эшлим дип әйтеп кара син аңа... Өйдә телефон бар, тота да психушкага шылтырата. Бер көнне мин ана ялгыш, Надюша, дип дәшкән идем... бәбәген өшегән бәрәнге шәе акайтып (х. ж.) тизрәк телефонга барып ябышты. Ул бер нульне җыйганчы шнурны кисеп кенә котылдым.

Хатын белән иртә таңнан заочно әрләшеп йөреп эшемә соңга калганмын. Килсәм, митинг инде башланган, мине көтеп өмете өзелгән шадра капитан мәрмәр пьедесталга үзе менеп баскан. Ичмасам фуражкасын да салмаган, бөегем. Килбәтен күр син аның—килештерә бит, тәки. Кулын да дөрес итеп Европа ягына сузган, учын гына өскә таба каратып тоткан, хәерсез... Мине күргәч сөенеченнән авып кына төште теге.

—Кайда йөрисен син?! Прогульщик!—ди бу мине һәйкәлгә таба этә-төртә. Мәйдан халык белән тулы. Бар инде, кеше-кара күргәнче мен тизрәк кунычаңа.

—Хезмәт хакымны арттырыгыз, аннан соң менәм. Совнарком председателе окладына хатын риза түгел,—дигән булам һәм үзем ашыкмыйча гына тәмәке кабызам.—Даешь президент окладын, митингка барам да фаш ителәм.

—Мин сине хәзер менә шушы омон таягы белән, үзем фаш итәм!

—Алайга китсә мин баскан урынымда уникe сәгатьлек байкот ясыйм! Мин... мин... мин шагыйрьләргә кушылып ачлык игълан итәм, белдеңме?!

—Ну, ярар инде, ярар, син дигәнчә булсын. Үҗәт! Бу хәтлек һәйкәленә охшасаң да охшарсын икән. Мәйдандагы авазлар боза сине. Бар инде тизрәк, менеп бас!

—Менеп басам, ләкин килешү ышанычлырак булсын өчен төш вакытында ярты окладны кесәмә аванс итеп саласыз, юкса...

—Ярар, ярар дидем ич инде, бар!

Иренеп кенә менеп бастым. Эшлисе килми бүген, әллә больничный аласы инде, таныш логопедым да бар, яза да бирә больничныйны. Белмим, аванс алгач кына үзгәрмәсәм...

Бик тавышлы мәйдан бу. Житмеш ел буе халыкны шушында җыеп "УРА"

кычкырттылар, инде жиде ел буе кычкыртып сүгәләр. Кайда нинди яңалык ишетелсә шушы мәйданга йөгереп киләләр. Көн саен мәйданга йөреп, митингдашлар инде тәмам туганлашып беткәннәр, килү белән үзара кул бирешеп күрешеп чыгалар.

Митинг дәвам итте.

“Яшәсен—гуманизм! Радикаллар партиясенә язылыгыз! Берьеллык взносы нибарысы 25 сум. Курыкмагыз, мондый взнос белән безнең партия бервакытта да рулевой була алмаячак. Барлык илләрнең люмпен-пролетарийлары, берләшегез! Демократларга иярмәгез, центристларга ышанмагыз, коммунистларны идән астыннан чыгармагыз, либералларга таянмагыз, милләтчеләрне тыңламагыз!.. Без һәрвакыт сезнең белән!”

“Бөтен влач сельсоветларга! Базары—шәһәргә! Фермерлар сезне ач-ялангач итмәс. Жир барыбызга да житәрлек. Без күрше дәүләтләр белән горизонталь мөнәсәбәттә. Кулга тигән байлыкны вертикаль файдаланмыйк. Жир барыбызга да житәрлек—көрәк калынлык туфрагы арендаторларга, метр ярым тирәнлегендәге катламы “Водоканал”га, йөз метргача тирәнлеге карьерларга, ә инде мең метрдан соңгы катламнары—нефтяникларга. Эш сүзенең аваздашлары күбәйде, ә авылда кызу урак өстендә авызга бер кашык су салырлык та кеше юк! Менә мин әле дә яңып-көеп авылдан килдем. Шәһәрегездә житмеш сырахәнә бар—әйтергә оят, шушы көнгә кадәр сыра сөючеләр партиясе төзи алмыйсыз...”

Обком бинасына альтернатива итеп салынган Опера театры янына егерме “Икарус” килеп туктады. Күрсәгез икән!.. Чулман аръягындагы тугандаш шәһәрләрдән Яшь гвардиячеләр килгән! Аларны иллеләп вездеходка төялгән сенат укчылары елмаеп каршы алды. Яшь гвардиячеләр икаруслардан таш бушаттылар, аларга җавап итеп укчылар калкан тезде. Монарчы гамьсез генә сагыз чәйнәп фәрман көтеп йөргән ОМОНчылар күз ачып йомганчы тезелешеп тимер бәдәннәрен киереп басты. Мин камалышта калдым. Гипслы кулымны төшереп хәл жыям, кирәге чыгар. Дулкынланудан муеным якага, күкрәгем жилетка, аякларым туфлиемә сыймый башлады. Мин көрәшкә әзер, ләкин баррикаданың кайсы ягына басарга?! Теге якка чыгар идем—яшерен-батырын түгел, Рәсәй министрына буйсына торган эчке эшләрдән зарплата алам, уң якта калсам Ижтимагый үзәкнең күзенә ничек күренермен?! Икеләнеп торуымны сизделәрме—Яшь гвардиячеләр ин беренче ташны мина томырды. Ну жегетләр, башны иеп калмасам пеләшемә кутыр чыгаралар (х. ж.) иде. Болайга китсә омономны укыталар минем, төшеп качарга кирәк лутчы исән чакта. Юлбашчылар өчен баш белән таш чүпләп торыр хәл юк монда... Сикереп төшәм дигәндә генә шадра капитан килеп житте, ул үзенә кассирша кызны иярткән.

—Син, ярты получканы алдан ук биреп куешлы дигән иден. Пожалысты, менә монда гипслы кулыңны куй.

—Вакытын белеп кенә йөрисез инде түлке,—дидем мин авыр кулым белән ведомостька имза куеп.

Кассирша кыз үрелеп кенә минем кесәгә акча төргәге салмакчы иде—буе житмәде. Жинел сөякле икән үзе, сикереп менде дә яныма—шалт кесәгә акчаны! Янәдән жиргә сикерергә өлгермәде... Хатын сөйрәп төшерде тегене... Ну, шадра капитан да югалып кала торганнардан түгел икән: синең ишеләрне генә күргән без дигәндәй, минем хатынны читкә селтәп ыргытты... Әле ярый мәйданның бездә гаме юк, халык Яшь гвардиячеләрдән мажара көтә. Мин дә озак уйлап тормыйм—хатынга ярдәмгә дип аяк астына сикерәм. Ә хатыным шуны гына көткән икән—эләктереп алып, сарык кыркыгандай, муенымны бот арасына кыстырып, барлы-юклы чәчемне йолкып пеләшемне зурайта башлады.

—Әле син, карт азгын, обком каршысында кызлар белән аягүрә...

Безнең илдә кичә генә цензураны бетерделәр. Шулай да хатынның миңа атап әйткән башка сүзләрен кабатлый алмыйм. Башны хатынның бот арасыннан көчкә тартып алдым. Шул шатлыктан патетик рух белән укчылар бөжрасын өзеп Яшь гвардиячеләр ягына чыгып бастым. Хатын минем арттан! Кемлегемне онытканмын, карт юләр, яшьләр мине шундук уң якка очыртып чыгардылар. Хатын Яшь гвардиячеләр ягында калды, калды гынамы—"Икарус"ларга Киндер карьерыннан төялгән кырлы-кырлы ташларны минем өскә томыра башлады, аннан күреп башка гвардиячеләр дә пролетариат коралын укчылар өстенә яудырдылар. Китте атыш, китте дөмбәсләү, китте куышу... Кем кемне кулга алырга белми, чөнки граждански киенгән кешеләрнең бик күбесе үзләре кулга алучылар булып чыкты. Мәйданны сирәгәйтер өчен сул якны калай савытлы машиналарга төяп ташыдылар.

Мин, ыгы-зыгыдан файдаланып, әкрен генә үземнең эш урыныма менеп бастым. Нишлисең бит, бу болгавыр заманда һәркемнең үз эше... Хатын юкка чыкты—аны да калай машинага төяделәр, ахрысы, ичмасам мин эшне бетергәнче генә тотсалар ярар иде.

Кайтып кесәдәге акчаны биргәч бәхилләтәм мин аны.

Мәйдандагы чуалыш митингка дәрт өстәде. Аз гына фикере булган кешенең дә хәзер микрофонга барып җитәрдәй сабырлыгы юк—кайда баскан, шунда сөйли... Алла каргаган мәйдан булды бу! Иртәгесе көн минем өчен ни белән бетәр? Җае килүгә эшне алыштырырга кирәк, эшне түгел инде, урынны,—дип уйлап бетерүемә шадра капитан килеп җитте. Кыяфәте—туктаусыз ике машина утын төягән диярсең!

—Бүген табабыз синең һәйкәлне.—Ул аяк чолгавы хәтлек кульяулык белән бит-кулларын сөртте, формасын тәртипкә китерде.—Тапкан кешегә ике президент оклады күләмендә премия игълан иттек.

—Кемгә кирәге бар ул акчаның! Сез лутчы төсле телевизор бирегез,—дидем мин өемдәге кылка "Рекорд"ымны искә төшереп.

—Телевизор?! Ә нишләп тузан суыргыч түгел?

—Ул да ярый. Холодильник белән кер юу машинасы бирсәгез дә риза.

—Тапсыннар гына, ни теләсәләр шуны бирербез.

—Алайса үзем табам һәйкәлне! Миңа комачаулама! Әнә, олы микрофонга кил дә демократлар исеменнән берәр нотык сөйлә. Калганы минем эш.

"Мөхтәрәм милләттәшләр! Җөмһүриятебезнең статусын тагын да күтәрү өчен тәхет белән идарә итүгә күчәргә һәм беренче королева итеп сайлау өчен үзебезнең Ана төрекне, айлар буе ач торып та исән калган чын совет гражданкасын—депутат..."

Микрофонны шадра капитан йолкып алды.

"Без бүленмәс Россия!!! Татарлар, уйланыгыз, сезне өйдә маржа хатыннарыгыз көтә! Коммунистлар коткысына бирелмәгез!"

"Коммунизмга юл юк! Социализм үз-үзен акламады! Капитализм безне күчтәнәчләр белән сатып алмакчы! Африка илләре белән киңәшеп карарга кирәк!"

"Дары заводларын ябарга!"

"Нефтьне туктатырга!"

"Болыннарны су астыннан чыгарырга!"

"Бөтен һәйкәлләрне җыеп алырга, Ура!!!"

"Демонтаж! Демонтаж! Демонтаж!!!"

Тагын кич җитте. Эш сәгатем бетәргә ике сәгать чамасы вакыт калды. Мәйдандагы карангылыктан коты алынгандай, баганадагы лампалар һәр куак төбен тикшерергә теләп яктырта. Шунысы гаҗәп, миңа бүген чәчәкләр китерделәр, дөрес, кемнәрдер аны җыеп та алып китте. Кин чалбарлы

малайлар пумаланы буяуга манып минем нигезгә тыелган сүзләрнең исемлеген теркәде. Көн саен шулай. Бу мәйданнның этләренә чаклы аполитичный—ул ана этләрне куып тоткач, ник минем аяк астына сөйрәп алып килергә кирәктер инде?!.

Этләр белән ырылдашып торган арада күземә дүрт прожектор китереп терәделәр: олагаем автокран белән теге таныш "ГАЗ" самосвалы. Иске танышлар: өчесенә бер калфак, ике чалбар, бер күлмәк, бер майка... Килә килешкә үк вакыт әрәм итмичә, билемә аркан урап кран белән самосвалга күтәреп салдылар. Күптән, бик күптән ачык машинада утырып йөргәнем юк иде инде, аска салам җәйгәч аунарга рәхәт икән үзе. Шулай да рәхәт белән мавыгып онытылмыйм, юлны карап барам, кире кайтасы да бар бит әле! Казанны чыктык, Аккош күленә життек, сулга борылдык... утыз жиденче елларда төзелгән ярымжимерек дачалар арасында тукталдык. Озак маташмадылар, ике эт өргән арада, өч борын жиргә коелып, минем һәйкәлдән урланган калай юлбашчыны машинага ыргыттылар. Өстемә төшеп изәдер иде—читкә тәгәрәп өлгердем. Өч борынның берсе: "кайсыбызның гаражына яшерәбез?" дип сораган иде, бәхәс китте. Ник сина да ник мина, кая да кая?!. Туйдым бәхәсләреннән.

—Алга, иптәшләл, коммунизмның тулы жинүенә!—дидем мин һәйкәлдәгечә горур басып, гипслы кулымны алга сузып. Тегеләрне күрсәгез, куркуларыннан өч якка чәчелеп, караңгылык эчендә эреп юкка чыктылар, ыңгырашулары гына ишетелеп калды. Ә мина шул гына кирәк тә: малксизм-ленинизм идеяләле мәңге яши!—Кузовтан тиз генә очып төшеп кабинага үрмәләдем. Машина йөртергә безгә куш! Аккош күленнән Черек күлгә—ун минутлык юл, шикләнә-нитә калсалар бернинди инспекторларга да туктап тору юк, үзебез милициядә эшлибез.

Милиция бүлегенә кайтып кергәч, шадра капитанымны танымадым—чырае айсыз төн кебек. Ә стена тирәли тезелгән урындыкларда Дзержинский, Маркс, Вахитов, Жәлил, Горький, Тукайларга охшаган агайлар тезелешеп утыра. Беләм мин аларны, партҗыелышларда күрешкәнем бар. Чорыбызның бөтен даһилары, каһарманнары милиция бүлегенә допроска жыелган кебек.

—Университет каршындагы мәйданнан тагын юлбашчыны урлаганнар,—диде шадра капитан теге һәйкәлгә охшаган агайларны журналга теркәгән арада.—Сине алмаш-тилмәш ике урынга куя алмыйбыз бит инде...

—Телевизорыңны давай! Алып кайттым мин аны. Ирек мәйданында үзе басып торыр. Ә мин—Университет янына. Әллә боларның һәйкәлләрен дә урлап бетергәннәрме?—дидем мин яна һәйкәлдәшләремә таба ымлап.

—Авызыңнан жил алсын! Әлегә ул-бу юк. Дөнья хәлен белеп булмый, хәстәрен алдан күреп таныша торабыз.

Төсле телевизорны күтәреп кайтып кердем өйгә. Иртәгә тагын эшкә әзерләнәсе. Күрше малайларның туган тел китабыннан юлбышчыбызның яшь чагын табып бераз образга керә тордым. Хатын да әзерләнә. Иртәгә Ирек мәйданында демократлар митинг үткәрмәкче була ди, шунда күрше мәмләкәтнең президенты портретын күтәреп йөрергә жыена. Не позволю! Бер өйдә ике төрле партия яши алмый!

Телевизорны кабыздык. Анда Ирек мәйданын күрсәтәләр. Минем эш урынымда чын һәйкәл хәзер. Булса ни! Мина эшнең бетәсе юк. Иртәгә Университетка, ә салкыннар башлангач мемориалга...

Так што, агайлар, дус-ишләр, туган-тумачалар, күрше-күләннәр, танышбелешләр, һәйкәлләргә таш ыргытканда берүк саграк кыланыгыз!

*Мең санның бер чаткысы*



2006 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 1000 нче САНЫ ДӨНЬЯ КҮРӘ

*Хроника*

**1935 елда күпме матур әдәбият китабы басылган?**

1935 елда Татгосиздатның матур әдәбият секторы барлыгы 54 исемдә матур әдәбият китабы басып чыгарган. Шуларның барсының басма табак исәбе—366, тулы тиражлары 362 мең 445 данә. Табак саны буенча еллык планның үтәлеше—72,71 %, тираж буенча—69 %.

Балалар һәм яшьләр әдәбияты секторы буенча барлыгы 60 исемдә китап чыгарылган. Барлыгы 166 табак, тулы тиражы 548.150 данә. Еллык планның үтәлеше—тираж буенча 75 %, табак саны буенча 59 %.

**Казан эшчеләре консерваториягә һәм балет мәктәбенә укырга баралар**

Казанда булып үткән үзешчән сәнгать олимпиадасында эшчеләр арасында күп кенә күренекле сәнгать һәвәскәрләре барлыгы беленгән һәм шулардан берничә иптәш аеруча югары бәя алганнар иде.

Хәзер шулардан Язу машиналары заводы эшчесе Мостафа иптәшне металлистлар Союзы Үзәк Комитеты Мәскәү балет мәктәбенә, ә Төзү эшчеләре Үзәк Комитеты җыры белән танылган төзү эшчесе иптәш Исхакованы Мәскәү консерваториясенә укырга җибәрергә булды. Бу иптәшләр бу мәктәпләргә керү өчен хәзерләнәләр.

**2.207.500 стабиль дәреслек**

Татарстан дәүләт нәшрияты - "Татгосиздат" бу елны 2.207.500 стабиль дәреслек чыгарды. Аларның 95 проценты татар телендә чыгарылды. Үткән, 1935 елны бөтенесе 1.838.650 дәреслек чыгарылган иде.

*(Совет әдәбияты.—1936.—№2.).*

# Uqucı süze
# Укучы сүзе

Хөрмәтле "Казан утлары".

Әй, яратып та укыйбыз соң үзеңне! Гаиләбез белән көтеп алабыз. Шәп чыга журнал! Олы Салтык авылындагы дәү апабыз кочагы белән алып китеп укый. Инде 40 елга якын алдырабыз бит сине. Рәхмәт шунда эшләүче хезмәткәрләргә, рәхмәт безне үзләренең әсәрләре белән сөендерүче язучыларга, публицистларга, галимнәргә...

Кайчакта "Укучы сүзе" рубрикасында минем кебек гади укучыларның да фикерләре басылып куя. Шуңа да яратып укыйбыз, ахры.

70-80 елларда телевидениедән күренекле язучыларыбызның әсәрләре буенча эшләнгән телефильмнар, телеспектакльләр күрсәтелә иде. Алар безгә, укытучыларга, аеруча татар теле, әдәбияты, тарих укытучыларына һәм укучыларга һава кебек, су кебек кирәк бит. Дөрес, хәзер язучыларның бик күп әсәрләре мәктәп китапханәләренә кайтты, шөкер, сөенеп бетә алмыйбыз, хөкүмәтебезгә, нәшриятка рәхмәт. Ләкин әсәрне уку үзе бер ләззәт булса, аның нигезендә эшләнгән телефильмны яки телеспектакльне карау икенче бер рәхәтлек ала торган хикмәтле шөгыл; чөнки анда күренекле артистлар, яшь артистлар белән очрашасың, режиссер белән танышасың, гомумән, фикерләр, уйлар тагын да байый төшә.

Мәсәлән, Ә. Баяновның "Тау ягы" повесте буенча эшләнгән телефильмны тамашачы бик яратып карады дип беләм. Ә безгә, укытучыларга һәм укучыларга шулкадәр кирәк ул. Йә булмаса Г. Ахуновның "Идел кызы" романы нигезендә эшләнгән "Габбас хәзрәт", М. Хәсәновның "Язгы аҗаган"ы, Т. Миңнуллинның "Үзебез сайлаган язмыш"ы һ. б. Яшьләрнең бу әсәрләрне укыганнары да, караганнары да юк. Алар безнең программаларда бар югыйсә. Аннан соң бит әле безнең ТНВны хәзер бөтен татар дөньясы карый ала. Ник рәхәтләнеп, сөенә-сөенә аларга тәкъдим итмәскә ул телефильмнарны. Ник башка әсәрләр нигезендә дә телеспектакльләр, телефильмнар эшләмәскә?! Бар бит безнең андый әсәрләребез. ТНВның программасы да баер иде, тамашачысы да артыр иде. Мин моны ни өчен "Казан утлары"на язам, чөнки бу журналны мин татар вакытлы матбугатының алтын баганасы дип саныйм, иң дәрәҗәле журнал бит ул. Икенчедән, бөтен язучыларыбыз, тәнкыйтьчеләребез шушы журнал тирәсенә тупланган бит. Язучылар үзләренең җыелышларында, утырышларында шушы бик кирәкле, халык өчен тәрбияви яктан бик әһәмиятле бу мәсьәләне күтәрсеннәр иде, тәкъдим ителгән фикерне тормышка ашырып, халыкны сөендерсеннәр иде.

Минем бу уй-фикерләремне игътибарсыз калдырмассыз дип ышанам.

Дуслар, сезгә исән-саулык һәм иҗади уңышлар!

**Мәдинә КӘРИМУЛЛИНА**

*Кама Тамагы*

## Фаяз Дунайга 70 яшь



Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә илленче еллар уртасында бергә укыган сабакташлары аны Фәсих Хисмәтуллин буларак беләләр иде. Башкалардан буй-кыяфәте белән дә, укымышы белән дә, әдәби даирәләрдә активлыгы белән дә аерылып торган бу егет ул вакытта ук инде шигырьләре, публицистик мәкаләләре белән матбугатта актив катнаша, каләмдәшләре иҗаты турында да төпле фикерләр әйтә иде. Өч курсны тәмамлауга ул язмышын журналистика белән бәйләде. Мөслим, Кайбыч, Балык Бистәсе район газеталарында эшләде. Чаллы төбәгендә мәһабәт Кама автомобиль заводы төзелә башлагач, романтик күңеле аны шул тарафларга тартып китерде—анда төрле административ вазифалар башкарды, университетны ул 1967 елда тәмамлады.

Кин катлау укучыларга ул Фаяз Дунай тәхәллүсе белән мәгълүм. Каләмдәшебезнең язмышы Әлки районының Алпар авылы белән бәйле. Ул анда 1936 елның 15 гыйнварында дөньяга килгән. Әдәбият белән бик яшьли кызыксынып китеп, әле югары уку йортына кергәнче үк иҗат сөенечен татый—ул аңа тора-бара иҗтимагый активлыгын арттырганнан арттыра барырга булыша. Татар халкының Мирсәет Солтангалиев кебек олпат затлары, Бөек Ватан сугышы каһарманнары, гади хезмәт кешеләре—аның очеркларында һәм публицистик язмаларында төп геройлар шулар. Шигъри әсәрләрендә ул ялкынлы мәхәббәтне, гаилә бәхетен, балалар шатлыгын төп тема итеп күтәрде. Аның “Иманнар какшаган дәвер”, “Таңнарның кадерен белеп” дигән китапларында ихлас публицистик рух тантана итсә, “Җанымның әрнүләре” исемле җыентыгы замана китереп куйган проблемаларны шигъри ачкыч ярдәмендә ача. Фаяз Дунай проза һәм драматургия өлкәсендә дә актив эшли.

Ф. Дунайның иҗат эшчәнлеге 1994 елда “Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе” дигән мактаулы исем белән бәяләнде. Ул—1992 елдан бирле Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## Солтан Шәмсигә 60 яшь



Язучы һәм тәрҗемәче, фәнни-тарихи темага багышланган күп санлы хезмәтләр авторы Солтан Шәмси (Солтан Сәләх улы Шәмсетдинов) 1946 елның 10 февралендә хәзерге Биектау (элекке Дөбъяз) районының Суыксу авылында туа. Юртыш авылында җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң Казанга килеп токарь һөнәрен үзләштерә. 1962 елда ул Мәскәүгә китә һәм ун ел буе башкала заводларында эшли. Совет Армиясендә булып кайткач Мәскәүдә полиграфист хезмәтен башкара, кичке урта мәктәпне тәмамлый.

1971 елда С. Шәмси Казанга кайтып К. Якуб исемендәге полиграфия комбинатында эшли башлый. 1972-1977 елларда ул Мәскәүдә М. Горький исемендәге Әдәбият институтында укый. Ә 1977-1985 елларда “Казан утлары” журналының проза бүлеге редакторы булып эшли. Соңгы елларда татар энциклопедиясе институтында хезмәт итә.

Әдәби иҗат өлкәсендә С. Шәмси тәрҗемәче һәм оригиналь проза әсәрләре авторы буларак билгеле. Тәрҗемәдә ул ике юнәлештә—татарчадан русчага һәм русчадан татарчага тәрҗемә итү юнәлешендә эшли. Г. Ибраһимов, М. Әмир, Л. Ихсанова кебек татар прозаикларының, С. Антонов, С. Воронин, И. Думбадзе һ. б. язучыларның хикәя повестьлары С. Шәмси тәрҗемәсендә дөнья күрә. 1984 елда аның хикәяләре "Көмеш чылбыр" исемле китапта басылып чыкты.

Соңгы елларда С. Шәмсинең фәнни популяр характердагы "Ибн Фадлан китабы" (2000), "Низаглы йортта" (2002) җыентыгы дөнья күрде.

Бу айда Солтан Шәмсигә 60 яшь тулды. Журналыбызның даими авторы булган Солтан Шәмсине юбилее белән кайнар котлыйбыз, аңа ныклы сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез!

---

## *Мең санның бер чаткысы*



2006 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 1000 нче САНЫ ДӨНЬЯ КҮРӘ

### Татар әдәбияты һәм язучылары турында

"1944 елның 10 январенда Берлиндагы Моабит төрмәсендә палач балтасы бер шагыйрьнең башын чабып өзде. Шунысы гаҗәп, безгә, атып үтерелгән Гарсия Лорканың исемен ишетеп җаны тетрәгән, атылган Жак Декурның соңгы сүзләрен яки нацистлар тарафыннан асылган Юлиус Фучикның төрмәдә язган китабын тын да алмый укып чыккан французларга, ул совет шагыйренең хәтта исеме дә билгеле булмады. Бу безнең өчен оят иде. Бу кеше үзенең һәрбер туганы—Казандагы һәм Новосибирскидагы, Одессадагы һәм Сәмәркандтагы, Владивостоктагы һәм Ленинградтагы, Тбилисидагы һәм Ригадагы туганнары өчен үлде. Ул шулай ук безнең өчен—французлар яки чехлар өчен дә үлде. Ул д'Этиен д'Орве яки Пери кебек үк үлде..."

Луи Арагон
*француз язучысы.*
*("Совет әдәбияты", 1957, № 11)*

• • •

*Хроника*

### Әдәби дискуссия

22-24 январьда Язучылар союзының Габдулла Тукай исемендәге клубында "Татар шигыренең төзелеше" турында әдәби-теоретик дискуссия булды.

Дусларча бәхәстә катнашу өчен тугандаш республикалардан килгән кунаклар: Казахстаннан Зәки Әхметов, Бейсембай Көнҗебаев, Башкортстан АССРдан Мостай Кәрим, Нәҗар Нәҗми, Шәриф Биккол, Муса Гали, Гыйлемдар Рамазанов, Гайса Хөсәенов, Әхнәф Харисов, Каракалпак АССРдан Җомаморатов катнашты. Тәнкыйтьче Хатип Госман һәм шагыйрь Хәсән Туфан доклад ясадылар. Фикер алышуларда Әхмәт Фәйзи, Г. Хөсәенов, Ш. Маннур, Н. Исәнбәт, С. Баттал, Х. Курбатов, Ә. Исхак, Ш. Сайганов, З. Әхмәтов һ. б.лар катнашты.

*("Совет әдәбияты", 1958, № 2)*

## Гамир Насрыйның тууына 90 ел

Күпләгән каләм ияләренә хас булганча, Гамир Насрый үзенең әдәби эшчәнлеген шигърият яки прозадан түгел, әле яшүсмер чагыннан ук драма әсәре язудан башлый. Уналты яшендә аның беренче "Ялкау Бикмөхәммәт" исемле дүрт пәрдәлек пьесасы дөнья күрә. Әлеге әсәреннән үк ул үзен үткен телле, вакыйгаларны тормышчан кора белүче драматург итеп күрсәтә.

1916 елның 3 гыйнварында Башкортстанның Кызыл Кама районы, Иске Янжегет авылында туып, башлангыч белемне авылда алып, жидееллык мәктәпне Казанда, 1934 — 37 елларда Казан театр техникумында укып, тормышның ачысын-төчесен күп татыган, үзен төрле һөнәрләрдә сынап караган Г. Насрыйның ун елга якын гомере Совет Армиясендә хезмәт итүгә китә. Ул ак финнарга каршы сугыша, аннары Бөек Ватан сугышында катнаша, орден-медальләргә лаек була. Һәрбер иҗат кешесе кебек үк сугышта да әдәби эшчәнлеген ташламый, фронт газетасында хәрби корреспондент булып эшли.

Шулай да, Гамир Насрыйның иҗаты тулысынча ачылу сугыштан соңгы елларда була. 1947 — 49 елларга кадәр Татарстан радиокомитетында драматик һәм музыкаль тапшырулар редакторы булып эшләгәч, ул профессиональ язучылык хезмәтенә күчә. Бу елларда аның "Күнел дәфтәре", "Без капчыкта ятмый", "Идел буенда" исемле комедияләре туа. Тормышчанлык хас булган әлеге әсәрләр тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителеп, профессиональ һәм үзешчән театрлар репертуарында күренекле урын ала. "Яшел эшләпә" әсәре исә әле дә күпләребезнең күңелендә саклана булыр.

Гамир Насрыйның сәхнә әсәрләренә һәм аерым җыр текстларына композиторларыбыз С. Сәйдәшев, З. Хәбибуллин, Ж. Фәйзи, Р. Яхин һ. б. тарафыннан музыка һәм җырлар иҗат ителә, "Алтын көз" ("Идел буенда") музыкаль комедиясе (Ж. Фәйзи музыкасы) Татар дәүләт опера һәм балет театрында куела. "Сайра син, тургай", "Яз шатлыгы", "Хак булса әгәр" һ. б. җырлары да киң танылу ала.

Дүрт дистәгә якын сәхнә әсәре язган Г. Насрый башка жанрларны да читтә итми, аның сатирик шигырьләре, поэмалары ("Дилбәр" 1954, "Әшнәкәй" 1954) хикәяләре, очерклары басылган.

Г. Насрый 1940 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

1959 елның 27 декабрендә вафат була.

❋

*Берлекнең яңа әгъзалары*

## Салават Юзеев



Салават Илдар улы Юзеев 1960 елны Казанда туа. Ул 1982 елда Казан университетының математика һәм кибернетика факультетын тәмамлый, озак еллар буе Казан предприятиеләрендә инженер-программист булып эшли. 1999 елны, хезмәт эшчәнлеге профилен үзгәртеп, "Татарстан" телерадио компаниясендә эшли башлый. Мондый адымга бару, күрәсең, Салаватның балачактан ук әдәбият-сәнгатькә тартылуыннан булгандыр. Шулай ук, Казан университеты һәм Горький музее каршындагы әдәби берләшмәләргә йөрү уңай йогынты ясагандыр.

Салаватның әдәби эшчәнлеге әтисенең—халык шагыйре Илдар Юзеевның шигырьләрен русчага тәрҗемә итүдән башлана. Соңрак үзенең шигырьләре һәм хикәяләре дә дөнья күрә. Алар төрле газета-журналларда, альманах-җыентыкларда басыла ("Идел", "Комсомолец Татарии", "Вечерняя Казань", "Кают—компания", "Стихи казанских студентов", "Театр теней" h. б.). 2001 елда Татарстан китап нәшриятында "Мин монда калам" ("Я остаюсь здесь") исемле проза китабы басылып чыга. Ул китап Татарстан Язучылар берлеге һәм Милли китапханә оештырган "Ел китабы—2001" конкурсында уңай бәя ала. Шулай ук, аның кайбер әсәрләре халыкара яңгыраш таба. Ул 2003 елны Америкада булып, Нью-Йорк һәм Санта Фе шәһәрләрендә шигырь сөючеләр алдында чыгышлар ясый.

Салават Юзеевның иҗаты телевидение һәм кино сәнгате белән нык бәйләнгән. Ул, автор һәм режиссер буларак, 20 дән артык документаль фильм авторы. Алар арасында татар халкының олуг шәхесләре турындагылары да бар: Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Риза Фәхретдин, Муса Бигиев, Хәсәнгата Гәбәши, Садри Максуди h. б. Бүтәнрәк рухтагы башка документаль фильмнары—"Фелина, Вумен, Ханым", "Мәңгелек хакыйкатьләр яктысы" ("Свет вечных истин"), "Коллыкка юл" ("Дорога в рабство"), "Аккан сулар, искән җилләр" ("Текущие воды, Поющие ветры")... 2004 елны татар тарихы турында уйлануларга корылган, "Китмибез!" исемле фильмы да дөнья күрде. Үткән ел Татарстан китап нәшриятында "Тынлыкның җилле чаты" ("Сквозняк тишины") дигән яңа хикәяләр җыентыгы басылып чыкты.

2005 елда Салават Юзеев Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

## *«Казан утлары» архивыннан*



*Татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханның 90 еллык юбилее утырышыннан соң. Беренче рәттә—уңнан сулга: Мөхәммәт Садри, Хатип Госман, Гомәр Бәширов, Йолдыз Нигъмәтуллина, Нәкый Исәнбәт, Мөдәррис Мусин, Мостафа Ногман, Вахит Хаков, Флера Сафиуллина; икенче рәттә—язучылардан: Мөхәммәт Мәһдиев, Нил Юзиев, Хатип Миңнегулов, Зәет Мәҗитов...*
*1976 ел. Казан университеты.*



*Хатын-кыз язучыларыбыз. Уңнан сулга—Гөлчәчәк Галиева, Фирая Зиятдинова, Роза Мулланурова. Әдәбият-сәнгать әһелләренең Васильеводагы иҗат йортында.*
*2005 ел.*



*Шагыйрь һәм тәнкыйтьче Наис Гамбәрнең 50 яшьлек юбилее кичәсендә төшерелгән фоторәсем. Казан. Язучыларның Тукай клубы.*
*1997 ел.*



*Дөньякүләм атаклы язучылар Чыңгыз Айтматов (уңнан беренче) һәм Олжас Сөләйманов Татарстан Язучылар берлегендә очрашу вакытында. Казан. 2000 ел.*



*Язучы Факил Сафин.*



*Күренекле галим Хатип Госманны 80 яшьлек юбилее белән тәбрикләү. Уңнан сулга—Миркасыйм Госманов, Хатип Госман, арткы планда—Диләрә Тумашева, Флорид Әгъзамов. Казан университеты. 1988 ел.*

Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ОЛУГ ӘДИПНЕ ЗУРЛАУ

2005 елның 21 ноябрь көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында танылган язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның юбилеена багышланган иҗат тантанасы булып узды.

Әлеге кичә олуг драматургның 70 еллыгына багышланган чараларның иң югарысы иде. Бәйрәм мәрасимнәре язучының нәкъ туган көнендә, 25 августта туган авылы—Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында башланып китте. Татар театр сәнгатенең Туфанын олылаган юбилей кичәләре республикабызның Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләрендә һәм башка төбәкләрендә дә гөрләп үтте.

Туфан Миңнуллинның тормышын һәм иҗатын яктырткан рәсми тантананың нәкъ менә Камал театры сәхнәсендә үтүе дә очраклы хәл түгел. Драматургны классик дәрәҗәгә күтәргән "Әлдермештән Әлмәндәр", "Диләфрүзгә дүрт кияү", "Без китәбез, сез каласыз", "Моңлы бер җыр"... спектакльләре халык күңеленә нәкъ менә шушы сәхнә аша юл алды. Туфан Миңнуллин белән Марсель Сәлимҗановның иҗади хезмәттәшлеге күп еллар Камал театрының гына түгел, гомумән, татар театрының йөзен билгеләде. Һәм әле хәзер дә драматург шушы театр белән тыгыз иҗади элемтәсен дәвам итә. Г. Камал исемен йөрткән, академик рухын күтәрә барган театрның хәзерге баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев күптән түгел генә Туфан Миңнуллин әсәрләре буенча ике спектакль куйды. Шуларның берсе—"Галиябану, сылуым-иркәм". Драматургның сәхнәләштерелгән әсәрләре генә түгел, юбилей бәйрәме дә күтәренке рухта узды. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев һәм Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм башка рәсми житәкчеләр килгән иде. Татарстан Президентының ихластан әйткән котлау сүзләре, теләкләре кичәгә гаиләдәгедәй җылылык өстәде. Драматург иҗатына югары бәя биреп, ул Туфан Миңнуллин пьесаларын берләштерүче идея турында уйланулары хакында да әйтеп узды. Минтимер Шәймиев фикеренчә, Туфан Миңнуллин геройлары беркайчан да авырлыклар алдында баш имиләр, киләчәккә өмет-ышаныч белән яшиләр.

Татарстан Президенты Туфан Миңнуллинга "Татарстан Республикасының халык язучысы" дигән мактаулы исем бирелүе хакындагы Указга кул куюы турында да хәбәр итте һәм әлеге исемнең тамгасын юбилярга тапшырды. Бүләкнең тагын берсе—Туфан Миңнуллинның туган көнендә—2005 елның 25 августында Минтимер Шәймиев язучыны "Татарстан Республикасы алдында хезмәтләре өчен" ордены белән бүләкләү турындагы Указга кул куйган иде. Юбилярга шушы бүләк тә тапшырылды.

Туфан Миңнуллинны котлап, Татарстанның күренекле әдипләре Туфан Миңнуллинга һәм аның иҗатына үзләренең ихтирамлы сүзләрен ирештерделәр.

Юбилярны, әлбәттә, иҗади берлек, театр вәкилләре дә котлады. Оренбургтан, Башкортстаннан килгән кунакларның тәбрикләүләре дә кичәгә якты ямь өстәде.

## ФУНДАМЕНТАЛЬ ХЕЗМӘТКӘ—ЮГАРЫ БӘЯ

Президент М. Шәймиевнең "Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасының 2005 елгы Дәүләт бүләкләрен бирү турында" Указы басылып чыкты.

Әлеге абруйлы бүләккә "Татар энциклопедик сүзлеге"н әзерләүгә зур хезмәт куйган бер төркем галимнәр дә лаек булды. Алар арасында ТР Фәннәр академиясе президенты, Татар энциклопедиясе институты директоры М. Хәсәнов, директор урынбасары Гомәр Сабирҗанов, институтның өлкән гыйльми хезмәткәрләре Рәис Даутов, Венера Абзалова, Алевтина Гарзавина, бүлек мөдирләре Рәфыйк Мөхәммәтшин һәм Рафаил Шәйдуллин бар.

Татар энциклопедиясе—фундаменталь фәнни хезмәт. Анда Татарстан Республикасында яшәүче халыкның тарихи һәм хәзерге матди, рухи һәм иҗтимагый-сәяси тормышы киң чагылыш тапкан. Анда тиене булмаган фәнни мәгълүматлар җыелган, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының төрле архив чыганакларыннан шактый күләмдәге тарихи материаллар урын алган. Аларның күбесе исә әле

беренче мәртәбә генә дөньяга чыгарыла. Китап универсаль характерда. Ул борынгы заманнардан алып бүгенге көнгә кадәр булган белемнәрнең барлык өлкәләрен колачлый. Анда табигать, икътисад, фән, мәдәният, сәнгать, шулай ук Татарстанда яшәүче күпмилләтле халыкның һәм татар халкының танылган вәкилләре эшчәнлеге яктыртыла.

Шунысы да куанычлы: яна лауреатларның өчесе—М. Хәсәнов, Р. Даутов һәм А. Гарзавина—Язучылар берлеге әгъзалары. Котлыйбыз!

### 100 ЕЛЛЫККА ӘЗЕРЛЕК

Киләсе февраль аенда татар халкының бөек улы, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 100 ел тула. Әлеге олы юбилейга багышланган чараларның тәүгесе шагыйрьнең туган ягы Оренбурда үтте. "Муса Җәлил батырлыгы һәм рухи мирасы" дип аталган әлеге төбәкара конференциягә Мәскәүдән, Татарстан, Башкортстан, Удмуртия республикаларыннан һәм илнең башка төбәкләреннән галимнәр, язучылар чакырулы иде. Анын эшендә Татарстаннан язучы Рафаэль Мостафин, Казан дәүләт университеты галимәсе Нурфия Гафиятуллина, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетыннан Рөстәм Гайнетдинов катнашты. Күп еллардан бирле герой-шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын өйрәнү юнәлешендә тарихи-гыйльми тикшеренүләр алып барган Рафаэль Мостафин конференциядә катнашучыларны яңа мәгълүматлар—шагыйрьнең һәм аның көрәштәшләренең монарчы билгеле булмаган шигырьләре белән таныштырды.

### БЕЗНЕҢ ДУСЛЫК, БЕЗНЕҢ КАРДӘШЛЕК

Алма-Атада Татарстан мәдәнияте көннәре булып узды. ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева җитәкчелегендәге бер төркем рәсми кешеләр һәм артистлар катнашында узган ул очрашулар казакъ халкы белән татарлар арасындагы дуслык, якынлык мөнәсәбәтләрен тагын бер кат раслау гына түгел, яңарту да булды. Зилә Вәлиева, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Закиров, Татарстанның Казакъстандагы вәкаләтле вәкиле Илдус Тарханов, күп кенә очрашулар уздырып, алдагы елларда ике республика арасындагы хезмәттәшлекне тагын да кинәйтү турында сөйләшүләр алып барды. Мәсәлән, Казакъстан Президенты аппаратында эшләүче милләттәшебез Тәүфыйк Кәримов һәм Казакъстан министрлары белән булган очрашуда сүз ике республика арасында нинди төр хезмәттәшлекне киңрәк җәелдерү, аны ничегрәк оештыру һ. б. турында барды.

Татар моңына, Татарстаннан килгән артистлар чыгышына халык шулкадәр сусаган, концерт тәмамлангач та, алар кунакларны озак җибәрмәде әле. Концертны Казакъстан Республикасының мәдәният, мәгълүмат һәм спорт министры Әсетҗан Косубаев, Президент аппараты вәкилләре, Алма-Ата шәһәре мэры тамаша кылды.

### МӨСЛИМӘЛӘР, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында Татарстан мөслимәләренең I корылтае узды. Бу олуг чарага район, авыл мөхтәсибәтләреннән 400 гә якын делегат, 100 ләп кунак чакырулы иде. Корылтайның максаты—Татарстан мөселман хатын-кызларын республиканың иҗтимагый, социаль-мәдәни тормышында актив катнаштыру, ислам нигезләрен тирәнтен үзләштереп, дәүләтебездә ныклы әхлакый кануннарны урнаштыру.

Республика мөслимәләрен Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева котлады. Ул Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең корылтайга котлавын ирештерде. Аннары корылтайда яңгыраган теләк-фикерләргә карата үз мөнәсәбәтен белдерде:

"Фикер алышуларда дәүләти караш сизелә. Заманалар үзгәрү белән гаилә проблемалары тагын да әһәмиятлерәк төс алды. Республикабызда ятимнәр, картлар йортлары ишәйде. Балалар һәм картлар йортларын берләштерү хакындагы фикерләрегезгә карата шундый тәкъдимем бар. Әби-бабайларыбыздан килгән күркәм гадәтләребезгә күз салсак, шуны күрәбез: элек авылларда ятим калган баланы берәр гаилә үз тәрбиясенә алган, чит-ятларга тапшырмаган. Ятим бала, үз гаиләсен югалтса да, үксезлек сизмәгән. Әти-әни җылысын ул игелекле авылдашлары гаиләсендә тапкан. Бүгенге көндә без бу мәсьәләне дәүләт югарылыгында карыйбыз. Көннән-көн артып торган ятимнәр санын, шушы юнәлештә эшли барып, киметә алсак, мәсьәләнең чишелешенең бер юлы шул булыр".

Корылтайда Татарстан мөслимәләре җәмгыятенең яңа җитәкчелеге һәм Остабикәләр шурасы сайланды, җәмгыятьнең берлек советы расланды, резолюция кабул ителде. Оешманың рәисе итеп Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең мәгариф бүлегендә эшләүче, югары һәм махсус дини белемле Наилә абыстай Җиһаншина сайланды.

### ЭРМИТАЖ КӨННӘРЕ

Санкт-Петербургта Эрмитаж көннәре тәгалләнде. Әлеге чараларда ТР Премьер-министры урынбасары —мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты.

Санкт-Петербург белән Казанның Татарстан Республикасында Эрмитаж үзәген

ачу буенча уртак проекты аеруча зур игътибарга лаек. Дәүләт эрмитажы татарстанлылар белән бергә бу максатка 10 ел дәвамында килде. Моннан берничә ел элегрәк ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее залларында Кубрат хан хәзинәләре күргәзмәсе оештырылды. Татар, рус һәм инглиз телләрендә каталог басылып чыкты. Моннан тыш, Санкт-Петербургның 300 еллыгына һәм Казанның мең еллыгына багышланган күргәзмәләр булып узды.

### ЯШЬЛӘР КОРЫЛТАЕ

Истанбулда төрки яшьләрнең XII корылтае үткәрелде.

Әлеге чарада, корылтай делегатларын сәламләп, Төркиянең тышкы эшләр министры Абдулла Гюль чыгыш ясады. Төрки яшьләр Исмәгыйль Гаспралының "Бердәмлек телдә, фикердә һәм эштә" дигән сүзләрен истә тотарга һәм тормышка ашырырга тиеш" диде ул. А. Гюль яшьләрне алга таба да Төркиянең яшьләр программаларын тормышка ашыруына ярдәм итәргә чакырды.

Корылтай эшендә катнашу өчен Татарстан, Кырым, Башкортстан, Чуашстан, Әзәрбәйҗан, Саха-Якутия, Алтай, Тыва, Балкан һәм Үзәк Азия республикаларыннан барлыгы 300 делегат килгән иде. Биш көн эчендә яшьләр тарих, мәдәният, икътисад, әдәбият һәм төрки халыклар тормышының башка өлкәләренә кагылышлы комиссияләр эшендә катнашты. Кичләрен делегатлар Төркия яшьләре өчен кичәләр оештырдылар, концертлар, спектакльләр күрсәттеләр һәм үз халыкларының мәдәнияте, сәнгате белән таныштырдылар.

### "МӘГАРИФ" ДУСЛАРЫН ҖЫЙДЫ

Моннан 15 ел элек, 1991 елда дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре бастыру максатыннан оешкан бу нәшрият шушы вакыт эчендә үз йөзен, үз юнәлешен тапты, меңләгән һәм меңләгән укучылар күнелен яулады.

Танылган әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Мөдәррис Вәлиев җитәкчелек иткән "Мәгариф" нәшрияты, дәреслекләр чыгару белән генә чикләнеп калмыйча, нәниләр өчен, мәктәп балалары, укытучылар һәм киң даирә укучылар өчен әдәби китаплар бастыру үзәге дә булып әверелде. Барлыкка килгән көннәреннән алып, бирелә 1400 исемдә китап дөнья күргән. Аларның гомуми тиражы 18 миллион данәгә җиткән. "Милли әдәбият китапханәсе", "Хәзинә", "Энҗе чәчтем—энҗе җыям", "Балалар күнеле", "Нәниләр китапханәсе", "Дөнья классикасын татарча укыйбыз", "Без тарихта эзлебез", "Малайларга-кызларга", "Мәгарә", "Тургай чәчәге" кебек серияләрдә басылып чыккан китаплар бик күпләрнең күңел түрендә урын алды.

Казанның Г. Тукай музеенда "Мәгариф" нәшрияты дусларын җыя" дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә узды. "Мәгариф" нәшриятының якын дуслары, авторлары, язучылар, рәссамнәр, артистлар җыелган иде. Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Роберт Миңнуллин, Хатыйп Миңнегулов, Нурмөхәммәт Хисамов, Фатыйх Урманчеев, Фәридә Хәсьянова, Эльмира Шәрифуллина, Ркаил Зәйдулла, Рифә Рахман, Луиза Янсуар, Казан дәүләт музыка училищесының скрипкачылары—алар һәммәсе бу нәшриятка ихлас рәхмәт хисләрен белдерделәр, эшлекле фикерләр әйттеләр, уңышлар теләделәр.

Кичәне Г. Тукай музее директоры, шагыйрь Рәмис Аймәт алып барды.

### "РУХИЯТ" БҮЛӘГЕ

"Казан" милли мәдәният үзәгендә "Татнефть" акционерлар җәмгыятенең "Рухият" фонды тарафыннан 2005 елда нәшер ителгән китапларны тәкъдирләү кичәсе узды. Быел дөнья күргән китаплар арасында Сара Садыйкованың "Рәхмәт җыры", Разил Вәлиевнең "Ядкарь", Рәдиф Гаташның "Мәңгелек сусау", Фоат Садриевның "Безнең гомер язлары", Рауль Мирхәйдәровның "Кара аксөякләр" китаплары бар.

"Рухият" фонды ярдәмендә чыккан китапларны тәкъдир итү тәүге тапкыр Әлмәт шәһәре мәдәният сараенда 1997 елда үткәрелгән иде. 10 елга якын вакыт эчендә 100дән артык китап нәшер ителгән.

Әлеге кичәдә 236 мең сумлык 1102 китап Милли китапханәгә, шулай ук Бөтендөнья татар конгрессына, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры китапханәсенә һәм Казан дәүләт университетына бүләк ителде.

### И ТУГАН ТЕЛ

Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институтында "Мөселманнарның дини уку йортларында татар теле, әдәбияты һәм әхлак укыту" дигән темага "Түгәрәк өстәл" булып узды. Бу чараны "Үзебез" яшьләр хәрәкәте Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте һәм Тарих институты белән берлектә уздырды.

"Түгәрәк өстәл" янында тикшерелгән проблемалар арасында дини уку йортларында татар телен укыту сыйфатына, шәкертләр өчен ана телен укыту ысулларын камилләштерүгә аеруча зур игътибар бирелде. Әлеге чарада катнашучыларны кайбер башка мәсьәләләрнең дә борчыганы ачыкланды. Болар, аерым алганда, татар теленең яшәеш өлкәсен киңәйтү һәм гомуми белем, һөнәри уку йортларына әхлак дәресләре кертү.

### ШИГЪРИ САБАНТУЙ

Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультеты, Татарстан Язучылар берлеге күркәм мәдәни чараны гамәлгә керттe—узган елдан башлап югары уку йортларында эшләп килүче әдәби иҗат берләшмәләре катнашында "Шигъри Сабантуй"лар үткәрелә башлады. Әлеге бәйге-конкурсларны оештыруда КДУнын "Әллүки" берләшмәсе башлап йөри.

"Шигъри Сабантуй"нын быелгысы "УНИКС"нын кече залында уздырылды. Бәйге башланыр алдыннан "Әллүки" әдәби берләшмәсенең язучылар ягыннан җитәкчесе Галимҗан Гыйльманов һәм татар филологиясе һәм тарихы факультетының әдәбият кафедрасы мөдире, профессор Тәлгат Галиуллин яшь каләм ияләренә уңышлар теләде. Жюри хөкеменә тәкъдим ителгән шигырьләр студентлар тарафыннан башкарылган җыр һәм биюләр, шулай ук сәхнә әсәреннән өзекләр белән аралашып барды. Ярышта Арча, Алабуга һәм Минзәләдән килгән яшь иҗатчылар да көч сынашты. Шигырьләргә Тәлгат Галиуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Зиннур Мансуров, Рафис Корбан, Фәйрүзә Мөслимова, Илсөяр Иксанова кебек тәҗрибәле каләм әһелләреннән торган жюри бәя бирде. Гомуми бәяләмә буенча 1 нче урын Ленар Шәехкә бирелде, 2 нче һәм 3 нче урыннарга Йолдыз Миңнуллина белән Лилия Гыйбадуллина лаек булды. Кызыксындыру бүләкләре исә Диләрә Һадиева, Рамилә Майорова һәм Резеда Баһавиевага бирелде.

Җиңүчеләргә диплом һәм бүләкләрне жюри рәисе Зиннур Мансуров һәм шигъри бәйгене оештыручыларның берсе Галимҗан Гыйльманов тапшырды.

### ӘДӘБИ ОСТАЛЫККА НИЧЕК ИРЕШЕРГӘ?

Татарстан Язучылар берлеге каршында эшләп килүче Шигърият остаханәсенең чираттагы утырышы танылган шагыйрьләрне Казан дәүләт университетының "Әллүки" иҗат берләшмәсе әгъзалары белән очраштырды. Төрле буын каләм ияләренең бергәләп сөйләшәсе сүзләре чынлап та күп җыелган икән. Мәҗлестә көн тәртибенә сорау арты сорау куелды: "Әдәби осталыкка ничек ирешергә?", "Югары поэтика күзлегеннән караганда, бүгенге татар шигъриятендә кайбер сәнгати сыйфатлар тоныклану кичермиме?", "Яшьләр иҗатына нiләр җитешми?", "Бүгенге заманда әдәби остазлык тиешле югарылыкта торамы?", "Туган телебезнең киләчәге нинди?" һ. б., һ. б.

Менә шундый көнүзәк сораулар уңаеннан уй-фикерләр белән уртаклашу рәвешендә оештырылган сөйләшүдә шагыйрьләр—Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Рәдиф Гаташ, Әхмәт Рәшит, Мидхәт Миңшин, Флера Гыйззәтуллина, Бикә Рәхимова, Нәҗибә Сафина, Фирдәвес Әһлия, язучы Зиннур Хөснияр һ. б.лар катнашты. Утырышка яшь шагыйрь Ленар Шәех җитәкчелегендә килгән "Әллүки"-челәр, фикер алышуда катнашу белән беррәттән, үзләренең яңа шигырьләрен дә укып күрсәттеләр.

Шигърият остаханәсе мәҗлесен шагыйрь Зиннур Мансуров алып барды.

### ҺӘР АНА ИҖАТЧЫ УЛ

Шушы көннәрдә Татарстан Язучылар берлеге Аналар көне уңаеннан, иҗат белән шөгыльләнүче әниләрне "Казан" милли мәдәният үзәгенә чәй өстәле янына җыйды. Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов язучы әниләрне котлау сүзендә әйткәнчә, бу бәйрәм чын-чынлап бер гаилә табыны булып әверелде. Татарстанның халык артисты Мирсәет Сөнгатуллин, популяр җырчылар Лилия Муллагалиева, Айдар Габетдинов башкаруындагы җырлар А. Алиш исемендәге балалар иҗат үзәгендә шөгыльләнүчеләрнең җырлы-биюле композицияләре, хөрмәтле әниләр-иҗатчылар чыгышлары белән үрелеп барды. Шагыйрь Роберт Миңнуллинның әнисе Гөлҗәүһәр апаның, Фәнис Яруллинның җәмагате Нурсия ханымның чыгышлары, язучы Нонна Орешина, Гөлшаһидә Максудова, язучы Фәкил Сафин, шагыйрь Гәрәй Рәхим, шагыйрәләр Салисә Гәрәева, Шәмсия Җиһангированың котлавы әниләргә карата иң җылы хисләр белән сугарылган иде.

### ПЕН-ҮЗӘК ХӘРӘКӘТТӘ

Фин ПЕН-үзәге чакыруы буенча Татар ПЕН-үзәгенең башкаручы директоры, язучы Әхәт Мушинский Хельсинкидә булып кайтты.

Фин ПЕН-үзәге белән татар язучыларын эшлекле җылы мөнәсәбәт бәйли. 1999 елда Мексикада фин әдипләре Татар ПЕН-үзәген Халыкара ПЕН-клубка кабул итү тәкъдиме белән дә чыккан иде. Дустанә мөнәсәбәтләр елдан-ел ныгый бара.

Татар ПЕН-үзәге вәкиле Хельсинкигә килгәч, анда матбугат-конференциясе оештырылды. Ә. Мушинский татар халкы, аның тарихы, әдәбияты турында сөйләде. Фин журналистларын исә татар язуының латин графикасына күчү-күчмәү мәсьәләсе кызыксындырды.

Ә. Мушинский шулай ук Хельсинки Матбугат-үзәгендә үткәрелгән журналистлар кичәсе—карнавалда да катнашты. "Villa Kivi" әдипләр йортында үткәрелгән халыкара шигъри кичәдә ул Татарстанда мәгариф, әдәбиятның торышы турында сөйләде, татар һәм рус телләрендә үзенең әсәрләреннән өзекләр укыды.

## СӘЙДӘШ: КИЧӘ, БҮГЕН, ИРТӘГӘ...

6 декабрь көнне Казанның Салих Сәйдәшев музей-фатирында бөек композиторның тууына 105 ел тулуга багышланган "Сәйдәш: кичә, бүген, иртәгә" исемле укулар узды.

С. Сәйдәшевнең тормыш һәм иҗатын өйрәнү һәм пропагандалау, бүгенге көн татар музыка сәнгате үсешендә композитор иҗади мирасының йогынтысын билдыру, аның музее фондларын яңа материаллар белән тулыландыру максатыннан оештырылган әлеге фәнни-гамәли конференциядә Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты профессоры Казбек Гыйззәтов, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты доценты Гөлнур Гобәйдуллина, профессор Эльза Литвинова, Казан дәүләт консерваториясе доценты Елена Парфильева, Казан музыка училищесы мөгаллимәсе Гүзәл Юнысова, композиторның туганнары—оныгы Эдуард, Валерий, Әлфия, Гөлия, Камил Сәйдәшевләр һәм "Салих Сәйдәшев" китабы авторы Дилбәр Саинова-Әхмәрова, С. Сәйдәшев музее фәнни хезмәткәрләре һәм музыка училищесы студентлары катнашты. Концерт программасында Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Эмиль Җәләлетдинов С. Сәйдәшев һәм башка композиторларның вокал һәм инструменталь әсәрләрен башкарды. Уен коралларында Татарстанның халык артисты Лариса Маслова уйнады.

## МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Г. Камал исемендәге театр бинасында күренекле язучы Мәдинә Маликованың юбилей кичәсе булып узды. Ул—күп санлы романнар, повестьлар һәм сәхнә әсәрләре авторы. Аның актуаль темаларга язылган публицистик мәкаләләре, юлъязмалары һәм очерклары да укучыларга яхшы таныш. Мәдинә Маликова—инде байтак еллар "Кызыл Ярымай" хәйрия җәмгыятенең президенты да.

ТР Премьер-министр урынбасары-мәдәният министры Зилә Вәлиева юбилярга тантанада Президентыбызның "Рәхмәт хаты"н житкерде. Ул әдибәне иҗат уңышлары белән тәбрикләп, Илбашы исеменнән ана "Казанның мең еллыгы" дигән истәлек медале тапшырды.

Язучыны каләмдәшләре, якташлары һәм әдәбият сөючеләр котлады. Сәхнә осталары тамашачыларны аның әсәрләре белән таныштырдылар, ул язган пьеса буенча куелган "Ач серенне, Америка!" спектакленнән өзекләр күрсәттеләр, ул яраткан җырларны башкардылар.

## ШАГЫЙРЬҖАННЫҢ ЙӨРӘК БӘЙРӘМЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында күренекле шагыйрә һәм публицист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Лена Шагыйрьҗанга 60 яшь тулу уңаеннан "Ышанам йөрәгемә" дип исемләнгән шигъри-музыкаль кичә үткәрелде.

ТР Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева юбилярга Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең котлавын ирештерде һәм шәхсән үз исеменнән шагыйрәнең зур иҗатына ихтирамын белдерде. Тәбрикләү сүзләрендә Л. Шагыйрьҗанның күпкырлы әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге, халыкны борчыган уй-фикерләрнең тезмә һәм чәчмә әсәрләрендә сәнгатьчә югарылыкта чагылыш табуы ассызыклап әйтелде.

Күпсанлы каләм әһелләре һәм әдәбият сөючеләр исеменнән юбилярны Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов котлады. Кичәдә бәйрәм хуҗабикәсен шулай ук якташлары—Актаныш һәм Әтнә районыннан килгән делегацияләр, аерым оешма һәм учреждениеләр вәкилләре һ. б. лар тәбрикләде. Юбилей кичәсендә яңгыраган шигырьләр җыр-музыка, биюләр белән аралашып барды. Әсәрләрне автор үзе—шагыйрә Лена Шагыйрьҗан һәм республикабызның сәнгать осталары башкарды.

## ТЫРЫШ ХЕЗМӘТ ЮГАРЫ БӘЯЛӘНДЕ


"Татарстан" телевидениесенең милли тапшырулар хезмәте башлыгы—Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Лия Заһидуллинаның эш бүлмәсен 3 халыкара диплом һәм яңа югары халыкара бүләк бизи. Агалтыннан ясалган "Бриллиант Содружества" призы һәм лауреат дипломы "Ханым" шәлкеменнән "Казан ханлыгының күренекле хатын-кызлары" программасын төзүчеләргә (программаның житәкчесе Лия Заһидуллина, сценарий авторы Леонид Девятых, режиссеры Роберт Хисамов) Алма-Атада узган "Лучшие программы содружества" I халыкара телевизион бәйгесендә "Милли горефгадәтләргә сакчыл мөнәсәбәт өчен" тапшырылды.

### *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Кышкы манзара.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Нәзифә Кәримова**.


# ЯҢА КИТАПЛАР



**Вуюисьлэн бигер буелъесыз** (удмурт телендә). Татар шигъриятенен салават күпере: шигырьләр. —Ижевск: Удмуртия, 2005.—144 б. Тиражы—500 данә.

Казанның мең еллыгы унае белән Удмуртиядә татар шагыйрьләренен удмурт телендә күмәк шигырь җыентыгы чыкты. Ул китапка бүгенге заман шагыйрьләре—Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Зөлфәт, Зиннур Мансуровларның шигырьләре кергән. Китапның төзүчесе, шигырьләрнен тәрҗемәчесе—Удмурт халык шагыйре Вячеслав Ар-Серги.

"Әдәбиятлар дуслыгы—халыклар дуслыгы" девизы белән яшәгән элекке елларда тугандаш халыклар әдәбиятларын үзара тәрҗемә итү югары дәрәҗәдә куелган иде. Соңгы дәвердә бу эш сүрелә төште. Шуңа күрә дә, мондый китапның чыгуы үзгә бер әһәмияткә ия.



Эльмира Шәрифуллина. **Сөюемнән мин бер чибәр идем...** Шигырьләр, поэмалар.—Казан: "Рухият" нәшр., 2005. —528 б. Тиражы—2000 данә.

Бу китап шагыйрә иҗатын чагыштырмача тулы күз алдына китерерлек басма. Аны сайланма әсәрләр томлыгы дип тә әйтеп була, чөнки бу китапка Э. Шәрифуллинаның элеккеге җыентыкларында ("Яңгыр җиле", "Гөлләр елы", "Зәңгәр энгер", "Таң чыгы", "Уйлы еллар") чыккан иң яхшы шигырьләре тупланган. Шулай ук, китапта шагыйрәнең "Без—Тукайлы" һәм "Каюм коесы" дип исемләнгән поэмалары да урын алган.

Җыентыкка кереш сүзне шагыйрь Зөлфәт язган. "Өлкәнәя барган саен шагыйрә тәрбия мәсьәләләренә, халкыбызның гореф-гадәтенә, йола-канунарына игътибар беләнрәк карый, шулар хакында уйлана".

Китапның мөхәррире—Наис Гамбәр. Рәссамы—Ринат Хәсәншин.

Индекс 73210



Нәзифә Кәримова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)